


# КАЗАН УТЛАРЫ

11
НОЯБРЬ
1980

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

11
НОЯБРЬ
1980

## БУ САНДА

КПССның XXVI СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

М. ГӘРӘЕВ. Ташкүмер җыры. Очерк . . . . . 3
Ш. ХАММАТОВ, Г. РИЗВАНОВ. Октябрь үстергән дәүләт эшлеклесе . . . . . . . . . . . . 10

Т. ТАҺИРОВ. Галия. Повесть . . . . . . . . . 18
Р. ФӘЙЗУЛЛИН. Сәйдәш. Поэма . . . . . . . 85
Ә. ГАФФАР. Язлар моңы. Драма . . . . . . . 100
М. ХӘСӘНОВ. Зөбәрҗәт. Хикәя . . . . . . . . 128

ПУБЛИЦИСТИКА

К. ФАСЕЕВ. Ирек-хокуклар: чын һәм ялган . . 132

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Н. ЮЗИЕВ. «Ач, шигърият, серләреңне!» . . . . 136
Кочкенә рецензияләр . . . . . . . . . . . 144

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Р. НӘФИКОВ. Яңа документлар, яңа бурычлар . 147

С. СӘЙДӘШЕВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ ТУЛУ АЛДЫННАН

Ф. ВӘЛИЕВА. Ул яулаган үрләр . . . . . . . 154

А. БЛОКНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

А. БЛОК. Скифлар. Шигырьләр . . . . . . . 158

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Ф. САФИН. Еллар яктысы . . . . . . . . . . 161
Л. ХӘМИДУЛЛИН. Чыңгыз тауларының бөркете . 163
Ж. МОЛДАГАЛИЕВ. Акыннар агасы . . . . . . 166

ТӨРЛЕСЕННӘН

А. ШЕШИН. Декабрист якташыбыз . . . . . . 167

НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

Г. ШӘРӘФИ. Күрше малае. Повесть . . . . . 170

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

Г. АФЗАЛ. Бу уклар кемгә тияр! . . . . . . 184
З. НУРИ. Үлчәве юк . . . . . . . . . . . 185
Г. РӘХИМ. Планнарны планлаштырдык . . . . 187

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 190

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

**Баш редактор: ЗӘКИ НУРИ**

**Редколлегия:** **ӘХСӘН БАЯНОВ** (баш редактор урынбасары), **ШАМИЛ БИКЧУРИН, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, КОЯШ ТИМБИКОВА** (җаваплы секретарь), **СИБГАТ ХӘКИМ, НИЛ ЮЗИЕВ**

---

Техник редакторы *Р. Сөләйманова*
Корректорлары *Ф. Кадыйрова, Т. Шакирҗанова*

---

**Редакциянең адресы:** Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

**Телефоннар:** баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-63, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

---

Производствога бирелде 22/VII-1980 ел. Басарга кул куелды 24/X-1980 ел. ПФ 09035. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 92600 экз. Заказ У-327. Бәясе 50 тиен.

---

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1980 ел.

Мәгъсум Гәрәев

# ТАШКҮМЕР ҖЫРЫ

## Кузбасс энҗесе



Сәфәр шактый ерак: Урал тауларын үтеп, Көнбатыш Себер иңкүлеге аша Кузбасска кадәр. Поезд иксез-чиксез дала һәм урман эченнән туктаусыз алга чаба. Меңнәрчә еллар буена җир куенында яшеренеп яткан алтын һәм алмаз хәзинәләре, ташкүмер һәм тимер рудалары белән тулы ятмалары, нефть һәм газ чыганаклары, затлы мехлары белән дан тоткан тайгаларга күз салып, Себернең байлыгына сокланып үтәбез.

...Поезд Прокопьевскига таң беленер-беленмәстә килеп туктады. Утлары җемелдәп янган күп катлы биналарның күбесе — чыршы-наратлар арасында.

«Америкада төш вакыты җиткәндә, Себердә — төн уртасы. Прокопьевск һәм Чикаго бер үк меридианда капма-каршы торалар. Озын инә белән глобусны Прокопьевскидан үтәли тишсәң, нәкъ Чикагога килеп төртеләсең». А. М. Горький тәкъдиме белән иҗат ителгән «Фабрикалар һәм заводлар тарихы» китабы авторларының берсе Александр Бек әнә шулай яза. Ул чакта Прокопьевск авылына килү өчен юл да булмый. Беренче шахтадан кәйлә һәм көрәк белән ташкүмер чыгара башлаучылар А. Бек сүзләренең мәгънәсен аңламаган әле, чөнки аларның беркайчан да глобусны күргәннәре булмаган, укырга-язарга да өйрәнмәгәннәр.

Прокопьевск тирәсендә күмергә бай ятмаларның зур мәйданнары барлыгы беленгәч, биредә шахталар һәм шәһәр төзергә керешәләр. Хәзерге күмер чыгару индустриясенең барлыкка килүе шахталар коруда могҗизалар күрсәткән Андрей Давыдович Туманов исеме белән бәйле. Ул беренче пот күмерне көрәк белән чыгара. 1922 елда Андрей Давыдович Тумановны шахтерлар Мәскәүгә В. И. Ленин янына җибәрәләр. Юлбашчы аны бик җылы кабул итә. Прокопьевск халкының тормышы белән кызыксына, шахтерларга бүләк итеп динамомашина бирә. Бүгенге Дзержинский исемендәге шахтаның оешуы менә шушы вакыйгадан башлана.

Шәһәр һәм шахталар белән бергә, Совет властена чын күңелдән бирелгән көчле рухлы кешеләр дә үсә. Аларның иң данлыклысы Татарстаннан килгән Шәйхи Зәйнетдинов була. 1935 елда шахта файдалануга тапшырылгач, күмер чабучы якташыбыз: «Стахановча эшләргә!» — дигән хәрәкәт кузгата. Шул ук елны ул, сменага 981 тонна күмер чабып, даны бөтен илгә таралган Алексей Стаханов рекордын кабатлый. Шәйхи Зәйнетдиновка, Кузбасста беренче булып, Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелә. Зур бүләкне аңа Мәскәүгә чакырып — олылап һәм хөрмәтләп тапшыралар.

Менә шәһәр һәм шахталарның корылу тарихы, бүгенге көне, аның хезмәт батырлары белән «Прокопьевскуголь» берләшмәсенең күмер чыгару директоры Юлий

Алексеевич Волков таныштыра. Ул Бөек Ватан сугышыннан соң бераз Казанда яшәгән. Бу бассейнда эшләүче якташларыбызны яхшы белә. Аларны мактау сүзләре белән генә телгә ала. Дзержинский исемендәге шахтада эшләүчеләрнең 40 проценты татарлар икәнен, һәммәсенең дә Прокопьевскида гына түгел, бөтен Кузбасста тырыш эшчеләр булып танылулары хакында горурланып сөйли.

Бу турыда соңрак...

— Прокопьевск — өч районнан торган хәзерге заман шәһәре, бакча шәһәр, индустриаль шәһәр,— ди Юлий Алексеевич.— Безнең калада биш культура сарае, ун клуб, драма театры, йөзү бассейны, һәр шахтаның тайгада профилакторие һәм туристлар базасы бар. Ике спорт сарае салдык, культура ял парклары булдырылды. Безгә Казан артистлары да еш килә. Әле бер генә атна элек Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры коллективы гастрольләре тәмамланды. Шахтерлар якташларын бик җылы каршыладылар. Тамаша залы һәр спектакльдә шыгрым тулы иде... Берләшмәбез үзе исә 20 шахтаны эченә ала. Алар илгә ел саен 20—25 миллион тонна «промышленность икмәге» бирәләр. 10 миллион тоннасы кокслый торган күмер. Мондый ягулык безнең илдә шулай күпләп Прокопьевск шахталарында гына чыгарыла. Ул югары сыйфатлы металларны эшләү өчен кирәк. 5 миллион тонна чамасын хәтта Донбассның үзенә дә җибәрәбез. Менә шуңа күрә Прокопьевск бассейнын «Кузбасс энҗесе» дип йөртәләр.

## Гыйльметдин

Шәһәрнең Тынычлык урамындагы Җиңү мәйданы. Аның уртасында — Себер гранитыннан эшләнгән мәһабәт һәйкәл. Аңа алтын хәрефләр белән «Прокопьевскуголь» берләшмәсендәге Социалистик Хезмәт Геройларының исемнәре уелган. Беренче булып Шәйхи Зәйнетдинов исеме, аннары Гыйльметдин Идрисов... Барлыгы 11 шахтер. Берләшмәнең кадрлар бүлегендә: «Идрисов — сезнең якташ, Кукмара районының Мәмәшир авылында 1927 елда туган. Ленин орденлы «Коксовая» шахтасында эшли. Бүген ял итә, мөгаен, өйдәдер», — диделәр миңа һәм өй адресын да әйттеләр.

Сап-сары нарат бүрәнәләрдән коттеджга охшатып салынган йорт матур рәшәткәләр белән әйләндереп алынган. Стенага мәрмәр мемориаль такта кадаклап куелган: «Бу йортта Кузбассның атаклы бригадиры, Социалистик Хезмәт Герое Гыйльметдин Гайфетдинович Идрисов тора».

Уртача буйлы, пәһлеван кебек киң җилкәле, чәчләренә көмеш бөртекләре сибелә башлаган — бу шахтер әнә нинди икән. Кукакчыл, киң күңелле, сүзгә җор. Хатыны Гафбану апа (ул да ире туган авылдан), кызлары Зөлфирә дә өйдә иде. Танышып, хәл-әхвәл сорашып өлгергәнче, өстәлгә самовар да килеп утырды. Чәй янында гомумән шахтерлар тормышы, рудникларда эшләүче башка якташларыбыз турында да гәпләштек.

Берләшмәнең Бөтенсоюз һәм бассейн рекордлары куйган бригада җитәкчеләренең эш күрсәткечләре теркәлгән китабында рекордлар исәбен Шәйхи Зәйнетдинов ачып җибәргән булып чыкты. Анда бүгенге көндә 160 рекорд теркәлгән. Шулардан Гыйльметдин Идрисов, Сәетҗан Хуҗин, Зиннур Халиков, Наил Гыйлаҗев, Бәдретдин Казаков, Әһлимулла Хәйруллин, Мәрдән Халиков — һәммәсе Татарстаннан икән.

...Икенче көнне Юлий Алексеевич:

— Әйдәгез, Гыйльметдинне утыртабыз да, «Коксовая»га китәбез. Шахтага төшмичә, анда эшләүчеләр турында язып булмый,— диде.

Инструкция таләбенчә киемнәрне алыштырабыз, каскада шахтер фонаре, бил каешында аны яктыртучы аккумулятор. Лифтка утырып тормадык. Вертикаль баскычлардан 300 метрга түбән төшеп киттек. Минем кебек күнекмәгән кешегә җир куеныңа тирәнрәк төшкән саен бу маршрут кыенлаша бара. Ә шахтерлар өйрәнгән, андый авырлыкны сизмиләр дә кебек.

Юлий Алексеевич утызынчы еллар ахырында үзе дә гади забойщиктан башлаган. Аннан бригадир, читтән торып политехника институтын тәмамлый. Сугыштан соң участок начальнигы, шахта директоры. Хәзер инде зур берләшмә җитәкчеләренең берсе.

— Башта гел шулай төшә һәм менә идек, хәзер лифтка утырып йөрибез, — дип аңлатты ул.

Ниһаять, без күмер чыгаручылар янында. Төрле якка берничә километрга сузылган «урамнар», штреклар, суүткәргечләр... Тимер юллар белән күмер ташыган кечерәк вагоннар, поездлар. Телефоны да, радиосы да шунда. Хәтта ашханәсе дә бар. Көнозын йөрдек без анда. Юлий Алексеевич, шахта директоры Николай Иосифович Яковлев һәм күмер чыгаручылар сөйләвеннән мин аларның авыр да, мактаулы да булган хезмәтенең күп серләренә төшендем. Герой шахтерлар Гыйльметдин Идрисов һәм Сәетҗан Хуҗинның бөтен шахтерлык биографиясен күңелемнән үткәрергә тырыштым.

...Социалистик Хезмәт Герое, РСФСРның атказанган шахтеры Гыйльметдин Идрисов Ленин орденлы «Коксовая» шахтасында утыз елдан артык эшли. Идрисов — оста, Идрисов — бригадир. Бу ике сүз никадәр тирән мәгънәне эченә ала.

Оста... һәр эшнең остасы бар, алар кеше акылы һәм көче белән башкарылырга тиеш эшләрнең чикләрен киңәйтәләр, киләчәккә юл салалар.

Оста... Болай дип олыларны, зур коллектив белән гадел һәм акыллы җитәкчелек итә белүчеләрне атыйлар. Ул — яшь эшченең беренче остазы. Табигый сәләте белән генә түгел, хезмәттә тоткан урыны белән дә. Бригадир Идрисов нәкъ менә шундый оста инде. Ул хезмәттәшләренең һәркайсы белән тыгыз элемтәдә тора, аларга даими рәвештә йогынты ясый белә. Гыйльметдин йогынтысының көче шахтерларның кәефен, тормыш ихтыяҗларын һәм фикерләрен белүдә, аның хезмәткә карашында, башкаларга үрнәк булуында чагылыш таба. Мәсәлән, Идрисов белән Подберезный кайчандыр бер бригадада эшләгәннәр: беренчесе бригадир, икенчесе — проходчы. Хәзер Николай Подберезный үзе бер зур коллектив җитәкчесе. Шахтада хөрмәтле кеше һәм танылган бригадир дәрәҗәсенә күтәрелү аңа үзеннән-үзе генә килмәгән. Ул бик күп нәрсәгә өйрәнүдә Гыйльметдин Идрисовка бурычлы булуын яхшы аңлый.

— Бригадирыбызның сөмсере коелып йөргән көннәрне бүгенгедәй хәтерлим,— ди Николай Адамович.— Минем белән эш турында гына сөйләшә, өйдәге хәлләр хакында ләм-мим. Күңелемә: «Шахта җитәкчеләре белән бәхәскә кергәнме әллә!» — дигән ят уй килде. Шуны белергә теләдем. «Юк, Коля, эшем тәртиптә, гаиләмдә тынычлык, — ди бригадир.— Синең өчен борчылып йөрим. Болай... әйбәт кенә егет син. Үз улым шикелле якын күрәм. Эштә дә, ял иткәндә дә йөзгә кызыллык китермисең». «Нәрсә булган соң, Гыйльметдин Гайфетдинович!» — «Сиңа яхшырак билгеледер. Өйдә үзеңне ничек тотуың турында кызыксынган идем, әтәчләнәсең икән. Беләм, синдә көч җитәрлек...— Бригадир миңа җитди итеп карады да бер генә сүз әйтте.— Рыцарь...» Эсселе-суыклы булып китте.

Инде бүйга җитеп килә торган балалар үстерүче Подберезный миңа бу хәлне сүз бөтенләй икенче кеше хакында барган шикелле итеп сөйләде. Ул чакта яшь ирне акылга китерү өчен бригадир Идрисовка педагогик һәм кешелек таланты кирәк була. Моны тик үзе зур тормыш мәктәбе үткән тәҗрибәле остаз, инде өч бала үстереп, аларны олы тормышка аяк бастырган әдәпле ата гына шулай эшли ала.

...Сугыштан соңгы авыр еллар. Донбасс шахталары җимерелгән. Илнең төп ягулык базасы — Кузбасс. Беләкләрендә көч, йөрәкләрендә дәрт булган егетләр Себергә ашкына. Егерме яшь тулыр-тулмас чакта Гыйльметдин генә яшьтәшләреннән калышсынмыни!! Тәвәккәлли, Себер ягына юл тота. Прокопьевскида егетләрне җылы каршылыйлар, шахтерлар арасында бик күп белгечлекләр барлыгын аңлаталар. Төп һөнәр ике — проходчы һәм забойчы. Беренчесе күмер чыгаручыларга эш мәйданы әзерли, җир астында юл сала; икенчесе, шул тар сукмаклардан барып, калын-калын катламнарны ваттыра да бөтен запасны җир өстенә чыгару өчен хәстәрләп куя. Проходчыдан башка забойщик — ике кулсыз. Гыйльметдин беренчесен һәм иң авырын сайлый. ФЗӨ мәктәбенең тау промышленносте проходчылары бүлеген тәмамлый. Себергә килүенә инде ай тулды дигәндә, өйрәнчек булып шахтага төшә. 50—60 көн чамасы хәзерге шахтада директоры Николай Иосифович Яковлевның булышчысы булып, механизмнарны өйрәнеп йөри. Эш читтән тыш авыр. Күтәрү-төшерү җиһазлары

бик аз, шахтадан чыккач, кул-аяклар йөрәкне чәнчеп диярлек сызлый. Ләкин Гыйльметдиннең кире кайтып китү турындагы уй башына да килми. Николай Иосифович Гыйльметдиннән чын шахтер чыгасын яхшы аңлый. Яшьтәшләре Идрисовны тырышлыгы, ярдәмчеллеге өчен яраталар, староста итеп сайлыйлар. Күнеккәч, эш җиңеләйгәндәй тоела. Шахтага яңадан-яңа машиналар кайта, бу аның сайлаган һөнәрен яратуын бермә-бер арттырып җибәрә.

Кышкы салкын көннәрнең берсе. Үнөченче участок проходчылары иртән гадәттәге нарядка җыелалар. Шахтага төшәр вакыт җитеп килә.

— Безраз сабыр итегез әле, егетләр,— ди участок начальнигы Яковлев.— Сөйләшеп аласы бар. ФЗӨдан тагын унике егет килде. Ун көн инде кайсы кайда эшләп йөри, күңелләре суына. Бригадирлары зарлана. Җитәкче кирәк үзләренә.

Бүлмә бер мәлгә тып-тын кала. Проходчылар бер-берләренә карашып алалар.

— Тотыйк та Идрисовны куйыйк! Менә дигән проходчы.

Сменадан соң Николай Иосифович Гыйльметдинне шахта алдында көтеп ала. Кайтырга бергә чыгалар. Шактый ара сүзсез узыла.

— Нигәдер үзгәреп киттең. Авырмый торгансың ич! — дип сүз ката башлык.

— Юк, сәламәтлегем әйбәт... Миннән нинди бригадир чыксын ди, үз эшем дә җиткән, булдыра алмам мин.

Кайтып җиткәч тә алар урамда бик озак сөйләшеп торалар. Николай Иосифович киңәшләреннән соң Идрисов егетләрне җитәкләп барырга тәвәккәлләвен белдерә.

Эш шома гына китми әлбәттә. Ике атналап тегендә-монда буталып йөргән егетләр санга сугарга теләми бригадирны. Исрафил Шәрифуллин бигрәк тә чәпчи. Бер атна чамасы түзә Идрисов, эндәшми. Ялкаулар өчен дә үзе икенче сменада эшли. Әмма түзәр хәле калмый.

— Кем намус белән эшләргә теләми, бүген үк бригададан элдертсен, калганнар белән өч сменада булса да бурычны үтәп чыгарбыз...

Бригададан берәү дә китми. Бригада бер йодрык булып нык туплана. Шахта җитәкчеләре дә, коллектив кешеләре дә ара-тирә Идрисов турында җылы сүзләр әйтә башлыйлар. Бригадир булып эшләвенең өченче елында аның проходчылары «Коксовая»да беренче урынны яулап ала.

Шахтерлар арасында шундый тәртип бар: әгәр син ярышта җиңүче икәнсең, тизләтелгән ысул белән эшләүгә күчәсең, башкаларга үрнәк күрсәтәсең, шуның белән осталыгыңны раслыйсың. Бу хакыйкать Идрисов проходчыларын да читләтеп үтми.

Бригадирның моңа карата үз фикере яңара. Унбиш кешедән торган коллективка җитәкчелек итү авыр түгел. Әгәр коллективка 60—65 кеше берләштерсәң! Хезмәт җитештерүчәнлеге күтәрелергә тиеш. Күпме хезмәт хакы янга калачак.

Экономистлар бу фикергә каршы төшәләр. Илдәге шахтерлар арасында әлегә андый бригада юк. Идрисов, бригада членнарын дүртләтә арттырып, рекорд куймакчы була, имеш.

Шахтада бу тәкъдим үтми. Ул үз фикеренең акланачагына шикләнми-чигенми. Киңәшкә «Прокопьевскуголь» бассейны директоры Анатолий Иванович Петров янына китә. Күп еллар буена шахталарда җитәкче эшләрдә эшләгән директор үзенә мондый фикер белән мөрәҗәгать итүчене хәтерләми. Идрисов тәкъдиме Петровта кызыксыну уята.

— Иртәгә шахта җитәкчеләренең киңәшмәсе була, сине дә чакырам. Шунда үй фикерләреңне әйтерсең, — ди ул.

Киңәшмәдә каршы төшүчеләр күп булса да, директор новаторны яклап чыга. Идрисов 65 кешедән бригада төзи һәм алтмышынчы еллар уртасында шахта күләмендә рекорд кую өчен ярышка чыга. 35 эш көнендә, 305 метр проходка биреп, максатына ирешә. Бу чын хезмәт батырлыгы була! Идрисовларның эш ысулы бөтен Кузбасска тарала. Июньдә тагын бер биеклек яулана. 35 эш көнендә — 481 метр! Ярты ел эчендә ике рекорд! Илебез шахтерларының мондый тизлекне әле ишеткәннәре булмый.

Новатор-бригадирның эш алымнарын өйрәнү өчен Кузбасс, Донбасс, Казагыстан шахтерлары килә, тәҗрибә мәктәбе оештырыла. Чөнки аны өйрәнмәскә мөмкин түгел. Бригаданың тизләтелгән ысул белән эшләве билгеләнгән вакыттан ике ел алдан 4 миллион тонна күмер чыгарырлык мәйдан ача, 30 мең сум чыгымны янга калдыра.

СССР күмер җитештерү промышленносте министры Б. Братченко котлау өчен Гыйльметдин Идрисовны Мәскәүгә чакырып ала. Күкрәгенә «Шахтер даны» билгесенең беренче дәрәҗәлесен тагып җибәрә. Алтмышынчы елларны илебезнең ташкүмер чыгару промышленностенда Идрисов еллары дияргә тулы нигез бар. 1965 елда ул Бөтенсоюз рекордларын штурмлауга керешә. Февраль урталарында идрисовлылар каты токымнарда проходка эшләрен җәелдерәләр. Бер үк вакытта параллель ике юл салалар. 31 көн дигәндә 302 метр проходка бирелә. Бу сан СССР министрлыгында Бөтенсоюз рекорды итеп теркәлә. Ноябрьда яңа рекорд өчен көрәш барган көннәрдә, Гыйльметдин Идрисов Мәскәүгә СССР профсоюзларының XIII съездына делегат булып китә. Үзе башкалада, ә күңеле — шахтада. Егетләр сынатмаслармы дип борчыла ул.

— Тыныч бул, Гыйльметдин Гайфетдинович, съезд президиумына яңа рекорд турында рапорт бирербез, — дип озата аны бригада членнары һәм сүзләрендә торалар. Кичен кунакханәгә ике генә сүз язылган телеграмма килеп төшә: «390 метр!» Идрисов үз бригадасының уңышлары турында съезд трибунасыннан сөйли, бөтен зал шушы коллективның хезмәт җиңүләренә сокланып кул чаба. Шул көннәрдә «Труд» газетасы болай дип яза: «Хәзер бөтен ил проходчылары Г. Идрисов бригадасына тигезләнергә омтылырлык итеп эшли. Коммунист-новатор Г. Идрисов бригадасы Кузбасс шахталары бригадаларыннан биш мәртәбә тизрәк эшләүгә ирешге».

Съездда Г. Идрисов ВЦСПС члены итеп сайлана.

...«Коксовая»да аны ул көнне бөтен шахта коллективы шатланып, чәчәк бәйләмнәре белән көтә, һәр кеше бригадирны кочакларга, котлап кулын кысарга, күккә чөяргә тели. Бу котлаулар Гыйльметдин Гайфетдин улы Идрисовка Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелү уңаеннан иде. Ә ул үзенә генә хас тыйнаклык белән: «Ватаныбызның олы бүләгенә без бергә эшләп лаек булдык. Ул минеке генә түгел, барыбызныкы да. Мең-мең рәхмәт сезгә!» — ди.

Прокопьевскидан киткәндә Юлий Алексеевич Волков миңа берләшмәнең Почет тактасын күрсәтте. Анда Василий Кулик, Михаил Козленя, Александр Архаров, Николай Адамович Подберезный рәсемнәре бар иде.

— Идрисов шәкертләре, аның кул астында эшләп, бассейн күләмендә танылган бригадирлар дәрәҗәсенә ирештеләр.

## Сәетҗан

Шахтада эш иртән сигездә башлана. Бригадир Хуҗин ярты сәгать алдан килә. Аңа бүгенге көн тәртибен билгеләп, эш коралларын барлап чыгасы бар. Шахтага төшәргә биш минут калганда бригадирлар кызыл почмакка җыела. Кыскача һәм төгәл сөйләшеп алырга өлгерәләр: кичә ничек эшләгәннәр! Кем кайсы операциядә вакытны әрәм иткән! Бүгенге бурычлар нидән гыйбарәт! Техника куркынычсызлыгы мәсьәләләре ничек тора! Аннан алар үз шахтерлары белән эш урыннарына юнәләләр. Юлда һәр кеше җитәкчесеннән тиешле күрсәтмә ала, үз фикерен әйтә. Кызыл почмакта сөйләнгән сүзләр һәммәсенә барып җитә. Сәетҗан Хуҗин белән бергә аның бригадасындагы берсеннән-берсе таза 27 ир-егет атлый. Мин — егерме тугызынчы. Сәетҗан сүзне икенчегә бора:

— Биш минутлык сөйләшү җырның башы гына әле, якташ, — ди ул миңа карап. — Җыр көнозын шахтада дәвам итә. Күңелле дә соң ташкүмер җырын тыңлау. Ирексездән үзең дә кушылып китәсең.

«Кузбасс шахталары — тирән шахта...»
Мәңге китмәс бу җыр йөрәктән.
Ундүрт тулар-тулмас бу җыр безне
Үзе белән бергә ияркткән.

Ияркткән дә авыл кырларыннан
Алып киткән Кузбасс куенына.
Шахтер иткән... Хәзер Кузбасс миңа
Үз ягымдай якын тоела.

Тоннарен дә эзләп торганым юк
Маяк булып янган утларын:
Күзне йомган килеш таба алам,
Забойларның һәрбер сукмагын.

Егерме биш ел инде Сәетҗан җыры, аның шахтерлары җыры, ташкүмер җыры белән бергә яңгырый. Бүген мин шул күмәк җырда Сәетҗанның тормыш юлын күрәм. Ул бик кыска: 1933 елда Азнакай районының Кәкре Елга авылында туган, шунда җидееллык мәктәпне тәмамлаган. Аннан Прокопьевск, шахтада грузчик, ФЗӨ мәктәбе, күмер чабучы һәм бригадир... Кузбасстагы 32 еллык гомере бер җөмләгә сыя. Ә аның хезмәт батырлыгы турында озын, хәтта роман язарга була.

«Прокопьевск шахталарында яңа рекорд! Сәетҗан Хуҗин бригадасы механикалаштырылмаган лавадан 31 эш көнендә 27 мең тоннадан артык күмер чыгарды. Дан сезгә, көн батырлары!»

1970 елның 15 февралендә Хуҗин егетләрен хөрмәтләү тантанасында Дзержинский исемендәге шахтаның бөтен эшчеләрен шушы плакатлар каршылый. Музыка уйный. Күмер чыгару батырларын президиумга утырталар. Беренче булып Хуҗин егетләрен атаклы бригадир Миңлегали Алдакаев котлый.

— Егет икәнсең, Сәетҗан! Минем бригада рекорды шулай кыска гомерле булыр дип һич уйламаган идем. Бер ай дигәндә мең тоннага уздырдың. Шундый көчле бригада белән ярышуы үзе зур бәхет ул. Әйдә, рекорд өчен ярышны тагын да көчәйтик! — дип, шатлыгын яшерми сөйли Миңлегали.

Шахта директоры Михаил Васильевич Тихонов Хуҗинга Социалистик Хезмәт Герое Шәйхи Зәйнетдинов исемендәге призны тапшыра. Пионерлар (арада Сәетҗан



*Сәетҗан Хуҗин (уртада) бригада членнары арасында*

улы Рәшит тә бар) шахтерларны данлап чәчәкләргә күмәләр.

Сәетҗанның чыгышы гадәттәгечә кыска һәм төгәл:

— Рәхмәт, мең рәхмәт, дусларым! Бер генә ел элек 15 мең тонна турында хыялланган идек. Анысына ярышташыбыз Алдакаев бригадасы иреште. Аннары ул 20 меңгә якынлашты. Бүген без 30 мең бусагасында. Болай тырышып эшләгәндә бездән дә уздыручылар булыр...

Хужин житмешенче елларда стахановчылык хәрәкәтенең эчтәлеге үзгәрүен яхшы белә. Хәтта бүген зур рекорд куйган коллективның да ахыр чиктә ярышта җиңеп чыкмавы ихтималына төшенә. һәрчак уңышка ирешүнең шарты бер: бригададагы һәр кешенең бөтен операцияләрне белүе, хезмәткә иҗади каравы зарури. Бригаданың бурычы катлаулана төшә; ул планнарны үтәү һәм арттырып үтәүгә генә кайтып калмый. Бригадир үз кул астындагы кешеләрне тәрбияләргә тиеш. Көн тәртибенә бригададагы һәр кешенең киң профильле шахтер булу мәсьәләсе килеп баса. Моңа ирешкәндә, кем дә булса чираттагы ялга китсә яисә авыру сәбәпле эшкә чыга алмаса, бригаданың хезмәт җитештерүчәнлеге барыбер кимемәскә тиеш. Хужин яңа педагогия ысулы уйлап чыгармый, әлбәттә. Көндез — эш, кичен — уку. Ул бригадирларның осталыгын күтәрү курсларына йөри, анда үзләштергән алдынгы ысулларны шахтерларына өйрәтә. Беренче карашка мәсьәлә хәл ителгән кебек. Эш ягыннан шулай. Ә бригадир үзе төшенгән культура дәрәҗәсе үсеше кайда! Бергәләп уйлаша, киңәшә торгач, рационализаторлык тәкъдиме бөреләнеп җитә: ял көннәрен гаиләләрне бергә җыеп үткәрергә дигән уртак карарга киләләр. Күмәкләп киноларга, театрларга бару, табигать кочагына чыгу коллективның төрле яктан үсешенә этәргеч була. Сәетҗан нәкъ шушы эштән буш вакытларда Павел Баяров, Николай Руденко, Тәлгать Шәмсетдинов, Шәмси Исламовның оештыру сәләтләрен күрә. 31 эш көнендә 30210 тонна ташкүмер чыгарып, Кузбасста яңа рекорд куйгач, Хужин аларның дүртесен дә бригадирлыкка тәкъдим итә. Шахта җитәкчеләре моны хуплап каршылый.

1978 елның август ахыры. Прокопьевскиның бер төркем алдынгы шахтерларын Мәскәүгә бәйрәмгә дәшеп алалар. Дзержинский исемендәге шахтадан берьюлы җиде кеше: Сәетҗан Хужин, Миңлегали Алдакаев, Леонид Соловьев, Франц Мельхиор, Геннадий Воробьев, Юрий Маркелов, Анатолий Бозин — барысы да ил күләмендә танылган бригадирлар. Башкалага Кузбассның бер шахтасыннан да берьюлы бу хәтле кешенең чакырылганы булмый әле.

Шахтерлар тормышында бик матур гадәт яши. Аларның профессиональ бәйрәме көнендә хөкүмәт бүләкләре, «Шахтер даны» билгеләре тапшырыла, мактаулы исемнәр бирелә. Ул елгы бәйрәм тантанасы СССР Күмер промышленносте министрлыгының утырышлар залында үткәрелә. Анда паеклыларның да иң паеклылары җыелган. Министр Б. Братченко атаклы шахтерларны бәйрәм белән котлагач, бүләкләү башлана. Беренче булып Хужинны чакыралар. Аның күкрәгенә министр үзе Октябрь Революциясе һәм Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары янына Ватаныбызның иң олы бүләге — Ленин орденын таға. Хужинны «Шахтер даны» билгесенең өченчесе белән бүләкләнүе һәм РСФСРның атказанган шахтеры дигән исем бирелүе уңаеннан кайнар котлый. Бөтенесе алдында аңа якалары һәм җиңнәре ука белән чигелгән мактаулы шахтер костюмы кидерәләр. Зал гөр килеп кул чаба. Сәетҗан Хужин зур бүләкләрне үз хезмәтенә, үзе җитәкләгән коллектив эшенә бирелгән бәя итеп ала.

— Осталыкка хөрмәт зур бездә, — ди залдагыларның берсе күршесенә, Хужин күкрәгендәге орденнарга күз салып.

— Хикмәт бер кешенең осталыгында гына түгел, — дип каршы төшә тегесе.— Ул үз осталыгына бөтен бригадасын өйрәткән. Кузбасста беренчелекне тота икән ич. Өч мәртәбә рекорд куюын министр үзе билгеләп үтте...

В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу елын Сәетҗан Хужин җитәкләгән бригада коллективы рекордлар белән башлаган иде. Ун елда дәвамында атаклы бригадир Кузбасс шахтерлары арасында социалистик ярыш инициаторы булып килде. Дәһи юлбашчыбызның тууына 110 ел тулган көнгә 500 мең тонна ташкүмер чыгарып, унынчы бишьеллык планын тутырды. Хәзер Сәетҗан Хужин һәм Миңлегали Алдакаев җитәкләгән коллективлар елына 200 мең тоннадан күбрәк ягулык чыгаралар. Дзержинский исемендәге шахтада Шәйхи Зәйнетдиновның Алексей Стаханов рекордын кабатлаган 1935 елдагы бөтен шахта 12 айда биргән күмер хәтле, бу — КПССның чираттагы XXVI съездына шахтерларның паеклы бүләге.

# ОКТЯБРЬ ҮСТЕРГӘН ДӘҮЛӘТ ЭШЛЕКЛЕСЕ



Быел без Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүнең 60 еллыгын зур бәйрәм итеп билгеләп үттек. Милли республиканың нигез ташларын салучылар арасында 1917 елның июнь аеннан Коммунистлар партиясе члены, большевик-революционер, дәүләт эшлеклесе Шәйгәрдән Шәймәрдәнович Шәймәрдәнов та бар. Шушы елның сентябрь аенда аның тууына 90 ел тулды.

Үзәге Иске Байсар авылы булган колхозга Актаныш район Советы башкарма комитетының махсус карары белән Шәйгәрдән Шәймәрдәнов исеме бирелгән. Идарә каршына исә аның бюсты куелган. Хуҗалыкта ел йомгаклары буенча иң югары күрсәткечләргә ирешкән алдынгыларга бирү өчен Ш. Шәймәрдәнов исемендәге приз булдырылган.

Бормаланып аккан Сөн буенда
Тезелеп киткән яшел авыллар.
Шулар белән бергә дан казанган
Байсар дигән матур авыл бар.
Күңелләргә якын син, Байсар!
Күкрәгеңдә синең уйнап үскән
Шәймәрдәнов — безнең комиссар.

Моннан дистә еллар элек шагыйрь Мостафа Ногман сүзләренә композиторлар Сара Садыйкова һәм Аллаһияр Вәлиуллин иҗат иткән «Шәймәрдәнов комиссар» дигән җыр әнә шулай башлана. Ул халык арасында киң таралган.

Ш. Шәймәрдәновның тормышын һәм дәүләт эшчәнлеген чагылдырган документлар КПСС өлкә комитетының партия архивында (15 ф., 1 тас., 1328 эш; 30 ф., 1 тас., 658 эш) һәм Татарстан Үзәк Дәүләт архивында (137 ф., 1 тас., 26 эш; 732 ф., 1 тас., 586 эш) саклана. Бу юлларның авторлары шул документларны өйрәнделәр һәм Ш. Шәймәрдәновның хатыны, инде сиксән биш яшен тутырган Гыйльмикамал Шәймәрдәнова, кызлары — хезмәт ветераннары Хаҗәрә, Әлфә, Дилә, энесе — Бөек Ватан сугышы һәм хезмәт ветераны, 1939 елдан КПСС члены Шаһинур Шәймәрдәнов белән, шулай ук Шәйгәрдән Шәймәрдәнович белән бергә эшләгән иптәшләр белән сөйләшеп, кайбер факт һәм вакыйгаларны ачыкладылар.

...Иртән иртүк баш очында күе кара болытлар бөтерелде. Менә-менә җиһанны яңгыратып күк күкрәр, яшен яшьнәр, аннан чиләкләп-чиләкләп яңгыр коя башлар кебек тоелды. Табигать рәхәтләнеп бер сулыш алыр, күңелләргә дә сафлык, тынычлык бәркелер сыман иде. Юк икән, туган авылы Иске Байсарга таң беленү белән үк, кеше-кара күренгәнче, дип кайтып килүче Шәйгәрдәнгә бу болытлар кайгы хәбәрчесе булды. Җил капканы ачып керүгә хатыны Гыйльмикамал ишек алдына атылып чыкты да Шәйгәрдәннең беләкләренә ябышты. Үзенең йөзеннән нур качкан, көч-хәл белән генә аякларына басып тора. «Ярый әле кайттың, ярый әле кайттың»,— дип кабатлый ул.

Шәйгәрдән күңелсез хәбәр барлыгын сизенә, әмма ни булганлыгын тәгаен генә абайламый. Ул, әллә юатырга теләп, әллә сагынуын белдерүе булдымы, Гыйльмикамалны кочагына алды. Бу минутлар озакка сузылмады. Өй ишегенә ачуга Шәйгәрдән сискәнеп китте. Болай да кечкенә, ярым җимерек өйдә әнә төшәрлек тә урын юк иде. Күрше тирәдәге карт-коры җыелган. Моңарчыга кадәр өй түрендә торган агач караватт уртага күчкән, аңа әтисенең гәүдәсе салынган. Үги әнисе Мәгърифә ире Шаймәрданнең баш очындагы урындыкта утыра, аның елаудан күз кабаклары шешенгән, үзе нидер сөйләгәндәй итә.

— Староста белән мулла әтиеңне авыл зиратына күмдермәскә карар чыгардылар, я нишлибез, балам, — ди ул Шәйгәрдәнне күрүгә.

— Ни өчен?

— Синең коммунист булганлыгың өчен, күз нурым. Коммунистлыгыннан ваз кичсен, байларга кул күтәрмәскә, аларга каршы сүз әйтмәскә ант итсен, дигәннәр. Шуннан соң уйлап карарбыз әле, дип әйтәләр, ди.

Шәйгәрдәннең болай да ярсыган күңеле тәгәл генә ни дип җавап бирергә дә белми иде.

— Ак чехлар сине бик озаклап эзләде, — дип сүзен дәвам итте үги әнисе, — авылда кермәгән өйләре калмады. Ахыр чиктә: «Улы өчен әтисеннән үч алабыз, әтисенең исән калуын теләсә, коммунист Шаймәрданов качкан җиреннән чыксын»,— дип бөтен авылга сөрән салып йөрделәр. Дошман исә әтиеңне авыл читендәге сазлыкка алып киткән иде инде. Шунда җәзалап үтергәннәр дә. Карар җире калмаган, кан эчендә иде...

Ярты көн эчендә булган вакыйга бу. Шәйгәрдән, баштанаяк коралланган ак чехларга каршы торуы ифрат авыр булачагын сизеп, иптәшләре белән вакытлыча урманга күчкән иде. Максатлары: күрше-тирә авылларда яшәүчеләрдән бер отряд туплап, ак чехларга каршы көрәш ачу. Кич, я булмаса иртән кайтып, Шәйгәрдән авылдагы хәл-әхвәлләрне белешеп торды. Бу кайтуында менә нинди ерткычлык эшләнгән.

Шәйгәрдән кече яшьтән үк гел әтисе янында кайнаша, Шаймәрдән ага исә моңа сөенеп бетә алмый. Шактый ишле гаиләне алып бару яшьтән ятимлектә, ялгызлыкта, коллыкта үскән картка бик авырга килә башлаган иде. Вакыты-вакыты белән тыны кысылып, сәгатьләр буена кыл да кыймылдатмыйча кайда туры килә шунда яткан вакытлары да ешаеп китте. Кулы эшкә өйрәнә башлаган улы Шәйгәрдәнгә аның васыяте бер: «Һөнәрле булсаң, җиңелрәк көн итәрсең». «Ә үзе ул башта байларда эшләгән, тора-бара сагыз кайнатырга керешеп, шуны тирә-як авылларда сатып йөри торган булган. Шәйгәрдәнгә «сагыздан туган» дигән кушамат та менә шуннан тагылып калган. Көннәрдән бер көнне авыллар арасындагы үзәнлектә ял итеп утырган арада әтисе улына бер укымышлыдан ишеткәннәрен сөйли: «Дөрестерме, юктырмы, — дип башлый ул сүзен, — бездәй ярлы халыклар өчен рәхәт дөнья китерергә йөрүчеләр дә бар икән, улым, аларның башлыкларын Ленин дип йөртәләр, ди. Әмма ул, улым, бик еракта икән әле. Гаскәре дә юк икән аның. Шулай да залим патшаны бәреп төшерергә исәпли икән. Хәзер әнә эшчеләр бергә тупланалар, ди. Сиңа да шул дөньяларны күреп кайтырга кирәк булыр, улым».

Баштарак әтисе сөйләгәннәргә әллә ни исе китми Шәйгәрдәннең. Әмма торабара уйландыра, күңелен кайдыр еракка, моңарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән җирләргә җилкендерә бу сүзләр. Озакламый, кап-кара чәчле, киң җилкәле шул егетне патша армиясенә алалар. 1911 елга туры килә бу.

Чая егеткә хезмәтенең беренче көнендә үк бик күпләр игътибар итә. Исәп-хисап эшенә бераз өйрәнгән, шуның өстенә авыл мәктәбенең ике классын да тәмамлаган Шәйгәрдән армиядә башта сатучы, аннан артиллерист, интендант була. Һәр солдат белән диярлек якыннан танышып чыгарга да өлгерә.

1917 елның февраль буржуаз-демократик революциясе патша армиясендәге бик күпләрнең күзен ачып җибәргәндәй итә. Әмма җирле власть башында торучылар ул хәбәрне сер итеп саклыйлар, шуңа да Шәйгәрдәннең туган авылында да Февраль революциясе турында шактый соңарып ишетәләр. Ә ярлы баласы Шәйгәрдәннең йөрәгендә ут уйный, авылына тизрәк кайтып, сәүдәгәр Гыйлаҗетдиннәргә, Әмирхан муллаларга, Фәттах байларга алар җыйган мал-мөлкәтнең халыкныкы булуын төшендерәсе, әтисе Шәймәрдәнгә туйганчы ипи ашатасы килә аның. Шәйгәрдән революцион карашлы иптәшләре үрнәгендә 1917 елның июнь аенда үз язмышын мәңгелеккә большевиклар партиясе белән бәйли.

Вакыйгалар көне-сәгате белән үзгәреп тора. 1917 елның 25 октябре иртәсендә властьның Петроград эшчеләр һәм солдат депутатлары Советы кулына күчүе турындагы хәбәр Минзәлә өязенә 26 октябрьда ук килеп ирешә. Әмма Совет властен урнаштыру җиңел генә бармый. «Безнең якларда әкәмәт чуалышлар башланды, — дип хәбәр сала Шәйгәрдәнгә әтисе, — кулаклар, патша иярченнәре Совет властен урнаштырырга һич ирек бирмиләр. Сезнең кул җитешми, улым».

1918 елның гыйнварында бер рус егете белән кайта ул авылына. Алар икәүләп гади халыкка илдә ниләр булуын аңлатырга керешәләр. Кайтуының икенче көнендә үк авылдашлары Шәйгәрдәнне волость җир комитеты члены итеп сайлыйлар. Солдат-большевик, үз тирәсенә ярлы активны туплап, кулак-кулаштаннарга көчле отпор бирә. Авылда беренче авыл Советы оештырыла. Аның председателе итеп шулай ук Шәйгәрдән Шәймәрдәнов сайлана.

Иске Байсар элек-электән тирә-якта дан тоткан базарлы авыл. Сату-алуның иң кызган чагында берәү арбага менеп баса да, нотык сөйли башлый.

— Бер генә минутка тыңлагыз әле, — ди ул. — Властьны коммунистларга биреп нәрсә оттыгыз? Хәерчелектән башка ниләре бар соң аларның? Ышанмагыз сүзләренә!

Халык төркеме шау-гөр килә. Кемнең ни әйткәнлеген абайлау һич мөмкин түгел. Шул арада бөтен җегәрен җигеп Шәйгәрдән сүз башлый.

— Совет власте ул, иптәшләр, Иске Байсар, я булмаса Минзәлә өязе генә түгел. Бөтен Россиядә власть халык кулына күчте. Бөтен булган байлык сезнеке, ярлыларныкы хәзер. Киләчәктә шуңардан ничек файдаланасыз, монысы инде сезнең үзегезгә бәйле.

Шәйгәрдән фикерен әйтеп бетерергә дә өлгерми, арадан берәү ачы тавыш белән кычкырып җибәрә:

— Юкны сөйләмәсен, дөмектерегез үзен!

Авылдашлары алдында ихтирам казанып өлгергән егеткә берәү дә кул күтәрергә батырчылык итми. Аның хак эш өчен көрәшүче булуын ачык беләләр.

— Куркытмагыз, — ди Шәйгәрдән, аңа каршы сүз ишетелгән якка борылып.— Мин партия тарафыннан Совет власте казанышларын якларга билгеләнгән кеше. Кулакларның бүре тешләрен сындыру өчен кискен чаралар күрергә кирәк. Хәзер аларның аркаларыннан сыйпар чак түгел. Мине үтерерсез, минем урынга икенче коммунист килер, ул да шулай ук актык сулышына кадәр хак эш өчен көрәшер.

Сүз башлаучы яклаучыларын тапмый. Әмма барыбер сүзен җилгә очырырга теләми ул.

— Сүзеңне үлчәп сөйлә, сиңа да чират җитәр, — ди дә күздән югала.

...Әтисенең үле гәүдәсе янында басып торганда Шәйгәрдән менә шул вакыйгаларны хәтереннән үткәрде. Ике яшьтән ятим калып, кеше аягы астында сынык ризык теләнеп үскән Шәймәрдән Габделгалимовны бөтен авыл халкы соңгы юлга озатырга чыга. Халык җыенында чыгыш ясап, Шәйгәрдән Совет властена каршы элементларга болай ди: «Сез минем әтиемне үтердегез. Совет хөкүмәтен булдырмабыз, дип уйлыйсызмы? Юк, ялгышасыз, хаклык җиңәр, Советлар яшәячәк».

Ләкин озак та үтми Минзәлә якларына Колчак бандалары ябырылуы турында чаң сугалар. Бу вакытта инде бөтен өяздән җыелган ашлык һәм терлекнең шактые

Минзәләгә тупланган була. Шәйгәрдән Шәймәрдәнов шул байлыкны эвакуацияләү башлыгы итеп билгеләнә. Ул аны түкми-чәчми Казанга илтеп тапшыруны оештыра. Шуннан соң туган якларына кайтып Колчакка каршы сугышларда катнаша. Кулаклар коткысы белән авылларны сәнәкчеләр фетнәсе чолгап алган вакытларда да тәшенкелекнең ни икәнлеген белми, халык массасын үзенә иярттә.

Илдә авыл хуҗалыгы продуктларына кытлык үзен аеруча нык сиздерә. Социалистик дәүләт дошманнары ашау-эчү әйберләренә булган кризисны тагын да көчәйтергә омтылалар: Минзәлә өязендәге күп кенә авылларда ашлык амбарларына ут төртелә, капчык-капчык ашлык елгаларга ташлана. Шул ук вакытта ярлы-ябагай ачлыктан интегә. Мәскәүдә, Петроградта ачлыктан үлүчеләр турында да хәбәрләр алына.

Шәймәрдәновны Минзәләгә чакырып алалар. Ул анда түбәндәге эчтәлекле телеграмма белән таныша:

«Запастагы армия реввоенсоветына

Телеграмма

1920 ел, 8 февраль.

Мәскәү, Петроград, Көнбатыш фронт һәм Төньяк фронт армияләре икмәксез калу алдында торалар. Оборона Советы, продорганнар күрсәтмәләре нигезендә, Казан тимер юлы буенча икмәк төяү һәм озату өчен Көнбатыш армия Реввоенсоветына бөтен тырышлыкны җигүне тапшыра. Аз гына акрын кыймылдау да өч-биш көннән барлык икмәк запасларының бетүенә китерәчәк. Күрелә торган чаралар һәм, төяү урынын күрсәтеп, нәтиҗәләр турында телеграф аша көн саен хәбәр итеп торыгыз.

Оборона советы председателе
Ленин»[1].

Большевиклар Ленинның «Ашлык өчен көрәш — социализм өчен көрәш ул» дигән лозунгысын тормышка ашыру өчен армый-талмый көрәшә. Шул чакта Байсар волость комитеты председателе (1920 елның мартында сайлана) һәм хәрби комиссар итеп билгеләнгән Шәймәрдәнов бик зур авырлыклар белән халыктан ашлык һәм мал-туар җыеп, аны хәрәкәттәге Кызыл Армиягә озатуны оештыра. Аның ярлылар турында чын-чынлап кайгыртуы, ягымлылыгы, кыюлыгы турында сүзләр тирә-яктагы волостьларга да тарала.

1921 елның язында ил өстенә тагын бер явыз дошман ябырыла: монысы инде— корылык һәм шуның нәтиҗәсендә туган ачлык була. Мулла-мунтагайлар, бай-бәтчәләр, аны үзләренчә аңлатып, аңсыз крестьян массасын үз кубызларында биетергә ниятлиләр. Шулай итеп, коммунистларга, совет яклыларга каршы күтәрелү өчен тагын бер «дәлил» табыла: «Коммунистларга ияру мәнә нәрсәгә китерде инде, алласызлык сезне гүргә кертәчәк». Ә коммунистлар моның табигать бәла-казасы, вакытлыча гына киенлык булуын аңлатырга, шул турыда һәркемгә җентекләп төшендерергә тырышалар. Шәйгәрдән дә халык алдында чыгышлар ясый, хәтта үгетли дә, мөмкин булган кадәр түземлелек белән эш итәргә чакыра. Билгеле, Шәйгәрдәнне элеккечә үк күпчелек халык яклап чыга, әмма авыллары-авыллары белән икмәклерәк якка юл тотарга җыенучылар да табыла, алар китеп тә баралар. Өстәвенә тирә-якта тиф, холера кебек эпидемия дә тарала.

Халык массасына якынрак килү, аларның аһ-зарына колак салып, төшенкелеккә бирелмәү өчен ныклы ярдәм итү максатыннан Минзәлә кантоны берничә районга бүленә. Шул вакытта Ш. Шәймәрдәнов Александровка-Карамалы дип исемләнгән районга ВКП(б)ның райком председателе итеп җибәрелә. Шушы постта вакытта ул республика Советларының икенче Бөтентатар съездында катнаша, ачлыктан интегүче крестьяннар исеменнән чыгыш ясый. Шул ук мәсьәләдә Мәскәүгә мөрәҗәгать итүдә турыдан-туры шөгыльләнә. Озак та үтми, Татарстанга Ленин тарафыннан ашлык җибәрелә.

---

[1] Ленин и Татария. Татарстан китап нәшрияты, 1970, 98 б.

Бер елдан Ш. Шаймәрданов Минзәләгә кантон башкарма комитеты председателе итеп күчерелә. Ачлык-ялангачлык бераз җиңеләеп килә, әмма аның авырлыклары адым саен сизелеп-күренеп тора әле. «Ачлык еллардагы фаҗигале вакыйгалар бер дә истән чыкмый, — дип яза комсомол ветераны Тимер Кручев Октябрьның 50 еллыгы уңаеннан басылган «Без үткән данлы юл» дип исемләнгән мәкаләдә. — Татарстанның IV өлкә комсомол конференциясеннән соң, шәһәрдә күп кенә китаплар алдым да, Әгерҗе поездына утырып, юлга чыктым. Казаннан Әгерҗегә кадәр 300 чакрым араны поезд берничә тәүлек кайтты. Паровозга ягулык юк иде. Әгерҗегә мин ач һәм хәлсезләнеп килеп төштем. Минзәләгә кадәр ничек кайтырга? Җитмәсә үзем белән толып һәм зур гына китап бәйләме! Бер әбидән чана таптым да толыпны һәм китапларны төяп Минзәләгә юл тоттым. Унбер тәүлек кайттым. Авылларда миңа алабуга ипиеннән башка бернәрсә дә бирә алмадылар. Минзәлә өязенә кергән бер рус авылына җиттем. Авыл Советы председателен белә идем. Ул мине ат белән Минзәләгә кадәр озатуны оештырды. Толып һәм китапларны ат чанасына салдым да юлга чыктым. Авылдан өч-дүрт чакрым үткәч, ат егылып үлде. Ат хуҗасы дилбегә, камыт ишеләрне җыйды да:

— Ә син, энем, ашыкмыйча атла, бәлки кайтып җитәрсең,— дип үз авылына юл тотты.

Мин киттем. Ат егылган җирдән бер чакрым чамасы юл узганымны, юл кырыена толыпны җәеп, китапларны баш астына куеп, йөзтүбән ятканлыгым турында соңыннан миңа сөйләделәр. Мине, бәхеткә каршы, Минзәлә кантон башкарма комитеты председателе Ш. Шаймәрданов шәһәргә алып кайткан»[1]. Бу эпизод ул вакытларда партия, совет, комсомол работникларының эшендәге авырлыкны ачык чагылдыра, Ш. Шаймәрдановның кешелеклелек сыйфатлары, ярдәмчел булуы турында да сөйли. Чордашлары аның нәкъ шушы сыйфатларына кат-кат басым ясый.

Вакыт бертуктаусыз алга ашыга. Без аны магнитофоннар, фотоаппаратлар ярдәмендә бер мизгелгә туктатып торырга өйрәндек. Архивлардагы документлар да шул хезмәтне башкара. Алар — әйтеп бетергесез зур байлык. Әмма теге яки бу вакыйгаларның эчендә кайнаган кешеләрне тыңлауны бернинди документлар да алыштырмый. Шуңа да без Шәйгәрдән Шаймәрдановның кордашлары, туганнары, аның белән бергә эшләгән шәхесләр белән мөмкин булган кадәр әңгәмә корырга тырыштык.

Беренче әңгәмәдәшебез — Гыйльмикамал Шаймәрданова. Хәзер ул Мәскәү янындагы Зеленоград шәһәрендә яши. Шәһәрнең почетлы гражданкасы. Ул дулкынланып сөйли:

«Без бер-беребезне яшьтән үк белеп өйләнештек. Аныкы кебек үк, минем әтиәниләрем дә үтә ярлы иделәр. Иске Байсарда әтисе салган саман йортта тордык. Әмма тынычланып яшәргә насыйп булмады. 1918 елның язында авылга ак чехлар якынлашкач ук Шәйгәрдән тирә-күрше авыллардагы яшьләрдән отряд оештырды. Минзәләдән исә аның исеменә атап корал һәм егерме кешедән торган атлы кызылармеецлар җибәрелгән иде. Шәйгәрдән шул отрядның башлыгы булды. Август аеның беренче көннәре иде булса кирәк, кичләтеп безгә бер кызылармеец килеп керде дә Шәйгәрдәнне Минзәләгә чакыруларын әйтте. Чөнки бу вакытларда ак чехларның һөҗүме шактый көчәйгән иде инде, бөтен өязне камап алу куркынычы туган икән. Идел елгасы буйлап ак чехларның зур, шактый үк көчле отрядының һөҗүмгә әзерләнүе дә билгеле булды. Мин шунда ук отряд урнашкан аланга йөгердем. Хәбәрне аларга җиткереп авылга кайтсам, чехлардан берничә кеше мине көтеп торалар булып чыкты. Шәйгәрдән отряды турында бик төпченеп, кат-кат сораштылар. Әмма бернинди янау, куркыту булмады. Сизәм, үзләренчә хәйлә корганнар: алар бик мәрхәмәтле, янәсе. Соңгы баруымда Шәйгәрдән: «Безнең янга артык килеп йөрмә, күзәтеп торулары бар»,— дип кисәтте. Шуңа да алар ягыннан элемтәче итеп Сәләх Шәрәфетдинов дигән авылдашыбыз билгеләнде. Аның белән без көнгә ике тапкыр авыл янындагы күпер башында очрашырга сүз куештык. Мин су алырга төшәм, ә ул су эчәргә килә, янәсе. Ә чиләкләрдә алар өчен кирәкле документлар була торган иде. Көннәрдән бер көнне сизеп алдылар да, мине Нургали Сәлимов дигән

[1] «Социалистик Татарстан», 1966 ел, 20 декабрь.

байның келәтенә ябып та куйдылар. Сорау алулар башланды. Кара көймәгән җирем калмады диярлек. Бер көнне иртән келәт янына беләгенә кызыл бәйләгән берәү килде. «Һиһаять, үзебезнекеләр», дип уйлап куйдым мин. Сөйләшә торгач ул провокатор булып чыкты. Ярый әле серне чишеп өлгермәгән идем. Кулга алынуымның бишенче көнендә Сәләх Шәрәфетдинов унлап иптәше белән төнлә килеп мине коткарды. Ә Шәйгәрдән белән бу вакытларда һич күрешергә ярамый иде. Чехларның безнең авылга килүләре дә шул Шәйгәрдәнне кулга төшерү нияте белән икәнлеге ачыкланды. Анысын шактый еллар үткәч миңа үз өендә чехларга сыену урыны биргән бай-бәтчә Нургали сөйләде... Төнлә Минзәләгә таба юлга чыктык, без килеп җиткәндә анда кызылармеецлардан берәү дә юк диярлек иде инде. Кама аръягына чигенгәннәр икән. Төп отрядны куып җиттек. Алар белән бергә Кама буйлап Сарапул шәһәренә кадәр йөздек. Сарапулда Минзәләдән килгән отрядка тагын бик күп кеше өстәлде, шулай итеп отряд көч җыйды, ныгыды, аннан Минзәләгә кайту юлына чыктык. Чехлар шәһәрне тулысынча камап алырга өлгермәгәннәр иде әле, ләкин аларга каршы сугышу шактый авыр булды. Төп отрядка башка частьлардан да ярдәм иттеләр. Чехларны тәмам куганнан соң Минзәләдә Революцион комитет оештырылды, Шәйгәрдәнне яңадан туган авылына Совет властен торгызу өчен җибәрделәр.

Иске Байсарга кайту юлында бик озаклап, иркенләп сөйләштек. Шәйгәрдән уй-фикергә бик бай кеше иде. Башында әллә нинди хыяллар йөрткән булып чыкты ул. Шуларның барысы турында да сөйләде, аннан: «Минем белән тормыш корып җибәрүеңә үкенмисеңме?» — дип сорап куйды. Хак эш өчен көрәшүен, ярлы-ябагай үз хезмәтенең җимешен үзе татысын өчен янып-көеп йөргәнлеген белгәнгә күрә аңа булышырга, көчтән килгән кадәр ярдәм итәргә тырышуымны әлбәттә үзе дә белә иде... Авылга кайтуга ул Шәйхелислам Нуретдинов һәм башка иптәшләре белән берлектә ярлылар комитеты, хәрби комиссариат һ. б. оештыруга кереште. Кич җиттеме, авылда иң аулак урынны сайлап, әңгәмә корырлар иде. Сүзләре күбрәк фронтка ярдәм итү хакында барды. Инде бераз эзгә төшәбез генә дигәндә, Колчак бандаларының һөҗүме турында хәбәр килде. Шәйгәрдәнне яңадан Минзәләгә чакырып алдылар. Ә минем авырлы килеш алар белән юлга чыгарлык хәлем юк иде. Иң өлкән кызыбыз Хаҗәрәне землянкада таптым».

Икенче әңгәмәдәшебез — Всеволод Петрович Сюганов. Ул Ш. Шәймәрдәновның Минзәләдәге эшчәнлеген бик ачык хәтерли. Үзе Казанда эшче гаиләсендә туган. Хәзер Мәскәүдә яши. Озак еллар буе КПСС Үзәк Комитетының марксизм-ленинизм институты каршындагы карт большевикларның тарихи-әдәби берләшмәсенең Казан секциясенә җитәкчелек иткән. 1921 елдан КПСС члены, 1919 елның сентябрендә Бөтенроссия Гадәттән тыш комитетының махсус бүлегендә эшли башлый. 1922 елның апрель аенда аны Минзәлә кантоны буенча Дәүләт Политик идарәсенә уполномоченный итеп билгеләләр.

«Шәйгәрдән белән без беренче көннәрдән үк дуслашып өлгердек, — дип сөйли карт большевик. — Кеше белән бик тиз уртак тел таба торган гадәте бар иде аның. Башкарма комитет утырышларының берсендә миңа таба борылып нәрсәдер әйтергә җыенган иде, туктап калды. Нәрсә булды икән, дип уйладым мин. Исемемне хәтеренә төшерә алмыйча азаплануы икән. Аннан югалып калмады үзе. «Сибагат» дип әйтеп салмасынмы? Аннан барлык татарлар да мине Сибагат дип йөртә башладылар. Шәйгәрдән акыллы һәм ифрат тырыш кеше, вакыты-вакыты белән бик шаян, җор сүзле дә иде. Без Минзәләдә күрше бүлмәләрдә тордык. Шуңа бөтен килеш-килбәте, хәрәкәтләре, әйткән сүзләре исемдә калган диярлек. Бер көнне күршемне казармага кызылармеецлар алдында политик темага чыгыш ясарга чакырдык. «Күптән көткән идем, әллә Сибагат мине санга сукмаска уйлыймы, дип тә фикер йөрткән идем инде», — диде ул, шаяра төшеп. Икәүләп казармага киттек. Кызылармеецларыбыз аңа сорауларны яудырыпмы-яудыра башлады бит. Шәймәрдәнов аларны түземлелек белән тыңлый һәм һәрнәрсәне энәсеннән-җебенә кадәр төшендереп җавап та бирә»...

Соңыннан Шәймәрдәновны үзебезнең командага почетлы кызылармеец итеп алдык. Шул хакта махсус приказ чыгарылды, Шәйгәрдәнгә почетлы кызылармеец кенәгәсе дә тапшырылды. Башкарма комитет председателе постында эшләгәндә ул безгә бик нык шефлык ярдәме күрсәтте. Ә очрашканда һәрвакыт кулын каш өстенә

куеп, сәлам биреп китә иде. — Тагын бер вакыйга хәтергә сеңгән, — дип дәвам итте сүзен Всеволод Петрович, — кетмәгәндә-уйламаганда Шәйгәрдән мине ишек алдына чакырып чыгарды. Я, әйт әле, без яшәгән урын матурмы?— диде ул. — Йортыбыз чыннан да яшеллеккә төренгән иде, һавасы чиста, бакчасында күңел тели-гән чәчәкләр, җимеш агачлары үсә. «Ифрат матур» дидем мин.— Мин дә шул фикердә, — диде Шәйгәрдән. — Шулай булгач, без яшәгән йортны балалар бакчасы итсәк, ни булыр икән? — Шәйгәрдәннең тел төбендә менә нәрсә яшеренгән икән. Озак та үтмәде, балалар өчен менә дигән бакча булдырылды, ә без торырга икенче йортка күчтек. Теге яки бу мәсьәлә буенча кешенең фикерен ярата иде ул, шуннан соң гына берәүне дә читкә какмыйча, уртак фикергә килеп, эшкә керешер иде. Җитәкче өчен бу сыйфатлар аеруча кыйммәт. ТатЦИК председателе булып эшли башлагач та миңа аның белән бик күп тапкырлар очрашырга туры килде, аның характерында мин тискәре якка һичнинди үзгәреш сизмәдем».

Минзәлә өяз башкарма комитеты председателе вакытында Ш. Шәймәрданов наданлыкны бетерү өчен ныклы көрәш җәелдерә. Волостьлардан һәр ай саен үзләренең эшчәнлекләре турында отчет алуга да ирешә. Ә отчет 41 пункттан торган. Анда башкарма комитетның составы, җаваплы работниклар, советларның бүлекләре һәм аларның эшчәнлеге, кызылармеецларның гаиләләренә ярдәм күрсәтү, башкарма комитетка алынган жалобаларны тикшерү, больницаларда, башка дәвалау урыннарында санатория һәм медицина хәленең торышы турында сораулар булган.

1922 елның язында Ш. Шәймәрданов Мәскәүдә була, партиянең XI съездында катнаша. Менә шунда инде ул Ленинны соңгы тапкыр тыңлый. «Дөньядагы бернинди көч тә, — дип белдерә Ленин съездда, — ул миллионнарча кешеләргә тагын күпме генә явызлык, бәлгенлек һәм газаплар китерә алса да, барыбер безнең революциябезнең төп казанышларын кире кайтарып ала алмас, чөнки ул казанышлар инде хәзер «безнеке» генә түгел, бәлки бөтендөнья күләмендә тарихи казанышлар»[1].

1922 елның 30 декабрендә Советларның I Бөтенсоюз съезды ачыла. Съезд Совет Социалистик Республикалар Союзын төзү турында декларация кабул итә. Азат халыкларның ирекле союзын чын күңелдән бердәм яклауларын белдерү өчен Татарстан АССР хезмәт ияләре бу күп милләтле форумга кырыктан артык вәкил җибәрә.

Озак эшләп тупланган тәҗрибә, политик сизгерлек, теге яки бу авырлыкларга тиз һәм дөрес бәя бирү Шәйгәрдән Шәймәрдановның халык алдындагы абруен күтәрә. Ул һәрвакыт халык массалары белән аралашырга ярата, күп йөри, аны барлык нәрсә дә кызыксындыра. Барысына да җавап таба Шәйгәрдән. Көнне-төнгә ялгап хезмәт итә, ә алда аны тагын да зуррак эшләр көтә: 1924 елның апрелендә Ш. Шәймәрданов ТатЦИК председателе урынбасары итеп билгеләнә. Татарстан АССР Советларының V съезды исә (1925 елның гыйнваре) аны Татарстан Үзәк Башкарма комитеты председателе итеп сайлый. Шул ук елны ул РКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты бюросы члены итеп сайлана. Моңарчы кантон күләмендә хәл ителгән мәсьәләләрне хәзер аңа республика масштабында тормышка ашырырга, киңрәк колач белән эш итәргә, ил күләмендә фикер йөртергә кирәк була.

Ш. Шәймәрданов башта иң авыр мәсьәләләргә иң берсе — эшсезләр проблемасын хәл итүгә зур игътибар бирә. Татар телендә эш алып баруны тормышка ашыру комиссиясенә дә ул җитәкчелек итә, укый-яза белүчеләргә зур мохтаҗлык кичергән елларда милли кадрлар хәзерләүне дәүләткүләм мәсьәлә итеп куя. ТатЦИК президиумы утырышларында бу мәсьәләләр берничә кат тикшерелә. Президиум 1925 елның 16 июнендә раслаган резолюциядә, мәсәлән, шундый юллар бар: «Совет аппаратының татар хезмәт ияләре массасына якынаюына зур әһәмият биреп, өяз, кантон бюджетларын төзегәндә татар телендә эш алып баруны гамәлгә кертүгә расходлар билгеләргә» һәм анда бу юнәлештә үткәрелергә тиешле конкрет мәсьәләләр турында да сүз алып барыла: өяз башкарма комитетларында штатка өстәмә рәвештә татарлардан кимендә бер практикант-техник работник билгеләү, татарлар арасыннан техник

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр. Дүртенче басмадан тәрҗемә. 33 том. 308 бит.

работниклар хәзерләү буенча кантонда курслар оештыру, язу машиналарын татар шрифтына көйләү һ. б. Республикада татар телен гамәлгә ашыру буенча да перспектива план төзелә.

ТАССР Конституциясен төзү мәсьәләсен дә ТатЦИК Президиумының утырышлары (1925—1926 еллар) нәкъ шул чорда карый.

«Кызыл Татарстан» газетасы 1925 елда Татарстан АССР төзелүнең биш еллыгы уңаеннан үз укучыларына махсус сан тәкъдим иткән. Андагы язмалар «Яшәсен Татарстан җөмһүриятенең бишьеллыгы» дигән баш астында тупланып бирелгәннәр. Сәхифәдә ТатЦИК председателе Ш. Ш. Шәймәрдәнов «Алтынчы ел бусагасында» дигән мәкалә белән катнаша. Ул болай дип яза: «Татарстан җөмһүриятендәге хезмәт иясе халыклар үзләренең яңа тормышларын инде биш елдан бирле төзеп килләләр... Авыл хуҗалыгы, промышленность һәм халык мәгарифе эшләре көннән-көн яхшыра...»

Татарстан партия оешмасыннан съездга Сокольников, Хатаевич, Вахитов, Габидуллин, Чанышев, Бендюков иптәшләр белән бергә делегат буларак барып, Ш. Шәймәрдәнов партиянең XIV съездыннан аеруча дулкынланып, илһам алып кайта. Эшчеләр, колхозчылар, интеллигенция вәкилләре алдында отчет биреп чыгыш ясаганда ил, республика күләмендәге үсешкә киләчәктә тагын нинди эшләргә кирәклегенә басым ясый, киң массага партия политикасын җентекләп аңлата. Ул елларда матбугат битләрендә дә аның чыгышларын еш очратырга мөмкин. Аның 1927 елның октябрендә Татарстан хатын-кызлары съездында сөйләгән докладының эчтәлеге кыскача «Кызыл Татарстан» газетасының 8 октябрь санында басылган. Анда хатын-кызларның тормыш-көнкүрешен, эш шартларын яхшырту проблемалары турында җитди сүз алып барыла, хатын-кызлар арасында наданлыкны бетерү өчен җәелдерелгән көрәш киң чагылдырыла, хатын-кызлардан милли кадрлар хәзерләү мәсьәләсе шулай ук игътибар үзәгендә була. «1916 елда Татарстан җирендә авыл мәктәпләренең саны 1200, шулар эченнән татар мәктәпләренең саны 35 булган булса, хәзер 2 меңнән артык мәктәп бар, шуларның 1017 се татар мәктәпләре», — диелә докладта.

Ш. Шәймәрдәнов ТатЦИК председателе постыннан Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы председателе итеп билгеләнә, аннары ВКП(б) Үзәк Комитетына җаваплы инструктор итеп алына. Бишенче дистәсен ваклап килгәндә партия Ш. Шәймәрдәновны Тышкы сәүдә академиясенә укырга җибәрә. «...мин академияне барлык предметлар буенча да бары тик «бик яхшы» билгеләренә генә беренче студент булып тәмамладым» — дип яза ул үзенең автобиографиясендә. Дипломын ул немец телендә «бишлегә яклый. Академияне тәмамлагач ул Совафганторг председателе итеп билгеләнә, аннан Ш. Шәймәрдәновны Тува Халык Республикасына җибәрәләр. Ике ил арасындагы сәүдә мәсьәләләрен хәл итүгә ул күп көч куя, үзара мөнәсәбәтләрне аңлата, халыклар дуслыгын ныгыту юлында чын интернационалист булып чыгышлар ясый.

Без шул елларда Тува Халык Республикасында эшләгән Шәриф Фазлетдинович Зәбиров белән очраштык. Шәриф ага 1920 елдан партия члены. Казагыстанда комсомол оешмасын төзүчеләрнең берсе. Күп тапкырлар В. И. Ленин белән очрашкан. Ул яшьләрнең Коммунистик интернационалы II, III, IV конгрессларында, РКСМның IV, V съездларында делегат булып катнаша[1]. 1927 елда ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитетында инструктор булып эшләгән. Хәзер Мәскәүдә яши, персональ пенсионер. «Мин Шәймәрдәновны Казанда эшләгән вакытта да бик яхшы белә идем,— дип сөйли Шәриф ага. — Тува Халык Республикасында инде кулга-кул тотынып эшләргә туры килде. Хезмәтенең беренче елларында ук җирле халык сөйләмен өйрәнде һәм радиодан Тува халык телендә чыгышлар да ясый иде. Искиткеч сәләтле, һәрнәрсәгә кызыксынучан, оста оештыручы буларак күңелемә кереп калган ул минем. Чем кара күзләреннән һәрвакыт ягымлылык сирпеп тора. Аның язмышы — хезмәт халкына бәхетле тормыш юлында янып-көеп йөргән меңнәр-миллионнар өчен уртак язмыш иде.

Шәйгәрдән Шәймәрдәнов Советларның I, III, IV Бөтенсоюз съездларында катнаша, III һәм IV чакырылышта СССР Үзәк Башкарма Комитетының Милләтләр Советында член була, Советларның VIII, X, XII, XIII, XIV Бөтенроссия съездларына делегат итеп сайлана. Аның якты тормышы — Коммунистлар партиясе эшенә хезмәт итү, интернациональ бердәмлек һәм халыклар дуслыгын ныгыту үрнәге.

**ШӘМСИ ХАММАТОВ,**
доцент, тарих фәннәре кандидаты.
**ГАБДЕЛБӘР РИЗВАНОВ,**
СССР Журналистлар Союзы члены.

[1] «Комсомольская правда», 1978 ел, 2 март.

Таһир Таһиров

# ГАЛИЯ

Повесть

## I

Генерал-лейтенант Хәйдәров, Берлинда эшләрен тәмамлагач, Зеелов калкулыкларыннан урап килергә булды. «Иртәгә — Мәскәүгә, — дип уйлады ул, — монда тагын кайчан булырга туры килер әле? Ярты көн буш вакытым бар — форсаттан файдаланыйм».

Хәйдәров Бөек Ватан сугышын Дүртенче Украина фронтында, танкка каршы артиллерия дивизионының батарея командиры сыйфатында, Чехословакиядә тәмамлады. Шул җәйне үк дивизионны Көнчыгыш Пруссиягә, совет оккупацион гаскәрләренең Төньяк группасына күчерделәр. Ике елдан соң егерме дүрт яшьлек дивизион командиры академиягә укырга китте. Аннары — Ерак Көнчыгышта һәм Урта Азиядә хезмәт итү, Генеральный штаб академиясендә уку һәм, менә ун ел диярлек инде, ул СССР оборона министрлыгында эшли.

Германия җиренә әлеге шул Чехословакиядән Көнчыгыш Пруссиягә марш ясаганда беренче мәртәбә аяк баскан иде. Ул чак — дәһшәтле сугыштан исән котылу шатлыгыннан туган игътибарсызлыктанмы — әллә ни зур истәлек калдырмады. Хәтерендә нибары төтен пыскып торган җимерек өемнәр һәм хурлыклы җиңелү билгесе булып ят тәрәзәләрдән җилфердәгән ак чүпрәкләр генә калган. Ул Берлинны әлеге килүендә генә яхшылап күрде. Һәм... күп нәрсә таныш булып чыкты: укылган исемнәр, киноларда күрелгән урыннар...

Берлин уртасындагы тау гына ят иде. Аңлаттылар: шундый зур шәһәрнең җимерекләрен, чүп-чарларын читкә чыгарып бетерергә әмәл дә, хәл дә булмагач, бер урынга җыеп өйгәннәр дә, өстенә туфрак түшәп, үлән чәчкәннәр, агач утырткannар икән, шулай итеп кала уртасында шәһәрнең үз кабере хасил булган.

Монда каберләр, исемле дә, исемсез дә каберләрдән торган зиратлар күп. Әйтерсең, миллионлаган кешеләрне һәлак итү хәзер чәчкәләр салу, тантаналы митинглар үткәрү урынына әверелгән матур зиратлар төзү өчен кирәк булган...

Зеелов калкулыклары да таныш икән. Дөрес, монда хәзер ватык танклар, үле гәүдәләр, ут-төтен булмаса да, Хәйдәров, академиядә Берлин операциясен җентекләп өйрәнүе буенча, аның күптәнге чын рәвешен күз алдына китерде.

Бер зиратта тукталдылар. Яшел мәйданны йөзәрләгән гранит плитәләр каплаган. Һәммәсе тәртиптә һәм пөхтә.

Гадәтенчә, Хәйдәров язуларны җентекләп укып барды. Һәм кинәт, үзен кемдер дәшеп туктаткандай, катып калды. Плитәдә: «Старшина Баязитов Б. Х. 1916—1945» дип язылган иде.

«Баязитов Б. Х.?.. Син дәштеңме? Әмин сине беләмме соң?..»

«Баязитов... Баязитов...» Булат! Әйе, шундый фамилияле, шундый исемле танышы, дусы бар иде бит. Күпләр онытылган, ә ул һаман истә икән. Аерылышканга утыз елдан артык гомер үткән, менә кайда очраштылар!

— Юк, ул түгелдер. Һәлак булганнар арасында Баязитовлар аздыр дисеңме? Ә шулай да... Әтисенең исеме ничек иде соң әле? Хәйрулла?.. Хәйрулла?.. Түгел. Ул чакта картлар белән сирәк аралашкангамы, хәтердә сакланмаган. Ә «Х»гә башлануы хак. Тукта, тукта! Булатны бит «действительныйда» хезмәт иткәндә «Булат Харитоныч» дип йөрткәннәр... Үзе сөйләгән иде. Заһир да аңа еш кына, шаяртып, «Харитоныч» дип дәшә иде. Менә сиңа «Харитоныч!» «Булат Хәйретдинович!» «Б.Х.»

Баязитов — шул Булатмы, түгелме? Белешергә кирәк. Ничәмә еллар буе дусларыңны искә алмау, аларның язмышы белән кызыксынмау — оят та, аяныч та. Моны акларлык сәбәп тә юк. Мине — читтән вакытлыча гына килгән бер малайны — үз иткәннәр, хөрмәтләп озатканнар, чакырып калганнар иде. Ә мин?..

Тагын кемнәр һәлак булды икән? Ә бит нинди канатлы уйлар, кояшлы хисләр белән яши иде алар!

... Икенче көнне, рәсми хушлашулардан соң, «ТУ-154» лайнеры Берлин — Мәскәү маршруты буенча болытлар өстендәге сихри киңлектә юл алгач, Заһир уйлары белән 1940 елга, көтмәгәндә ерак дуслар җирендә хәтеренә төшкән, кайдадыр, Башкортстан таулары арасында урнашкан, бик азларга таныш булган Ленага кайтып китте.

## 2

Лена — шул исемдәге үзән буена бер рәт булып утырган кырыклап йортлы авыл. Тәрәзәләр барысы да каршыдагы таулар тезмәсенә карый. Ә абзар артындагы бәрәңге бакчалары калкулыкка барып терәлә, аннан — каен урманы башлана. Ул дуга булып әйләнә дә тау урманына тоташа.

Авыл очында гына башланган инеш, үз агышында вак-вак чишмәләрне җыеп, түбән очта шактый зурая. Ул монда, урманга җиткәч, авылдан аерыласы килмәгәндәй, агымын сүлпәнләндереп бераз боргалана да, туры юл табып, якындагы чуваш авылына — Ягурга таба юнәлә.

Елга, тауга сыенып, зирек, балан, шомырт агачлары арасыннан ага. Яр буена мунчалар тезелеп киткән. Җәен елга тулы каз-үрдәк йөзә, бала-чага уйный, ә кышын ул тирән кар астында кала. Һәр йорттан су юлы, мунча юлы итеп сукмаклар керәләр.

Лена — яшь авыл. Аның халкы монда егерменче елларда җиде чакрым ераклыктагы Зуравылдан күчеп утырган. Исемен кайчандыр Се-

бердә алтын прискаларында эшләп, соңыннан шунда партизан булып йөргән авыл Советы председателе Хәмит-рәис куштырган. Тора-бара бөтен үзәнне шул исем белән атап йөртә башлаганнар.

Авыл уртасындагы калкулыкта — кечкенә мәктәп. Кичләрен ул клуб хезмәтен үти.

Лена бәләкәй булса да, бала-чага күп биредә. Мәктәптә дүрт класс, аларны берьюлы Гайшә апа укыта. Халыкка иң ошаганы — балаларны ул тәртипле тота: кирәк икән — колагын бора, аеруча шукларына көн дә чиратлап дежурныйлар шомартып алып килгән таяк та эләгә.

Авылда сәгать-фәлән юк, вакытны кояш та әтәчләр генә белдерә. Мәктәптә дәресләр, Гайшәнең җаена карап, я иртә таңнан, я төш җиткәч башлана. Тәнәфескә ул: «Апа, җитәр инде, бигрәк арыдык, әзрәк уйнап алыйк», — дип балалар ялынып-ялваргач кына чыгара.

Кырыгынчы елның көзендә икенче укытучы килде. Бу — яңа уңҗидесе тулып узган, кара керфекләре астыннан зәңгәр күзләре белән көлемсерәп караган озын буйлы, какча егетне Бишкаен больницасына әрдәнә илтә барган Садрый абзый буш чанасына утыртып кайтты. Тәүге кичне үзендә куна калдырды, ә икенче көнне ат абзарында каравылчылар йортында сөйләп утырган имеш:

— Ерактан, Бәләбәй аръягыннан. Бик башлы малайга охшаган: бер пот чамасы китап күтәреп килгән. Шуларның барын да укып чыктым, ди. Гармунчы икән. Озынтауны төшкәндә сыздырып җибәрде әй, өздерә генә! Алла сакласын, гөнаһлы булырсың! Шулай да үзе ничава, ачык егет күренә...

— Бала-чаганы аздырмаса ярый инде, — диешкәннәр картраклар. Ә яшьләр шатланган.

— Лена чокырына ямь керә икән, Хәлим киткәннән бирле авылда мәет чыккандай.

Хәлим — үткән яз армиягә киткән гармунчы егет. Аның әнисе — Чечекәй карчык (халык ни өчендер шулай атаган, чын исемен белүче дә юк, бугай), гармунын сандыкка бикләгән дә беркемнән уйнатмый. Хәер, уйнаучылары да юк. Яшьләр озын кичләрне аулакта үткәрә, я, бик күңелсез булыйн китсә, Ягурга бара. Чуваш кызлары белән балалайкага биеп кайталар да, үз авыл кызларын көнләштереп, мактанып йөриләр: «пер син генә тимәгән, пес Ягурда Упруча пелән пиегән!»

Яңа укытучы иртән, мәктәпкә кереп Гайшә белән танышкач, алар икәүләп, колхоз канцеляриясенә килделәр. Председатель Галәветдин кулларын җәеп каршылады:

— Әйдәгез, иптәшләр, әйдәгез! Түрдән узып утырыгыз! Ни йомыш?

— Мин, Галәветдин абзый, безгә укытучы җибәргәннәр. Исеме — Заһир, белеме бар — миңне егар, дигәндәй. Кая, брат, дукамитларыңны күрсәт әле!

Заһир, җиңел пальтосын ычкындырып, пинжәк кесәсеннән кәгазьләр чыгарды.

— Менә — роно приказы, болары — училищедан.

Галәветдин кәгазьләрне җентекләп укып чыкты. Аннары, Заһирга сынаулы карап, шактый озак дәшми утырганнан соң сорап куйды:

— Бәләбәйдән дисең алайса?

— Әйе, педагогия училищесыннан. Безне соңгы курстан практикага җибәрделәр.

— Практикага гынамыни?

— Практика дип, уку елы беткәнче эшләячәкмен. Беренче, өченче класслар укуны майда тәмамлый, аннан соң мин госэкзаменга китәм.

— Хуш. Бик шәп. Комсомолмы?

— Әйе, өч ел стажым бар.

— Шәп, шәп! Хәлим киткәннән бирле бездә комсомоллар башлыгы да юк әле. Эти-әниең кем?

Заһир җавап бирми торды. Аннан боек кына:

— Әти-әнием юк. Детдомда үстем, — диде.

— Алай икән. Бик шәп!.. — Галәветдин, бу сүзләрнең ялгыш ычкынганын сизеп, тамак кырып алды, аннары рәсми тонга күчте: — «Безнең «Марс» колхозы районда яхшылар рәтендә дияргә була. Обстановка нормальный. Политик хәл — тужы. Но, иллә-мәгәр, үзегезгә мәгълүм, тынычланырга ярамый. Алда зур бурычлар тора. Конкритно гына әйткәндә, Гайшә туташ белән без кулга кул тотынып эшлибез. Ә хәзер безнең көчләр артыр. Яшьләр белән эшне яхшыртырга кирәк. Бузатюрлар бар, брат, бузатюрлар!

Гайшә аны бүлдерде:

— Галәветдин абзый, Заһир иптәшне фатирга урнаштырасы иде бит. Билгеле, бу — авыл Советы эше, ләкин колхоз ярдәменнән башка...

— Әйе, фатирсыз булмас. — Галәветдин, түшәмгә карап бераз уйланып утыргач, Заһирга: — Чечекәй дигән бер карчык бар, улы армиядә, өе зур, бер үзе тора, — диде. — Шунда урнаштырырбыз. Ашау-эчү якларын үзең сөйләшерсең. Колхоздан да кой-чава биргәләрбез.

— Рәхмәт. Ә ул әби риза булырмы соң?

— Мин әйткәч булыр. — Галәветдин ишеккә борылды: — Мәчтүрә! Мәчтүрә, дим, кер әле.

Бүлмәгә урта яшьләрдәге хатын керде.

— Бар әле, йөгертеп кенә Чечекәй карчыкны алып кил.

— Галәветдин абзый, кирәкми, алай килешеп бетмәс, — диде Гайшә. — Заһир иптәшне үзем алып барып сөйләшермен.

— Һым... Әйдә ату, үзең алып бар. Түльке мин кушты диген.

Галәветдин Заһирга кул сузды.

— Давай, брат, эшкә кереш! Алдан әйтеп куям: правление утырышларына йөрү мәҗбүри. Ну, пока!

— Хушыгыз.

Урамга чыккач, Заһир:

— Колхоз председателе болай әйбәт кешегә охшаган. Шулаймы? — диде.

— Шулай... Күрерсез әле.

Заһир, кепкасын басыбрак киеп, пальто якасын күтәрде.

— Ноябрь башында шулай салкын булыр икән!.. — Туктап, Гайшәнең күзенә карады: — Әй куркам, Гайшә апа. Ул балалар белән ничек эшләрмен?! Инде ничә төн йоклаганым юк. Котым очып тора. Булдыра алмам кебек...

— Куйчы әле. Егет башың белән!..

Ул Лена авылында төгәл бер ел эшләргә тиеш иде.

3

Берлиннан кайтып ашыгыч эшләрдән бушангач, Хәйдәров үзенең ярдәмчесе полковник Белоусовны чакырды:

— Андрюша, сиңа үтенечем бар. Берлин янында туганнар каберлегендә бер исем күрдем: старшина Баязитов Б. Х. Шул кеше турында белешмәләр табасы иде.

Полковник язып алды.

— Ә тулы исеме, атасының исеме юкмы?

— Юк. Инициаллары гына. Туган, үлгән еллары да бар.

— Эшләрбез, иптәш генерал. Бу бик тиз кирәкме?

— Ашыгыч түгел, шулай да...

Атна-ун көн дигәндә Белоусов, үзе тапканга үзе гаҗәпләнеп, Хәйдәровка документлар тапшырды.

— Менә, Заһир Закирович, монда шактый сәер хәлләр ачылды. Беренче документ: теге зиратта старшина Баязитов Булат Хәйретдинович күмелгән. Ул 1916 елда туган, 1945 елның 26 апрелендә һәлак булган.

Хәйдәров, урыныннан торып, белешмәне алды да җентекләп укып чыкты. Полковник икенче кәгазьне сузды:

— Фронт хәрби советының реляциясе: КВ танкы механик йөртүче старшина Баязитов Булат Хәйретдинович Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителгән.— Басым ясап өстәде: — Үлгәннән соң.

Генерал документны алды. Әйе, Баязитов Булат Хәйретдинович, туган елы 1916, Кызыл Армия сафына 1941 елның 24 июнендә Башкортстанның Бишкаен район хәрби комиссариаты тарафыннан алынган. Әйе, аны сугыш башланганның өченче көнендә үк озаткан идек. Бишкаенда, район культура йорты каршында митингта, бричка өстенә менеп речь тә сөйләде... Хәрәкәттәге армиядә 1941 елның 12 июленнән. Яралануларын саналып киткән: бер, ике, өч... Берлин операциясендә геройлык күрсәткән: бер көндә фашистларның батареядән артык тупларын таптап җимергән, ике йөзләп дошманны үтергән, янган танкы белән «Фердинанд»ка таран ясаганда һәлак булган.

— Да-а. Бу минем дус егет иде, Андрюша. Димәк, шул. Сугышның соңгы көннәрендә үлгән бичара.

— Иптәш генерал, монда нидер буталган. Менә карагыз әле, — полковник тагын бер кәгазь бирде. Белешмә: 1956 елның 9 маенда Баязитов Булат Хәйретдиновичка Советлар Союзы Герое исеме бирү турындагы грамота, Ленин ордены һәм Алтын Йолдыз медале тапшырылган.

— Ничек алай?!

— Шул шул. Җирле властьлар белән элемтәгә кердек. Менә Бишкаен хәрби комиссариатының хәбәре: «Советлар Союзы Герое Баязитов Булат Хәйретдинович «Марс» колхозында комбайнчы».

— Да-да... Бу ни хикмәт?

Шул көннән соң Булат язмышы Хәйдәровның күңелен биләп, аны яшьлегенә чакырган, кайчандыр кичергән хисләрне кабатларга, яңартырга өндәгән көчкә әйләнде. «Нишләп мин шул гомер Ленага бармадым, дусларымны кайтып күрергә вакыт тапмадым?!» — Ул үкенеп, үзен битәрләп озак йөрде. Һәм, шул якларны барып күрмичә тынычлана алмаячагына төшенеп, Ленага китәргә булды.

Июнь башлары иде. Атнакич Башкортстан хәрби комиссариатына шалтыратты: үзе белән таныштырды һәм иртәгә Уфага киләчәген белдерде.

— Рәхим итегез, — диде комиссар шатланып. — Үзем каршы алырмын.

— Тик мәшәкать булмаса гына! Мин шәхси йомыш белән барам.

Икенче көнне кич Уфа аэропортында Хәйдәров, самолеттан чыгу белән, трап янында кара «Волга» һәм урта яшьләрдәге таза гәүдәле генерал-майорны күреп, аны хәрби комиссар көткәнен аңлады. Өстенә соры костюм, коңгырт күн куртка кигән, озын какча буйлы, чикәләренә чал кергән, кулына «дипломат» — чемодан тотып траптан йөгерә-атлый төшкән кеше дә, үзен каршылаучының танымаячагын белеп, шул генерал каршына килде.

— Исәнмесез, Иван Петрович! Хәйдәров, — дип, аңа елмаеп кул бирде.

— Иптәш генерал!.. Заһир Закирович!.. Гафу итегез, танымадым да...

Унларча километрларга сузылган шәһәр аша үтеп, читтә, юкә урманында урнашкан коттеджга килделәр. Әллә юлда бераз арыганмы, мондагы салкынча һава исерткеч саф тоелды — Хәйдәровның башы әйләнеп киткәндәй булды.

— Яратам шушы вакытны! — ул, күкрәген киереп, рәхәтләнеп тирән

сулыш алды. — Хәзер сабантуйлар башлана бит инде?

— Әйе, сабантуйлар чоры. Табигатьнең иң гүзәл чагы.

Коттеджга кереп юынгач, ашамлык-эчемлек мул әзерләнгән өстәл артына утырдылар.

— Да-а,— Хәйдәров тышта башлаган сүзен дәвам итте.— Хәзер ничектер, әмма без яшь чакта сабантуйлар ифрат күңелле була иде. Күп еллар инде күргәнем юк, ә онытылмый.

Иван Петрович ризыкка ишарә итте:

— Рәхим итегез, Заһир Закирович. Сез үзегез дә безнең яктан түгелме соң?

— Әйе, Бәләбәйдән мин.

Официантка эчемлек салган арада бераз сүзсез утырдылар.

— Туган якларга күптәннән кайтканыгыз юкмы?

— Сугыштан соң туры килмәде.

— Озак еллар үткән икән шул. Хәзер Бәләбәйне танымассыз да. «Автонормаль» заводы үзе генә ни тора! — Иван Петрович бокал күтәрде. — Я, аш алдыннан! Сезнең исәнлеккә! Туган якларыгызга кайту уңае белән!

— Рәхмәт.

— Ашагыз. Менә аю итеннән авыз итегез, Заһир Закирович, маеннан рәхим итегез — Бәләбәй заводыныкы. «Башкорт мае» дип атала.

— Шулаймыни?! — Заһир кызыксынып икмәк кисәгенә май якты.— Тәмле, бик тәмле!.. Дөньялар үзгәрә — заманында Бәләбәй тәмәкесе белән дан тота иде...

— Хәзер заманалар башка...

Заһир җанланып китте:

— Әйе. Мин Уфаны күреп хәйран калдым. Элек, сугыш вакытында узып китүне санамаганда, монда булганым юк иде. Бу бит Европадагы күп кенә илләрнең башкаласыннан зуррак та, күркәмрәк тә. Шәһәрнең куәтле республика үзәге икәне әллә каян күренеп-сизелеп тора.

Мәҗлес дәвам итте. Заһир мактый-мактый кымыз эчте, казылыктан авыз итте. Ә инде бишбармак та килгәч, бөтенләй күңеле булды.

Аштан соң холлга чыктылар. Заһир, йомшак креслодан урын алып, төрепкә кабызды.

— Ну зурладыгыз, Иван Петрович... — Бераз уйланып утыргач, кыяр-кыймас кына итеп йомышына күчте: — Авырга алмасагыз, Сезгә бер үтенечем бар...

— Нинди? Рәхим итегез...

— Сез үзегез дә Бәләбәйне сөйләп йөрәкне җилкеттегез... Мин күптән шул якны барып күрергә хыялланам...

— Дөрес, Заһир Закирович! — Иван Петрович шатланып эләктереп алды. — Бергәләп барып кайтыйк. Хәзер үк шәһәр хәрби комиссариатына шалтыратам! — Ул якын өстәлдәге телефонга үрелде.

— Гафу итегез, Иван Петрович, — Заһир аның хәрәкәтен бүлдерде. — Рәхмәт. Ләкин мин, мөмкин булса, үзем генә бармакчы идем. Һәм Бәләбәйгә түгел, ә Бишкаен районындагы Лена авылына. — Иван Петрович, «ул авылны каян беләсез?» дигән кебек, аңа сораулы караш белән текәлде. — Анда мин сугыш алдыннан бер ел эшләп киткән идем. Инде өлкәнәйгәч тә күңел әллә нигә шунда тартыла. Ул чаклар матур төш кебек — әллә булган, әллә юк... Зәңгәр томан артында. Шул томанны ачып карыйсы килә. Сагындырды. Ностальгия дигәннәре шул буладыр инде.

Үзенә караганда яшь ягыннан да, дәрәҗә ягыннан да шактый өлкән кешенең йөрәгеннән чыккан ихлас сүзләрне ишетеп, Иван Петрович моңсу гына:

— Гафу итегез, — диде, — Үзегез генә барыгыз, Заһир Закирович. Бәлки, вертолетта очарсыз?

— Мәшәкать булмаса?..

— Хәл иттек.

— Рәхмәт.

Шулай да хәрби комиссарның Хәйдәровны ялгыз җибәрәсе килми иде.

— Бәлки, озатып барырга офицер билгеләргәдер?

— Кирәкми. Мөмкин булса, иртәрәк очасы иде.

— Әйтик, сәгать тугызда?

— Сигездә...

— Булды!

Иван Петровичны озаткач, Заһир озак уйланып утырды. Торып, пинжәген салып креслога ташлады да, пианино янына килде. Саклык белән генә капкачын ачты, гадәттәгечә, көйләнешне сынады һәм, утырып, тынып калды. Кинәт кулларын күтәрде, клавишларга йомшак кына сугып, аккорд алды. Холлда инде күптән уйналынмаган көй агыла башлады. Дәртле дә, моңлы да иде бу көй.

...Иртәгесен аэропортта вертолет командиры, республика хәрби комиссары алдына килеп доклад башлаган иде, ул, аны туктатып, Хәйдәровка күрсәтте:

— Генерал-лейтенантка докладывать итегез.

Заһир докладны көтмичә, кул биреп күреште.

— Әзерсезме?

— Так точно, иптәш генерал!

— Бик яхшы, — Заһир комиссарга борылды: — Рәхмәт, Иван Петрович. Кичкә кадәр!

— Хәерле юл.

Вертолет кабинасында икенче пилот каршы алды, урын күрсәтте:

— Рәхим итегез. Монда утырыгыз, карап барырга уңайлырак булыр.

Командир кереп баскычны күтәрде, ишекне япты да, икенче пилотка кузгалырга команда бирде.

Машина, салмак кына күтәрелеп, көньяк-көнбатышка юнәлеш алды. Аста — таныш манзара: Дим суы, Юмат... Әнә тимер юл күренеп калды — ул аннан 1941 елның салкын буранлы декабрендә Төньяк-Көнбатыш фронтка маршевый рота белән киткән иде.

4

Булат язмышы Хәйдәровның Ленага омтылуын көчәйткәннән-көчәйтә барган бер сәбәп кенә булды.

Заһир — инде ничәмә еллар — кешеләргә түгел, хәтта үзенә дә ачырга кыймаган моңлы сер саклый, күңеле түрендә кадерләп, кайчандыр аңа язмышы бүләк иткән аяз сагыш йөртә. Бу моңлы сер, аяз сагыш әзмәвердәй ирләрне бөгелеп-төшеп елар чакларда юаткан, башлар әйләнерлек уңышлар мәлендә аяк астындагы каты җирне тоярга мәҗбүр иткән гадәти дә, илаһи да бер кыз иде. Ул Заһир күңелендә ил буйлап бергә йөрде, әллә күпме кыен хезмәт урыннарын алыштырды, соңрак зур штабларда эшләде, чит илләргә барды, үзе һаман, сугышның беренче көзендәге сыман, яшь тә, мөлаем дә булып калды. Аның исемен телгә алмаганга күп еллар узса да, ул яши, һәр эшенә кысылып, киңәшләр бирә, бәхәсләшә, саран гына мактый, усал итеп шелтәли. Онытасы иде, дип, җитешсезлекләрен эзләгән, хәтта ачынып тиргәгән чаклары булды Заһирның, ә ул кыз һаман әзәрлекле һәм җиңә килде. Ничә еллар инде менә шул моңлы сер, балку сагыш югалмый да, табылмый да.

... Кичәгедәй хәтердә: Ленага килеп эшли башлавына атна-ун көн үткәч, кичен укучыларның дәфтәрләрен шактый озак тикшереп утырды да, кулына гармунын алды.

Чыбык-чабык күтәргән Чечекәй әби ишектән сөйләнә-сөйләнә керде:

— Әй, балакаем, шул кадәр моңлы итеп уйнатасың! Бөтенләй Хәлимем өйдә чактагыдай булып китте. — Ул утынын мич алдына ташлап, учакка бер-ике чыбык өстәде һәм өстәл янына килеп утырды. — Уйнат, улым, уйнат. Ятим бала моңлы була, диләр, дөрес икән. Бу борынгы көйләрне каян беләсең соң?

Заһир уйнавын туктатмыйча гына җавап бирде:

— Яшьтән үк этидән өйрәнгән идем. Радио биргән концертлардан да отып алдым.

— Шулайдыр инде. Хәлимемне озата баргач, Бишкаенда бер знакумга чәйгә кергән идек. Аларның да шул радио дигән нәмәстәкәйләре барые. Әй җырлады инде, мескен, әй җырлады! Елап күзкәйләрем калмады.

Әби бераз дәшми, уйлары белән әллә кайларга китеп, тыңлап утырды. Нуры тоныклана башлаган күзләреннән агып төшкән ятим яшьләрен яулык очы белән әледән-әле сөртеп алды.

Заһир озын көйдән җиңелерәгенә, аннары дәртле бию көенә күчеп, кинәт уйнавыннан туктады.

— Әй, маладис, улым! Елатасың да, юатасың да, бәхеткәйләрең генә булсын инде, ходаем! — Әби балаларча мышкылдатып борынын тартып куйды, авыр йөгеннән бушагандай терт басып, җитез атлап мич алдына юнәлде. — Хәзер аш ашарбыз, бүген бик тәмле билдәмә пешердем әле.

Аштан соң Заһир, бераз йөреп керәм дип, урамга чыкты.

Ноябрь урталары яңа узган булса да, аяк астындагы кар кышкыча шыгырдый. Заһир тәмәке төреп кабызды да, бераз уйланып торгач, түбән таба, колхоз идарәсе ягына юнәлде. Озак та бармады, ат караучы Галимҗан очрады.

— Саумы, Галимҗан!

— Нихәл, Заһир. Кая китеп барыш?

— Галәветдинне күрмәкче идем. Ә син конный дворгамы?

— Әйе. Атларны эчереп, төнгелеккә печән саласы бар. — Галимҗан Заһирдан тәмәке сорап, кәгазен дә алып, озак итеп төрде, аннары, уты да синнән булсын инде дип, аның төпчегеннән кабызды һәм исе китмәгәндәй генә әйтә куйды.— Ә Галәветдин кайтып җитмәгәндер әле — атын китерүче булмады. Бишкаенга киткән иде. Так што, малай, юлың уңмады.

— Уңмады дип, минем әллә ни йомыш та юк. Ат сорап, Чишмәгә барып кайтмакчы идем. Анда да яңа укытучы килгән, ди.

— Әй, шул гынамы? Әйдә, үзем алып барам! Уеннарын да карарбыз — бүген шимбә ич! Мужыт, аулак булыр, Чишмәдә кызлар!.. — Ул сүз тапмады — телен шартлатты, — бер кашык су белән йотарлык! Түлке гармуныңны ал!

— Килешсә...

— Килешмәгән кая! Мин тиз генә эшне бетерәм дә, ат җигеп киләм. Атның да әле ниндиен — председательнең үзенә эләкми торганын... Сыздырып, клубларына барып керербез! Түлке гармуныңны онытма!.. Булдымы?

— Булды.

Галимҗан югары очка — ат абзары ягына очты.

## 5

Авылда яшьләр күп булып та, гармунчылары юклыктанмы, Заһирны бик тиз үз иттеләр. Килүенә ике-өч көннән соң ук аның янына егетләр

кереп йөри башлады. Чечекәй әби дә аларны куанып, «Хәлимем бар чактагы кебек» дип, якты йөз белән каршы алды, тик өендә тәмәке тарту кир. кмәсен өзеп әйтте. Хәер, егетләр үзләрен тәртипле тота — дөнья хәлләрен сорашалар, газета-журнал укыйлар, китап актаралар һәм үзләре дә авыл яңалыкларын — аның бүгенгесеннән, үткәненнән кызыклы хәлләр сөйләп, гәпләшеп утыралар. Заһирның рәсемгә дә осталыгын белеп алгач, бер-бер артлы сурәт ясаталар, кәгазьдә көн дә көрешкән иптәшләрен танып, шаккатып көлешәләр. Мондый кичләр гадәттә бергә урам буйлап җырлашып, сызгырышып авылны әйләнү белән тәмамлана башлады.

Әле Галимҗан, «Чишмәдә, мужыт, аулак булыр» дигәч, Заһир үзенең беренче мәртәбә аулакка барганын хәтерләде.

Бер кичне шулай урамда җырлашып йөргәндә, әле күптән түгел генә Кызыл Армиядән кайтып, Бишкаен МТСында эшли башлаган Булат очрады. Хәл-әхвәл сорашкач, ул тәкъдим кертте:

— Әйдәгез, егетләр, аулакка барабыз!

— Ә кемдә бүген аулак?

— Миңзифа сездерде. Әти-әнисе кунакка киткән. Аларда кызлар җыелыша.

— Булды! Киттек, малайлар.

Аларны озак кертми тордылар.

Башта йортның тәрәзә төбенә килделәр, пыялага чирттеләр. Җавап бирүче булмады — хәтта өй эчендәге ут та тоныкланып калды.

— Ничава, — диде Булат, Заһирга күз кысып. — Ялындырыр өчен юри генә кыланган була алар. Тарт гармуныңны! — Заһир, гармунын бөтен хутына тартырга чамалап, пышкыртып сузган иде, тыйды: — Син ялындырып тарт — йөрәкләрен өзәр-өзмәс кенә. Аңладыңмы? — Булат тәрәзәгә авызын терәп диярдәй, әкрен генә җыр башлады:

Утларыңны, утларыңны,
Утларыңны сүндермә.
Утларыңны сүндерсәң дә,
Мич артына йөгермә.

Өй эчендә бераз тын тордылар. Түзмәделәр — шундый ук тавыш белән җавап ишетелде:

Тәмәкеңне, тәмәкеңне,
Тәмәкеңне көйрәтмә.
Кайтып әнкәеңне өйрәт,
Безне килеп өйрәтмә!

Эчтән кызларның канәгать көлүе ишетелде.

— Тәрәзә яулап алынды, егетләр, хәзер ишекне штурмлыйбыз. Алга! — диде Булат һәм беренче булып киртә аша сикерде дә ихата эченә төште, ишек алдына килеп басты. Тагын гармун, тагын җыр:

Көләсеме, үләсеме —
Ишегендә келәсе.
Ишекләрендә келәсе,
Әллә ватып керәсе?!

Егетләр, Булатка кушылып, җырны да җырлады, ул кыланганча, ишеккә колакларын куеп кызларның җавабын да көткән булды. Ә җавап әзер икән — кемнеңдер:

Көлгән чакта үлмәгез,
Үлгән чакта көлмәгез, —

дип башлап җибәрүе булды, башкалар дәррәү элеп алды:

Көлер өчен генә булса,
Келә ватып кермәгез.

Егетләрнең ялвару сүзләре китте:

— Көләр өчен генә түгел, кызлар, ачыгыз инде! Яраткан өчен! Валлаһи-билләһи!

Ниһаять, келә күтәрелде, егетләр алга омтылды, кызлар аларны шаулашып, чыр-чу килеп каршылады.

Ярым караңгы өйгә керү белән кемдер тәртмә сүзгә күчте:

— Сагындыгызмыни, кызлар?! Килеп житү булмады — ачтыгыз да!

— Әйе, түзәр хәлләре калмаган, малай!

Кызларның да җавабы әзер:

— Шулай булмый ни! Үзегез сәгатьләр буе «ачыгыз» дип авыз суларыгызны киптереп тордыгыз түгелме?!

Булат, шлемын салып, мич алдына өелгән кызлар ягына атлады:

— Кем тавыш бирә анда? Күрсәт әле нурлы йөзеңне!

Кызлар, чыркылдашып, артка чигенде.

— Кит, кит, якын килмә! — Миңзифа киң гәүдәсе белән аларны каплады. — Берегез дә түргә үтмәгез. Әнә, ишек төбе сезгә. Тик кенә утырмасагыз — кудым чыгардым булыр!

Егетләр — кем чишенеп, кем туннан, кем бишмәттән — төрле җирдән урын алды. Булат сәке кырына утырып кесәсеннән янчык чыгаруга, аңа алты-җиде кул сузылды. Ул ашыкмый гына тәмәкесен төреп кабызды һәм гаҗәпләнгәндәй сүз башлады:

— Ай-һай, Минзифа, күз тимәсен үзеңә! Бигрәк көр кышлыйсың!

Барысы да дәррәү көлеп алды.

— Ит бар, малай...

— Күлмәгенә ничек сыя, бичаракай...

— Мулла абзый биясеннән бер дә ким түгел.

Миңзифа егетләр ягына атылды.

— Кем әйтте әле моны? Синме, Зөфәр? — Сәкегә кырын ятып, сөйләшү аңа бер дә кагылмагандай тәмәке пыскыта башлаган яшь кенә егет янына килде ул.

— Синме, синме? — Минзифа шаяру катыш ачу белән аның чикәләрен суккалап алды. Зөфәр, коты очкандай, сәкенең түренә үк шуышты:

— Мин түгел! Әнә, Сәбахың әйтте ич!

Көлешү көчәеп китте. Аны басарга теләгәндәй, Миңзифа кинәт көчле тавыш белән җыр башлады. Почмакта, бозау янында, бүкәнгә урнашып алган Заһир, аулак тәртипләрен белмәсә дә, җырга гармуны белән иярде.

Булсагыз, булмасагыз да
Янмый эчкәйләребез.
Сезнең ише йолкышларга
Китми искәйләребез!

Заһир кинәт уйнавын туктатты:

— Юк инде, мондый сүзләргә уйный алмыйм.

— Әй, кызлар, эре чирттерәсез! — Булат торып шинелен салды да ишек янагындагы кадакка элде, гимнастеркасын сыйпаштырып яңадан сәке йөзлегенә килеп утырды. Аның түшендә «Ворошиловча атучы» значогы ялтырады. — Егетләр, җавап бирәсе иде бит, ә?!

— Эш бездән тормас! — Энесе Зөфәр нечкә тавыш белән:

Сез дә әллә кем түгел...—

дип, җавап җыры башлаган иде, кызлар ягы аны бүлдерде:

Без дә әллә кем түгел.
Әллә кемнәр булмасак та
Сезкәйләрдән ким түгел.

— Да-а, — Булат ясалма күрсенгән булды. — Хәзерге кызларга җавап табуы да җиңел түгел.

Миңзифа Заһирга карап елмайды:

— Әйдә, тарт корьәнеңне, бер юньләп җырлашыйк ичмасам.

Заһир җиңел генә авыл көен башлады. Аңа Сәбах:

Без урамнан үткән чакта
Ачулана агайлар, —

дип кушылуы булды, дәррәү күтәреп алдылар:

Ачуланмагыз, агайлар,
Сездә дә үсә малайлар!

Кызлар ягыннан җырны уртасыннан башлаган нечкә, ягымлы тавыш ишетелде:

Ятсам йокым килми лә...

— Эх, мескенең... — Зөфәр аны көлкегә алмакчы иде, кызлар ирек бирмәде:

Ятсам йокым килер иде
Гомер ике килми лә.

— Эх, кызлар, әйт шуны! — Булат азрак карлыккан тавыш белән башта сузып, аннары тизләткәннән тизләтеп икенче көйгә такмаклап китте:

— Ә-ә-әйт шуны ешырак,
Кыш эрәхәт чанага.
Көн дә шулай булыр идек,
Туры килми чамага.

Сәке түреннән энесе Зөфәр кушылды:

Көндә аулак булыр иде —
Туры килми чамага.

— Миңзифаның эти-әнисен көн дә кунакка чакырмыйлар, диюем инде, агай.

— Шулай шул. Капкан саен калҗа булмый ул. — Миңзифа казан артыннан, алъяпкыч итәге белән кулларын сөртә-сөртә, алга чыкты. — Хәзер өйрә пешә, урын әзерләгез, табын корабыз.

— Ә «кетмәдек» дигән булдыгыз, үзегез аш та әзерләп торгансыз икән.

Булат Заһирга карады:

— Аш алдыннан әзрәк селкенеп алу хилаф булмас. Әйдә, дус, уйна бию көен.

Заһир, аккорд итеп «Шахта» көеннән өзек уйнады да, кинәт «Әпипәгә» күчте. Идән уртасына Зөфәр сикереп төште:

— Әхмә! — Ул сары тунын салып ыргытты һәм шакмаклы күлмәк итәген чалбарына тыга-тыга тыпырдап китте:

Итек кимәгән, димә,
Читек кимәгән, димә,
Чабатага бозлар катса,—
Итек тавышы килә!

Ашъяулык җәеп йөргән Миңзифа да түзмәде, йөзеп кенә уртага чыкты. Зөфәр аның тирәсендә чүгеп бии башлады. Егетләрдән кемдер такмак әйтте:

Иске лә шырпы кабы,
Яңа ла шырпы кабы,
Матур бии, матур бии,
Биесен әле тагы!

Аны бүлдереп икенчесе кабатлады:

Юньләп атлап йөри белми,
Биегән була тагы!

— Кем? Минме? — Миңзифа, кинәт туктап, күзләре белән егетне эзләде. — Син әйттеңме? Ә, әләктеңме! — Ул Сәбахны, колагыннан тотып, уртага чыгарды. — Әйдә, үзең бие, алайса! — дип казаны кырына китте.

— Бию дәвам итте. Заһир көй артыннан көй алыштырды. Аерым-аерым биюдән соң парлап, аннары уртага чакырып биеделәр. Өйдә тузан купты. Ниһаять, биючеләрнең арыганлыкларын күреп, Заһир җиңел генә җыр көенә күчте. Инде аш әзерләп беткән Миңзифа аңа кушылды:

— Безнеке асылмалы...

— Асылмалы? — аны гаҗәпләнгән тавыш белән Зөфәр бүлдерде.— Сезнекеме?

Пыр тузып көлештеләр.

— Кит, нәрсәгә борасың? — Миңзифа үпкәләгән булды.— Беләсең килсә... Лампы турында ул.

Сезнең лампалар өстәлдә,
Безнеке асылмалы.
Ике күреп бер сөйләштем —
Йөрәгем басылмады. Вәт!

— Ә-ә-ә, алай икән. Мин тагы, ни... «асылмалы» дигәч...

— Ярый, телеңә салынма! Минем белән алышырга танау астың кибеп җитмәгән, туң аяк! Я, утырышыгыз! Үзебез генә сыйланырбыз дигән идем, килдегез бит, әрәм тамаклар.

Уен-көлке белән табынны уратып алдылар: кем түргә менеп сузылды, кем идәнгә тезләнде.

— Эх, егетләр, белгән булсак, ачысын да тапкан булыр идек тә бит...

— Ачысы ни, эчендә инде, Миңзифаның күгәргән мае бер дә ачыган балдан ким булмас.

— Ярай, ярай, лыгырдамый гына эч, Сарыбай корсагына сары май, дигәндәй...

— Егетләр! — нәрсәдер исенә төшереп, аны Зөфәр бүлдерде. — Ишеттегезме, Мөслим бабай карчыгын районда «лыгырдамай эч» белән сыйлап кайткан?

— Белмисезмени? Сөйлим, алайса.

— Я, я.

— Үткән базардан соң Мөслим бабай карчыгын ысталавайга алып кергән. Ул «суфыйны» беләсез бит — туры килгәндә бераз хәмер җибәрергә ярата. Кереп утыралар болар, аш алалар. Мәфтуха карчык, чучка ите юкмы дип бутап караса, «лабаравай лис» яфрагы килеп чыккан. «Нәмәстәкәй бу, әллә себерке яфрагы инде?» — ди икән карчык. Ә Мөслим карт үзе дә белми, үтеп барган әфисиаңнан сорый: «Шту такой трава?» Әфисиан ни: «Лабаравай лис», — ди дә китеп бара. «Нәмәкәй диде ул?» — ди Мәфтуха карчык. «Лыгырдамай эч» дип әйтте, — ди Мөслим.

— Ха-ха-ха!

— Менә син үзең дә лыгырдамай гына эч, — диде Миңзифа.

Бер тын сөйләшми генә зур табактан аш ашадылар. Беренче булып кашыгын ялап ашъяулыкка Булат куйды.

— Рәхмәт, кызлар, сыегыз бик тәмле булды. — Кесәсеннән янчык чыгарып тәмәке төрә-төрә хәтергә алды. — Да-а. Мин армиягә киткәндә Мөслим абзый стансага илтеп куйды. Юл буе өйрәтеп барды бу мине: командирларыңа каршы сүз әйтмә, белгәнеңне укынып йөр, паегыңны күршеләреңнән сакла, хатын-кызга күз салма... Өч елга түгел, ун еллык үгет-нәсихәт бирде.

— Бәй, ул каян белә — әрмис булганмы ни?

— Мөслим суфыймы? Шул да әрмис булып «айт-два» уйнаса...

Булат, тәмәкесен кабызып суырды да:

— Булган, ник булмасын? — диде. — Унсигезенче елны алар Самарда трудармиядә чабата ясап ятканнар. Тиф дигән чир белән кайткан.

— Самарский әрмис инде. Әби бәлеш пешергән самарский кишердән... — Зөфәр такмаклап алды.

— Ә Әхмәтҗан абзый неместә пләндә булган, — дип кушылды Галимҗан. — Немец маржалары белән типтердек, ди.

Зөфәр кул селтәде:

— Типтергән, типтерми ни! Бер кулакта сыер карап яткан.

Яшьләр акрынлап яңадан урыннарына утырышты. Кызлар кул эшләрен алды. Миңзифа табынны җыеп савыт-саба юа башлады.

Көтмәгәндә Гөлзаһира сүз кушты:

— Ә нигә аны «Бәләкәйдән зур булдым» дип йөртәләр?

— Кемне, Әхмәтҗан абзыйнымы?

— Әйе.

— Шуны да белмисеңмени? — Зөфәр аңа гаҗәпләнеп карады.— Ул бит җиңгисен алган.

Булат җитдиләнеп аңлатты:

— Әйе. Герман пленыннан кайтып төшсә, өлкән абзыйсы Мөхәммәтсафа югалган, ата-анасы ачлыктан үлгән, кече туганнары җиңгиләре кулында калган. Нишләсен, тоткан да җиңгисенә өйләнгән. Элегрәк ул, эчеп алса, елый-елый җырлый иде:

Бәләкәйдән зур булдым,
Җиңгине алып хур булдым.

— Ә нигә «хур булдым»?

— Кем белә инде аны. Бәлки, хур кызына хуҗа булдым димәкчедер.

Кайберәүләр көлешеп куйды.

— Һәркемнең бер җыры була инде ул, — диде Галимҗан. — Булат, син армиядә чакта монда бер хәл булып алды бит әле. Мөслим бабай күршесе Талип картның яшь хатыны Фәхрия җиңгине кәрмәштерә башлаган...

— Тәк-тәк-тәк...

— Талип карт эшне сизеп ала. Ләкин ул бит юаш, тормышы да шәптән түгел, ә Мөслим бабайның — хуҗалыгы да ныклы, үзе дә үт кебек. Ничек үч алырга? Күп уйлап йөргән бу. «Сәгать» бәйрәмендә бер табынга эләгәләр болар. Кызып алгач, Талип карт Мөслим бабайга, шундый җыр җырлап тустаган биргән:

Өй түбәсендә — күгәрчен,
Маңаенда бүрке бар.
Мөслимгә биргән мөлкәтне
Талипка бирсә дә ирке бар!

— Алланың мыни инде

— Әйе, соңыннан үзе дә: «Әһем, әһем, тәүбә» дип өстәп куйган.

— Ха-ха-ха!
Аулак сүлпәнләнгәнен күреп, Заһир гармунын алды.
— Әйдә, тарт, Заһир, күреген! — Галимҗан аның кырыена басты һәм сагыш белән җыр башлады:

Тимерләр лә күперләр селкенә
Кавалирлар үткәндә, шул!
Үпкә сүзләре онытыла
Каршы ла килеп үпкәндә!

— Әйе! — җырга Булат кушылып, куәтләп җибәрде.

Сәбах башлады:

Җил аздыра да, җил туздыра
Олы юлның тузанын, шул!..

Күмәкләп күтәреп алдылар:

...Белми лә калдым, сизми калдым
Яшь гомремнең узганын.

— Эх, туганнар, сезнең яшь гомер әле яңа башлана, — диде Булат. — Моңаймагыз, күңеллерәкне җырлагыз.
— Аның ни, күңеллесе шулай була инде! — Зөфәр такмак башлады:

Аксак-туксак, суксак ексак,
Бездә дә бар туратлар.
Уфада юк, Мәскәүдә юк
Безнең нише дураклар!

Ләкин шаяруны дәвам итүче булмады. Яңадан урам көенә күчтеләр дә озак кына җырлашып утырдылар.
Аулак Заһирда каршылыклы тәэсир калдырды. Ничектер кыргыйрак кебек күренсә дә, яшьләрнең җырга-моңга һәвәслеге йөрәккә якын иде. Әгәр аларны оештырсаң, зур эшләр башкарып була.
Берничә пар аулакта куна калды. Монысын аңлавы аңа бөтенләй кыен иде: ничек инде өйләнешмәс борын кунарга мөмкин? Соңыннан Галимҗан төшендереп бирде:
— Исең китмәсен, Заһир. Чишенми-нитми төне буе ләчтит сатып бер-береңә якын килергә базмыйча ятасың да, иртәгесен мактанып йөргән буласың.
... Заһир, аулаклар турында, аларны бетерү өчен клуб эшен яхшыртырга кирәклеге хакында уйлый-уйлый, Чишмә укытучысы белән киңәшләшергә дип дәрес планнарын, программаларын җыеп кесәсенә салды, күлмәген алмаштырып галстук такты һәм, гармунын күтәреп, урамга чыкты.
Ул арада, артлы чанага айгыр җигеп, Галимҗан килеп җитте. Хуш исле коры печән өстенә менеп утырдылар да киттеләр.

## 6

Чишмәгә турыдан гына да барып була, ә Галимҗан урап, Ягурга тиеп китәргә булды:
— Таныш кызларның йөрәкләрен яндырыйк бер, уйнат, малай, — ул дилбегә какты, — Әйдә, малкай! — Гармунга кушылды:

...Уйлый микән, сагына микән
Бергә булган чакларны...

Гармун тавышына ат та дәртләнеп китте шикелле: муенын бөгеп, башын югары күтәреп, пошкыра-пошкыра җилдерә. Ягурны үткәч, Галимҗан аны җиңел юыртуга күчерде. Тәмәке кабыздылар.
Кичкә шактый салкынайтса да, кар йомшак әле, чана тимерләгән табаны белән ишетелер-ишетелмәс сызгырып шуа. Бер эз итеп ярылган

юл үзән буйлап, чишмә яры куаклары арасыннан үтә. Уйдым-уйдым аланнарда яңа калкып килгән ай яктысыннан кар бөртекләре төрле төскә кереп җемелдиләр.

— Хәзер барып җитәбез — өч-дүрт чакрымлык юл. — Галимҗан аңлатып барды: — Чишмә дә безнең авыл зурлык кына башкорт авылы. Тик шунысы бар — Чишмәдә кызлар күп. Өй саен кыз, малай, берсеннән берсе чибәр. Зато бездә егетләргә муллык. Ачлык елдан соң хатыннар малай таба ди бит: күбесе егерме өченче, егерме дүртенчеләр — «алабута елыннан» соң туганнар. Чишмәдә дә бар, кәнишне, ну бездә — күбрәк! На! — Галимҗан атны кызулады. — Кыш суык булыр, ахры, иртә чеметә. — Ул пальто якасын күтәрде, тезләрен итәге белән япты.— На, малкай!

Бераз дәшми баргач:

— Әйдә, уйнат, Заһир, җитәбез, — диде.

Чишмә — Лена үзәне буйлап бер урам булып ике яклап сузылган. Салам түбәләр астыннан тәрәзәләр урам аша бер-берсенә караганнар. Авыл уртасыннан артка, калкуга тыкрык үтә — анда клуб, аннары колхоз келәтләре тезелеп киткән.

Атны чаптырып, клуб алдында килеп туктадылар.

Баскычта көлешә-көлешә тәмәке тарткан өч-дүрт егет аларны каршы алды. Заһир, гармунын күтәреп, Галимҗанга иярде.

— Ә-ә, Галимҗан кода, саумы! — Ике авыл күптән кыз алышып — кыз бирешеп яши, монда бары да, танышмы-түгелме, «кода» икәнен Заһир белә иде инде. Галимҗан үзен бик иркен тотты:

— Саумысыз, егетләр! Менә кунакка, кыз күзләргә килдек.

— Бик әйбәт. Кунак килсә сый килер, дигәннәр. Кызлары да булыр.

— Таныш булыгыз — Заһир, безнең яңа укытучы.

— Бик шәп. Рәхим итегез.

Кемдер атны клуб артына җитәкләп китте. Заһирны алга үткәреп, клубка керделәр.

Ул — шактый зур, озын йорт. Ишектән кергәч тә, уң якта — сәхнә, анда эреле-ваклы бала-чага менеп утырган. Тамашачылар залында стена буйлап куелган эскәмияләрдә төрле яшьтәге халык. Болар кергәндә мандолина уйный, ә бер пар уртада әйләнеп бии иде. Кунаклар керү белән музыка өзелде, бию тукталды. Каршы алып, олылап, урын бушаттылар. Заһир белән Галимҗан утыргач, кемдер:

— Гармунчы килгән! — дип белдерде. Шатлык авазлары ишетелде.

— Леналар гармунсыз йөрмәс!

— Уйнавын сорыйбыз!

— Әйдә, Заһир, уйна, малай, — дип пышылдады Галимҗан, — аларның гармунчылары юк.

Заһир гармун күрекләрен тартып җибәрде. Башта ул үзенең яраткан аккордын — берьюлы төрле көйне хәтерләткән музыкаль фразасын алды да кинәт алар кергәндә мандолинада уйналган «Карабай» көен башлады.

— Әйт шуны! — дип куйды бер дәртлесе.

Уртага нечкә озын буйлы, гаҗәеп мөлаем кыз очынып чыкты. Ул, башын кырын салыбрак күтәреп, куе кара кашлары астыннан көлемсерәде, бер мәл тирә-ягына карап торды да биеп китте.

Галимҗан үз кырында утырган кода тиешле егеттән:

— Кем бу, бер дә күргән-ниткән кешем түгел?..— дип сорады.

— Безнең Галия апа, укытучы.

— «Апа»! Моның «апалыклары» күренә генә башлаган әле. — Галимҗан төшенә инде — укытучы булганга «апа» диделәр. — Ару бу!

— Ару гына дисең, яру инде, яру! — Бу егет үзенчә: «Килмәгән җире юк, ләкин сиңа түгел», — дияргә теләде бугай. Галимҗан да, аны шулай аңлап, «Булдыра алсаң, бәхетеңне сынап кара», дигән мәгънәдә Заһирга төртте:

— Укытучылары шул!

Заһир дәшмәде. Аның карашы — биючедә, бармаклары күз иярмәс тизлек белән гармун телләре буйлап йөгерә иде.

Кыз, җилпенеп, соңгы мәртәбә түгәрәк ясады да, Заһир алдына килеп басты. Гөр килеп алкышладылар.

Кыз Заһирга кулын сузды:

— Таныш булыйк, Галия. Рәхмәт һезгә, шундый җиңел уйнайһыгыз!

Заһир гармунын идәнгә куйды һәм урыныннан торып күреште.

— Заһир. Җиңел биисез — уйнавы да җиңел.

Ул арада кемдер үтенде:

— Галия апа, бер җырла инде!

— Әйе, әйе. Җырласын әле, бигрәк матур җырлый, — диештеләр, кул чабулар ишетелде.

Үтенечкә Заһир да кушылды:

— Җырлагыз, сорыйлар ич. Рөхсәт булса, мин аккомпонировать итәм. Нәрсә җырлыйсыз?

Галия бер мәл уйланып торды һәм:

— «Сандугач»ны, — диде.

— Гаҗәп матур җыр, сез башлагыз, ә мин кушылырмын.

Заһир башкорт халык көенә кушылырга әзерләнгәндә Галия җыр башлады:

> — Җир җиләге ачы була, ачы була,
> Үз вакытында, үз вакытында пешмәсә, шул...

Бу әле тарала гына башлаган яңа җыр иде. Заһир аны радиодан тыңлап Салих Сәйдәшевнең Кәрим Тинчурин сүзләренә «Ил» мелодрамасы өчен язган музыкасы икәнен белсә дә, үзе уйнаганы булмады. Ул бармаклары белән гармун телләрен эзләде һәм Галия кушымтага җиткәндә генә кирәкле тонны тапты.

Кечкенә клубны тутырып чынлап та сандугач сайравын хәтерләткән җыр яңгырады:

> Сандугач, карлыгач,
> Күңелемне ач син бүген.

«Юкка гына сайламаган икән бу җырны — үзе һич тә сандугачтан ким түгел!»

Заһир, җырның сүзләренә бөтенләй игътибар итми, моңына чумып, аның нинди югарылыкларга күтәрелəсен зирәк күңеле белән сизеп, ләззәтләнеп иярде.

> Ак каенның җиләс, салкын күләгәсе
> Бүген безне күрештерсен, сөендерсен...

Тагын чын-чыннан сайрау:

> Сандугач, кошчыгым,
> Күңелемне ач син бүген!

...Җыр туктагач, шактый ара тып-тын булып торды. Аннары алкышлар, мактау сүзләре яңгырады:

— Һай, маладис!

— Әй, Галия апасы!

— Әйт шуны!

— Сандугачың бер читтә торсын!

Галиянең тагын җырлавын сорадылар. Ләкин ул җырламады. Бер Заһир белән Галимҗанга, бер тирә-яктагы халыкка елмаеп карап:

— Алай килешеп бетмәс, иптәшләр, — диде. — Кунак егетләрнең дә көчтәнәчен тәмләп карыйк.

— Вәт дөрес! Шулай!

— Кунак ашы — кара-каршы, дигәндәй...

Галимҗан сикереп торды:

— Әйдә, Заһир, күрсәт, малай, һөнәреңне, җырчы укытучылар бер Чишмәдә генә димәсеннәр! — Ул Заһирның тавышы шактый матур икәнен һәм җыр яратканын белә иде инде.

Заһир җырламады. Әле генә кичергән исерткеч тәэсирдән бармаклар гармун телләрен ихтыярсыз барлады. Моңа кадәр үзенә дә таныш булмаган моң агыла башлады. Ул кемгәдер нидер аңлатырга, бер үк вакытта үзе дә нидер аңларга тели, өзелеп чакырган кешесен ниһаять табуга шашынып шатлана да, нидәндер куркып, шикләнеп сызлана, үксеп елый кебек тә иде. Егет күңеленә буйсынып, кулындагы гармуны шашты, моңайды. Кеше үз гомерендә бер моң калдырырга тиеш булса, Заһир шушы минутта үзенең гомерлек моңын тудыра иде...

Уйнап туктагач, ул урыныннан торып гармунын куйды да гаҗәпләнеп аңа карап торган Галиягә елмайды:

— Гафу итегез... — Ник шулай дигәнен үзе дә аңламады.

Зал күкрәүне хәтерләткән көчле алкышларга күмелде.

Алар клубта тагын хәтсез вакыт булдылар. Заһир биетте дә, җырлатты да. Кайтырга бергә чыктылар. Галия кунакларны чәйгә чакырды.

Галимҗан, укытучыларны чана төбенә утыртып, үзе кузлага менеп кунаклады.

— Киттек, кая барабыз?

— Мин Җәмилә апаларда торам, — диде Галия.

— Шулаймыни!? Беләм мин аларның йортын. Әй, малкай! — Галимҗан ярып сызгырды. Алар, урамда төркем-төркем таралышкан яшьләрне узып, Җәмиләләргә килделәр.

Кереп чишенгәч, Галия: «утырышыгыз, егетләр» дип, чәй куйды. Аннары почмакта, уку әсбаплары, дәфтәрләр өеме белән тулы өстәл янында биек сандык өстенә утырып, үзе турында сөйләп алды.

Чишмәдә башлангыч мәктәп икән. Укытучылары армиягә алынгач, балалар бер ай чамасы укымаган. Монда Дәүләкән педучилищесының өченче курсы укучысы Галия Сәләхованы җибәргәннәр. Ул да, нәкъ Заһир кебек, уку беткәч, училищены тәмамлау имтиханнарына барырга тиеш.

— Башта үземне кая куярга белмәдем: ят җир, бер танышым юк. Беренче дәрескә бару алдыннан төне буе елап чыктым. — Галия күкрәгенә төшкән озын кара толымнарын бер үрә, бер сүтә көлә-көлә сөйләде. — Ярый әле, Җәмилә апа бар — мине ул үз әнкәем кебек үгетләде, юатты. Бүген менә күршеләргә кич утырырга китте... Башта балалар белән дә кыен булды. Ай буе укымаганнар, шаяннар. Элекке укытучы, егет кеше булгач, аларны нык тоткан. Ә мин нәрсә — бер кыз бала. Мандолинам булмаса, белмим, ни эшләр идем?! Хәзер тыңлыйлар инде. Авылда яшьләр дә күп... Җыр-бию яраталар. Ә үзем һаман күнегә алмыйм — әнкәйне, иптәш кызларымны сагынам. Көн дә шуларга хат язам. Сезгә, егетләргә, рәхәт ул, ә без сердәшне, ахирәтне тиз таба алмыйбыз.

Заһир гармунын идәнгә куеп шуның өстенә утырган да, күзләрен Галиядән алмыйча, аның көмеш тавышын гаҗәпләнеп тыңлый, һәр хәрәкәтен йотлыгып күзәтә иде.

— Әнә самовар да кайнап чыкты, хәзер чәй эчәбез.— Галия, толымнарын артка ташлап, итәген сыпырып сандыктан төште һәм табын әзерли башлады. Заһир клубта ук Галия бөтерелеп биегәндә, өздереп

жырлаганда аның зифалыгына хәйран калган иде. Хәзер, өйдә, кыз аңа тагын да матуррак, тагын да мөлаемрәк булып күренде. Ул үзенең нәкъ шушы йөзне, нәкъ шушы күзләрне, гомумән, нәкъ шушы кызны көткәнен, эзләгәнен, табачагына ышанганын аңлады. Кинәт аңа шушы кызны күрми үткәргән унҗиде ел гомере кызганыч һәм буш булып тоелды.

Заһир үз каршында елмаеп, чәй ясап утырган кызга сокланып үзе дә сизмәстән:

— Галия! — диде.

— Әү, Заһир... Заһир... Исемегез нинди матур! — Һәм, кашларын кыйгачландырып, нидер исенә төшерергә теләгәндәй: — Бая нинди көй уйнадыгыз соң? — диде.

Заһир көтелмәгән сораудан уңайсызланып китте:

— Үзем дә белмим. Моңарчы уйнаган көем түгел. Болай гына... импровизация...

— Импровизация? Ул шундый үзәккә үткеч моңлы!.. Шундый шатлыклы... Әллә ничек инде менә... Йөрәкне тетрәтә... Уйнагыз әле кабаттан!

— Әйдә, малай, тетрәт тагын кызлар йөрәген! — Мич алдына тәмәке тартырга тезләнгән Галимҗан шуны өстәп шаярды.

Заһир гармунын алып сандык өстенә утырды һәм бармаклары белән әлеге көйне эзли башлады. Тик көй чыкмады — бер күз ачып йомган арада шикелле югалды, кабатланмады.

— Гафу итегез, искә төшми.

— Кызганыч... Алайса үзегез теләгән бүтәнне уйнагыз.

...Алар кайтырга чыкканда этәчләр кычкыра иде инде. Авылны узгач та, Заһир гармунын алды. Аның күз алдында Галиянең бөтерелеп биегәндә, өздереп җырлаганда сирпелгән сихри карашлары чагылып киткәндәй булды. Ул уйнап җибәрде — теге көй!..

— Вәт көй, ичмасам! — Галимҗан шатлыгыннан кычкырып ук куйды. Аннары тынычланып өстәде: — Бая әллә юри уйнамадың инде? Дөрес! Кадерен белсеннәр.

7

...Летчик Заһирның уйларын бүлдерде:

— Иптәш генерал, без Бәләбәй өстеннән үтәбез.

— Шулаймы?

Заһир иллюминаторга капланды. Үзгәргән Бәләбәй, нык үзгәргән! Сугышка кадәрге шәһәр белән чагыштырырлык та түгел. Зурайган. Яңа йортлар. Яңа урамнар. Ә монысы базар мәйданы түгелме? Ул беренче мәртәбә Бәләбәйдә булганын хәтерләде.

...Алты-җиде яшендә, бик ялынып йөдәткәч, аны әтисе базарга алып барды. Бу як халкында шулай — көзге байлыкта Бәләбәй базарына барып кайту гадәте бар.

Кичтән шәһәр кырындагы каен урманына килеп кундылар. Әнә ул әле дә каланы Туймазы яклап уратып алган. Монда йөзәрләгән олау-базарчылар җыелган. Һәрберсенең диярлек товары ашлык, ә Заһирларныкы — ардәнә.

Иртәнге кояш белән Бәләбәйгә килделәр. Менә нинди була икән ул кала! Урам киң, әле иртә булуга карамастан, халык арлы-бирле чаба. Ә өйләр нинди зурлар — кайберләре икешәр катлы, түбәләре калайдан. Ә базар каршындагы кызыл кирпечтән салынган йорт хәтта өч катлы, тәрәзәләрен санап бетерерлек түгел. Җиде-сигез елдан соң шунда, педучилищеда укыйсың Заһир кайдан белсен әле!

Утынга хуҗа тиз табылды: калага кереп җитмәс борын ук бер әби ияртеп китте үзләрен. Олауны илтеп бушаттылар да базарга килделәр.

Авылда малайлар, олылардан ишетеп, «Гөҗләп тора, гөрләп тора

Бәләбәй базарлары» дип көйләп йөрсәләр дә, аның зурлыгы, халыкның күплеге бөтенләй хәйран калдырды. Әтисе аңа: «Арбадан төшмә, адашырсың» диде дә, үзе базар карарга китте. Заһир, тирә-ягын күзәтеп, чебеннәр белән сугышып, көне буе диярлек арбада утырды.

Хәтерендә иң нык сакланганы — үз яшьләрендәге сары чәчле, ялан-аяклы малай. Кояш багана буе күтәрелеп, көн эсселәнә башлагач, бер кулына чиләк белән су күтәреп, икенче кулына тимер кружка тотып килде ул һәм, Заһирлар арбасы янына туктап, ачы тавыш белән нидер кычкыра башлады. Аны халык сырып алды. Малай кружкасы белән су таратты, аңа акча бирделәр. Чиләге бушагач, ул яңадан тутырып килде, аннары — тагын, тагын. Заһир аның көн буе кычкырган сүзләрен дә отып алды: «Мука мукалоднай вода?»

Икенче көнне авылга кайткач ул, әлеге сары чәчле базар малаена охшатып, чиләк күтәреп, урам буйлап теге сүзләрне кычкырып йөрде. Тик авыл халкы — томана дисәң дә томана инде! — аны аңламады, су сатылмады. Ул ахырда, әрәм булмасын дип, суны туйганчы эчте дә, читән буена илтеп түкте...

Аның шәһәр белән танышлыгы шулай башланды. Соңрак сары малайның сүзләрен дә аңлады: «Кому, кому холодной воды!» дигән икән ул һәм аның шулай су сатып йөрүе һич тә шәһәрне матурлый торган күренеш тә түгел икән.

Кичен бер зур йортка килделәр. Монда да халык бер дә базардагыдан ким түгел, монда да — «гөжләп тора, гөрләп тора...» Бер почмакта табын корып җырлашып та утыралар.

Әтисе ап-ак тимер кружкаларда кайнар чәй алып килде. Сиртмәле кроватька менеп аяк бөкләп утыргач, кесәсеннән кечкенә төенчек чыгарды, иплап кенә чиште. Заһир гомерендә беренче мәртәбә тавык йомыркасы зурлыгында гына алсу алма күрде. «Алмалары-хөрмәләре кызарып пешәр әле, әле исенә төшмәсә дә, соңырак төшәр әле» дигән җырны ишеткәне булса да, үзе җырлап йөрсә дә, чын алманы аның беренче күрүе иде.

Әтисе алманы чалгы пәкесе белән иплап кенә урталай бүлде:

— Мә әле, улым, алма ашап кара, — диде горурлык белән.

Заһир гомерендә беренче мәртәбә кулына тотып авыз иткән алманың тәмен, әйтеп аңлата алмаслык исерткеч хуш исен һаман оныта алмый. Язын алмагачлар чәчкә атканда һәм, бигрәк тә, көзен алмалар пешкәндә әтисен һәм аның хыялларын исенә төшерә. Зур җиләк-җимеш бакчасы утыртырга хыяллана иде ул, карлыган, кура җиләге, шомырт агачлары утырткан да иде инде. Тик дөнья мәшәкате, авыр крестьян тормышы хыялларын төгәл тормышка ашырырга мөмкинлек бирмәде, күрәсең. Аннары — кәтмәгәндә, утызынчы ел башында әтисе, озак та үтми әнисе бер-бер артлы вафат булдылар. Заһир Бәләбәйгә балалар йортына озатылды. Әтисенең төсе булып, аның гражданнар сугышы фронтларын үткән тальян гармуны гына торып калды Заһирга. Һәм бу гармун әтисенең Бәләбәй базарында ашаткан алмасы, утыртырга хыялланган бакчасы кебек кадерле дә, истәлекле дә иде.

## 8

Вертолет Заһир җәяүләп күп тапкырлар үткән урыннар өстеннән оча. Таныш та, таныш түгел дә кебек. Нефть качалкалары күренеп кала. Асфальт юлдан машиналар чаба. Ул аларны күрә дә, күрми дә. Уйлары — яшьлектә.

... 1943 елның кышында, госпитальдән соң, аңа бер атналык отпуск бирделәр. Башка барыр урыны булмаганга, аннан да бигрәк Галия язмышын ачыкларга өметләнеп, Заһир Ленага кайтты.

Чечекәй әби аны шатланып, үз баласы кебек каршылады, кадерләп кунак итте. Авыл ярлыланган: ирләр аз, кызларның күбесе Пермь ягына торф чыгарырга киткән. Эвакуацияләнеп килгән ят кешеләр күзгә ташлана.

Күпләр Заһирны чәйгә алды. Элекке мул табыннар юк иде инде, шулай да сөйләшеп, җырлашып утырырлык сыен таптылар. Фронт хәлләрен сораштылар.

Кайтканның икенче көнендә яшьләр клубта аның хөрмәтенә «вечер»-га җыелыштылар. Ягурдан да килгәннәр иде. Элеккечә күңелле итеп, дөньяны онытып, биергә, җырларга тырыштылар, ләкин, әллә егетләр юклыктан, әллә барысы да көн-төн эштә йөреп арыганлыктан, «вечер» дигәннәре боек булды. Бары тик әйләнеп уйнаганда, Заһирны уртага чакырып, кызлардан кемнеңдер җырлавы гына бик нык хәтеренә сеңде:

Шинелкәйләрең кигәнсең,
Каешың да бу инде
Командирга охшагансың —
Командир да бул инде.

Теләге кабул булды, бугай, — ул, чыннан да, биленә каеш буып, гомерлек хәрби хезмәттә калды...

Заһир, куллары төзәлсә дә, уң аягына аксый, таяк белән йөри иде әле — кайтуының өченче көнендә чатанлый-чатанлый Чишмәгә китте.

Таякка таянган Заһирны күргән Җәмилә апа елап җибәрде һәм аны кочаклап алды:

— Әй, балакаем! Кайткан дип әйткәннәр иде шул, — чын икән! Үлеп тереледең бит, үлеп! Озын гомерле булырсың инде!

Йөгерә-йөгерә чәй әзерләде, кыстап-кыстап сыйлады. Заһир аның ире турында сорашты.

— Аллага шөкер, синең кебек раненнай булып, кайтып китте. Хәзер Уфада гына — трудавай армиядә, заводта эшли.

Икесенең күңел түрендә, тел очында гына торган сүзгә чәйдән соң күчтеләр. Җәмилә апа башлады.

— Улым ни, — диде ул кыюсыз гына, — Галияң кайда икән соң, хәбәрләшәсезме?

Бу сорауны көтеп утырса да, ишеткәч, Заһир дертләп китте.

Үткән җәй Старая Русса янында каты яралангач, ул озак кына авыр хәлдә ятты, Галиягә хат яза алмады, ә ят кул белән яздырып куркытасы килмәде. Ә инде бераз савыгып, кулына каләм тотарлык булгач, сәлам хаты җибәрде. Җавапны Җәмилә ападан алды. «Әй, балакаем! — дип язган иде ул латин хәрефләре белән. — Могҗизалар булыр икән! Синең үле хәбәрең килде бит! Галияң аны укыгач, һуштан язганчы елады-елады да, «үчен алам неместән!» дип сугышка китте. Киткәненә ничәмә ай, хаты-хәбәре юк». Заһир Галиянең адресын Дәүләткәннән, аның әнисеннән соратып алды. Ул: «Кызымның канатлары каерылды, дигән идем, исәнсең икән. Рәхмәт. Менә адресы, эзлә, улым, тап!» дип язган иде. Ләкин Галиянең үзеннән җавап булмады. Хатлар «Адресат выбыл» штампы белән кире кайтты. Дәүләткәнгә дә, менә ярты ел инде, беренче хатыннан соң хәбәр булмаган.

— Юк, апа... Сиңа да хат булмадымыни?

— Язмады шул, язмады...

— Ә мин, ни дә булса беләсеңдер дип, бик өметләнгән идем. Эзе югалды бит. Военкоматлар аша да эзләттем. Беркем белми...

Җәмилә апа өендә элек беркайчан да тәмәке тартмаган Заһир кесәсеннән янчык чыгарды.

— Тарт, улым, тарт, тартынма. — Җәмилә апа җәйпе китереп куйды. — «Без янганчы ул янсын» — дия иде абыең. — Тирән көрсенеп

Заһирга карады. — Әй, балакаем, башкайларыниләр күрә икән?

Өстәл өстендә Галиядән калган тәртип сакланган: өем-өем уку әсбаплары, дәфтәрләр. Заһир аларны озак җентекләп актарып утырды.

Менә ул үзе бүләк иткән китап: «С. Т. Аксаков. Аленький цветочек». Галия никтер аны бигрәк ярата, бөтенләен диярлек яттан белә иде. Аның дулкынланып, бер көлә, бер елый укыганын тыңлаганнан соң Заһир акварель буяулар белән, әкияттәге кызны Галиянең үзенә охшатып, кечкенә сурәт тә ясап бирде. Галия чиксез шатланды һәм аны китап эчендә тота иде. Хәзер — юк, бәлки, үзе белән алгандыр?..

«Аленький цветочек» эченнән бергә бөкләп салынган ике кәгазь килеп чыкты: Акча, берсе — Заһир турында, полк штабыннан: «Сержант Хәйдәров... хәрби антка һәм социалистик Ватанга тугры булып, батырлык күрсәтеп, 1942 елның 25 июлендә һәлак булды. Ленинград өлкәсе, Старая Русса районы, Медниково станциясеннән ике километр көньяк-көнчыгышта күмелде». Таныш имзалар: «полк командиры подполковник И. Худоногов, штаб начальнигы капитан В. Федоров».

...Ленинград өлкәсендә — Старая Русса ул чакта шул өлкәгә кергә иде — июль төннәре кыска: кояш баеп, әзгә генә эңгер-меңгер булып ала да, яктыра башлый. Инде ничәнче төн полк разведчиклары дошман тылына үтә алмый интегәләр. Җитмәсә, теңкәгә тигән яңгырлар туктады, көн утырды, айлы төннәр башланды. Ә дивизия штабыннан «тел» таләп итәләр. Бу көнне, кичтән үк боевое охранение окопларына чыгып яттылар да, караңгы төшә башлау белән алга шуыштылар. Капитан Федоров үзе озатып калды: «Давай, Захар, ни пуха, ни пера». Ләкин тагын тылга үтә алмадылар — немец бик сак хәзер, коточкыч ут ачты. Инде ни алга, ни артка. Бердәнбер юл: үзебезнекеләргә параллель юнәлештә күрше полк ягына хәрәкәт итү һәм аннары артка чигенү. Заһир, «За мной» дип, уңга шуышты. Ут астыннан чыктык дигәндә, күз алдында яшен яшьнәгәндәй мина шартлады һәм җир кайдадыр түбәнгә упты кебек. Аңына килгәндә ул санитар поездда тирбәлә иде инде. Разведчиклар ничек чыкканын, кемнәрнең исән калганын, үзенең ничек монда килеп эләккәнен Заһир озак вакыт белә дә алмады. Тик ике айдан соң гына, кулына каләм тота башлагач, полкка хат язды. Җавап килгәләгәнче, тагын бер ай чамасы вакыт үтте. Исән калган разведчиклар Федоровның да яраланып тылга җибәрелүен хәбәр иттеләр.

— Эх, Василий Федотович, Василий Федотович... Үлем хәбәрен бу тиклем тизләтмәгәндә дә ярар иде бит... Синең имзаң булмаса, Галия бәлки аңа ышанмас та иде! Ә мин синең хакта монда: «Гатаулла — парторг кебек якын дусым, өлкән иптәшем бар. Ул безне заданиегә озатып кала, каршы ала. Буш вакытларын разведчиклар белән бергә үткәрергә ярата. Мин уйнаганга кушылып җырлый», — дип язган идем. Шул кешенең имзасы куелган хәбәргә ышанмавы мөмкин булмагандыр аңа...

Икенче кәгазь Галия кулы белән бик ашыгып язылган: «Бетте... Шулай үк бары да бетте микәнни?! Кулларым яза, ә телләрем әйтә алмый: Заһирымның үлгән хәбәре — минем Кояшым сүнү хәбәре килде... Шундый зур, илаһи сөю дә саклый алмагач үзеңне?!.

Хатадыр! Хатларында «якын дусым» дип язган Федоров хәбәр итсә дә ышанмыйм! Ул «Галия каеннары» дип йөрткән сердәшләрем ышанмый! Тәнемдәге, җанымдагы һәр күзәнәгем аның төсе, сыны, моңы белән тулы. Ул һәм мин — бер дөнья идек, шул дөньямны җимергән, бәхетемнән мәхрүм иткән дошманнан үзем үч алам — фронтка китәм. Китәм! Ләкин барыбер аның үлүенә ышанмыйм!

Галия. 1942 ел, 7 август».

Азакта ачу белән өстәлгән: «Кәҗә ышансын!»

Бары да аңлашыла, тик «кәҗә ышансын»ы аңлашылмый. Галия телендә андый сүзләр булмый иде.

Китаплар астыннан кара клеенка тышлы калын дәфтәр килеп чыкты. Заһир ашыгып актара башлады: Галиянең көндәлеге:

«21 ноябрь, 1940 ел, шимбә. Уйларым, хисләрем эчләремә сыярлык түгел, — дәфтәр битләре белән уртаклашам. Минем кечкенә дөньяма зур үзгәреш керде, бугай. Әле генә кунаклар озаттым: күрше Лена авылыннан ике егет килгән иде — берсе укытучы, икенчесе аның дусты Галимжан. Укытучысы Заһир исемле. Йөрәгемне шунысы кузгатты. Шулай да була микән: клубка килеп керүләре белән коелып төштем. Кепкасын кырын салып, бөгелә-сыгыла гармун уйнаган азрак шук, азрак оялчан шул егеткә уйнавына биедем дә, жырладым да. Ә өйгә кайтып үзләренә чәй эчергәндә аңардан күзләремне ала алмадым. Оят та, рәхәт тә! Укучыларның дәфтәрләре дә каралмаган әле. Иләс-миләсләнеп, Заһирны уйлап утырам. Ул да уйлый микән? Уйласа иде!.. Эх, Галия, Галия, исәрләнмә, кызыкай! Шул яшеңнән егетләр турында уйлаганчы, эшеңне бетер дә йокларга ят.

Тыныч йокы сиңа, матур төшләр күр!»

Нинди төшләр күрде икән?..

«22 ноябрь.

Тагын килделәр! Галимжаны, йомыш тапкан булып, Заһирны янымда калдырып китте. Рәхмәт. Әтәчләр кычкырганчы сөйләшеп утырдык. Беренче дәресләребез, укучыларыбыз турында, яшьләре турында сөйләде. Гармун уйнады. Жырлатып, мине мактады. Мин дә мандолина чирттем. Теге «импровизациясен» бергәләп уйнадык. Аңа исем куштым: «Заһир көе»... Шашамдыр мин: гомеремдә икенче тапкыр гына күргән егеткә чак сарылып бармыйм. Әнкәй ни дияр? «Кызым, башыңны сакла», — дигән иде. Сакларсың монда!.. Көлдереп эчемне катырды — мене тел! Мандолинаны «калак сөяге» дип атады. Хәтта рәнжегәндәй булган идем, карасам — көлеп жибәрдем — чынлап та калак сөягенә охшаган! Түзмәдем, сорадым: «Сөйгән кызың бармы?» Кинәт житдиләнеп: «Бар» диде һәм күзләремә бик озак карап торды. Минем аның зәңгәр күзләренә карарга көчем житмәде. Ул беркемгә дә охшамаган. Сөйгән кешең шулай бер генәдер инде! Шул микәнни сөю дигәннәре? Әй, Галия, Галия, башкайларыңны сакла, кызыкай!

Иртәгә дә килер микән? Килсен иде.

Юрыйм әле: килсә — яратыр».

«23 ноябрь.

Килмәде. Кич буе көтеп утырдым, «прогулка» дигән булып урамны әйләнеп чыктым. «Килгәндер, көтәдер» дип кире йөгереп кайттым. Килмәде... Жәмилә апага көлке: «Сиңа ни булды, балам, әллә дәрт керә башладымы?» — ди. Дәрттер инде. Дәрт бар да ул...»

«24 ноябрь.

Бүген дә килмәде. Бәлки, ул килергә кыенсынадыр? Ник чакырмадым икән?.. Уф, тыныч гомеркәйләрем үтте! Озак итеп «Заһир көе»н уйнадым да, ятып түйганчы еладым. Жәмилә апа: «Ела, балам, ела, — елар чагың, еласаң рәхәт булып кала ул», — диде».

«25 ноябрь».

Бу көнне ике юл нидер язылган да, ныклап каралтылган, танырлык түгел.

«26 ноябрь.

Утырып тыныч кына, житди генә уйла әле, кызыкай! Юләрләндеңме әллә син? Бер ни дә булмады бит: килделәр дә киттеләр. Син чакырып китермәдең, йомышлары төшсә, тагын килерләр... Эш турында күбрәк уйла. Укучылар программадан шактый артта калган. Колхоз яшьләре белән дә мәшәкать башыңнан ашарлык. Буш вакытта күбрәк укырга, имтиханнарга әзерләнергә, кул эше белән шөгыльләнергә кирәк. Ә син — инде ничә көн! — иләс-миләс килеп йөрисең».

Бу көнне тагын нииндидер сүзләр, язылган да, ачу белән сызылган — хәтта кәгазь шул урында ертык. Язу шулай тәмамлана:

«Үзеңә үзең нотык укып була ла ул, ә миңа «килсә иде» дип төннәр йокламавы, һәр аяк тавышына сискәнүләр жиңел түгел. Үтте тыныч көннәрең; хисләрең йокыдан уянды... Шулай уятты да, киттемени? Килмәсә, йомыш табам да үзем барам. Русчалап әйткәндә, «или-или»! Ә болай, дәфтәр пычратып, күз жебетеп утыру — юләрлек. Башкача язмыйм. Миннән көндәлекләр алып барырлык «бөек кеше чыкмады».

Лəкин үзе тагын язган.

«27 ноябрь.

Килде! Килə алмаган гына икəн — Бишкаенда комсомол семинарында булган. Мəктəптəн, дəрестəн соң балалар белəн репетиция үткəреп, арып-талып, үземнең ялгыз башкайларымны кызганып кайтып килə идем, арттан ат белəн чабып килеп җиттелəр дə, Заһир, олаудан сикереп төшеп, кочаклап күтəреп үк алды, битлəремне, күзлəремне үбə-үбə, «Сагынып беттем сине, акыллым!» — дип əйлəндерə башлады. Аннары, кинəт җиргə төшереп, гаепле тавыш белəн «Гафу итегез», — диде. Түзмəдем, үзем кочаклап үптем дə җитəклəп урам буйлап йөгердем. Җəмилə апа судан кайтып килə икəн, аны чак кына карга төртеп аудармадык. Йөгереп өйгə кергəч тагын кочаклап күтəреп алды һəм «Яратам, яратам!» дип шашынып үпте. Мин дə: «Яратам!» дидем... Кич буена күз алдымнан җибəрмичə гармун уйнавын, семинарлары, Бишкаен турында сөйлəгəнен тыңлап утырдым. Сүзлəре истə калмаса да, күзлəре миндə калды. Ярата, ярата! Заһир киткəч, Җəмилə апа: «Кызым хəерлегə булсын, күзеңə ак-кара күренми бугай», — диде. Күренми шул, күренми! Күренмəсен дə!

Яратам, яратам, яратам!..»

Шул көннəн соң дəфтəр, тулысынча диярлек, көндəлектəн тора. Монда Заһир турында уйлар, мəктəп эшлəре, Җəмилə апа, авыл яшьлəре, колхоз хəллəре — бары да тик Галиячə эчкерсезлек белəн тезелеп киткəн.

Көндəлек нəкъ бер ел дəвам иткəн. 1941 елның 22 ноябренда Галия соңгы тапкыр язган: «Кичə Заһирым белəн очрашуыбызга ел тулды, ə бүген таң белəн аны сугышка озаттым. Дəфтəр белəн уртаклашыр серлəрем калмады. Хəзер көн дə аңа хат язачакмын. Хуш, җаным, Галияң бəхетенə исəн йөреп, сау кайт».

... Бер-берен тəүге күрүдəн бөтен йөрəклəре белəн, кинəт балкып кабынган уттай, шашып сөя башлаган, əле балалыктан яңа чыгып килгəн кыз белəн егетнең мөнəсəбəте сəер дə, сокландыргыч та иде.

Авылда хəбəр тиз тарала, сернең гомере кыска, — кичтəн туган яңалык иртəнгə я искереп кызыгын югалта, я өстəлмəлəр белəн баеп, танымаслык булып үзгəрə дə, телдəн телгə күчеп йөри, төрле фикерлəр, хəтта бəхəслəр сəбəпчесе була.

Заһир белəн Галимҗанның Чишмəгə барып таң беленгəндə генə кайтуына башта əллə ни игътибар итүче булмады. Тик, алар икенче төнне дə əтəчлəргə кадəр анда йөргəнне, ə аннары Заһирның кичлəрен Чишмəдə югала башлаганын белгəч, күп сүзлəр китте. Беренче булып, Сəҗидəлəрдə аулакта гармунчы юклыктан, ризасызлыгын Миңзифа белдерде:

— Гомер уздырып, чабата туздырып йөрилəр шунда. Үзебездə кыз беткəндер!..

— Əйе, чишмəлəр мөгезле түгелдер əле!..

— Заһирына ярый инде — укытучылары янына бара, ди. Ə Галимҗанга анда ни калган?

Авыл яшьлəре гадəттə хислəрен яшерə. Бу яктагы йола буенча үзара кунып йөрүлəр исəпкə керми — кунган да беткəн, кемнең эше бар да, катнашы бар. Əгəр Заһир белəн Галимҗан Чишмə кызлары янында булып кайтып тынса, эш шуның белəн тəмамланыр, сүзлəр дə туктар иде. Лəкин бөтенлəй булмаган хəллəр башланды: Җəмилə апаның сөйлəвенə караганда, Заһир белəн Галия озын төннəр буе серлəшеп утыралар, җырлашалар, хəтта кочаклашканнарын күргəн, тик кунмыйлар. «Сəбəп табып, күршелəргə куна киткəлəдем, ə боларга барыбер — утыруларын белəлəр, я урамда сабый балалар кебек кар бəрешеп уйныйлар, я култыклашып йөрилəр». Иң сəере аларның көндез дə, кеше алдында шулай җитəклəшеп йөрүе, колхоз идарəсенə, мəктəпкə, китапханəгə бергəлəп керүе булды.

Сүзлəр куерган мəлдə, Галиялəргə Гатаулла-парторг килеп керде. Ишекне какмый-нитми ачса, катып калды: Галия, сəкенең иң түренə менеп, почмакта мендəр кочаклап утырган, ə Заһир идəн уртасына ба-

сып, кулларын болгый-болгый нидер сөйли. Гатаулла соңгы сүзләрне генә ишетте:

Штабта телефоннар шалтырый,
Йөрәкне каплады каты куркыныч,—
Варшавага акларны куа Буденный...

Ишектән салкын һава керүгә Заһир кинәт туктап калды, ә Галия, сикереп төшеп, урындык тәкъдим итте:

— Әйдүк, Гатаулла абый, рәхим итегез.

Гатаулла, нишләргә белми аптырап бераз басып торды да, утырып папиросын чыгарды.

— Мөмкинме?

— Мөмкин, мөмкин абый.

— Мин сезне бүлдердем, бугай. Гаепләмәгез, балалар, күреп чыгыйм, дидем. Эшләрегез ничек?

— Әйбәт, абый, — хуҗа буларак Галия җавап бирде. — Балалар белән концерт әзерләргә уйлыйбыз. Менә Заһирым бик кызыклы инсценировка тапкан.

— Бик әйбәт. Ә мәктәптә эшләр ничек?

Бусы турында шактый күп сөйләштеләр. Гатаулла, карт педагог буларак, үз практикасыннан мисаллар китереп, төрле-төрле киңәшләр бирде... Аннары, сүз уңае чыгарып, «Заһир көе»н уйнатты, Галиянең җырлавын тыңлады да икесен дә мактады. Дәртләнеп китеп, «Баламишкин» көенә үзе дә җырлаган булды. Соңыннан җитдиләнеп:

— Ярый, туганкайлар, утырышыгыз әле, бер сүзем бар, — диде. — Сезнең турыда төрле сүзләр йөри, шуңа ничек карыйсыз?

— Нинди сүзләр, абый?

— Ну, ничек әйтергә... Ну, йөриләр икән, дип әйтсәк...

— Шул гынамы? «Яратышалар» димиләрме? — Галия көлеп сорады.

— Алай да диләр. Ни дисәң дә, сез укытучылар, авылда күренекле кешеләр. Сезнең авторитет — мәктәп авторитеты дигәндәй...

— Ә сез үзегез моңа ничек карыйсыз?

— Мин ни... Минем яратышу заманнарым үткән инде.

Заһир торып Галиянең кулын тотты һәм Гатаулла алдына басып:

— Без чынлап та яратышабыз, Гатаулла абый. Аны яшерер хәлебез дә, сәбәбебез дә юк.

Галия өстәде:

— Гатаулла абый, сез безне гафу итегез, ләкин бу — минем Заһирым, мин — аның Галиясе. Без икебез дә комсомоллар, безнең иң зур байлыгыбыз — мәхәббәт.

Бу кадәр ачык сөйләшүгә әзерләнмәгән Гатаулла бераз югалып калды һәм кыюсыз гына:

— Ләкин эш мәсьәләсе бар бит, — диде. — Кеше сүзе кеше үтергән, ди. Гайбәт китсә?..

— Совет властенең егерме дүртенче елында, без, совет балалары, мәхәббәтебезне яшереп яшәсәк, сезнең фронтларда ятып калган дусларыгыз истәлеген рәнҗетер идек.

Гатауллага җиңел дә, кыен да иде: хисләрне бу кадәр туп-туры белдерүгә ул күнекмәгән. Ә, уйласаң, яшерсәләр, алдашсалар яхшырак булыр иде мени? Хәзерге заман яшьләре шулдыр инде.

— Алай икән, — Гатаулла канәгатьләнеп урыныннан торды. — Мин сезгә карап сокланам, балалар. Иллә-мәгәр хисләрегезнең кадерен белегез, әрәм-шәрәм итмәгез.

— Рәхмәт, абый, — дип калдылар.

...Заһир белән Галия турындагы имеш-мимешләр тынды. Икесе дә читтән килгәнгәме, ни дисәң дә, белемнәре, бүтән яшьләрдән холыклары

белән аерылып торгангамы, аларның кылганнары табигыйга әйләнеп китте. Бу ике үсмергә карап күпләр шатлана, ничектер үзләрен дә чистарак, матуррак, шәфкатьлерәк тоя иде. Әбиләр хәтта: «Әй, шул ике баланы! Бер-бере өчен ходай үзе яраткандыр инде, Таһир белән Зөһрәмени!» — дип сөйли башладылар.

Ә кәҗә Галәветдин: «Ничек инде, понимаеш, комсорг башы белән шулай кыз артыннан чаба ул?» дип Заһир турында сүз башлагач, Гатаулла-парторг: «Аларның мәхәббәте, туганкай, дусларга — үрнәк, дошманнарга гыйбрәт булырлык. Кагылма!» — дип аның авызын томалаган.

Галия белән Заһир һәр кичне диярлек очраштылар, ә көндез ике авыл арасында хатлар йөрде — сүзләре сөйләшеп кенә бетәрлек түгел иде. Икесе дә күп укый һәм күп уйлана, төрле планнар кора иде: алда башланмаган диярлек гомер бит. Ә тормыш шундый бай — тирә-якта күпме кызык, төрле-төрле кешеләр, аларның мөнәсәбәтләре, гореф-гадәтләре, уй-фикерләре. Сабыйлардан җитлеккән кеше тәрбияләү йөкләтелгән үсмерләр өчен алар — очсыз-кырыйсыз, мавыктыргыч бер дөнья иде. Һәм шул дөньяда иң көтелмәгәне — ә бәлки иң көткәнедер! — берберсен табу, беренче күрүдән үк шуны үз язмышлары санап чын йөрәктән кабул итү булды. «Азагы ни белән бетәр, тормыш юлын киләчәктә ничек үтәрләр?» — алар өчен мондый сорау юк иде әле. Без икәү һәм бөтен җиһан, безнең мәхәббәт һәм Ил, зәңгәр төндә безнең өчен генә кабынган йолдызлар, Галия каеннарында сайраган кошлар... Беренче мәртәбә шашынып «яратам», диешкәннән соң ул сүз кабатланмады да диярлек: үзеннән үзе аңлашылмый мыни, — башкача булуын күз алдына да китерү мөмкин түгел бит! Киләчәк — ап-ачык һәм якты. Аңлашылмаганы шул гына: алар ничек әлегә кадәр бер-берсен күрмичә генә түгел, хәтта белмичә яшәгәннәр?

— Мин сине күргәч тә таныдым, — ди иде Галия. — Ә син?.

— Мин дә... Ничек итеп шулай гомереңдә күрмәгән кешене танысың инде? — һәм үзе җавап бирә иде: — Күңел күзе дигәннәре шулдыр инде...

Кичен эшләрен тәмамлагач, Заһир гармунын күтәреп түбән очка, Чишмә ягына юл тота, авылны чыгу белән үз көен уйный башлый иде. Гармун моңы, үзән буйлап яңгырап, Чишмәгә җитә һәм Галия аңа каршы килә. Юл буенда, тау астындагы куе таллыктан чишмә ага, өстәрәк — кечкенә алан. Уртасында ике бөдрә каен — озынрагы туп-туры булып күккә ашкан, ә икенчесе — аңа сыенып, чукларын салындырып утыра.

Шул каеннар янында очрашыр булдылар. Заһир аларны «Галия каеннары» дип атады.

— Икебезгә охшатам, — ди иде Галия. — Күрәсеңме, сыенып үскәне — мин, ә озынрагы — син. Алар безне аңлыйлар төсле. Сине уйлап, сине каеннарга охшатып саташам бугай инде. Кайбер көнне, кичләр җиткерә алмый, монда мин үзем генә килеп йөрим. Сине күргәндәй булам. Кызларга шулай әчендәге тышында булырга ярамыйдыр, ә мин яшермим, оялмыйм, Заһир, гафу ит мине!

Сугыш башлангач очрашулар сирәгәйде.

21 июньдә кич Бәләбәй педучилищесында тантаналы җыелыш булды. Анда Заһирларга укуны тәмамлау турында документ бирделәр. Концертта Заһир үз көен башкарды. Монда Галия булмагач, көй ничектер моңсу чыкты, шатлыклы кичәне ничектер бозгандай яңгырады кебек. Күпләр аңлап та җитмәде бугай. Заһир, тантаналы табынга да калмый, фатирга кайтып китте. Ә иртәгесен базар аша училищега барышлый мәйдан тутырып гүләп торган репродуктордан Молотов чыгышын тыңлады. Шул көнне җыелышып военкоматка бардылар: «Бүгеннән фронт-

ка җибәрегез!» Аларга: «Үз районнарыгызга, үз военкоматларыгызга кайтыгыз»,— диделәр.

Ленада, башка урыннардагы кебек үк, сугышның беренче көннәрендә халык ополчениесе отряды оештырылды. Карты-яше, таннан торып, эшкә таралышканчы, стройда йөрде, сугыш һөнәренә өйрәнде. Партия райкомына чакыртып, комсорг Заһирны отрядның комиссары итеп билгеләделәр. Тик, бер ай чамасы үтүгә, ополченецларның күбесе фронтка китте һәм отряд акрынлап таралды. Заһирны Бишкаенга бер айга Осовиахим курсына чакырып алдылар. Ә Галия Дәүләкәндә иде. Үзенең Чишмәгә август азакларында киләчәген хат белән ул хәбәр итте.

Курста занятиеләр беткәч тә, соң дип тормады, Заһир, гармунын күтәреп, җәяүләп Чишмәгә китте. Авылга ул төн уртасында гына барып җитте. Урам тып-тын. Тәрәзәләрдә ут юк. Очраган кеше дә булмады. Җәмиләләргә җитәр-җитмәс, алда тәмәке утлары күренде. Якынрак килсә, бер төркем халык утыра, ә Галия үзенә генә хас тавышы белән җитди итеп нидер сөйли. Заһир үзен көчләп туктатты да тыңлый башлады.

—... Менә шундый гаҗәп талантлы кеше, биш яшьлек чагында ук опера язган, алты яшеннән Вена, Париж, Лондон залларында концертлар биргән, унҗиде яшендә дүрт опера, унөч симфония, егермедән артык соната авторы булган композитор, бөек музыкант архиепископка хезмәткә керә...

— Ул упер, симфони, сонатлары нәрсә инде?

— Музыкаль әсәр төрләре.

— Көйләр, җырлар значит?

— Шулай дияргә дә була.

— Әй, бүлдермәле! Сөйлә, Галия апа!

— Тукта, ә «архискубы» кем инде? Берәр баймыни?

— Дин әһеле. Зур дәрәҗәле поп димме... Ул композиторны мыскыл иткән, мәсхәрәләгән. Шуңа түзә алмыйча, Моцарт туган шәһәренә кайтып китә...

... Караңгы төндә, ярты халкы кайдадыр ерак сугыш яланнарында үлем белән алышкан кечкенә башкорт авылы урамында «Фигаро туе», «Дон-Жуан», «Сихри флейта», «Реквием» исемнәрен ишетеп Заһир хәйран калды. Галиянең сөйләве бер, ә сугыш башлангач кайгылары баштан ашкан колхозчыларның, йокы калдырып, Австриянең унсигезенче гасырда яшәгән композиторы турында бирелеп тыңлаулары таң калдырды. Ул әңгәмәне өзмәде, читэнгә терәлеп, азагына кадәр, Галиясе белән горурланып, хәтта аны бераз көнләшеп, йотлыгып тыңлады.

— Менә шулай, Хәмәтдин абзый, — Галия сүзен йомгаклады. — Австриядән бер Гитлер гына чыкмаган, Германия дә гел фашистлардан гына тормый. Теләсәгез, Бетховен дигән композитор, Гейне исемле шагыйрь хакында сөйләрмен әле. Ә бүгенгә җитәр, сезгә иртүк эшкә барырга бит.

— Да-а, малай, — диде кемдер. — Шундый бөек кешеләре булган халык хәзер безнең белән сугыша.

— Халык түгел, — Галия төзәтте. — Фашистлар сугыша.

— Анысы шулай, ләкин немец—немец инде ул... Ярый, рәхмәт, Галия апа. Кайтыштык, егетләр, иртәгә бәйрәм түгел.

Бу төнге әңгәмәне Заһир кырык бишенче елның җиңүле язында, үзләренең туплары белән танкларга каршы пехота сафында сугышканда, һәр буш вакытын файдаланып, әле һаман Галиянең табылуына ышанып төрле якка хатлар язган көннәрдә, Штернберк дигән шәһәрдә исенә төшерде. Ул шәһәр Карпат тауларының үзәнендә зур җәйпе кебек уйсулыкта урнашкан: читендә кирпечтән озын һәм биек стена. Шуңа беренче булып кергән частьләрдән кемдер зур плакат эләргә өлгергән иде: «Калтыраныгыз, немецлар! Әҗәлләрегез җитте!» Кичен дивизион шта-

бында алдагы көнгә приказ игълан ителгәч, командирның политик бүлек буенча урынбасары:

— Хата сүзләр язылган анда, — диде шәһәр читендәге лозунг турында. — Немецлар түгел, фашистлар калтырансын! Солдатларга шуны аңлатыгыз.

— Бәй, барыбер түгел мени? — диде офицерлардан берәү.

— Түгел, — диде комиссар — аны дивизионда элеккечә «комиссар» дип йөртәләр иде — немец халкы фашисттан гына тормый...

... Халык таралгач, читәң кырындагы эскәмиядә нидер уйланып утырган Галия янына килеп, Заһир:

— Акыллым! — диде.

— Заһирым! — Галия аның кочагына атылды.

Өч ай чамасы очрашмый торганнан соң бу күрешү исерткеч шатлыклы да, аерылышачакларын сизгәнгә, моңсу да иде. Алар бер-берсенә тагын да якынрак, кадерлерәк һәм кирәгрәк булып очраштылар.

## 10

Төнен Чишмәдән кайтканда, сөйгәне турында бер ни дә белә алмаган Заһир «Галия каеннары» янында туктады. Һәм — иртән узганда ничек игътибар итмәгән ул! — аланда катып калды, үз күзләренә үзе ышанмады: каеннар юк, кышын да туңмаган чишмә урыны кар белән капланган.

Әллә алама төшме бу: Галия дә, каеннары да, ул су сибешеп уйнарга яраткан чишмә дә юк? Күпме генә вакыт үтте — шундый үзгәрешләр!

Кышкы салкын төндә, кара куаклар белән уратылган җансыз аланда ул үзен бөтенләй югалып калган, беркемгә дә кирәге булмаган җан иясedәй хис итте.

Бераз басып торгач, «Галия каены»ның төбен табып кардан тазартты һәм утырып тәмәке кабызды.

Кайдадыр еракта дәһшәтле сугыш бара. Менә, шушы сәгатьтә кемнәрдер, аның кебек, разведкага шуыша, атакага күтәрелә. Үлем белән алышу-якалашулары аяныч һәм хәтәр булса да, анда киеренке, бай эчтәлекле тормыш дәвам итә. Ул гына хәзер биредә, таулар арасында, кайчандыр үзенең иң бәхетле минутларын кичергән урында уйларының очына чыга алмый утыра. Түштә, шинель астында — Галиясенең сердәш дәфтәре.

«Еласаң җиңел булып китә ул». Бәлки, шулайдыр. Ләкин аның, инде ничә еллар, елаганы юк. Ичмаса, гармунның булса икән янда! Галияне күргәнгә кадәр ул бит аңа бердәнбер сердәш иде. Икесе дә юк хәзер...

Заһир үзләренең соңгы кичләрен хәтерләде.

... Яздан ук алар, ике авыл яшьләрен оештырып, «Галиябану» пьесасын сәхнәгә куярга булдылар. Башта бу турыда кем сүз күтәргәндер, тик барысы да шатланып ризалашты.

Рольләрне бүлгәндә Галиябану белән Хәлил турында баш ватасы булмады. Галимҗан хәтта: «Совет заманының Галиябануы белән Хәлиле шул безнең Галия белән Заһир инде», диде. Тик үзенә Исмәгыйль ролен тәкъдим иткәч, Заһирга өч-дүрт көн үпкәләп йөрде: «Шул икән синең дуслыгың. Колхозның старший конюхына кулак малаен бирмәсәң, әйтерсең, роль беткән... Бирегез ичмасам Бәдрине — яхшымы-яманмы, Галиябануның әтисе, ә Гөлчирә Галимәбану булыр». (Гөлчирә — Чишмә кызы, Заһир белән монда килеп йөри башлагач танышканнар иде.)

Исмәгыйль ролен Чишмә милиционеры Гаптерәй үзе сорап алды. Галия дәшмәде, икәү калгач кына Заһирга үзенең ризасызлыгын белдер-

де: «Женем сөйми шуны, болай да теңкәмә тия иде, инде сәхнәдә очрашабыз икән». Ярый ла Галимҗан коткарды: беренче репетициядә ук Гаптерәйнең Исмәгыйлен эштән чыгарып тиргәп ташлады ул: «Ну жебегәнсең, кода, атлауларыңны, сөйләшүләреңне әйтер идем! Бу сиңа Ягурда чуваш бичәләрен куркытып көмешкә эчеп йөрү түгел шул! Ярый, бирегез рольне үземә, ничек тә ерып чыгармын,— диде һәм Заһирга үпкәсе үткәнен белдереп көлде: — Тыңкыш Гаптерәй кулыннан үткәнче, Галияң өчен минем белән тартышып кара».

Ә Бәдри картны Булатка тәкъдим иттеләр. Ул Бишкаенда МТСта эшләсә дә, репетицияләргә кайтып йөрергә булды.

Заһир моңсу елмаеп искә алды: рольләрне язып, яттан өйрәнеп йөргән көннәрдә Булат кайтып төште.

— Заһир, мин, пьесаны бераз үзгәртергә булдым бит әле, малай, — диде ул. — Хәлилне шул Исмәгыйльдән үтерткәнче, тотыйк та азакта сәхнә тутырып туй ясыйк, ә? Подумаешь, ул авылны тетрәтеп тора имеш! Ә Бәдри карт үз гаебен танып кызыннан елый-елый гафу үтенсен? Мин риза. Теләсәң, хәзер уйнап күрсәтәм.

Заһир аңа пьесаның социаль юнәлешен, Булатча куйсаң, драманың бер көлке комедиягә әйләнеп китүен үзе белгәнчә аңлатты. Булат «Әйдә, бер рәхәтләнеп көлешербез ичмасам» дип, нык кына бәхәсләшсә дә, соңыннан Хәлилне үтертергә риза булды.

Май бәйрәме алдыннан генеральный репетиция ясадылар. Тик Галиягә ошамады, — эшне дәвам итәргә булдылар. Печән өсте җиткәч, сәхнә кайгысы онытылып торды. Аннары — сугыш, кайгы-хәсрәт. Булат һәм тагын берничә «артист» беренче көннәрне үк фронтка китте, аларны алыштырырга туры килде.

Спектакльне көзгә генә әзерләп җиткерделәр. Галиянең аңа күпме көч салганын, спектакльне искиткеч әһәмиятле вакыйга итеп көткәнен яхшы белгән Заһир премьераны Чишмәдә үткәрергә, Галиягә багышларга булды. Ә көнен Галия ачыклады — 21 ноябрь.

Клубтан кайтканда Заһирның беләген кысып:

— Беләсеңме, ул нинди көн? — диде ул һәм ничектер карлыккан тавыш белән үзе җавап бирде: — Безнең очрашуга нәкъ бер ел тула. Бер ел! Шулай ук ел да үтеп китте мени? Юк, бер ел гына әле! Киләчәктә саналмаган елларыбыз күп булсын!

Бу кичне клубта, сугыш башланганнан соң тәүге тапкыр, яше-карты шыгрым тулы иде — зур вакыйга бит: ике авылның яшьләре бергәләп спектакль куя! һәм нинди спектакль — тыныч чаклар истәлеге!

Заһирның күз алдыннан пәрдә ачылулар, Галиянең дулкынланып аны көтү, очрашу картиналары, су буе сәхнәләре үтте.

Тәнне эсселе-суыклы итеп, тагын шул су буе искә төште. Репетицияләр вакытында ул турыда сүз булмаса да, Галия — Галиябану Хәлилдән «Заһир көен» уйнавын үтенде. «Артистлар» аптырашта калган иде, Галимҗан коткарды — үзенең Исмәгыйльлеген онытып тәкъдимне күтәреп алды:

— Әйдә, малай, сыздыр үз көеңне!

Заһир, беренче уйнавындагыча ярсып, гармун күрекләрен сузып җибәрде, сәхнә җыр белән кушылды.

Мәңге кабатланмас илаһи минутлар!

Җыр бетәр-бетмәс залдан тавыш яңгырады:

— Сабыр итегез, иптәшләр! — Тынып калган халык арасыннан сәхнәгә Чишмә председателе менеп басты. Ул «артистлар»дан гафу үтенеп, залга эндәште:

— Ашыгыч игълан, иптәшләр. Әле генә Ленадан хәбәр иттеләр: Заһир иптәш Хәйдәровка повестка килгән. Иртәгә сәгать тугызда Бишкаенда военкоматта булырга тиеш.

Әле менә тикле бик еракта кебек тоелган сугыш, күзгә күренеп, сәх-

нәгә килеп керде. «Артистлар» да, тамашачылар да үзгәреп китте, спектакль көчәйгәннән көчәйде.

Заһир су буенда Галиябануны, Исмәгыйльдән аралап, кочагына алганда Галиянең бөтен тәне калтырый, күзләрендә яшь иде. Ә инде финалда, Исмәгыйль Хәлилне аткач, ул Заһир өстендә аунап, чын-чынлап үксеп елады. Ә залда тамашачы елый...

Спектакльдән соң халык таралгач, Галия мандолинасын шакмаклы ашъяулыкка төрә-төрә:

— Шул кадәр көтеп алган көнем иде, синең киту көненә әйләнде. Хәерле генә булсын инде, — диде. Бераз моңсу карап торганнан соң дәвам итте: — Җәмилә апа, беләсеңме, нәрсә ди? «Заһирыңны бер кич тә кундыра алмадың, яратмыйсыңдыр, яратсаң түзмәс идең», ди.

— Бәлки, чынлап та яратмыйсыңдыр?

Галия кайнар пышылдады:

— Яратуларның чиге булса, мин ул чиктән дә узганмын. Китәсең бит, җаным! Соңгы кичем, соңгы төнем сиңа булсын. Әйдә, бездә куныйк.

Ул күз яшьләренә буылды, Заһир аны кочагына алды:

— Акыллым, чибәрем минем, елама. Мин шатланып китәм. Урынсыз булса да әйтим: иң курыкканым сугышта катнаша алмау иде. Хәзер теләгемә ирештем.

— Ә мин?..

— Ә син көт мине, Галиям. Мин кайтырмын, күңелем сизә — кайтырмын. — Ул Галияне үбә-үбә юатты. — Без әле синең белән гөрләтеп туй ясарбыз, балалар үстерербез. Сиңа охшаган кечкенә кызыбыз булыр...

Җәмилә апаларга килгәч, Галия чыккан арада, Заһир үзенең үтенечен әйтте:

— Минем үз йортым-җирем дә, агай-энеләрем дә юк. Бар байлыгым — шул Галия. Ул әнисе янына кайтып китмәсә, кыенлыкларны бергә үткәрерсез инде, апа. Китмим, ди, кайтканыңны монда көтәм, ди.

— Борчылма, улым, Галия миңа үз балам кебек.

— Рәхмәт, апа.

Тыштан көлмәкчән генә кергән Галияне Җәмилә борчулы сүзләр белән каршы алды:

— Бигрәк сакланмыйсың, кызым, салкын алдыруың бар.— Аннары табынга чакырды: — Әйдә, утырышыгыз, чәй эчик бер ичмасам.— Ә чәй эчкәндә ул күп кенә яңалыклар сөйләде.

— Бүген кич кенә абыегыздан хат алдым. Калинин дигән каладан. «Туп тәгәрмәченә куеп язам, тагын сугышка керәбез», — дигән. Исәнсау гына чыксын инде, мескенкәем, — бигрәк кырыла бит халык. — Нидер хәтерләп, көлеп дәвам итте: — Түбән оч Мәликә дә хат алган әле. Ул иренә хатка кушып җыр язган булган икән. «Одеял ябынасыңмы, юрган ябынасыңмы, мамык юрганнар астында мине сагынасыңмы?» — дигән. Ә Әхмәтшасы аңа җавап җыры җибәргән: «Одеяллар да юк монда, юрганнар да юк монда, баш очымда туплар шартлый — синең кайгың юк монда» —дигән. Шул кирәк, исәрләнеп иреңне юрган белән котыртып ятма. Булыр анда мамык юрганнар! Әнә Галиәкбәр кода раненнай булып кайткан. Шул сөйләп торды: җир чокып кереп, шунда гына котыла, ди, адәм баласы. Тереләй гүргә керү белән бер, ди.

Һәркем үз уена бирелеп, бер ара сөйләшми утырдылар. Кинәт Галия Заһирга карады:

— Гармуныңны да алып китәсеңме?

— Алам. Мин бит аныз яши алмыйм.

— Ал, балам, ал, — сүзгә Җәмилә кушылды. — Эчкәйләрең пошканда бер юаныч булыр.

Галия урыныннан сикереп торып гармунны алды һәм бер мәл кочаклап утырды да, уң як капкачын ачып, нидер яза башлады.
— Нәрсә, кызым, әллә берәр дога язасыңмы? Яз, яз, балам, саклап йөрер. Мин дә үземнең картым сизмәгәндә күлмәгенә бөти тактым.
— Әйе, апа, — Галия боек елмайды, — Заһирыма дога яздым. — Ул Заһирга гармунын сузды. — Мә, укы.
Заһир сокландыргыч якын почерк белән язылган сүзләрне укыды:

Мәхәббәтем — чиксез,
Сакчы булсын
Авыр яу юлларында.

— Рәхмәт, Галиям!
Җәмилә апа аларга комачауларга теләмәде.
— Күгәрченнәр кебек гөрләшеп утырып калыгыз, балакайлар, — дип, чаршау артына йокларга кереп китте.
Галия дә, чынаякларны тиз генә җыйды да ут сүндерде, үзенең яраткан урыны — почмактагы биек сандык өстенә утырды.
— Кил, Заһирым, кочакла мине...
Аларның кайнар тыннары бергә кушылды.
...Таң атканда Галимҗан килеп чыбыркы сабы белән тәрәзә какты:
— Заһир, кайтырга вакыт!
Галия озата чыкты. Аерылыша алмый шактый тордылар. Соңгы сүзләр әле дә колакта:
— Кайт, җаным, Галияң бәхетенә кайт. Мин сине өзелеп көтәрмен.
— Кайтырмын...
...Заһир сүзендә торды — яраланып булса да кайтты, ә Галиясе — юк.
Ничек булды соң әле бу? Бәлки, немецлар чигенер юлны ябып ут ачкач, уңга түгел, ә артка гына чыгарга тырышырга кирәк булгандыр? Разведка үзебезнең полкка кайтса, мондый аңлашылмаучылык тумас, шул каһәр суккан үлем кәгазе дә язылмас, килмәс иде. Курыкмадым да бит юкса — унда чокыр бар, житез генә шунда кучсәк, котырынып ут яуса да хәтәр зонадан чыгачакбыз дип бик төпле исәпләгән идем. Буталыш хәтәр киткән, күрәсең... «Эх, шул мина гомерне дә бөтенләй өзә алмаган...»
Заһир, тешләрен шыгырдатып кысып, таягы белән карга сукты. Үз каены төбенә туры килде. «Каеннар да юк хәзер». «Каеннарыбыз булсын, кайгыларыбыз булмасын», ди иде. Менә хәзер каеннарыбыз юк, кайгыларыбыз гына калды.

## 11

Ленага ул таң беленгәндә генә кайтты.
Чечекәй әби аны битәрләп каршылады:
— И, балакаем, көтеп-өркеп арып беттем, төне буе йөргәнче, кунып кына кайтыр идең. Хәзер, ир-ат китеп беткәч, сунарчылары да юк, бүрегә-фәләнгә юлыгуың бар, — дип ул самоварга ябышты.
Заһир аны туктатты:
— Рәхмәт, әби, куйма, эчәсем килми. Әзрәк черем итеп алам да, бүген юлга чыгам. Китәргә вакыт.
— Тагын ике көнең бар түгелме соң, улым?
— Юк, әби, ялгыш санаганмын. Китәргә кирәк.
— Кайларга китәсең инде? Яңадан шул ут эченәме?
— Юк, башта мин укырга китәм. Хәрби училищега направлением бар.
— Бик әйбәт, балам. Утына өлгерерсең әле.
Чечекәй әби урын җәйде.

— Ят, ял ит. Күп-күмгәк булып өшеп беткәнсең ич. Ичмасам, ат сорыйсың булган.

— Зарар юк, әби.

— Чирләмәсәң генә ярар иде... Ни, улым, Галияңне белештеңме? — Ул Заһирның Чишмәгә нинди йомыш белән барганын белә иде.

Заһир, чишенеп, тәмәке кабызды һәм шактый ара дәшмәде. Аның җавап бирергә теләмәгәнен аңлап, Чечекәй дә тынып калды.

— Юк, әбекәем, бер ни дә белә алмадым, — бераздан уфырып Заһир үзе сүз башлады. — Җәмилә апага да язмаган. Идарәләренә, мәктәпләренә дә кереп чыктым — белүче юк.

— Әй, ходаем! — Чечекәй әби хафаланып дәвам итте: — Ниләр генә булды икән балага?

— Белмим инде, әби. Фронт бит ул...

— Шулай ук сугышка китте микәнни?

— «Китәм» дип язып калдырган.

— Мескен бала... Йомыш тапкан булып, килеп йөри, синең хатларыңны укып күрсәтә иде.

Заһир кинәт торып утырды.

— Әби, син «Галия каеннарын» белә идеңме?

— Беләм, белми ни! Кем белми инде аларны? Бер килүендә Галияне шунда тиклем озата барып, каеннар астында икәүләп озак кына сөйләшеп, кошлар сайравын тыңлап та утырган идек. Галәветдин утынга кистерде бит, оятсыз! Урманда яшәп, агач беткәндер аңа! Бүтән кешенең кулы бармасын белгәндерме, имансыз, — вакуиранный карттан трудадинь язып кистергән. Чишмәләр прсидәтеленә, тегесе килеп сүккәч: «Җир безнеке — каеннар да безнеке», дип әйткән, ди.

Заһир Галиянең «Кәҗә ышансын»ын хәтерләде. Нәрсә аңлата соң ул сүзләр?

Озак уйланып ятканнан соң ул, торып, киенә башлады.

— Йоклый алмадың инде, балам. Ярый, хәзер мич ягып, бәрәңге тәгәрәтермен.

— Мин йөреп киләм әле, әби.

— Таңнан кайда гына барырсың икән, улым?

— Әллә кая түгел, әби. Каравылчы йортына барып ат белешәм.

Заһир Галәветдин йортына карап юл тотты. Урам тыныч. Сирәк-мирәк әтәчләр кычкыра. Түбән очта шарлап капка ачылганы ишетелеп калды, кайдадыр иренеп кенә эт өрде дә, тагын тынды.

Ике ел элек, шундый тыныч төннәрнең берсендә, ул Булат белән Миңзифаларга барган иде.

— Әйдә әле, Заһир, сөйләшәсе бар. Шуның өчен МТСтан кайттым. Тик үземә генә уңайсыз, — диде Булат. — Аннары, син бит төрле тарихлар яратасың — тагын бер тарих ишетерсең.

Киттеләр. Миңзифа үзе генә иде. Булатның йөзеннән үк егетләрнең юкка гына килмәгәннәрен аңлап, үзе сүз башлады:

— Рәхим итегез, егетләр. Утырышыгыз. Ниләр кырып йөрисез, йомыш бармы әллә?

Заһир — сәкегә, Булат мич алдына урындык аударып, утырыштылар. Булат ашыкмый гына тәмәке төреп кабызды һәм бер-ике суыргач, Миңзифага карап сүз башлады:

— Йомыш дип, ничә чәйнәсәң дә бер балык башы дигәндәй, Хәмдия турында сөйләшергә иде. Син бит аның әхирәте түгелме соң?

— Хәмдия турында сөйләшәсе юк инде, Булат. Ул — ир хатыны, кеше өлеше.

— Ничек ул шул Кәҗәгә чыкты?! «Мәңге көтәрмен», дип ант иткән иде бит?

— Ант итүләре җиңел ул, Булат, антны тотулары кыен. Эх, бары да без дигәнчә генә булса! — Миңзифа тирән сулап куйды. — Шул син

эрмиягә киткән көзне Хәйрулла абзыйны өтермәгә утырттылар. Иртән бригада буйлап өйдән-өйгә эшкә әйтеп йөргән, ә төнлә алып киткәннәр. Кәҗә эше, ди, әллә нинди яла яккан. Атна-ун көннән гаиләсен колхоздан чыгарып, өй-каралтыларын тартып алдылар, бәрәңге бакчаларын кистеләр. Ул көзне трудоденьгә тигән ашлыгын да бирмәделәр.

— Ә соң халык күрмимени: Хәйрулла абзый — колхозны оештыручы бит!

— Күреп нишләсен? Соңыннан шул «Кәҗә», үзе председатель булып алгач, аңлатып маташты: рәис Хәмит абый белән икәүләп колхозны таратмакчы булганнар, ди.

Булат ачу катыш көлеп куйды:

— Хәмит абзый — колхоз таратучы! Шул колхоз өчен аңа сәнәк кададылар түгелме соң?

— Бары да электән уйланган, исем өчен генә булган, ди.

— Куй! — Булат тагы да ачулана төшеп дәште: — Син дә тузга язмаганны лыгырдап утырма.

Миңзифа үпкәләгән тавыш белән:

— «Шыр»лыгын да искә алдылар. Тәре тагып йөргәнен... — диде.

— «Тәре»! Тәремени ул! Медаль ич!

— Булса ни, патша мидалы бит!

— Бәй, патша вакытында башка нинди медаль булсын? Аны Хәйрулла абзыйга патша биргән мени? Фронтта батыр сугышканы өчен бүләк итеп биргәннәр. Оят, билләһи! — Булат, тәмәке төпчеген учакка ыргытып, сикереп торды.

Заһирга бу төнге сәер сөйләшү тормышның бөтенләй күренмәгән якларын ачты.

Булат, ишекле-түрле йөреп алды да әзрәк тынычланып, сәкегә килеп утырды.

— Шуннан Хәмдия кияүгә чыктымы?

— Хәмдияләр, инәсе, бәләкәй энеләре белән, кышны алачыкта үткәрделәр. Өйләре буш торса да, анда кертмәделәр. Шул кышны Галләнурлары, хәер сорашып йөреп, буранда туңып үлде. Еракка киткәндер дигәннәр иде, Рамазан чокырында гына яткан икән. Язын этләр чокып чыгарды.

Булат яңадан сикереп торды:

— Моның өчен судка бирергә кирәк иде! Парторг Гатаулла ни караган — алар Хәйрулла абзый белән гражданнар сугышында бергә йөргәннәр ләбаса!

— Гатаулла абзый үзе дә балтасы суга төшкәндәй йөрде, аннары кыш буе диярлек я районга чапты, я больниста ятты.

— Ә Хәмдия? — Булат Миңзифа алдына килеп басты.

— Әй, «Хәмдия» дияр шушы! Хатыны бәбәйдән үлеп, атна-ун көн үтмәде, Хәмдияне сората башлады Кәҗә. Ничәмә тапкыр миңа килеп елады ул! Инәсенә: «Кызыңны бирсәң, өегезне, каралтыларыгызны кайтарам, колхозга алам, бирмәсәң — авылдан куам», дип әйткән ди Кәҗә. Инәсенең сүзен тыңлады, риза булды — тагын ике үсмер энесе бар бит.

Булат ачынып сорады:

— Ник миңа язмадыгыз соң? Безнең комиссар андый гына эшләрдә ярдәм итәр иде.

— Язмаска кушты. «Өлешемә чыккан көмешемдер», диде. Шулай язгандыр инде. Икенче ел торалар — көн күрсәтми мескенгә. Балага узгач тукмады бит мөртәт. — Миңзифа ачу белән өстәп куйды: — Кәҗә! Шуның аркасында Хәмдия бала ташлады.

Булат тешләрен кысты, яңадан мич алдына килеп утырды да, тәмәке кабызды.

Сүзгә Заһир кушылды:

— Ә ник тора соң шуның белән?
— «Ник тора»? Ни эшләсен? Башыңны ташка бәреп булмый, туганкаем! Сарыга сабышты инде.
— Мин ул Кәҗәне! — Булат сикереп торды һәм ашыгып киенә башлады.
— Син нәрсә?! — Миңзифа аңа килеп ябышты.
— Хәзер барып шыерам!
— Шыерып нишләрсең? Булган да беткән. Узган эшкә кар яуган, ди. Хәмдиягә болай да, син кайтканнан бирле, көн юк.
— Дөнья... — диде Булат, өметсезлек белән кулын селтәп. — Безнең ротада андыйларга «темный» ясыйлар иде.
— Ул нәмәстәкәй тагын?
— Караңгы почмакта башына одеял ябалар да дөмбәслиләр...
— Дөмбәсләп карадылар инде. Үткән ел сабантуйдан кайтканда Галимҗан белән Гариф исерек Кәҗәне урманга аты белән борып керткәннәр дә кирәген биргәннәр иде. Соңыннан чак үзләре этермәнгә эләкмәде. Ярый әле, юлын табып Гатаулла абзый аралап калды.
Бераз дәшми утыргач, китәргә җыендылар.
Булат шинель кесәсеннән бер уч конфет чыгарды:
— Мә, сыйлармын дип салган идем, онытканмын. Картая башладым бугай.
— Рәхмәт, — диде Миңзифа, алъяпкыч итәген җәеп. — Картаябыз бит, әй: сиңа егерме дүрт яшь, миңа да егерме бер китте. Егетләргә нәрсә ул, ә менә миңа һаман кияү чыкмый. Син дә шул Хәмдия дип исең китте...
Булат шаярууны кабул итмәде.

## 12

Хәмдиянең үткән кыш ук үзе теләп торфка киткәнен, ә Галәветдиннең Бишкаенда бер бичәгә ияләшкәнен, авылда да ялгыз хатыннарга кул сала башлаганын Заһирга сөйләгәннәр иде инде.
«Бәлки, өендәдер әле». Заһир капка шакыды. Ихатада эт өрә башлады. Бераз көтеп торгач капканы ачып, әрсез этне таягы белән селтәнә-селтәнә, күтәрмәгә таба атлады. Өйдә ут алдылар. Чоланда аяк тавышлары ишетелде.
— Кем бар анда?
— Мин, Заһир. Керергә мөмкинме?
Бер мәл тынып торган Галәветдин шат тавыш белән:
— Ә-ә! Әйдә, брат, рәхим ит, — дип ишекне ачты. — Монда берни күренми, әйдә, минем арттан атла.
Кереп ут кабызгач күреште.
— Чишен, Заһир! Кайтканыңны ишеткән идем. Көтеп тә тордым, правлениегә кермәдең. Эреләнгәнсең, эреләнгәнсең, брат!
Заһир, таягын стенага сөяп, шинелен салып элде.
— Кергән идем — булмадың.
— Шулайдыр, шулайдыр. Эш күп, малай, көн-төн я — Бишкаен, я — станса, я — МТСка чабам. — Заһирның түшендә орден күрде: — О, герой! Орденоносец! Котлыйм, котлыйм! — дип савыт-саба кузгата башлады. — Әйдә, утыр!
— Рәхмәт. Таңнан уятканым өчен гафу ит. Миңа китәргә вакыт — ат сорамакчы идем.
— Китәргә дә мени инде? Күргән кебек тә булмады. Ә ат — пожалысты, айгыр белән стансага үзем мендереп куярмын. Фронтовик, понимаешь, орденоносец!
Галәветдин, каяндыр шешә чыгарып, стаканнарга тутырып аракы койды.

— Әйдә, тот! Без монда тоже «наркомски»сыз тормыйбыз.— Ул стаканын Заһирныкына чәкәде дә бетереп эчте, суган кабып чәйни башлады. Заһирның кулына да алмавын күреп аптырады: — Бәй, нигә тот мыйсың?

— Таң белән эчәсем килми.

— Ну, давай!

Галәветдин элеккегә караганда бераз тазарган. Ләкин, әллә кырынмаганга, әллә йокыдан әле генә торганга, нык кына картайгандай күренде. Заһир тирә-якка күз салды. Өйдә, хатын-кыз кулы тимәгәнгә, ничектер котсыз иде.

— Холостой мин хәзер... — Галәветдин сүзләрен бик исе китмәгәндәй әйтсә дә, үзе авыр сулап куйды. Тагын койды да: «Әйдә, тот», дип эчте. Аннары стаканны читкә этәрде: «Житте, норма».

Тәмәке кабыздылар.

— Ну, ничек анда, фронтта эшләр? Немецның кирәген бирәсезме?

— Төрлечә. Мин фронттан киткәнгә дә ярты ел була инде. Ул чакта күбрәк безнең бирәләр иде...

— Ничава! Сабан туенда да бер аста буласың.

— Анда сабан туе түгел шул...

Заһир үзен борчыган сорауны бирергә җаен тапмады. Галәветдиннең аны шатланып диярлек каршы алуы бераз кәефен үзгәртте. «Бергә эшләгәндә алай дуслык күрсәтми иде, хәзер үзгәргән. Сугыш моны да акылга утырттымы икәнни?»

Йөрәкне ярып әлеге сүзләр үтте:

«Кәҗә ышансын!..»

«Кәҗә». Бу тискәре, тупас кешене халык яратмый, ләкин түзә иде. Күз алдында «Галәветдин абзый», «Галәветдин туган», «Галәветдин Гайнетдинович» дип бөтерелеп торучылар да аны бөтенләй бала чактан калган кушаматы белән «Кәҗә» дип йөрткәннәрен белгәнгә, Галәветдин гомер буе кәҗә мамыгыннан бәйләгән бияләй кимәде, шарф урамады, хуҗалыгында шул малны тотмады. Ә кушамат аңа тагын да ныграк ябышты. Галәветдиннең көн-төн эш дип чапканын күргән Заһир халыкның аңа карата шулай шәфкатьсезлегенә башта аптырый иде. Ләкин Хәйрулла, Хәмдия тарихларын ишеткәч, үзе дә комсорг буларак еш аралашканнан соң аңа күңелендәге беренче хөрмәт тойгылары югалды. Ә хәзер сугышның нәрсә икәнен белмәгән шушы сау-сәламәт ирнең: «Сабан туенда да, бер өстә, бер аста буласың», — дигән сүзләреннән соң бик ачуы килде:

— Галәветдин Гайнетдинович, — диде Заһир карлыккан тавыш белән. — Чишмәдә укытучы кыз бар иде... Беләсеңдер...

Галәветдин дертләп китте.

— Теге Сәләховамы? Беләм, белми ни! Хәзер юк бугай, ул...

— Фронтта.

— Фронтта диген, ә? Немецны мандолин белән кыра микән? Ха-ха-ха!

Галәветдиннең сары сирәк тешләрен ыржайтып шулай көлүе Заһирның ачуын тагын да кабартты. Ул, урыныннан торып, Галәветдиннең күзләренә карады.

— Син аның белән күрештеңме ни?

— «Күрештеңме ни?» — мыскыллап көлде Галәветдин. — Мало што мин кем белән күрешкән дә, ул кем белән үбешкән...

— Галәветдин! — Заһир, тешен кысып, аның якасына үрелде.

— Ну-ну, утыр, этәчләнмә. — Галәветдин, күзләрен чылт-чылт йомып, елмайган булды. — Шаярганны аңламыйсың, брат!

Заһир ишекле-түрле йөри башлады һәм кинәт туктап: — «Галия каеннары» нигә кистерден? — диде.

— Во-первых, Галия каеннары түгел, колхоз каеннары алар. Во-вторых, колхозның нинди каен кисүендә кемнең ни эше бар?

— Дөрес, ләкин сезнең арада ни булды?

— Брось ты, понимаешь.. Бәйләнде!.. Сиңа кыз беткәнме? Буа буарлык хәзер алар!

Заһир, Галәветдин алдына килеп, теш арасыннан пышылдады:

— Әйт, сезнең арада ни булды?

— Кызма, брат! — Галәветдин аракы салып эчте һәм, тынычланып, сөйләп китте: — Бер ни дә булмады. Сизеп торам: сиңа язып өлгергән икән. Чипуха! Менә тыңла. Уракчылар яныннан кайтып килә идем. Агачлар арасында ак нәрсә күренде. Карасам, кемдер утыра. Атны шунда бордым. Күрәм — шул, Чишмә укытучысы. Каен төбенә утырган да бер кәгазь кисәгенә карап каткан. Мин ни, кызмача идем. Шаярып куркытмакчы булдым да, шым гына артыннан кереп, кочаклап алдым. Ачы тавыш белән чыелдап җибәрде бу! Кем белгән аның шундый назлы икәнен! — Заһир коты очкандай, күзләрен киң ачып, инде исерә башлаган Галәветдингә текәлде. Ул дәвам итте: — Ну, мин үпкән булдым. Ә ул, тыпырчынып, ычкынды. Мин ни, тагын эләктереп алдым. Шул чак бу «Заһир!» дип кычкырмасынмы! Котым очты — син бар икән дип торам.

Галәветдиннең шаркылдап көлүе буш өйне яңгыратты. — Тирә-якка карасам, кеше-фәлән күренми. Болай, шаярып кына, әйткән булдым: «Инде Заһирың череп беткәндер!» Ә моңа җитә калды: агарынып, тырнаклары белән битемә үрелә. Акылдан язганмыни! Мин ни, трандаска утыр да, тай. Әллә хатын-кыз беткән дип белә...

Заһир, рәнҗү катыш ачуыннан сүз таба алмыйча, Галәветдиннең өстенә килде:

— Син, син!..

Галәветдин мич алдына сыешып йодрыгын күтәрде:

— Син, нәрсә, брось, понимаеш. Подумаеш! Якын килмә! Күрсәтермен мин сиңа, чатан!..

Заһирның тыны кысылды, госпитальдәгечә күз аллары караңгыланып, башы әйләнеп китте. Ул сәкегә сыгылып төште. Бераз хәл алгач, әкрен генә торып таягын тапты һәм шинелен сөйрәп ишеккә атлады.

— Ну, гафу ит... Ну ялгышканмын... Әйтәм бит — кызмача идем.

Заһир Галәветдиннең соңгы сүзләрен ишетмәде, ишекне аягы белән тибеп ачты да чыгып китте.

Каршы тау артыннан кызарып-алсуланып яңа көн туа иде.

Шул көнне ул җәяүләп станциягә атлады, Ленага бүтән килгәне булмады.

## 13

Лена үзәненә җиткәч, Заһир вертолет командирына:

— Мөмкин булса, югарырак менәсе иде, — диде.

Машина салмак кына күтәрелде, офык киңәйгәннән киңәйде. Менә Лена. Ул тау астында яшел урманга уралып, ап-ак булып сузылган. Ә тегесе Ягур. Ә арада, элек пыш-пыш Чтапан көтүләрне ял иттергән зиреклек урынында, ниндидер корылмалар. Әнә — Чишмәгә юл... Еракта агарып авылы да күренә.

Галия каеннары кайда соң әле? Әһә! Менә бит тау битендә алан. Ул әле дә түм-түгәрәк. Тик анда төрле төстәге чәчәкләр булып халык кайнаша...

Хәйдәров төшәргә кушты. Вертолет, тузан күтәреп, әлеге корылмалар янына утырды.

Командир, башта үзе сикереп төшеп, баскыч ныгытты һәм Заһирга ярдәмгә кулын сузды:

— Килеп җиттек, Заһир Закирович.

Винтлар әйләнүдән туктагач тирә-як тып-тын булып калды. Күптән авылдан аерылган Заһир өчен мондагы тынлык та, саф һава да гаҗәп тоелды.

Якындагы корылмадан ике ир чыгып Ягур ягына юнәлде. Алар вертолетка әһәмият тә итмәделәр бугай, тик: «Кемнәр алар, әллә тагын геологлар килгәнме?», «Белмим, бәлки шулардыр, һаман эзләнәләр бит», дигән сүзләре генә ишетелеп калды.

— Сез, егетләр, ял итегез, мин бераз йөреп киләм.— Заһир, курткасын эчкә ыргытты һәм тирә-ягына карана-карана, Лена ягына атлады.

Көн бөркү. Күк йөзендә сирәк-мирәк ак болытлар гына күренгәли. Җилнең әсәре дә юк.

Заһир күргәннәрен үткәннәр белән чагыштырып барды. Бу урында елга боргаланып ага, ә монда кечкенә күпер була иде. Аны язгы ташу алып китә дә, ирләр өмә ясап яңадан салалар иде. Хәзер агач арасыннан туп-туры асфальт юл үтә, күпер таштан, ә елга бөтенләй бәләкәйләнеп калган. Бәлки шулай тоела гынадыр. Ә бу борылмадагы яр башында кичке уеннар була, ул төш җәй буе пләшләнеп-каралып ята иде. Хәзер уйнамыйлар күрәсең — мәйданны үлән баскан.

Авылга ул бик тиз җитте һәм туктап торды. Лена — таныш та, ят та кебек. Йортлары эрерәк, салам түбәләр күренми. Антенналар, электр чыбыклары. Хәтергә сеңеп калган ямь-яшел бәпкә үләне генә юк — урам тоташтан кап-кара. Техника заманасы.

Заһир икеләнеп торды: кайда, кемгә бара ул? Бер кемгә белдерми, көтмәгәндә күктән килеп төшү көлке түгелме? Соңгы елларда шул авылны, аның кешеләрен өзлексез уйлап, бик нечкә күңелләнеп реаль тормыштан аерылды түгелме? Аны көтеп алучы түгел, белүче булуы да шикле хәзер: аңарда бер ел укыган кешеләр калса, алар хәтерлиләрме, ә яшьтәшләреннән кемнәр исән икән? Генерал белә: үз тиңдәшләреннән сугышка киткәннәрнең йөздән нибары өчесе әйләнеп кайткан. Ә шуларның берсе дә Лена өлешенә тимәгән булса?

Картаеп барган башы белән шулай сабыйланып, яшьлек эзләрен эзләп йөрү килешеп тә бетмидер. Инде нишләргә?

Заһир беренче капка төбендәге эскәмиягә барып утырды. Урам тыныч. Тик чишмә буенда элеккечә, чыр-чу килеп, бала-чага уйнаганы гына ишетелә. Шушы йорт урынын үткәч, ул гармунын тартып җибәрә торган иде...

Әйе. Бүтән замана, бүтән кешеләр. Тик авылны уратып алган урман гына, бераз картайса да, һаман ямь-яшел, һаман матур.

Шыгырдап капка ачылды һәм аннан көянтә-чиләк күтәргән яшь кенә бер ханым күренде. Ул чакка гына тукталды һәм башын түбән иеп:

— Здравствуйте, — диде.

— Здравствуйте. — Заһир торды. — Извините, вы здешняя?

— Канишно, здешняя, откудышняя ишо? — хатын көлеп җавап бирде. Теленнән рус түгеллеген аңлап, Заһир татарчага күчте:

— Гафу итегез. Рөхсәтсез килеп утырдым.

— Рәхим итегез, эскәмия җәл түгел. Сез читтәнме әллә? «Сәгатькә» килдегезме? Кемгә? Соңлагансыз азрак.

— Нинди «Сәгать»?

— Бәй, бүген «Сәгать» бәйрәме ич! Безнекеләр «Галия тавына» уенга китте.

«Галия» исемен ишеткәч, Заһир сискәнеп куйды. Аптырап калганын сиздермәскә тырышып сорады:

— Ә сез ник бармадыгыз?

— Барган идем. «Жигули» белән кайтарып киттеләр. Кунакларым

бар — шулар кайтуга аш әзерлим. Ә сез бәйрәмгә килмәдегез мени?

— Юк... Ә «Галия тавы» дигәнегез кайда ул?

— Ерак түгел. Күп булса өч чакрым булыр. Ленадан түбәндәрәк, Чишмә авылы ягында. Тау дип йөртәләр генә инде, бер калкулык шунда. Чишмәсе дә бар. Болай матур гына урын.

— Ә ник «Галия тавы» диләр?

— Кем белә инде аны...

Заһир тынып калды. Хатынның чиләкләрен алып китәргә җыенганын күреп, тагын сорады:

— Гафу итегез, ә сез кем кызы?

— «Кем кызы», дип... Гариф исемле иде минем әтием...

— Нигә «иде?»

— Мин аны хәтерләмим дә диярлек. Сабый чагымда ук үлгән. Сугыштан каты яраланып кайткан булган.

— Алай икән...

— Ярый, абый, мин китим әле, югыйсә озакламый кайтып җитәрләр. Өйгә су кертелгән лә ул, тик чәйгә ерак коедан алабыз — аның суы тәмлерәк. Теләсәгез, көтегез, чәй эчеп китәрсез.

— Рәхмәт. Ә Галимҗан дигән кешене белмисезме?

— Галимҗан? Кайсы Галимҗан икән ул — яшеме, картымы? Ә сез теге аксак Галимҗан абыйны сорыйсыздыр әле?

— Аксак?

— Әйе, сугыштан бер аягын өздереп кайткан. Ул исән.

— Гафу итегез, юлыгызны бүлдем. Тагын бер генә сорау: авылыгызда Хәлим дигән кеше бармы?

— Гармунчы Хәлим абзыймы? Бар, югары очка таба тора. Ул да шул «Сәгать»тәдер әле, андый җирдән калмый.

— Алай икән. Тотмыйм инде сезне. Рәхмәт.

Бу чикәләре агарган, төскә-биткә әллә ни карт та күренмәгән сәер кеше хатынның игътибарын җәлеп итте. Түзмәде, сорады:

— Ә сез кем соң, абый? Күргән-ниткән кешем түгел... Үзегез безнең авылныкыларны беләсез?.. Геологмы әллә?

— Түгел...

Заһирның сөйләшергә бик теләмәвен аңлап, ул китә башлады.

— Алай икән, сау булыгыз... — Бер-ике адым атлагач, тагын кире борылды. — Чынлап, абый, кичкә безгә килегез, кунак булырсыз.

— Рәхмәт...

Заһир урам буйлап югары очка юнәлде. «Булатны сорыйсы калган, бәлки, беләдер. Да-а. Димәк, Гариф исән кайтып монда үлгән. Ә Галимҗан — аксак...»

... «Сәгать». Бүген шул көн икән. Заһирның «Сәгать» бәйрәмендә дә булганы бар иде. Кырык беренче елның май азагында, Бәләбәйгә имтиханнар тапшырырга китәр алдыннан, авылда бәйрәмгә әзерлек башлангач, аның тарихы, эчтәлеге белән кызыксынды. Комсорг Заһирны борчыганы — бәйрәм дин белән бәйләнгән булмасын. Чечекәй әбидән, тагын берничә карттан сорашып карады, ләкин юньләп аңлата алмадылар. Диннең монда катнашы юклыгы гына ачыкланды. Чечекәй әби: «Элек мулла бик каты тыя иде «Сәгать»не, ырвалютсия чыккач кына курыкмый бәйрәм итә башладылар», — диде.

Заһир юл уңаенда Бишкаенда МТСка кереп, Булаттан сорашты. Ул исә мәсьәләне тиз чиште:

— Календарьне ачып карасаң, күрерсең — бу көннең озынлыгы унҗиде сәгатьтән артык. Менә сиңа «сер». Минемчә, кеше кыргый чакта, кояшка ышанганда уйлап чыгарганнар аны. Бәйрәмнең чын исеме «Сәгать сукган көн», ягъни унҗидене сугып үткән көн. Хәзер «Сәгать» кенә дип йөртәләр. Күңелле була ул — кайтырга тырыш. Гармунчыларга анда особо почет!

Галия белән бәйләнештеләр дә алтынчы июньдә кичен Аксен станциясендә очрашып, җәяүләп Чишмәгә кайттылар. Аерылышуларына ун көнләп вакыт үткән һәм бер-берен бик сагынганнар иде. төне буе Җәмилә апалар капкасы төбендә сөйләшеп утырдылар. Киләсе уку елына үз мәктәпләренә кайту да шунда хәл ителде.

— Әнием ялгыз, Дәүләкәндә генә калырмын дигән идем, — диде Галия, — ләкин синсез яши алмыйм, Заһирым. Монда киләм, син дә Ленага кайт.

Иртәгесен яшьләр белән бергәләшеп озынтау буена киттеләр.

Гаҗәп бәйрәм булып чыкты ул. Тирә-яктан йөзәрләгән кеше җыелган. Һәркем үз һөнәрен күрсәтергә тырыша: җырлый, бии. Йола бар: шул көнне кыз күзлиләр, танышалар, ә көзен, каз өмәләре җиткәч, кавышалар икән.

Язылмаган тәртип буенча, бәйрәм тирә-якта дан тоткан иң оста гармунчының уйнавына биюдән башлана икән. Аны уртага утырталар, якягына ике кыз баса. Гармунчы уйный, ә кызлар алмашлап аның маңгай тирен сөртеп торалар.

Бу елны уеннарны башлаучы гармунчы булу Заһир өлешенә төште. Чишмәләр һәм леналар тәкъдиме белән аның кырына бер генә кыз — Галияне бастырдылар.

Шулай итеп ул көн аларның мәхәббәтен зурлау көне булып калды...



## 14

... Авыл уртасындагы калкулыкта заманында Заһир эшләгән мәктәп юк иде — монда хәзер бакча: сугыш башланыр язны балалар белән утырткан каеннар үсеп, койма булып тезелгән; ә мәктәп бинасы урынында сирень куаклары. Тирә-юньдә кошлар сайрый. Яшеллек арасында нәрсәдер агарып күренә.

Заһир кечкенә ян капканы ачып эчкә үтте. Кызыл кирпеч комы сибелгән сукмак чәчкәләр белән уратып алынган кечкенә таш мәйданга китерде. Анда ерактан агарып күренгән әлеге истәлек ташы — стела: урта өлешендә каска кигән солдат башы сурәте, очында — кызыл йолдыз. Алдында тимер плитә ята. Аңа сүзләр коелган: «Бәхетле тормыш, якты кояш өчен көрәштә һәлак булган авылдашларыбызны онытмыйк!»

Заһир һәйкәлгә озак карап торды: сугыш корбаннарын шулай ихтирам итү әйбәт. Һәйкәлләр, обелисклар, стелалар үлгәннәргә кирәкми инде, алар — тереләр өчен. Корбаннарның һәркайсы үзенең үлеме белән һәйкәл куйган, үз бурычын соңгы сулышына кадәр үтәгән. Европаның чиксез зиратларында аларның исемнәре язылган. Күз алдында тагын теге плитә пәйда булды: «Старшина Баязитов Б. Х.»...

Заһир стеланың арт ягына чыкты. Металлдан исемнәр тезелеп киткән. Санады — егерме тугыз. Кырык йортлык авылдан өч дистә кеше һәлак булган. Коточкыч! Ә барлыгы ничәү китте икән? Игътибар белән укый башлады: онытылган дуслар, танышлар: Сәбах, Зөфәр, Абдулла, Зәйнулла... «Алабута елыннан соң туганнар...»

Никтер искә бөтенләй вак, әһәмиятсез вакыйгалар да төшә. Бер кичне клубта уен вакытында Зөфәр белән Сәбах, буш арадан файдаланып, «мәзәк» күрсәттеләр. Сәбах тыпырдап биеде, ә Зөфәр, кемнеңдер шәлен ябынып, бармак шартлата-шартлата такмак әйтте:

Уфимский самаринка,
Синий трава не харашинька,
Каекадер, каекадер, каека,
Каекадер, каекадер, каека!

Бу сүзләр нәрсә аңлаткандыр инде...

Аннары Зөфәр яулыкны атып бәрде дә икәве кочаклашып «Шахта» көенә чуашча җырладылар:

Пирен хура лаша чук —
Тыпыртатса тырас чук, шул!
Пирен кунта савни чук —
Шынса-мынса чүрәс чук!

Монысын барсы да аңлады: «Безнең кара атлар юк — тыпырдатып торасы юк, безнең монда ярлар юк — өшеп-туңып йөрисе юк!» Тик читтән килгән утырма кызы гына гаҗәпләнде:

— Кара, кара, малакаем, чуашның көе дә тач безнеке икән!

Кызык булып калды. Зөфәр утырма кызына:

— Чуаш кына дисеңме, урыс та тач безнекечә җырлый. Мона тыңла әле, Бәләбәйдән үзем отып кайттым,— дип, шул ук көйгә сузып җибәрде:

По улицам ходила шул,
Балшая кракадила...

Озак көлештеләр. Утырма кыз, шаяртканны аңлагач, чак еламады. Төнен Зөфәр аңа куна кергән — ничек килешкәннәрдер, күз асты күгәреп чыккан иде...

Әй Зәйнулла дигәне күп һөнәрле, шаян кеше иде. Май бәйрәмендә Чишмәдән килен төшергәч, халыкны «Ник җыелдыгыз, әллә туймы?»— дип көлдерде.

Куаклык арасында кечкенә эскәмия ясалган. Заһир, утырып, төрепкәсен чыгарды. Ул да — сугыш истәлеге. Аларның дивизионы фашистик Германия капитуляция ясаганнан соң да бирелергә теләмәгән эсэсовчылар һәм власовчыларның зур гына төркемен бетерүдә катнашты. Камаудан чыгарга омтылган дошманның соңгы танклары белән алышканда батарея командирының башына снаряд ярчыгы тиде. Беренче взвод командирының документларын, орден-медальләрен штабка тапшырды, гаиләсенә хат язды, ә дусының яраткан төрепкәсен, төсе итеп, үзендә калдырды.

Менә шул төрепкәгә тәмәке тутырып ашыкмый гына кабызды да, каршы таулар тезмәсенә карап, уйга талды Заһир.

— Да-а. Шактый гомер узган, ә бу кешеләргә булган йөрәк җылысы суынмаган. Хәтта үзе озак кына хезмәт итеп киткән кайбер частьләр дә ул кадәр истәлек калдырмагандыр төсле. Әллә бик яшь булганга, беренче кичерешләрне үткәргәнгә шулай тоела микән?..

Урамнан җиңел машина үткәне ишетелеп калды. Заһир сәгатенә күз салды: ике тулып килә. «Вакыт тиз авыша, авылны карыйсы иде бит әле». Тагы стелага текәлде: «Хәйдәр, Мөхәммәтҗан, Ибраһим...»

Тукта, тукта, исемлектә бер рус кешесе дә бар: «Николаев Степан Михайлович». Кем соң әле ул Степан Михайлович? Ә-ә, бу бит пыс-пыс Чтапан абзый! Сугыш башланыр алдыннан гына Ленага Ягурдан күчеп килгән иде. Аны да алганнар икән, ә безгә ул нинди карт күренә иде.. Хәтер тагын үткәннәрне актарды. Бу тәбәнәк буйлы шадра кеше һәрчак диярлек кызмача йөри, тәмәке төрепкәсен төшерми иде. Шуны туктаусыз пыскытып йөргәне өчен «пыс-пыс» дип исем таксалар да, леналар аны үз итәләр, һәр йортта ачык йөз белән каршы алалар иде. Чтапан ел саен монда көтүче булып ялланды. Түләү — мал башыннан, он, бәрәңге белән, ә иртә-кич ашау чиратлап. Кыскасы, Чтапан җәй буе сыйланып йөри — шарт буенча аңа кичен аш алдыннан я бер чәкүшкә аракы, я әче бал тәкъдим ителә, мунча ягыла. Көтү кайтуга Ягурдан хатыны да килеп чираттагы өй каршында ирен көтеп ала. Тамак туйгач, Чтапан, тешләрен рәхәтләнеп казый-казый, хуҗаның малларын

озак итеп мактап утыра. Сөйләмәсә дә беләләр — ул мал ярата, аларны яхшы көтүлекләрдә йөртергә, вакытында эчерергә тырыша. Шуңа үзен дә хөрмәт итәләр.

Әй, хәтер дигәнен! Ул аның җырын да саклаган. Кәефе күтәренке мәлләрдә Чтапан көйләп җибәрә иде:

Кысыл пәрлегәнтин кысыл
Пула икән, туханнар, тун тышы.

Аннары серле итеп хуҗага текәлеп тора да өстәп куя:

Паятан пирле карап торам —
Сес кенә икән пескә кул кеше!

Кабатлаганда хатыны да кушылып икәүләп очлыйлар:

Сес кенә икән, туханнар,
Пескә кул кеше, шул!

Чтапанны бигрәк тә бала-чага ярата, «Пыс-пыс абзый» дип өтәләнеп кенә тора иде. Төшкә малларны Ягур очындагы зиреклеккә ялга алып кайткач, аның янына малай-салай уйнарга җыела. Зирек арасында сыерлар күшәп ята, шунда ук Чтапан ял итә, ә малайлар аның озын чыбыркысын шартлаталар, чиратлап төрепкәсен кабып карый. Чтапан барын да рөхсәт итә, ә бик кәефле чагында кәҗә савып сөт тә эчерә.

Чтапанның башы яртылаш пеләш — маңгаеннан колак артына кадәр кырган кебек. Бала-чага шуңа бик гаҗәпләнә:

— Пыс-пыс абзый, нишләп синең чәчең шулай?

— Әй, ана теге сукыр тавык җиңгәгез, — дип сөйли Чтапан. — Сатрыйларта мунча кергәндә пашымны пешертте. Ләүкәтән кычкырам: «Эссе, тим, суык су сал!» Ә ул пер чүмеч кайнар су җибәрде. Үлтем тип, тәгәрәп төштем. Шуннан пирле чәчнең тамыры корыды.

Кышын Чтапан чабата үреп сата иде. Аларын да бик яраталар — чөнки бик җыйнак, төбен калын итеп ясый, ә язгы епшектә күтәрмәләр тага...

Урамнан тагын, инде түбән таба, машина үткәне ишетелде.

... Исемлектә бер хатын-кыз да бар: «Бакирова Бибигайшә Мансуровна». Ә монысы кем? «Бибигайшә»... Соң бу Гайшә апа бит! Укытучы! Эх, Гайшә апа, Гайшә апа...

Бергә эшләгәндә аларның мөнәсәбәтләре рәсмилектән артыкка китмәде: ни дисәң дә, яшьтә ун еллап аерма, мәктәптә Гайшә — мөдир, ә Заһир гади укытучы иде. Ә колхозның отчет-сайлау җыелышы алдыннан идарәдә председатель кандидатурасын тикшергәндә Заһир Галәветдингә каршы чыккач, шактый озак бер-берене тик эш турында гына сүз кушыштылар. Гатаулла-парторг та, Гайшә яклы булып: «Кандидатура тиешле урында каралган, комсорг буларак, синең бурыч — аны үткәрү. Ә син күрсәткән Булатны МТСтан җибәрәселәре килми, анда да белгечләр артык түгел», — диде. Заһир Чишмәдә югала башлагач, Гайшә тагы да салкынайды. Бер мәл хәтта: «Сез генә яшьлек кичермәгән: олы бар, кече бар — шул кадәр эчегездәге тышыгызда булмаса ярамый мыни!» — дип шелтәләп тә алды.

Яраланып кайтканның икенче көнендә Гайшә апа аны чәйгә чакырды. Ул элеккечә мәктәп бинасындагы кечкенә бүлмәдә яши иде. Заһир килүгә бүлмәне җылы итеп яккан, өстәлдә самовар чыжлап утыра, үзе мич алдында коймак пешереп маташа иде. Әллә ни зур теләк белән килмәсә дә, салкыннан җыйнак җылы бүлмәгә керү һәм йөз алмалары кызарган, яулыгын, чикә чәчләрен чыгарып каерып бәйләгән чандыр гәүдәле Гайшәне күрүдән Заһирның күңеле күтәрелеп китте. Ишек төбенә таягын терәп, ул аксый-аксый түргә үтте һәм «Сау гынамы, Гайшә

апа» дип күреште. «Заһиркаем, исән кайтуың белән», дип, Гайшә аның аркасыннан сөйде.

Озак сөйләшеп утырдылар. Галия турында сорашты. «Теге чактагы сүзләрем өчен гафу ит, — диде. — Бер каһәр сукканы өстегездән яза иде, Гатаулла абзый белән ничәмә тапкыр аңлатмалар бирдек, — һич сакланмадыгыз бит. Шул «Кәҗә» эше булды, ахры. Үзегезгә әйтеп, күңелегезне төшерәсебез килмәде — ике авыл өчен күз өстендә каш идегез бит!»

Гайшәнең шәхси тормышы турында юньләп белүче юк иде. Үзе сөйләде: Уфа кызы, ире дә бар икән — Кызыл Армиядә кадровый командир. «Ялга кайткан иде, сезнең кебек, дөньябызны онытып, бер күрүдән яратыштык та, кавыштык. Үзе белән Украинага, хезмәт иткән урынына алып китте, — диде Гайшә. — Тик үтә кызыл тиз уңа диләр бит, вак-төяккә үпкәләшеп, бер-беребезне рәнҗетә башладык. Бер бозылышканда кайттым да киттем. Уфада калырга гарьләндем — Наркомпростан направление алдым да монда килдем. Өч ел хат та язышмадык. Ә сугыш башлангач, эзләп тапты. Икебез дә акылга утырганбыздыр — тормышны яңадан башларга булдык. Исән-сау кайтсын гына!»

Гайшә фронтка китәргә хыяллана иде. «Военкоматны күндердем, Роносын да күндереп булса, шушы арада китәчәкмен. Минем дә заманның хәлиткеч вакыйгасында, фашистны дөмектерүдә катнашасым килә», — диде. Фронт турында җентекләп сорашты. Анда хатын-кызга түгел, ирләргә дә ни кадәр авыр икәнен сөйләгәч, «Беләм, аңлыйм, — диде. — Ләкин барыбер китәм. Аннары үзеңне авырлыкта да сынап карарга кирәк бит»... Дуслар булып аерылыштылар. «Галияңне эзлә, туганкаем, табырсың», — дип калды. Үзенекен иткән — фронтка киткән икән. Менә хәзер — солдат ирләр исемлегендә...

Хәйдәров кинәт үзенең исемлектән механик рәвештә «теге ике баланы» эзләвен аңлады. «Фу, эллә саташа башладым инде»...

«Теге ике бала» алар үзләре — Заһир белән Галия бит! Гармунчы малай белән җырчы кыз аңа еллар биеклегеннән шулай, кайчандыр якын, бик якын булып та, искиткеч еракта, зәңгәр томанга кереп югалган ят кешеләр сыман тоелды. Гадәти шартларда армиягә алынырга яшьләре дә җитмәгән, язмышларын дәһшәтле сугыш үзенчә хәл иткән, хыялларын челпәрәмә китергән бу ике үксез олы яшьтәге генералга күптән яндырып үткән, ә хәзер тәндә тик җөй генә булып калган каты яраны хәтерләтте. Стела да, анда тезелгән исемнәр дә, плитәгә салынган чәчәк бәйләмнәре дә — җөй, вакыт-вакыт искә төшеп сыкраткан, ә гомумән инде онытылып барган җәрәхәт эзләре бит. Шушы кечкенә авылның зур яра эзләре.

Ә «теге ике бала» монда юк. Акыл аңлый: булулары да мөмкин түгел — берсе — үзе, исән, икенчесе сугышка башка авылдан киткән, икесе дә монда вакытлыча гына килеп яшәгән. Тик йөрәк, хәтта күпне кичергән карт йөрәк аңлый алмый, аңларга теләми дә: аларны бәйләгән, шушы авылның тормышына хозурлык өстәгән гаять якты, илаһи хисләр эзсез югалган мыни!

Генерал белә: тормышның үз законнары, үз агышы бар, аны туктатып та, үзгәртеп тә булмый. Тик килешүе кыен, теге «икәүне» йөрәктән алып ташлавы, каршы тауларның, урманнарның аларсыз да шулай мәһабәт һәм тыныч булуларын, кояшның һаман шул чаклардагыча нур сибүен, күкнең зәңгәрләгән башка сыйдыруы читен.

Хәйдәров күкрәгән тотты: соңгы елларда болай да бирешә башлаган йөрәкне нидер кисеп үтте...

Хәзер, ерактан-читтән караганда, бары да аңлашыла: беренче очрашу юлда ук гармун моңы тудырган җилкенүдән, клубка кергәндә ишетелеп калган мандолина чыңлавыннан тагын да көчәйгән хисләрдән

башланмаса, әле сүз дә әйтешкәнче үк искиткеч бию һәм җыр акылларыннан элек йөрәкләрен бәйләмәсә, бәлки, бер нинди эз калдырмас иде. Әгәр шунда аларны тыярлык, һушларына китерерлек сәбәп булса, ул гомерлек моңга да әверелмәс, тормышта Заһир белән Галия бер-берсен бөтенләй танымый үтәр иде. Дөньяда бөтен барлыклары белән сокландыргыч бер бөтенне хасыйл итәрлек булып та, кайдадыр үзләренең икенче чын җаны яшәве турында башларына да китермәүчеләр аз мыни!

Моң көчен язып та, әйтеп тә бетерерлек түгел. Заһирның ул турыда еш уйлаганы бар. Днепропетровскида хәрби училищеда укыганда ул хәтта атларның музыкага күңеллерәк, җиңелрәк атлауларын гаҗәпләнеп күзәтә иде. Ә хезмәт иткән частьләрендә оркестрлар оештыруга зур әһәмиятле эш итеп карады.

Лена белән Чишмә алар өчен чынлап та рухи байлык дөньясы булды: монда татар һәм башкорт моңнары кушылып, тормышның бөтен якларына үтеп кергән иде — җырсыз уен булмады, эш башланмады, табын үтмәде. Алар, үзләре дә сизми, шул сихри биеклекнең нәкъ түбәсенә менделәр, аны хисләренә куштылар, тагын да баеттылар. Моңга һәвәслек, музыкаль сәләт аларны бер итте, тормышларын аллы-гөлле төскә буяп, бөтен тирә-якны яктырак, эчтәлеклерәк, эзсез үтмәслек бер матур дөньяга әйләндерде. Боларга тагын илебезнең бөек идеаллар белән яшәвен, ә ул ил балаларының аларга ихлас инануларын да кушсаң, чынлап та, монда сөйми һәм сөелми, җырламый һәм моңланмый яшәү мөмкин булмаган гүзәллек дөньясы иде...

Генерал Хәйдәров элекке яшь егет Заһирдан көнләшеп дуйды: шундый бәхет һәр кемгә тими бит! Энциклопедик сүзлектә «ностальгия — «ватанны сагыну», ә кайбер китапларда «ватанны сагынып шашыну» дип аңлатыла. Бәлки, шулайдыр да. Ләкин һәр күренешкә һәркемнең үз карашы булган кебек, сүзләр дә бер генә мәгънәдә кабул ителми. «Ватанны сагыну»... Ә үз ватанында аның аерым урыннарын сагыну, фронтта шул ватанны ике каен итеп күз алдына китерү һәм, әгәр һәлак булырга туры килсә, тагын бер генә тапкыр күрәсе иде дип шашыну ностальгиягә керә микән? Үткәннәрне, аның кара кайгыларын да зәңгәр буяуларга буяп, күптән югалган эзләрне эзләүнең исеме бар микән?

Әле Уфага сәфәргә җыенганда гына соңгы почтаны караганда АКШта чыгарылган бер журналда аноним имза белән бирелгән сүзләр күзгә чалынды: «Кеше — ач булмаса да ашаган, сусамаса да су эчкән һәм ел әйләнәсенә мәхәббәт белән шөгыльләнгән бердәнбер җан иясе». Кызык, ләкин «мәхәббәт»не бу аноним нинди мәгънәдә кулланды икән?

Юлга укырга дип хатыны аңа инглиз телендә Пирс Пол Ридның «Профессор кызы» романын салган иде: «Укы, — диде көлеп, — син дә профессор, синең дә җиткән кызың бар...» (Заһир берничә ел инде кайчандыр үзе укыган академиядә эксперименталь баллистика курсын алып бара).

Кичә йокы алдыннан «профессор» шул китаптан мәхәббәт картинасын укыды: бер-берен беренче күрүдән ярата башлаган профессор кызы Луиза белән Джонсон идәндә, пычрак матрацта, яталар. Егет анадан тума шәрә, ә кыз әле алай ятарга ояла. Джонсон, кулын Луизаның блузасы эченә тыгып, хисләрен сөйли: «мин синең бу түшләреңне учлап алтынга әйләндерсәм, алар күпме торыр икән, дип уйлыйм. Валлаһи... Мин аларның авырлыгын чамалыйм һәм эчтән генә хакын исәплим...»

Әгәр аноним шундый «мәхәббәтне» күз алдында тотса, ул «кеше» дигәненең җан ияләренең ниндие булыр иде? Хәлил белән Галиябануның, Заһир белән Галиянең, Булат белән Хәмдиянең һәм сөйгәннәрен өрмәгән җиргә утыртмый кадерләп, кулларына кагылуны бәхет санап йөргән күпме гашыйкларның мөнәсәбәтләрен ничек атарга?

Стеладагы исемнәр әнә шул мөнәсәбәтләргә, кешене кеше иткән хисләргә дә һәйкәл түгелме соң?

— Картаясың, генерал. Профессиянә бөтенләй хас булмаган нечкәлекләр — шул картаю билгеседер инде...

## 15

Заһир, бакчадан чыккач, калитка баганасына сөялеп, бераз урамны күзәтеп торды. Авыл тып-тын. Бөтен халык «Сәгать»кә китмәгәндер китүен, тик бу эсседә йөрүчеләр күренми.

Мәктәп ихатасын тиз генә калдырасы килмәде. Бу якларга башка килмәячәген аңлагангамы, кайчандыр беренче тапкыр курка-курка класска кергән урыннан, ул чактагы яшь малайның хәзер бик кечкенә булып тоелган дулкынлануларыннан аерылу кыен иде.

Заһир пинжәген салып беләгенә элде, изүен ычкындырып галстугын бушатты һәм, һәр йортны элеккесе белән чагыштыра-чагыштыра, югары очка юнәлде. Ара-тирә бала-чага, таныш булмаган кешеләр очрап, исәнләшеп үтте. Чечекәй әби ихатасына җиткәч, ул туктап калды. Такта койма, төрле төскә буялган «рус капкасы». Тәрәзәләрен элеккечә урамга каратып салган зур йорт. Япкан капканы ачып чиста ихата аша үтте һәм сап-сары итеп юылган болдырга менде, ишек какты. Ачучы булмады. Бераз икеләнеп торганнан соң ишекне ачмакчы булды. Ләкин ул бикле иде. Заһир урамга кире чыккач күрше яктан тавыш ишетелде:

— Абый, сез Хәлим абзыйны эзлисезме әллә? Ул «Сәгать»кә китте.

— Алай икән, рәхмәт.

— Озакламый кайтыр инде, безгә кереп торыгыз, урамда бик эссе бит.

— Зарар юк. — Заһир койма буендагы бүрәнәгә утырды. Ул арада теге кеше күренде: егермеләрдәге озын буйлы, шактый килбәтсез егет. Ул, кыймый гына якынлашып, исәнләшергә кулын сузды һәм янәшәсенә утырды.

— Мөмкинме? Күргән-ниткәнгә ошамыйсыз, сез кем, абый?

— Болай гына, үтеп баручы.

— Алай икән. Ә Хәлим абзый «Сәгатьтә», — дип кабатлады.— Миңзифа җиңги улы Заһир янына Төмәнгә китте. Ул анда буровик. Хатыны тагын бәбәйләгән, Хәлим абзыйның өйдә бер үзе утырасы килмәгәндер.

— Хәлимнең хатыны Миңзифамыни?

— Әйе, Миңзифа җиңги. Үзебезнең авылныкы. Югары очта әле дә иске өйләре бар. — Заһирның күз алдына тулы гәүдәле, кунакчыл, бер шаян, бер моңсу Миңзифа килеп басты.

— Ә уллары Заһир исемлеме?

— Әйе. Хәлим абыйның инәсе Чечекәй әби куштырган, ди. Аларда элек, хан заманында, Заһир исемле кеше фатирда торган диме шунда... Шул хәтле үк гомерләр үтте микәнни?

— Ә сез «сәгатькә» ник бармадыгыз?

— Чөгендер сирәкләтәбез. Шул «Сәгать» дип, ашарга да китермәделәр, өйгә кайтырга туры килде. Бары да шунда купканнар. Хәзер трактор тик тора инде.

— Сез тракторчымы әллә?

— Әйе.

— Кем баласы буласыз?

— Безнең фамилия Исмәгыйлов. Исемем Мансур. Әтине Миңлебай дип йөрткәннәр...

— Шулайдыр шул...

Миңлебай, Миңлебай... Кырык өченче елның кышында, Заһир яраланып кайтуының беренче көнендә үк, Чечекәй әбиләргә күрше бичә килеп керде. Хәл-әхвәл сорашкач, сөйләнә-сөйләнә куеныннан төенчек чыгарып, Заһирга сузды:

— Күп тормыйсың икән, дип ишеттем, балам, ә без бүген стансага симәнәгә китәбез — күрми дә калырмын... Менә шушы күчтәнәчемне Миңлебаема тапшыра гына күр инде. — Заһирның гаҗәпләнүен күреп, юаткан да булды: — Авыр түгел ул, бер кадак май да оек-бияләй. Ала гына күр инде, балам, капчыгыңда бер почмак тап. Улымның күңеле булыр: икмәккә әк май ягып чәй эчәргә бигрәк ярата иде. Моңарчы сәлкыннарда аяк-кулы да өшидер. Посылка итеп тә салмакчы идем, Зурәвылдагы пушты алмаган булды. «Фрутка посылка алмыйбыз» диде. Бишкаенга барырга вакыт юк — көн-төн олауда йөрим...

Заһир аптырады.

— Ни бит, Шәмсениса апа, мин бик шатланып илтеп тапшырыр идем дә, ничек табыйм соң аны?

— «Ничек табыйм» дип, шул бер әрмия, бер фрунт бит инде, шунда бергә сугышып йөрмисез мени?

— И, апакаем! «Бер армия, бер фронт» — миллионлаган кеше, меңнәрләгән километр бит ул!

Уңайсызлыктан Чечекәй әби коткарды:

— Ярар, ярар, килен. Калдыр күчтәнәчеңне, илтеп тапшырыр.

Шәмсениса рәхмәтләр яудырып, Миңлебаеның адресын калдырып чыгып китте. Адресны укыгач, Заһирның бөтенләй күңеле төште: «Донской фронт»...

— Нишләдең син, әби? Анда бүтән фронттан түгел, үз частеннән кеше табулары кыен бит!

— Пошынма, улым, — диде Чечекәй. — Күчтәнәчен алмасаң, хәтере калыр иде: аңа болай да җиңел түгел — ире белән малае сугышта, үзе ал-ял белми эшли. Соңыннан үзем әйбәтләп аңлатырмын...

Егет сүзчән булып чыкты. Сигарет кабызды да, әйтергә теләгәнен тезеп китте:

— Мин этине дә аз хәтерлим шул. Итәгенә утырта иде дә нәрсәдер сөйли, ә мин аны тыңлый-тыңлый йокыга талам. Бөтен истә калганы шул. Ул сугыштан кайтып ун ел үткәч кенә өйләнгән, ә мин өченче белән барганда үлеп тә киткән. Тәнендә пуля бар иде, ди әни, башына шул җиткән. Мине әнием бер үзе тәрбияләп үстергән. Шуңа да юаш булдым.

— Ә әнигезнең исеме ничек?

— Әнием Фәһимә.

Заһир аны хәтерләмәде, тик егет сүзен дәвам иттерәсе килде.

— Ә юаш дигәнегез нәрсә аңлата?

Мансур бераз көлемсерәп алды.

— Юаш дип, болай үзем әллә ни юаш та түгел кебек. Башымда әллә күпме уй-хыялларым да бар. Ләкин кеше арасында коелам да төшәм. Ни кирәген әйтә алмыйм, ни иптәшләрем кебек шаярта белмим. Әнә Сәми, тоткан җирендә өзеп бара. Уттай егет. Ана нишләсә дә килешеп тора. Менә бүген эшен ташлап «Сәгать»кә китмән — бер ни дә булмас та әле үзенә. Яшьтән үк шулай иде: башлангыч мәктәптә укыганда мин «бишле» алам, ә ул «өчле»не. «Ә нәрсә, — ди торган иде. — «Өчле» — билге түгелмени, «Өчле», беләсең килсә, иң ышанычлы билге». Шулайдыр да. Еш кына мин үк кыен хәлдә кала идем: ул «өчле»сен «дүртле»гә төзәтсә, мактыйлар, мин «дүртлене алсам, әле һаман ялкауланасың дип тиргиләр. Сәми сигезенче класста ике ел утырды. Шулай да сер бирми, «кабатлау мешать итми ул» дип кенә җиффәрә. Аннан соң ул мәктәпне ташлады. «Хәзер кичке мәктәптә уку модада,— диде. — Кол-

хозда эшләячәкмен. Акыл хезмәтен физик хезмәт белән аралаштырырга кирәк».

Бер-ике елдан көч-хәл белән шул кичкедә тугызынчы классны тәмамлады да бөтенләй укымас булды. «Кешене хезмәт тудырган, — диде. — Материаль производство сферасына бөтенләйгә күчәм». Һәм трактор бригадасына хисапчы булып керде. Әле дә шунда эшли. Сүз дә юк, яхшы эшли. Тракторга күчеп утыру турында сүз кузгатсаң: «Тракторда кем дә эшли ала. Ә менә хисапчы! Беләсеңме, исәп-хисап турында классиклар ни әйткән?» — дип кенә җиффәрә. Ә мин, Зуравылда урта мәктәпне тәмамлагач, шул бригадага тракторчы булып килдем. Укыганда ук бу һөнәргә өйрәткәннәр иде. Университетка керергә дә тырышып карадым, ләкин булмады. Шул, әлеге дә баягы, кыюлык җитмәү. Белгәнемне дә юньләп сөйли алмадым имтиханда...

Егет беразга тукталып калды.

— Вузга керә алмавыгыз кызганыч, әлбәттә.

— Әйе, — диде Мансур. — Тик, мин бик кайгырсам да, әнием шатланды гына. «Укыган хәтлен җиткән, балам, әтиең кебек тракторчы бул. Өебездә ир-ат исе — бензин исе булыр, ичмасам» диде. Яхшы гына эшләп киттем. Нормаларны тутырам. Ара-тирә җыелышларда да мактап алалар. Ул яктан әйбәт. Ләкин эш бит шәп тракторчы булуда гына түгел, абый.

— Ә нәрсәдә соң? — Заһир көннәр буе бер үзе тракторда эшләгән бу егетнең нигәдер әчен бушатасы килгәнен аңлады.

— Нәрсәдә, дип, ничә әйтсәң дә, шул кыюсызлык. Кайчак табигатькә дә үпкәләп куям. Бирмәсә бирми икән. Еш кына көзгегә карыйм да, үземне Сәми белән чагыштырам. Төс ягына килгәндә, миндә юк та юк инде ул. Күрәсез: җирән чәч, сипкелле бит!

Мансурны чынлап та чибәр диярлек түгел иде. Заһир аны юатты:

— Эш тышкы матурлыкта түгел бит. Аннары егет кешегә...

Мансур бүлдерде:

— Шулаен шулай, ләкин, сер итеп кенә әйтәм: чибәрлекнең кирәк чаклары була. — Ул тирә-ягына каранып алды да дәвам итте: — Галиягә күзем төште.

Заһир кинәт сискәнеп егеткә текәлде.

— Әйе, Галиягә. — Егет кыюсыз гына кабатлады. — Авылда ике кызның берсе — Галия. Әллә дөньясында бүтән исем беткән — безнең эти-әниләр замандашы шул исемгә табына. Тик барлык Галияләр арасында минем Галия — иң чибәре.

«Минем Галия — иң чибәре». Заһир егетне ишетә дә, ишетми дә. Нинди көн булды соң әле бу? Галия дә Галия...

— Галия тирәсендә күпләр урала. Сәми дә итәгатьле генә, түбәнчелек белән сөйләшә. Беләм инде, ярата ул аны. Әнә быел сигезенче март концертында нишләде! Башкалардан яшереп кенә аңа багышлап номер әзерли: мине, исемен «Галия»гә алыштырып, «Әлфия» көенә җырлатырга булды. «Концертны үзем алып барачакмын, сюрприз ясыйк әле», — ди. Галиягә булгач, мин риза инде ул... Сәми сәхнәгә чыкты да: «Ханымнар, туташлар, авылыбызның мәшһүр җырчысы, минем якын дустым Мансур иптәш Исмәгыйлов шушы залда утыручы бер туташка багышлап җыр башкара. Ул минем аңа бәйрәм бүләгем булыр», — диде. Җырладым. Концерттан соңгы уен вакытында Галия миңа: «Мансур иптәш Исмәгыйлов, ә сезнең үзегезнең бәйрәм бүләгегез юк идемени?» — диде. Мин кызарынып-бүртенеп җавап эзләгән арада Галия, кулын селтәп, янымнан китеп тә барды.

Бу егет белән утыруы рәхәт иде. Заһирга ул авылның үз яшьтәшләрен, теге чактагы тарихларны кабатлагандай булды: һаман концертлар, сөюләр, көнләшүләр... Тормыш дәвам итә. Ә егет, тыңлаучы булгангамы, җәелеп сөйләвен дәвам итте.

— «Ни булса, булыр» дип, Галиягә аны яратып йөрүем турында хат аша әйтеп бирергә булдым, абый. Төннәр утырып әллә ничә төрле хат яздым. Ләкин бирергә кыюлык куәте җитми. Әгәр адәм көлкесенә калдырса, аннары ни күз белән күренермен?»

Мансур тәмәке төпчеген төкереп ташлады.

— Ә бер көнне Сәми килгән. Ничектер үзенә ошамаган иде ул — боек күренде. Гадәттәгечә сүзчән дә түгел. «Ни булган моңа?» — мин әйтәм. Озак көттермәде. «Слушай, — ди бу, — син бит язу-сызу ягына мастак. Бер хат язып бир әле». «Син нәрсә, мин әйтәм, хан заманындагы кебек, кешедән хат яздырасың?» «Бросьла, ди бу, — гади хат түгел. Мәхәббәт хаты. «Мин сине яратам», фәлән-төгән... Матуррак сүзләр тап». «Ә кемгә?» — дип сорыйм. «Анысы не важно,— ди,— исемен куйма». Белеп торам инде — Галиягә. Ничек кенә авыр булмасын, үземнең хатларның бер вариантын, исемен куймыйча гына, күчереп язып бирдем. Ләкин файдасы тимәде бугай. Ике-өч көннән соң Сәми коры гына: «Синнән хат яздырган мин ахмак»,— диде. «Шуны да юньләп яза белмәгәч...» Нишлисең инде, булмагач булмый шул...

Егет хәйләле елмаеп, бераз тирә-якны күзәтеп утырды да яңадан сөйли башлады:

— Ни әйтсәң дә, Сәминең башы эшли. Әнә былтыр стена газетасы белән ничек булды бит. Башта мине редактор итәргә уйлаганнар иде. «Мәктәптә дә редколлегия члены идең, буллдырырсың», — диделәр. Мин курыктым әлбәттә, булдыра алмам, дидем. Ә ул шүрли торганнардан түгел. «Үземне куегыз, — диде. Менә бит нинди йөрәкле! — Күрсәтим үзегезгә ничек газета чыгару кирәген! Ә Мансурны ярдәмче итеп бирегез. Аны да өйрәтермен. Бер-ике елдан бер дигән редактор булыр». Һәм өйрәтте бит. «Менә сиңа кәгазь, менә буяулар, — диде ул шул кичне үк. — Хәзер барлык фермаларны, бригадаларны йөреп чык. Колхоз алдындагы бурычларны белэсең. Ничек эшлиләр — бурычларга ярашлымы, юкмы, аннары бик әйбәтләп утырып яз. Только кара аны — матур булсын, эчтәлекле булсын. Эшләп бетергәч күрсәтерсең». Мин шулай иттем дә. Тик ул «йөреп чыгу» атнага якын вакытымны алды — колхоз зур, бөтен Зуравыл сельсоветы бит. Эш ташлап та йөреп булмый. Аннары төне буе утырып язганымны Сәмигә күрсәттем. Ул газетаны төрлечә боргалап карады да: «Син дә газета чыгарам дисең инде, ә?» — диде. Аннары: «Первый блин комом, диләр. Ничего, кайгырма. Бар, элеп куй, — дигән булды. — Өйрәнерсең әле». Дөрес әйткән. Әкренләп киттем...

Заһир егетне аңлап җитми — шулай беркатлымы ул, яки шаяртамы. Тыңлавы күңелле.

— Сәмине әйтәм, шундый тапкыр ул. Бер вакытта да югалып калмый. Әле кайчан гына, допризывник булып йөргәндә, бар сүзе ракетчиклар турында иде. «Алсалар да, алмасалар да, бары тик ракетный частька китәм. Хәзер техника заманы, солдатның иң шәбе — ракетчик», — дип йөри. Армиягә авылдан өчәү алындык — көзгә китәбез. Түбәноч Зәки белән Сәмине пехотага яздылар, ә мине, үзем һич тә көтмәгән идем — ракетный частька. Башта бу көтелмәгән хәлдән аптырап калган Сәми кайтырга чыккач та сүз башлады: «Дөрес эшләделәр, — ди. — Ракета нәрсә ул? Әле сугышта күргән-ишеткән әйбер түгел. Күктәге торнага ышанып, кулыңдагы песнәкне ычкындырма. Ә пехота? Юкка гына «царица полей» дип йөртмиләр». Ничек аның белән килешмисең инде? «Әйе, — дидем. — Әнә кукурузаны да бит «королева полей» диләр...» Сәми миңа текәлеп карап торды да: «Син кукурузны монда кыстырма, ямe?» — диде. Күз дә ачтырмый бу. Мин акланмакчы булган идем, бөтенләй кызып китте, русчалап сөйли башлады: «Син брось, понимаешь! Ракетчик дигәч тә, хәзер, туганкаем, пехота да җәяү йөрми, анда аяк озынлыгы төп шарт түгел, баш кирәк, баш!» Дөрес сүзгә җа-

вап юк иде: юл буе пехотаны мактап кайттык, мин ракета турында сүз дә кыстыра алмадым...

## 16

Мансур сөйләп бетерә алмады, түбән яктан кара «Волга» күренде.

— Райком машинасы, — диде егет. — Ул бая монда бер килеп китте инде. Хәлим абзыйны эзлиләр бугай. Авторитет бар аның — килгән-киткән начальство шунда туктала.

Машина чынлап та Хәлимнәр капкасына килеп туктады. Ике якка ишекләр ачылды. Утыз яшьләрдәге урта буйлы ир, пинжәк төймәләрен эләктерә-эләктерә, Заһир янына килеп кыяр-кыймас кулын сузды:

— Исәнмесез, гафу итегез, сез иптәш Хәйдәров түгелме?

— Әйе, Хәйдәров. Саумысыз.

— Партиянең Бишкаен райкомы секретаре Моталлапов, Рамазан Тимерханович.

Машинадан озын буйлы яшь кенә подполковник чыгып честь бирде:

— Бишкаен район военкомы Алексеев. Исәнлек телибез, иптәш генерал!

— Исәнмесез, иптәшләр. Танышуыма шатмын.

«Генерал» дигәнгә аптырап калган Мансур китәргә җыенды.

— Гафу итегез, — диде ул Заһирга гаепле карап. — Мин белмәдем, шуңа әллә ниләр лыгырдап утырдым...

— Сез, Мансур, үзегез мине гафу итегез,— Заһир аны иңбашыннан кочаклады. — Сөйләшү бик күңелле булды. Мин сезнең әтиегезне яхшы беләм идем... Нәкъ менә сезнең яшьтә чакта гаҗәп бер егет иде. Шулай иртә дөнья куюы кызганыч...

— Рәхмәт, абый. — Егет тиз генә китеп барды.

— Без сезне шактый озак эзләп йөрдек, — диде Моталлапов. — Летчиклар «Авылга китте» диделәр.

— Мин бераз авыл карадым шул.

— Безнең беренче секретарь иптәш Рәхимов ялда. Менә хәрби комиссарга Уфадан сезнең килүегез турында шалтыратканнар иде. Каршы алырга дип чыктык, ләкин соңлаганбыз. Гафу итегез.

— Юкка мәшәкатьләнгәнсез. Эшегезне, ялыгызны бүлеп килеп йөрмәскә иде.

— Куегыз әле: нинди ял да, нинди мәшәкать ул? Килүегез — бер шатлык. Сез монда кайчандыр эшләп киткәнсез икән?

— Әйе. Ләкин бу бик күп еллар элек булды. Хәзер бирейдә бөтен нәрсә үзгәргән.

— Үзгәрешләр бар, иптәш генерал.— Ул район турында, төрле саннар китереп, ун-унбиш минут сөйләде һәм тәкъдимен әйтте:

— Бәлки, иптәш Хәйдәров, районны карап әйләнербез? Журавылда мөгезле эре маллар симертү өчен бик шәп колхозара комплекс салдык. Ике атналык үгез бозауларны җыеп, унөч ай эчендә 400-450 килограммга җиткереп дәүләткә сатабыз. Бер керүдә ун мең баш! Сугышка кадәр бөтен районга ул кадәр мал булмаган. Әллә барып карыйбызмы?

— Масштаблар башка хәзер. — Заһирның бик санаулы вакытны мал турында сөйләшеп үткәрәсе килмәде. — Комплекска барып булмас ахры — бүген миңа китәргә кирәк. Аннары минем андый комплексларны күргәнем бар. Аларның технология принциплары бер бит...

— Әйе, шулай да бераз үзгәрешле. Бездә бит колхоз маллары, төрле токымнан...

Заһир секретарьны бүлдерде:

— Гафу итегез, әгәр мөмкин булса, без «Сәгать» бәйрәменә барыйк.

— Рәхим итегез. Тик... нинди бәйрәм икән ул, кайда? Киләсе атна-

да районда — сабантуй.
— Сез белмисез дә мени? Әсез, иптәш военком, беләсезме?
— Күрергә туры килмәде...
Уйлар тагын үткәнгә тоташты. Чишмәгә барып кайтканның икенче көнендә Заһирны колхоз идарәсенә чакырттылар. Гатаулла янындагы таныш булмаган кеше үзе килеп күреште.
— Миронов, райкомол инструкторы. Утырыгыз, иптәш Хәйдәров.
Заһир утыргач, Гатаулла сүз башлады:
— Я, ничек, энем, авылга күнегәсеңме?
— Рәхмәт. Күнегә башладым инде.
— Күнегерсең. — Һич көтмәгәндә сүзне гармунга борды: — Ишетүемә караганда, гармунчы да икәнсең?
— Әйе...
— Бик әйбәт. Безнең заманда авылда гармун — революцион корал, культура фронты коралы ул. Кызганычка каршы, яшьләргә башка әллә ни тәкъдим итә алмыйбыз, ә аларның уйныйсы да, җырлыйсы да килә. Шулаймы?
— Шулай инде...
— Монда сиңа кадәр Хәлим дигән бер гармунчы егет комсорг иде. Шуны алмаштырырга туры килер.
Аннары сүзгә Галәветдин кушылды:
— Мин аны фатирга да шул Хәлимнәргә урнаштырдым.
Гатаулла хуплады:
— Бик әйбәт. Чечекәйгә дә күңеллерәк булыр — бер үзе бит. Менә шул, туган, сине колхозның комсоргы булырга тәкъдим иттек, райкомол риза. Үзең ничек карыйсың?
— Әйе, райкомол да кандидатураңны карады, — диде Миронов. Заһир, икеләнеп, җавап бирде:
— Ышанычыгыз өчен рәхмәт, әлбәттә. Тик кулымнан килер микән? Мин монда бөтенләй яңа кеше бит әле.
— Кулыңнан килгәне генә җитмәс, туган,— диде Гатаулла.— Колхоз тормышына ныклап катнаш. Яшьләр белән яхшы таныш, аларны үз тирәңдә тупларга тырыш. Исеңдә тот: колхозда партия оешмасы юк, комсомол — бердәнбер политик оешма.
— Әйе, — Галәветдин өстәде: — Кулга кул тотынып эшләргә кирәк. — Кинәт бер нәрсәне исенә төшерде: — Ә аулакка йөрүләрне туктатырга туры килер.
— Аулакка? — Гатаулла Заһирга текәлеп карады. — Аулакта буласыңмыни?
— Булырга туры килә. Чакыралар бит — гармунчы юк.
— Зарар юк, клуб эшен җайга салсаң, аулак үзеннән-үзе бетәр ул.
Төштән соң өч-дүрт комсомолецны җыеп Заһирны комсорг итеп сайладылар. Миронов аңа Хәлим калдырып киткән «дело»ны — эш планнарын, взнос җыю ведомостьларын, җыелыш протоколларын тапшырды. Соңыннан Чечекәй әби дә, «Менә, балам, Хәлимемнең камсамул язулары» дип, бер төргәк кәгазь бирде. Анда авыл кешеләре турында кыскача хәбәрләр, кемнәрне комсомолга әзерләү, кем белән аерым әңгәмәләр үткәрергә кирәклеге, агротүгәрәкләр, дингә каршы концертлар оештыру турында уй-фикерләр, төрле цитаталар, инструкцияләрдән күчермәләр тупланган иде. Заһирга алар нык ярдәм итте.
Менә хәзер күрештеләр. Хәлим көчле куллары белән кочаклап ук алды.
— Менә минем энекәшем нинди икән! Гомер буе әни сезнең хакта сөйләде. «Шул бала булмаса, киткәнеңнең беренче елларында саргаер идем», — ди иде мәрхүмә. Рәхмәт инде.
Хәлим әнисенең исемен оныткан иде инде Заһир, ә «Чечекәй әби» дияргә теле бармады:

— Әби юк мыни инде?
— Әйе, Чечекәй карчык былтыр дөнья куйды, — диде Хәлим.
— Алай икән, белмәдем. Кызганыч.
Аланнан болар янына кояшта кара янган йөзен тирән җыерчыклар каплаган, костюмы түшендә «Алтын йолдыз» медале ялтыраган урта буйлы ир килеп Моталлаповка кулларын сузды:
— Әйдүк, әйдүк, кунаклар. Исәнмесез!
Заһир аны күрү белән таныды:
— Булат!
Булат, төсмерләп бераз карап торгач, колачын җәйде:
— Заһир! — Алар бер-беренең аркаларын кагышып күрештеләр. — Чынлап та синме бу? Кайчан, ничек килеп чыктың? Вот молодец, «Сәгать»не онытмагансың. Егетсең икән әле. — Булат Заһирның чикәләрен сыйпады. — Чәчләрең агарган, ә үзеңне танырга була. Нинди җилләр китереп ташлады, күпкәме?
— Әйе, Булат, бу мин. Сине күрүгә чиксез шатмын! Менә үзеңне, леналарны сагынып килеп чыктым.
— Вот рәхмәт!
«Галия тавы»на Заһир кайту хәбәре таралды. Картыраклар — ә аларга ияреп яшьләр дә — болар тирәсенә җыйналды. Аксый-туксый Галимҗан килеп җитте. Ул ерактан ук сөйләшә-сөйләшә атлый иде:
— Әйткән идем бит, исән булса, Заһир бер килер әле дип, менә күрәсезме? Нихәл, малай! — Заһирны кочаклап бер мәл тынып калды һәм, аерылып, күз яшьләрен сөртә-сөртә, аның кулларын кысты. — Исән икәнсең, малай, белми идек бит. — Галимҗан сары мыегын сыпырып тирә-ягына карады.— Менә, агай-эне, безнең Заһир шушы инде. Сөйләгәндә «Булмас, экияттер, арттырасың» ди идегез, күрәсезме — экият түгел, ә бары да чын.
Халыкны ерып, кызмача бер карт та килеп кулын сузды:
— Кайда, кайда минем дусым, минем Заһир дус?..
Булат аның каршысына басты һәм терсәген күтәрде.
— Ә син читтәрәк тор.— Ул, Заһирны кочаклап, аланга таба атлады.
Заһир бераз аптырап калды:
— Кем булды ул?
— Кем булсын — «Кәҗә»! Игътибар итмә. — Булат шат иде. Эх, туган, бүгенге бәйрәмгә син генә җитми идең, менә килеп шәп иткәнсең! Ерактанмы, күпкәме, ник хәбәр итмәдең? Үзем матай белән станциядән барып алыр идем.
— Мәскәүдән. Бер көнгә.
Булат туктап аңа шелтәле карады:
— Бер көнгә? Син нәрсә, шул хәтле еллар күрешмә дә...
— Шулай, Булат, бүгенгә генә. Барысы да без теләгәнчә булмый бит.
Аларга ияргән райком секретаре аңлатты:
— Генерал-лейтенант Заһир Закирович Хәйдәров тик бер генә көнгә килгән.
Булат шак катып Заһирга текәлде:
— «Генерал-лейтенант»?! Ну, малай, синең белән сөйләшүе дә куркыныч. Ә без: «Заһир да Заһир». Гафу ит инде, белмәдек.
— Куйчы әле. Мин сезгә нишләп генерал булыйм, мин шул элеккеге Заһир инде.
— Рәхмәт, малай, — Булат Заһирны иңбашыннан кочаклап алан уртасына алып килде.
Шул ук урында ике каен — берсе туп-туры булып күккә ашкан, икенчесе аңа сыенып утыра. Алар яшел рәшәткә эчендә, яннарында кечкенә эскәмия. Якында, таллар арасында, чишмә чылтыраганы ише-

тело. Заһир, каеннарга карап чиксез дулкынланып, эскәмиягә утырды. Күз алдыннан күптәнге күренешләр үтте. Ул арада бер кыз тустыган тутырып кымыз тәкъдим итте:

— Эчегез, абый, юлдан арыгансыздыр. Көне дә эссе.

Заһир рәхәтләнеп салкын кымыз эчте һәм савытны кайтарганда сорады:

— Кем кызы буласыз?

— Мин, абый, Чишмәдән, белмисездер.

— Алай икән. Рәхмәт сезгә, Чишмә кызы. Исемегез кем?

— Галия...

Тагын бер Галия. Чишмә кызы Галия...

Аланда уен туктады. Картыраклар танып, ә яшьләр кызыксынып, Заһир тирәсенә җыелышты. Күрешүләр тәмамлагач, кемдер тальян сузды.

— Заһир абый, сез гармунчы булган, диләр. Бәйрәм котлап, бер уйнавыгызны сорыйбыз.

Теге чактагы Чишмә клубын хәтерләтеп:

— Сорыйбыз, сорыйбыз, — диештеләр, кул чабулар ишетелде.

Заһир бер тын уйланып утыргач гармунны тартып җибәрде. Бармаклар таныш теллләрдән аның үз көен эзләп йөгерде. Лена үзәне буйлап элекке көй — Галия каеннары, яшьлек, мәхәббәт, шатлыклар, югалтулар хакында дәртле дә, сагышлы да моң яңгырады.

Тынып калган мәйданда кемнеңдер мыш-мыш килеп елавы ишетелде.

*

* *

Уенны бик бирелеп шактый вакыт карадылар. Ул элеккегә охшаган да, охшамаган да иде: биюләр, җырлар башка, яшьләрнең өс-башлары да шәһәрнекеннән аерылгысыз. Шулай да авылга хас гадилек ниндидер эчкерсезлек сизелә.

Бер арада Галимҗан пышылдады:

— Китәм, дисең, жаның түзмәс, малай, әйдә Чишмәне урап килик. Мин Булат белән Хәлимгә кунакларны миңа, өйгә алып барырга куштым. Хәзер бәйрәм дә бетә инде.— Заһирның җавабын көтмичә, райком секретарена мөрәҗәгать итте:

— Без бераз йөреп килер идек, ничек карыйсыз?

— Барыгыз, ә без сезне көтәбез.

Заһир район житәкчеләрен тоткарларга теләми иде.

— Бәлки, сез кайтып ял итәрсез, болай да көнегезне бодым,— диде.

Моталлапов риза булмады:

— Әгәр рөхсәт итсәгез, без калыр идек, бәйрәме дә бик күңелле.

— Ихтыярыгыз, тик минем өчен генә булса көнегезне әрәм итмәскә иде.

— Юк, юк, безнең өчен көтелмәгән ял булды бу, Заһир Закирович. Зур рәхмәт сезгә. Сез безнең машинада барыгыз.

## 17

Галимҗан йомышларын кушып урап килде дә, кыенлык белән аякларын урнаштырып, машинада арткы урынга утырды.

— Әйдә, малай, Лена буен кара «Волга»да бер урыйк әле.

Заһир аның янынннан урын алды.

— Кузгал, туган,— Галимҗан шоферның аркасына кагылды.— Әмма бик тиз кума, туган якларын күбрәк кунак күрсен.

Заһир таныш та, онытылган да таулар, агачлар артка чигенүен йоглыгып күзәтә башлады.

Галимҗан канәгатьләнү белән:

— Менә, дус, Галияң тавын да кайтып күрдең, — диде. — Ямь өстәлде. Хәмдиягә өйләнгән көнне Булат безне шушында алып килде. «Уйнагыз, шатланыгыз, бу — мәхәббәт тавы», — диде. Аның исәбе — аланны шулай атау иде. Нигәдер халык үзенекен итте. «Галия тавы» дип йөртә башладылар. Шул елны «Сәгать»не дә монда үткәрдек. Әнә хәзер каеннар нинди матур булып үсте! Галия дә, исән булса, түзмәс, йөрәге тартылып килер әле...

Галимҗан Заһирга сораулы караш ташлады, тик дустының дәшмәвен күреп, төпченмәде, сөйләвен дәвам итте:

— Синең көеңне дә онытмадык. Үзенең туенда Булат аны Хәлимнән уйнатты. Башка гармунчылар да өйрәнгән. Хәзер алар күп, баяннар да, аккордеоннар да бар. Ләкин әллә ни матур итеп, үзең уйнаганча дәртле дә, моңлы да итеп уйный алмыйлар. Әллә дөньясы үзгәрде, әллә үзебез...

Көн кичкә авышса да, һаман эссе. Машинада бик бөркү булгач, Заһир ишек пыяласын төшерде.

«Нинди җирләрне үтәм мин! Менә бу шөлеклектә язгы чәчүдән калган кыр вагоны тора иде. «Сәгать»тән кайтканда яңгыр башлангач, Галия белән шунда кердек. «Өшедем, Заһирым, җылыт мине»,— диде... Ә монда, яр астында чишмәләрнең кавын-карбыз бакчасы була иде. Галимҗан аларга ниндидер сугару корамалары да эшләп бирде: «Гөлфирәнең су ташып куллары тала, бераз ярдәм булыр», — диде. Шуның аркасында Галәветдин белән сүзгә дә килештеләр бугай, имеш, чит колхоз мәнфәгатен үзенекеннән югары куя. Ә тегендә буа һәм кечкенә су тегермәне иде, хәзер биек тирәкләр генә калган.

— Чишмәгә җитәбез, Заһир,— Галимҗан хатирә битләрен актарудан бүлдерде.— Исеңдәме, без монда киң урамнарны тар итеп йөри идек? Менә шунда син гармуныңны тартып җибәрә идең. — Галимҗан кеткелдәп алды. — Исәпләсәң, исең китәр, малай. Сугышта чакта шуларны өзелеп сагына идем. — Беренче йортларны үткәч, сорады: — Кая барабыз? Хәзер клублары урынында алар мәктәп салдылар, ә келәтләр урынында — бакча. Син кереп йөргән мәктәп юк инде.

Мәктәп... Кышка кереп күбәләк-күбәләк карлар ява башладымы, Заһирның күз алдына ни өчендер хәтеренә сеңеп калган күптәнге күренеш килә. Кышкы күренеш...

Әле алар өчен искиткеч еракта, авырлыклары, каһәрләре әллә кайда, күренмәс киләчәктә булган, ә хәзергә йөрәкне ярсытып үзенә чакырып торган сугыш бара иде инде. Заһир дәресләрен иртәрәк тәмамлап Чишмәгә ашыкты. Галиясе өйдә юк иде: «Кайтып җитми шул әле, — диде Җәмилә апа,— мәктәбендәдер. Ул шулай син килгәнче эшен бетереп торырга ярата».

Клуб артына тезелеп киткән келәтләр тыкрыгын үтеп, Заһир мәктәпкә килде. Ишекне сак кына ачып коридорга керү белән күзенә сап-сары итеп юылган идән һәм ап-ак мич кырына кибәргә куелган таныш кара пималар күренде. Ничектер күңел тулырлык рәхәт булып китте. Кечкенә мәктәп эче тып-тын иде, кайдадыр стена сәгате генә келт-келт йөгергәне ишетелә. Каршыдагы ике ишекнең сул яктагысын ачты Заһир һәм сокланып басып калды: Галия нәкъ нәни балалар кебек аякларын бөкләп утырган да тырышып-тырышып нидер яза...

Җылы мәктәп, кайнар тойгылар Заһирның хәтерендә ул авыр заманның кадерле истәлеге булып саклана, «ярый әле, тормышта шундый мәлләр булган» дип, күптән үткән, дистәләрчә кышлар явып эрегән кар сулары алып киткән эзләргә карата.

Галимҗан әйтмешли, исән булса Галия дә шул эзләргә карар, аларның җылысын үзе белән елдан елга алыр әле... Һичшиксез алыр сыман...
— Ә Җәмилә апа исән микән?
— Җәмилә апа да, карты да дөнья куйдылар.
Авылны ашыкмый гына урап, кире Ленага борылдылар.
— Син сугыш вакытында кайтып киткәнсең икән? — диде Галимҗан. — Соңыннан монда «Кәҗә» әлләниләр сөйләп йөргән: имеш, аны тукмамакчы булгансың, тик булдыра алмагансың. Ныграк бирергә кирәк иде шул сволочка.
— Анысы булмады.
— Кызганыч. Малай, гафу ит, — диде Галимҗан. — Гаиләң-фәләнең бармы?
— Бар. Хатыным, улым һәм кызым бар.
— Алай икән, бик әйбәт.
— Ә син кемгә өйләндең? Мин беләмме? Уенда ничектер сорарга кыймадым.
— Беләсең! Мин бит Гөлзаһираны алдым. Уенда булмады ул — аш әзерләп өйдә калды.
— Балаларың да бармы?
— Бар, балаларның балалары бар инде. Өлкән улым нефтяник, берсе — зоотехник, кечесе әле укып йөри — институтта.
— Малайларга бай икәнсең?
— Ул якка сынатмадык. Әнә Булат мине «мужской мастер» дип йөртә, — Галимҗан канәгатьләнү белән көлде.
Гөлзаһира... Менә кем бәхетенә эләккән икән! Бик әйбәт.
Армиягә китәр алдыннан, кинәт повестька килсә өлгерә алмам дип, Заһир аңа комсомол эшләрен тапшырды. Көтмәгәндә Гөлзаһира Заһирны кочаклап елап җибәрде:
— Яшьләрнең башлыгы булып йөрдең, ә бер ни дә белмәдең...
— Гафу ит, Гөлзаһира, әле дә бер ни белмим.
— Булат яраланган, ди бит...— Бу турыда Заһир белә иде.
— Соң син?..
— Әйе, мин шул! — Гөлзаһира, бераз тынычланып, серен сөйләде. Ул сөйләгәндә туган күренеш әле дә күз алдында.

## 18

... Сугыш башланган елның печән өсте. Өзынтау буенда, бөтен колхоз белән диярлек, кунып эшлиләр. Басу станы дип аталган алты почмаклы өй сыйдырмаганга, печәнчеләр урман буенда куышлар корып шунда йоклап йөри.
Гөлзаһиралар куышы агалы-энеле Булат белән Зөфәрнекенә янәшә туры килгән.
... Кичтән сибәләп кенә ява башлаган яңгыр көчәйгәннән-көчәйде һәм иртәнгә кадәр туктамады.
Гөлзаһира гадәттәгечә таңнан торып чәй әзерләргә уйлаган иде дә, куыш янында өелеп яткан чытыр-чатыр яңгырдан тәмам җебегән булып чыкты. Гөлзаһира аңа куыш эченнән коры печән дә кушып карады, ләкин учакны һич кабыза алмады. Җитмәсә, җиргә ялгыш төшкән шырпысы бик тиз юешләнде. Ул шулай үз-үзенә үртәлеп, инде нишләргә дип торганда күрше куыштан Булатның башы күренде — пумалаланып беткән кара чәчләренә үлән буталган, ак майка кигәнгә нык тәненең коңгырт төсе аеруча җете булып күренә.

— Нәрсә, сеңелем, янмыймы әллә? — Булат бер караудан Гөлзаһираның хәлен аңлады.

— Кабынмый шул, бигрәк нык чыланган, — Гөлзаһира шуңа ачуыннан иреннәрен бөтәрләде.

Булат аягына итек киеп, иңсәсенә майка өстеннән генә кожан салып куыштан чыкты.

— Кая, үзем кабызып карыйм әле.

Аның ут кабызып маташканына карап, Гөлзаһира үзенең Булатны тәүге күрүен исенә төшерде. Каз өмәләре үтеп кыш башлангач, югарыч Миңзифаларда аулакка җыелганнар иде: уналтысын яңа тутырган Гөлзаһираның җиткән кызлар рәтендә чыгып йөрүләре башланган беренче елы, аңа бары да кызык, бары да дулкынландыргыч.

Кайткач Гөлзаһира бик озак йоклый алмый ятты — уйлары һаман шул аулак тирәсендә чуала иде. Анда җыр-бию, табын гына булмады, алар белән рәттән үзенә күрә икенче аулак та барды. Гөлзаһира Гарифның Әкълимәгә күз кысканын, Сәлихның су эчү сылтавы белән мич артында Сәҗидә белән пышылдашканын, бернича парның ара-тирә чоланга чыгып керүләрен һәм тагын әллә нәрсәләрне күзәтте. Гөлзаһираның үзе кырына да Зөфәр килеп сүз кушып йөрде. Тик аның уе-күзе Булатта булды: тирле маңгаена төшкән озын кара чәчен кул сырты белән артка сыйпаулары, елмайганда ап-ак тигез тешләренең җилдә, кояшта янган йөзен яктыртып җибәрүе, җырлаганда бармак арасында тәмәке кыстырган кулын селтәүләре, төсе-башы, барлык кыланышлары белән Булат Гөлзаһираны үзенә җәлеп итте.

«Ник миңа карамады да соң ул?» Йөрәген ярып үткән шул сорау йоклатмады Гөлзаһираны. Бу хәл кичә булса, бер дә исе китмәс иде. Булатны ул элек бөтенләй белми иде диярлек. Ни әйтсәң дә, сигез яшь аерма бит. Булат инде егет булып армиягә киткәндә Гөлзаһира әле кечкенә иде һәм күрше авылда укып йөрде. Бишенче классны бетергәннән соң ул укырга бара алмады: көтмәгәндә әнисе үлеп китте, әтисе Бәдретдин: «Укыган хәтлең кыз балага бик җиткән, үзеңә кирәк-ярак әзерлә, кече туганыңны, мал-туарны карарга да ярдәм кирәк», — диде. Әтисе, әле карт булмаса да, яңадан өйләнмәде. Гөлзаһира өстенә дөньяның бөтен авырлыгы төште.

Үзе дә сизмәстән Гөлзаһирә көнләшә иде. Аның сәбәбе дә бар: бүген иртән генә күрше кызы Сәҗидә пышын-пышын хәбәр сөйләп китте: «Әй, малакаем, Булат кәләш эзли икән. Хәмдиясе көтмәде бит, инәсенең сүзен тыңлап, анау Каҗәгә чыкты исәр. Хәзер терсәген тешләмәкче дә инде — соң. Әнә Булат: Хәмдиягә үч итеп, авылның иң чибәренә өйләнәм дип әйтә ди. Сиңа яучы җибәрмәкче икән. Мәфтуха әбинең үзеннән ишеттем, менә күзем чәчрәп чыксын!»

Гөлзаһира, инде үзен җиткән кыз санаганга, моңа гаҗәпләнмәде. Ә Булаттай егетнең аны соратырга уйлавы ошады. «Куй әле, Сәҗидә, гомергә шулай тузга язмаганны сөйләдең», дисә дә, эченнән генә шатланды һәм аулакка, үзе дә сизмәстән, зур өметләр белән барган иде... Ә Булат аңа карамады да. Гөлзаһира үзенә үзе кызганыч булып калды. Мендәрен кочаклап елап та алды һәм таң алдыннан гына йокыга талды, төшендә ул Булатны күрде: көлтә төягән фурман өстендә Рамазан чокырыннан төшеп килләләр икән. Юл текә, үзе рәтләп күренми дә: аны куаклар бөтенләй каплаган. Булат дилбегә тоткан, атны чыбыркылап куа да куа. Гөлзаһира коты очып көлтәгә ябышкан, ә үзе көлә: ни күрсә, тәртәләр арасында ат түгел, Миңзифа икән. Ә Булат аның юан гәүдәсенә суккан саен: «Айт-два, айт-два!», ди. Үзе Гөлзаһирага карап күз кыса. Үзе мыеклы. Әнә, сакалы да бар. Бәй бу Мөслим бабай ич! Ник миңа күз кыса ул?.. Юл инде үргә таба борылды, ә тәртәләр арасында хәзер — Булат: фурманга арты белән җигелгән дә, күз кыса-кыса, тә-

мәке тоткан кулын болгый. Куаклар арасыннан кемдер дәшә:
— Гөлзаһира, Гөлзаһира...
Гөлзаһира әнисен чакырырга тырыша, тик тавышы чыкмый. Тиргә батып, уянып китсә, — әтисе:
— Нәрсә, кызым, саташтыңмы әллә?
— И ходаем, әллә нинди төш күрдем шул...
— Кичен озак йөрисең бит.
... Болар турында Гөлзаһира шундый җентекләп сөйләп бирде, хәтта әле дә хәтердә. Булат дип үлеп тора иде, Галимҗанга насыйп булган икән...

## 19

Ул арада Лена аша үтеп, элек ат абзары булган урынга җиттеләр.
— Килеп җиттек, малай, рәхим ит.
Машинаны туктатып тирә-якка күз салуга, тагын әллә кайчангы бер төн искә төште. Яшьләр таралышкач, юл уңаенда үткәндә каравылчы йортында ут күреп, Булат белән шунда керергә булдылар. Конюх Галимҗан пима төпләп утыра иде.
— Син нәрсә төне буе чемченеп утырасың? Саумы? — диде Булат.
Галимҗан — ул чакта озын какча буйлы, җирән чәчле, унсигез-егермеләрдәге егет — эшен читкә куеп, аяк-үрә торды.
— Ә-ә, әйдәгез, егетләр, түрдән узыгыз. — Сүз тапмый торды. — Тартасызмы? — Ул өстәл өстеннән зур янчык алып сузды.
— Тәмәке безнең күрше Тимербай абзыйныкы, үзәкнең әллә кай җирләренә үтеп керә.
Төрделәр.
— Каравылчы юк мыни, нишләп төн буе үзең утырасың?
— Каравылчы сырхап тора, кайтып китте. Ә бүген Садрый абзыйның теге җирән биясе колынларга тиеш, шуңа үзем кунарга булдым. Тыңлаштырып утырам. Ә сез нәрсә, «сунарда» йөрдегезме әллә?
Булат почмактагы тимер мичкәдән чүмеч тутырып су эчте дә такта кроватька килеп утырды. Заһир да шуннан урын алды һәм:
— Менә ләчтит саттык, — диде. — Йокы да килми.
— Шулай инде, читтән килгәч, безнең тормыш бик ошап та җитмидер. — Галимҗан өстәлдәге иске самаварга ишарә ясады. — Чәй эчәсезме, самовар җылы, бер дигән мәтрүшкә чәе дә бар?
— Рәхмәт. Бу вакытта чәй эчеп утыру...
Галимҗан, серле елмаеп, кароват астыннан тузанга буялган көршәк чыгарды:
— Бездә аның аруракы да бар. Йоклап-нитеп Җирән бияне сизми калырмын дип кенә кагылмадым. Хәзер, өчәү булгач, куркыныч түгел. — Чәшкеләр алып көмешкә салды, ашъяулыкка төрелгән кара икмәк кыерчыгын waклады. — Әйдәгез, исәнлеккә-саулыкка, тазалыкка-байлыкка дигәндәй.
Эчеп, икмәк чәйни башладылар.
— Ару бу, — диде Булат. — Каян?
— Кичен чуашта булган идем. Атнук апага кереп чыктым, ул бит моның мастеры.
— Атнук карчык мастер инде ул. Ну элек ачыган балы шәп була иде аның. Әле дә ачыта микән?
— Ачыта. Ләкин мин көмешкә алдым, колмаклы балдан баш авырта. Сало да биргән иде. Тик урамда пыш-пыш Чтапан очрады, аңа биреп калдырдым.
— Исән мени әле ул?
— Әй, аңа ни булсын? Ул бит карт та түгел... — Ике аякка икәү булсын, — дип, Галимҗан тагын коймакчы иде, Булат:

— Житте,— диде.— Иртәгә иртә торасы бар.

Бераз тын утыргач, Галимҗан:

— Кайда эшләргә уйлыйсың, Булат? Шул тимерлектәдер инде? — диде. Әле Булат ныклап эшли башламаган иде.

— Юк, МТСка китәм. Мин бит армиядә танк йөртүче булдым. Ул трактор гына түгел. Эшли алырмын, дим.

— Шулай инде, һөнәрленең эш башка. Без генә монда... Мин дә армиягә китсәм, берәр һөнәргә өйрәнермен әле.

— Синең һөнәр — ат инде. Сиңа ат җене кагылган дип юкка гына әйтмиләр бит.

— Туйдырды, малай.

— Син дә аттан туйгач...

— Аттан түгел. Аттан туеп буламыни! «Кәҗә»дән туйдым мин!

— Анламадым?..

— «Кәҗә» үзенә кучер итәргә дип теңкәмә тия. Идарә атларын болай да карыйм, ә нишләп шуны утыртып йөрергә тиеш мин? Җенем сөйми шуны! Бер туры китереп анасын...— Галимҗан, кинәт сүзеннән туктап, сикереп торды.— Туктагыз, малайлар, биянең вакыты җитте бугай.— Ул почмакта эленеп торган фонарьне алып филтәсен күтәрде дә ишеккә атлады.

Аңа Булат белән Заһир иярде.

— Әйдә, безнең дә файда тияр, — диде Булат. — Мин кавалерист булмасам да, ат тирәсендә йөргән бар.

Алар ашыгып абзарга юнәлделәр.

... Бу урынны хәзер танырлык түгел. Яшел койма белән уратып алынган зур, верандалы йорт, иркен ихата, бүрәнә каралтылар, ә алар артында бакча күренә. Машина килеп туктау белән капка ачылды. Каршыга Булат, Моталлапов, военком һәм тагын берничә ир, хатын чыкты. Алдан, беләкләрен алъяпкычы белән сөртә-сөртә, таза гәүдәле, мөлаем ханым килеп машинадан төшкән Заһирга якты елмаеп кул сузды:

— Сау гынамы, Заһиркаем! Сине дә күрер көннәребез бар икән!

Заһир Гөлзаһираны төсмерләде.

— Саумы, Гөлзаһира! Менә нинди икәнсең син!

Гөлзаһира нык үзгәрсә дә, төс ташламаган. Өстендәге зәңгәр чәчәкле күлмәк аның һаман яшь зәңгәр күзләренә килешеп тора.

— Сине тормыш җиңә алмый, күрәсең бөтенләй үзгәрмәгәнсең.

Гөлзаһира йөзе тагын да ачылып китте.

— Син һаман шул Заһир икәнсең — элек тә сүзгә оста идең. Әйдә, керегез. Галимҗан, чакыр кунакларны.

Күрешеп-танышып, шаян сүзләр сөйләшә-сөйләшә кул чайкадылар да иркен верандага үттеләр. Монда салкынча. Өстәл өсте тулы ашамлык, эчемлекләр.

Утырышып бетүгә, кухнядан озын буйлы мөлаем хатын чыгып Заһирга куш кул сузды:

— Исәнмесез, Заһир.

Заһир күреште, ләкин танымады.

— Кем дип әйтим...

— Хәмдия. — Булат хатынын биленнән кочаклап үзе янына утыртты. — Минем Хәмдия карчык бу, әллә танымыйсың дамы?

— Куй әле шул «карчыгыңны» — диде Хәмдия үпкәле тавыш белән. — Танымас шул, күпме еллар үтте бит.

Заһирга уңайсыз булып калды. Элек Хәмдияне күрмәгән дә диярлек иде — ул уеннарга чыгып йөрмәде, яшьләр белән аралашмады. Хәзер бу өлкәнәеп барса да чибәр, кыю карашлы хатында теге чактагы чандыр, басынкы хатынны төсмерләп кенә була иде.

— Сезне тануы кыен, Хәмдия ханым, бөтенләй үзгәреп киткәнсез, хәтта яшәргәнсез, дияргә була. Кызлар кебексез.

— Шулай булмый ни, кызымның кызлары үсеп килә инде. — Хәмдия ап-ак тигез тешләрен күрсәтеп елмайды да, Булатка: «Хатын-кыз белән менә ничек сөйләшәләр, ә син «карчык»та «карчык» дип, — аның чәчләрен бутап алды.— Үзенең чәчләре агарганын, бабай икәнен белми.

Булат шаяртуын дәвам итте:

— «Бабай»... Әле мин унҗиде яшьлек кызлардан да баш тартмам.

— Син тартмассың да бит, кызлары нишләр? Иртән торсаң, «уф»та «ух», я билем дә я башым. Бер карт та шулай үлем түшәгендә «кыз, кыз, гыж, гыж» дип яткан ди.

— Дәртле карт булган икән.

— Дәртле булгандыр да бит, дәрманы булмагач...

— Әйе, кесә булудан ни файда, карманы булмагач... — Галимҗан, хуҗа буларак, табынга ишарә итте.— Ягез, агай-эне, бер утыру — бер гомер, гөрләшик әле бергәләп. Заһир, монда яшьләр юк, аларның үз кайгысы — җыелышып клубка киттеләр.

Булат өстәде:

— Сез киткәч «Сәгать»нең рәте калмады... Сораштылар, барын да төпчетделәр. «Галия тавы»ның тарихын сөйләргә туры килде.

— Әйе, — Моталлапов кушылды. — Бик кызыклы тарих. Без военком белән сөйләшеп тордык: тау үзенә күрә бер сугыш истәлеге, һәйкәл дисәк тә ялгыш булмас. Бу бик матур бәйрәмегезне анда үткәреп, яхшы итәсез. Безгә шундый йолаларны киңрәк таратырга кирәктер.

— Әйе, — военком аны куәтләде. — Әнә хәзер сабантуйлар ничек үтә! Заманында тыеп маташкан булдылар — имеш чамадан тыш милли. Карасаң, ул интернациональ бәйрәм икән.

— Дөрес, иптәш подполковник, — диде Булат. — Теге илленче еллар чагында шулай иде. Ул гынамы: көне-төне радиодан немецның Мәскәүгә җиткәнен сөйләделәр, әйтерсең, без, Берлинны алмаган да, немецның астын-өскә китермәгән!

Савыт-саба куеп, сөлгеләр биреп йөргән Гөлзаһира да сүзгә кушылды:

— Ә «Кәҗә»гә ничек җан керде ул чакларда! Күкрәк кагып йөрде бит мөртәт!

Галимҗан көлде:

— Йөрсә ни, Булат аңа кирәген күрсәтте бит инде. — Заһирга борылып аңлатты: — «Кәҗә» амнистиягә эләгеп кайтып төшкәндә Булат парторг иде. Килгән теге моның янына: «Партиягә кире алыгыз, элекке стажым белән», ди икән. Син нәрсә дидең әле, Булат?

— Әйтелде инде.— Булат Заһирга: — Син белмисең бит,— диде,— теге елны, син кайтып киткәннән соң, аны утыртканнар.

— Шулай икән шул, Галимҗан сөйләде.

— Монда бөтен халык, фронтка ярдәмгә дип, җылы киемнәр, төрле самолет эскадрильяләренә, танк колонналарына акчалар биргән...

— Әйе, ул эш мин бар чакта, кырык беренче елның көзендә үк башланды.

— Шулай шул, — Гөлзаһира кушылды. — Исеңдәме, Заһир, бер мәл син доклад ясадың да, «Кызыл Армиягә ярдәмгә» дип, өстәлгә акча салдың? Синең арттан пыш-пыш Чтапан абзый, «пестән дә пулсын — мона пиш йөз» дип, бер төргәк акча чыгарды. Шуннан китте, шуннан китте — өстәл акчага күмелде. Иң кызыгы: халыктан калыр хәле булмагач, Мөслим суфый да эшләпә тасмасы астыннан берлек чыгарып бирде. Моны күреп, Чтапан абзый аны якасыннан алды: «Син нәрсә, сабака, черегән кулак пашың пелән пер тәнкә пирәсеңне? Ал, мә перлегеңне, Кысыл Армия аңа калмаган!» Акчасын йөзенә ыргытты. Әй көлде халык,— яратмыйлар иде шул саранны.

Булат дәвам итте:

— Өч-дүрт имансызы шул изге акчалардан, ятим хатыннарның сабыйлар авызыннан өзеп биргән бүләкләрдән үзләренә өлеш чыгарып, типтереп яшәгән.

— Булмас!

— Булган шул. Галәветдиннең Бишкаендагы сәяркәсе маташтырган.

Заһир, нәфрәтләнеп, сорады:

— Соң, контроль-фәлән булмаган микәнни?

— Контроле шундый булган... Галәветдин дә катнашкан. Председательдән төшергәч, аны шул дуслары налог агенты итеп урнаштырганнар. Без фронтта кан койганда болар кәеф-сафа корып, дөньяның рәхәтен күреп ятканнар. Галәветдин белән теге бичә Бәләбәйдә йорт сатып алганнар. Бер исергәч Кәҗә: «Шундый рәхәтлекләр гомергә булмас инде»,— дип елаган ди кабәхәт!

— Бу бит фашист булу белән бер!

— Артыграк! Фашист — фашист инде ул. Ә бу һаман безнең арада йөри. Бая сиңа «дус» дип килде бит. Кул биреп куймагаең дип, арагызга кердем. — Булат сигарет кабызды. — Килгән бу, «партиягә кире восстановить итегез», ди. Түзмәдем, якасыннан алдым да, чыгарып баскычтан ыргыттым. «Партия — абзар түгел, мин әйтәм, анда кәҗәнен кирәге юк!» Шыңшып нидер әйтмәкче иде, тагын берне кундырдым. Карасам, Гатаулла абзый килә...

— Гатаулла-парторгмы?

— Әйе. Мәрхүм инде хәзер, ул чакта колхоз председателе иде. «Иплэп, Булат, хайванны имгәтерсең», диде. Вот кеше иде, ичмасам! Ә теге адәм актыгы райкомга барган. Анда бер юньсез бар иде—миңа «дело» такмакчы булды.

— Ә теге компаниянең башында кем булган?

Җавапны Галимҗан бирде:

— Онытмасаң, синең «дус». Исеңдәме, бер вакыт яшелчә бакчасына барган идек: син әңгәмә үткәрергә, ә мин — көлтә бәйләүче хатыннарга бераз кавын-карбуз алырга дип. Шунда сиңа полнамуч бәйләнгән иде?

— Теге сыңар күзлеме?

— Әйе, Әсфәндияров, Сайран Имаевич. Райсовет тирәсендә буталып йөри иде. Садрый абзый аңа, беренче күргәннән соң ук, «Хайван Иваныч» дип исем дә кушкан иде.

— Исемдә. — Заһир көлеп хәтерләде: — Ну, тетте ул мине ул чакта. Әңгәмә үткәреп, арбага кавын-карбуз төяп кайтырга гына чыккан идек, рессорлы тарантаста Галәветдин белән киләләр болар. Юл биреп, Галимҗан атны читкә борды. Ә алар туктадылар. «Кемнәр?» — ди. Аңлаттык. «Ә ник гармун белән,— ди,— сугыш вакытында нинди гармун мөмкин?» Галимҗан ярдәмгә килде: «Хатын-кызның әзрәк күңелен күтәрдек». Кызып китте теге: «Әле сез хатын-кыз күңелен күреп йөрисез мени, собатажниклар?» — ди. Мин аңлаткан булдым, «Гафу итегез, хәзер гармунның иң кирәкле чагы, — дим, әнә бит сугыш башлангач күпме яңа җыр чыкты». Бу килешмәде, күрәсең, «демагогия» диде. Минем кулдагы кәгазьләргә «Ә болары нәрсә, тоже күңел күтәргечләрме», ди. Күрсәттем. Стена газетасы да бар иде — аны ябештергәнче шулай эш участокларында укып, күрсәтеп йөри идек. Исеменә бәйләнде — «Көрәш» иде. «Нинди көрәш, кем белән көрәш?» Мин бу сәер сораудан югалып калган идем, Галимҗан: «Гитлерга каршы, фашизмга каршы көрәш», ди... Болай политик яктан суктыруны көтмәгән Әсфәндияров, ни әйтергә белми, тынып калды. Сүгенә-сүгенә киттеләр болар.

Галимҗан Булатка борылды: — Ул «Кәҗә» өчен сиңа әләгә иде дә инде, бәхетең — Мәскәү коткарды.

Заһир бер Булатка, бер Галимҗанга карады. Булат аңлатты:

— Әйе. Шул эш куерып торганда минем Герой икәнлек билгеле булды. Үлгән саналганмын. Ә мин үлеп терелдем.

— Гафу ит, Булат, — диде Заһир, — ә син үзеңнең кабереңбарлыгын беләсеңме?

— Каберем?! — Булат агарынып китте һәм аягүрә басарга теләгәндәй урыныннан кузгалды. Хәмдия аны сул кулы белән билеңнән кочаклап, коты очкан күзләрен Заһирга текәде. Табындашлар аш-суны онытып калды. — Минем каберемме?

— Әйе, Булат, Берлин тирәсендәге туганнар зиратында синең кабереңбар. Тимер плитәдә исемең коелган.

Галимҗан шик белдерде:

— Ай-һай, малай, ялгышмыйсыңмы, исеме генә туры килмиме?

— Тикшердек, дөреслеген документлар раслады. Башта күргәч мин үзем миллион корбаннар арасында Баязитовлар аз булмагандыр, дип уйлаган идем.

Почмактан исе китеп тыңлап утырган әби — Галимҗанның әнисе — тавыш бирде:

— Ходаем! Шулай, үлеп терелгәч, озын гомерле буласың әле, улым. — Аннары ул хәтерендәгене сөйләп алды. — Үлем хәбәреңкилгән иде шул. Зөфәр туганыңның кайгысына синеке өстәлгәч әниең күтәрә алмады — дөнья куйды мескенкәем...

Сүзне, бер Заһирга, бер Булатка карап, Хәлим йомгаклады:

— Заһир, синең дә үле хәбәрең килгән булган бит. Икегез дә үлеп терелгәнсез — озын гомерле булыргадыр...

— Әйе, — диде Гөлзаһира, — шулай гына була күрсен инде. Теге чакта, Булатның әнисен жәлләп, шул кара кәгазьне ничәмә көн кесәмдә йөрттем. Бәй, сугыш беткәч килеп төште бит! Ә берәүләрнең әле дә хәбәре юк, — исәннәр исемлегендә йөриләрдер инде. — Ачынып өстәде: — Әй, бу сугышны! Балалар үскәч — бигрәк куркыта икән ул. Ичмасам, берәрсе кыз булмады бит!

Бераз тынычланган Булат Заһирга:

— Анда минем бөтен экипаж ятадыр әле,— диде.— Бүтән фамилияләр исеңдә калмаганмы? Холмогоров, мәсәлән? Ул танк командиры иде.

— Юк, таныш фамилияне укыгач, мин башкаларына карый да алмадым. Ә булуы бик мөмкин — сезнең экипаж тулысынча һәлак булган санала бит.

— Шулайдыр. — Булат тирән көрсенде. — Мин танк яна башлагач «Фердинанд»ка таранга барганда берсе дә исән түгел иде инде...

Заһир торып басты:

— Соравым, бәлки, урынсыз булгандыр, Булат, гафу ит. Ләкин шунысы: чит илдә кабер өстендә язылган исемең күңелдән бөтен гомерне кичертте. Ә исәнлегеңне белгәч, килеп күрми түземлегем калмады. Һәм менә мин сезнең арада! — Ул рюмкасын тотты. — Сугыш кырларыннан кайта алмаган дусларыбызны искә алыйк.

Барсы да аягүрә басып эчемлек капты.

Аннары, тынлыкны бозып, Булат:

— Мин, ара-тирә газеталарда Хәйдәров фамилиясен күргәндә, — диде Заһирга,— гомергә синдер дип башыма китермәдем. Искә төшкәндә, «Исән булса, я укытучы, я музыкант-фәлән булып йөридер», ди идем. Ә син — генерал! Лена буенда гармун тартып йөргән малай генерал булган! Син генералга охшамагансың да!

Заһир көлде:

— Ә ник, Булат Харитоныч?

— Аны да онытмагансың икән... «Ник», дип, исеңдәме, син мине хәрби училищега китәргә өнди идең? — Булат табындагыларга аңлатты:— МТСта тракторлар ремонтлап ятабыз, бер көнне газета тотып Заһир

килгән. «Менә, Булат, игълан, ди, армиядә действительныйны хезмәт иткәннәрне курска алалар, аннары хәрби училищега җибәрәләр, бар, малай, син коеп куйган командир бит». Бер уйласаң, кызык. Син ул чакта үзең командир булырга хыялланып йөргәнсең икән.

— Дөресен генә әйткәндә, минем хәрби хезмәт турында уйлаганым да юк иде. — Заһир галстугын чишеп урындыкка элде — Гафу итегез, эссе булып китте. Артистлык турында уйлый идем, сугыш башланмаса, бәлки, укырга да киткән булыр идем.

— Ул якка булдыра иден син. — Галимҗан телен шартлатып куйды. — Безне дә әртис итеп бетердең бит. Ә үзең генераллыкка укыгансың.

— Шулай туры килде инде.

— Пошынма, малай, Галимҗан үзе дә генералдан ким түгел, ул— гвардия ефрейторы! — Булат сүзне шаяруга борды.

— Ә нәрсә, — Галимҗан бирешмәде, — солдат өчен иң зур начальник — ефрейтор ул. Бер вакыт...

Гөлзаһира ирен туктатты:

— Ярый, ярый, сүзне үз файдаңа борырга гына торма әле, әнә кунакларыңны сыйла.

— Ә-әй, була ул. Әйдәгез, дуслар, үзебезнең генерал хөрмәтенә берне тотыйк әле. Тагын шулай генераллар белән утырып буламы, юкмы?— Заһирга шаян шелтәләү белән карап: — Формадан кайталар аны,— диде. — Орденнар тагып, фуражканы кырын салып, урамнан бер гармун белән җырлап үтәр идек. Хет, бераз корсак та үстерәләр аны!

Заһир көлеп төрттерде:

— Син бигрәк тә Ягур кызларының эчен яндырып үтәргә ярата идең...

— Булды инде, малай. Яндырдык та, көйдердек тә, йөри белә идек.

Гөлзаһира иренең сүзен җитдигә борды:

— Ул чакта безнең кысылмаган эш булмады бит: колхоз җыелышлары димә, заем үткәрү, карт-корыны уку-язуга өйрәтү, комсомол гаетләре оештыру димә — шул безнең ише кыз-кыркын, малай-шалай алда йөрде. Әй, өлкәннәр ачулана, «имансыз» дип тирги иде! Хәзерге яшьләр әллә ничек — читтәрәк торырга тырыша...

— Хурлама хәзерге яшьләрне. — Булат Гөлзаһираның беләгеннән тотып туктатты. — Вакыты җиткәч алар да, шулай безнең кебек яшьлекләрен сагынып сөйләрләр әле. Ә сөйләр нәрсәләре бар. Менә минем белән ике сезон ярдәмче булып түбәноч Гайнетдин малае эшли...

Мәҗлес кыза төште. Ашау-эчү арасында хатирәләр дәвам итте.

— Курск дугасында чакта, малай... — Галимҗан ниндидер тарих сөйләмәкче иде, аны Хәлим бүлдерде:

— Югославиядә сугышлар каты булды. Бер мәлне мин үземнең автоматчиклар белән...

— Ташла әле син, кода, шуны, — дип кушылды Булат, — менә безнең участокка, Берлин юнәлешендә кызу булды дисәң дә...

Бәхәсләшеп тә алдылар: «Әгәр шунда болай итсәк, шәһәрне тизрәк алып була иде»... «Юк, анда артиллерия түгел, авиация шәбрәк эшләде»...

Заһир йотлыгып тыңлап утырды: «Полководецлармыни! Илләр, шәһәрләр, елгалар, ерак җирләрдәге исемсез калкулыкларны искә алалар. Географияне алар җәяү, янсә танкларда йөреп, ут астында шуышып, янсә бозлы суларда батып өйрәнгәннәр шул. Туган илебез азатлыгы, кечкенә Лена, Чишмә авылларының иминлеге, «Галия каеннарының» яме өчен сугышларда өйрәнгәннәр».

Бу кешеләр арасында Заһирга җиңел дә, рәхәт тә иде: бары да гади, дәрәҗәләр турында уйлау юк. Шатланып, чын күңелдән, тик авылча итеп сөйлыйлар, үткәннәрне ничектер, ирония катыш сагыш белән

искә алалар, ләкин аңардан трагедия ясамыйлар. Хәтта сугышта үлеп калганнар турында да еш кына шаяру катыш сөйләнелә. Батырлыклар, югалтулар турында монда сүз юк — дөньяда әйбәт кеше яшәгән һәм якты эзләр калдырып киткән. Бары да табигый. Таләп итсә — янадан кабатларга әзерләр. Заһирны шул хәттә тетрәтте. Бер караганда үз мәнфәгатьләре белән мавыгып, көндәлек тормышта дөнья өчен бөтенләй әһәмиятсез булган үз авылы вакыйгалары белән яшәгән бу кешеләрнең иминлеген, хәтта язмышын алар түгел, ә кайдадыр, акылга сыймаслык еракта хәл итәләр кебек. Шулай да алардан башка хәл итә алмыйлар.

— Булат дус, — диде Заһир. — Син күпне күргән кеше. Әйт әле: гомереңдә иң истәлекле, иң кадерле, әгәр үткәннәрне кабатлап булса, яңадан бер кат шул чактагы хисләрне кичердәй булып хәтереңдә калган көнең бармы? Соравыма аптырама: минем шундый көнем бар — ул Галимҗан белән беренче мәртәбә Чишмәгә барган көн. Мин шуны эзләп килдем, бәлки, юләрлектер бу?

— Түгел, дускай, түгел — Булат, тәлинкәсен читкәрәк этәреп куйды да, карашын тәрәзәдән яшәреп күренгән каршы тауга текәде. — Минем дә андый көнем бар. — Ул берничә минут сүзсез утырды, күңеле белән үткәннәргә кайтты бугай. Кунаклар да ашау-эчүдән тукталып калды.

— Күп җирләрне гизеп, ут кичеп госпитальдә бер елга якын аунаганнан соң Ленага кайткан беренче көнем ул минем. Иртә яз иде әле. Кар катыш яңгыр ява. Станциядә поезддан төшкәч, олау-фәлән эзләп тормадым, котомкамны аркага астым да, йөгерә-атлый үзебезнең якка карап юл тоттым. Ничә еллар түзгәнне, сәгатьләр генә калгач сабырлыгым җитмәде. Хәмдиям белән дә хат аша сүз куешкан идек. — Ул хатынын аркасыннан сыйпап алды. — Караңгы төшәр алдыннан каршы тауга килеп җиттем. Шунда гына ничектер җиңел булып китте. Солдат паегыма соңгы тапкыр алган махорканы юан итеп төреп кабыздым да, ял итәргә ташка утырдым. Авыл — уч төбендә мени! Анда-монда морҗалардан әкрен генә төтен бөрки. Урамда җан иясе-фәлән күренми. Беренче булып Хәмдияләр ихатасын күзләп чыктым. Сизенмәгәндер — күренмәде. Үзебезнең йорт каршында бер ала сыер йөри. Безнең әүкәш! Әнә ул да читән аша ихатага кереп китте. Менә шул җимерек читән аша үткән ала сыер йөрәкләремне әллә нишләтте. Таудан өч-дүрт сикерүдә диярлек төшеп җиттем. Йөгереп өебезгә килеп кердем. Каршыма киндер ыштаны юка юешеннән каештай ялтырап беткән карт әтием торып басты. Ясап утырган чабатасы идәнгә төште. Әткәй мине кочаклап кысты да башын күкрәккә салып елап җибәрде...

Менә шул көн инде минем гомеремдә иң кадерле, иң рәхәт көнем. Тормышыбыз хәзер җимерек читәнне такта коймага алыштыргандай: бар да бар, бөтенесе әйбәт. Тик чит җирләрдән туган авылыма, әтием кочагына кайту минутларыннан яктырагын да, татлырагын да хәтерләмим. Бүгенгеләр әнә шул сугыштан кайту минутларыннан башлана бит...

Булатның сөйләгәнен тыңлап, әсәрләнеп утырган Заһир ризалашмаска, «Юк, безнең халыкның бүгенгесе Бөек Октябрьдан башлана» дип әйтергә дә уйлаган иде. Тик алай итмәскә булды: монда утырган һәркем Туган илне үзенчә аңлый, аларның һәр кайсысының илебез тарихына билгесез өлеш булып кергән үз язмышы бар бит. Стеладагы егерме тугыз исемне хәтерләде.

— Да-а, — диде Хәлим көрсенеп, — әллә ниләрне искә төшердең син, Булат.

Хәрби комиссар сүз кыстырды:

— Аларны оныту һич гафу итмәслек гөнаһ булыр иде.

— Дөрес. — Хәлим аны куәтләде дә уйчанланып дәвам итте. — Менә мин кайчак төннәрен уйланып ятам да башым бутала башлый. Хәзер

мода китте: ни генә сөйләмәсеннәр — докладмы ул, әңгәмәме, — сугышта катнашучылар турында булса, тоталар да, «Безнең бүгенге бәхетле тормыш өчен...» дип, без мескеннәрне кызгана башлыйлар. Күпләренең тел төбе шуңа бара: имеш без үзебез бәхетсез булганбыз да, хәзерге буынны бәхетле итәр өчен нужа күреп интеккәнбез. Дөрес, хәзер тормыш башка: мал-туар дисеңме, өс-баш дисеңме, ашау-эчү дисеңме. Ә бәхеткә килгәндә, без дә аңардан мәхрүм түгел идек бугай. Берәр үлчәү уйлап чыгарсалар, кемнеке күбрәк тартыр иде әле! Шулай бит, Галимҗан?

— Дөрес! — Галимҗан бизәкле тастымал белән маңгаен сөртә-сөртә, карашларын түшәмгә төбәп бер мәл уйланып утырды. Аннары елмаеп, бераз хыялланып алды. — Колхозда «Җидегән» исемле алмачуар айгыр бар иде. Вәт, малай, ат ичмасам! Шуны иярләп менеп, каеш тезгенне тарта биреп, кепканы кырынырак салып, Чишмә буйлап бер биетеп үтү үзе бер гомер иде...

Хуҗабикә, өстәлгә сый өсти-өсти, үпкәле тавыш белән ирен бүлдерде:

— Әй, синең шул булыр инде — атыңа күчәсең дә китәсең. Ә Озынтау буенда җырлашып печән җыюлар, ярышып йөгерә-йөгерә көлтә бәйләүләр, кызыл олаулар белән стансага ашлык ташулар, аннары шаулашып уңыш бәйрәмнәре үткәрү бәхет түгел идемени? Күңелең көр булса, киемең хөрт булу сизелми дә ул. — Гөлзаһира елмая-елмая кунакларын сыйлады. — Әйдә, ашап кына утырыгыз әле. Галимҗан, ник кыстамыйсың, вазифаңны оныттыңмы әллә?

— Шулаен шулай анын, карчык. — Галимҗан шешәгә үрелде. — Тик карының буш булса, күңелең дә төш була бит. Әйдә, кунаклар, тотыгыз әле.

Хәлим Гөлзаһира яклы булды:

— Сугыш алдыннан ачлык онытылып бара иде инде. — Ул Булатка ишарә итте. — Анау син армиягә киткән елны трудоденьгә тигән ашлыкны йөкләп-йөкләп кызыл әләмнәр белән тараттык. Кемнең салыр урыны юк — капка төбенә аударабыз. Авыл тулы уен-көлке, җырлашу...

— Менә шул шул. Бураң тулы булса, җырлыйсың аны. — Галимҗан көйләп алды:

Күзге байлык — буралар мул,
Шикәр салдык чәйләргә;
Язгы кытлык — улаклар буш,
Икмәк тә юк чәйләргә.

Аннары җитдиләнеп Заһирга:

— Парторг-Гатаулла абзый сүзләре исеңдәме? — диде. — «Килер бер көн,— ди торган иде ул,— бүгенге авырлыклар турында горурланып, сагынып сөйләрсез әле». Менә шул көннәр җиттедер инде. Тормышыбыз гөл кебек, ә күңелебез — үткәндә. Үзе күрә алмады мескен.

Галимҗан, рюмкаларга эчемлек коя-коя, хәтерләде:

— Иң авыры — сугыш беткәннең икенче язында булды. Ел коры килде бит. Өстәвенә әллә нинди ящур дигән имгәге чыгып юк-бар мал кырылды. Гатаулла абзый күргәнне сөйләп бетәрлек түгел инде. Сугышта ике улы үлеп калды, инде җиңдек дигәндә кайгыдан карчыгы егылды. Туйганчы ашаганы, ятып ял иткәне булмады. Шул тәмәкесе белән генә торды бугай. — Галимҗан сүнгән сигаретын кабызды. — Чәчү июнь азагына кадәр сузылды. Бер көнне райсовет председателе килеп төште. Шул, басуларны, фермаларны урап чыккач, идарә җыйдырды. Ну, кыздырган булды. Күреп торабыз инде — эшнең мөшкеллеген аңлый, ләкин ни чара күрсен, бөтен булганы — бер теле. Соңыннан Гатаулла абзыйга бәйләнде бу: «Нишләп син, саботажник, колхоз председателе башың белән шул кадәр сәләмә киенеп йөрисең, авторитет ту

рында уйламыйсың?» — ди. Ул аның гражданнар сугышы герое, карт коммунист икәнен әллә белмәде, әллә белмәмешкә салышты. Мин тешне кысып, «Күрсәтәм мин моңа саботажникны» дип утырганда мәзәк кенә тәкъдим кертте бу: «Колхоз исәбенә костюм алып бирегез, минем алда карар чыгарыгыз», — диде. Кул күтәрдек, карар чыгардык. Мыскыл итмәкче булды бугай, — колхоз кассасында бер тиен акча юклыкны белә иде бит юньсез! Соңыннан Гатаулла абзый хәтта елады мескен. Аңарда нинди костюм кайгысы булсын инде! — Галимҗан сигаретын соңгы тапкыр суырып, ачу белән басып сүндерде. — Үзен дә шул көзне колхоз уставын бозган өчен партиядән чыгарып, эшеннән кудылар — машинасының багажнигына мал җыеп йөргән, ди, барахольщик. Андыйларны фронтта строй алдына чыгарып аталар иде. Шул сволочь аркасында райком секретарына да нык кына эләкте бугай. Бик ипле кеше иде — партия җәзасы биреп түбәнрәк эшкә җибәрделәр.

Табын тынып калудан файдаланып, Заһир тагын Булатка мөрәҗәгать итте:

— Ә бүтән кабатланмасын, дип теләгән кара көнең нинди?

— Авыр чаклар күп булды инде. Үзегез беләсез, мин бит танкта да яндым, якын дусларым һәлак булганын күрдем, — диде Булат. — Әмма коточкыч булып истә калганы, «кире кайтмасын» дигәне бер генә.

— Аны хәтерләсәң дә инде... Хәмдиягә бәйләнгән ул. Үзенә дә сөйләгән юк әле. — Булат хатынына карап икеләнеп торды да, кинәт карар кабул иткәндәй, дәвам итте: — Ярый. Сугыштан элек булды бу кара көн. Кытай границасында, ком чүлендә без яңа танкларны сынадык. Үзәк өзгеч суык ком буранында тәүлек буе сугыш уены уйнадык. Хәлдән таеп казармага кайтуга энем Зөфәрдән хат килгән.— Булат якасын ычкындырды, тагын хатынына карады.— Хәмдия турында — «Кәҗә»гә кияүгә чыгуы хакында иде. Син, карчык, әллә ниләрне искә төшерүем өчен гафу ит,— бүген көне шундый — яшьлеккә кайту көне.— Ул уңайсызланып башын игән Хәмдиянең чәчен сыйпады.— Ул көнне ниләр кичергәнне үзем генә беләм. Кыскасы, андыйны дошманыңа күрсәтмәсен! — Булат бер мәл нидер уйланып утыргач, көтмәгән нәтиҗә ясап, өстәде: — Ә яңа танклар әйбәт булып чыкты. Соңыннан фронтта да аларны очратырга туры килде. Хәзер тагын да яхшырак машиналар бар ди.— Заһирга карап елмайды.— Иптәш генерал, әгәр ул-бу була калса, комбайн штурвалын КВ рычагына алыштыру бер ни түгел, хәтереңдә тот.

Хәрби кеше өчен бу сүзләр аеруча тәэсирле булды. «Әйе, ил уллары — ил терәге. Кичә дә, бүген дә, иртәгә дә...»

Галимҗан аның уен бүлдерде:

— Үзең турында сөйләмәдең дә бит әле, Заһир. Бер кемгә хат та язмадың, кайтмадың да.

— Шулай туры килде инде. Кырык өченче елны мин кайтып киткән идем — сез булмадыгыз. Әнә Гөлзаһира хәтерлидер, коймак пешереп чәйгә дә алган иде.

— Әйе. Тик син ул чакта яраңнан арынып та җитмәгән идең әле.

— Башкача килеп булмады шул. Сезгә кайтып киткәннән соң мин артиллерия училищесын тәмамладым. Ә сугыш беткәч бөтенләйгә армиядә калдым. Хәзер — оборона министрлыгында. Үзем турыда кыскача шул. — Заһир елмаеп Галимҗанга карады һәм рюмкасын күтәрде. — Мөмкин булса, сезнең саулыкка. Кем әйткәндәй, Хәлимне аерым котларга мөмкин: аның Төмәндә оныгы туган икән.

— Котлыйбыз!

— Шулаймыни? Каян белеп өлгергән!

— Каян белү — сер. Иң мөһиме — Хәлимнең ыруы арткан.

— Ыру бар ла ул. Монысы инде дүртенче онык. «Картәтәйне» ишетү күңелле, ә картинәй белән бер түшәккә ятулар — Хәлим сүзне шая-

руга борды. Аннары Заһирга: — Шунысы үкенеч — карчык китеп өлгерде, өй күрсәтеп тә булмады, — диде.

— Үкенмә, күрербез әле — рәхәт алда торсын. Ә Миңзифага миннән сәлам әйт, котла. Ул синең гомер юлдашың икәнлеген белеп шатландым. Дуслар идек бит.

— Шулай ди шул. Ике сүзнең берендә — Заһир. Беренче малайга да синең исемне куштык бит.

— Рәхмәт инде.

Табын тынган арада Галимҗанның почмактан кунаклар сүзен диккать белән тыңлап утырган әнисе башын чайкый-чайкый сүз башлады:

— Әй, балалар, балалар. Сезнең сөйләшү әллә ниләрне хәтерләтте. Кушылып бер сүз әйтим әле. Мин сугышка Галимҗаннан соң абыегызны да озаттым бит. Кайта алмады, мескен. — Ул көрсенеп дәвам итте: — Озынтау буенда печән җыя идек. Ерактан почтальонны күрү белән каршысына чыктым. «Безгәме, Галимҗанымнанмы?» дидем. «Сезгә,— диде,— тик Галимҗаннан түгел». Йөрәкләрем жу итеп китте. Картка повестка икән. Авылга йөгердем. Мунча яктым. Үзе эштән кайтканчы кием-салымын, сохариларын капчыкка тутырып куйдым. Ә иртән, алты айлык кызымны алып, Бишкаенга озата киттем. Стансага алып бармады — барыбер каласыз, балалар янына кайт, диде. Бер итәк бала белән калдым...

— Кыен идеме?

— Ходай күрсәтмәсен..

— Шулай да, әби?

— Төрлесе булгандыр инде. Үзе кайтмаса да, менә улым кайтты, — ул Галимҗанга баш какты. — Балаларымны саклап үстердем. Егермеләп оныгым бар хәзер. Әтисеннән алты айлык булып калган кызымның кызы да җитте инде.— Әби бераз уйланып утырды да килененә карады.— Иң авыры Гөлзаһира җилкәсенә төште бугай. Нигъмәтулла киткәч, ул бригадир булды бит.

— Әй, әнкәй, төрле чагы булды инде. Заһир, исеңдәме, гармун белән карабодай җыйганыбыз?

— Ә-ә, теге Рамазан тавындамы?

— Әйе, — Гөлзаһира көлеп сөйләп китте: — Сугыш чыккан елны иген бигрәк уңган иде бит. Ә җыярга өлгермәдек — көн дә әрмис озатабыз, эш кешеләре китеп бетте. Бер көнне, караңгы төшәр алдыннан, районнан телефонограмма килеп төште: төнлә кар явачак, буран чыгачак, диелгән, тизрәк мөмкин кадәр җыярга тырышыгыз. Ә безнең карабодай — күбәдә. Анда-монда йөгердем — берәү дә юк. Заһир янына килдем, хәлне сөйләп бирдем, нишлибез, мин әйтәм. Бу әзрәк уйланып торды да, гармунын алып, «Әйдә, диде, мин уйнармын, ә син җырла». Аптырап киттем, әллә мыскыл итәме, дим. Әмма нишлисең? Баскычтан ук уйнап җибәрде! Ә мин, исәр, үзем җырлыйм, үзем елыйм. Шулай урамны бер әйләнүгә яше-карты чыкты — «Ни булган да, ни булган?» Бәй, сугыш башлангач алай йөрмәделәр бит. «Әллә сугыш беткәнме?»— диләр. Җыелышып мәктәпкә килдек. Заһир: «Укы», — диде. Теге телефонограмманы кычкырып укыдым, ә бу: «Әйдәгез коткарыйк карабодайны, сугышка, кар болытына үч итеп, җырлашып эшлик!» диде. Юл уңаенда сәнәк-тырма алып, җырлашып тауга мендек, күбәләрне җыеп кибән салдык. Таң алдыннан, чыннан да, каты җил чыкты, кар ява башлады. Ә без җырлый-җырлый кайтып киттек. Кызык бит бер уйласаң! — Гөлзаһира күзләрен сөртте. — Ашап кына утырыгыз әле, Заһир, менә бәлешеннән авыз ит.

Заһир бәлеш төбен тәмләп карады.

— Әй остасың икән, Гөлзаһира, — ни капсаң — телләреңне йотырлык. Әллә берәр серен беләсең инде?

Мактауга Гөлзаһираның бит урталары алланып китте.

— Жылы сүзең өчен рәхмәт, Заһир. Синең килеп чыгуың шундый күңелле булды әле. Әллә ниләр искә төште.

— Без күбрәк үткәннәр турында сөйләшәбез. Бәлки, башкача мөмкин дә түгелдер: «Галия тавында» барыбыз да яшьлегебезгә кайткандай булдык. Моңа мин гаепледер. — Заһир елмаеп тирә-ягына карады.— Сездән башка бер кем белән дә ул заманнар турында сөйләшкәнем юк минем, һәм аны сөйләп кенә аңлатып та булмый: сүзләрне аңлыйлар да кебек, тик нечкәлекләренә төшендерү кыен.

— Әйе, — Булат аны бүлдерде. — Сүз белән генә аларны аңлатып та булмый. Госпитальдә чакта минем сынаганым булды: баштан узганнарны шул кадәр сагынып сөйлисең — аңлап җитмиләр. Бер мари егете ята иде, шуның бар белгәне — туйганчы бәрәңгене киндер мае белән ашау булды. Ул да мескен сагынгандыр инде, аңлап торам — сөйләгәне бәрәңге түгел, өе, якыннары турында, ә миңа җитми. Мин сөйләгәнне ул аңламый.

— Шулай инде, — Галимҗан тамагын кырып кушылды. — Мин сугышта сабантуе турында сөйли идем, ә аны җыелышып эчү дип аңлыйлар. Уйласаң, минем истә бер дә эчү калмаган...

Почмактан подполковникның тавышы ишетелде:

— Моңа Твардовский да гаепле. Ул бит үзенең «Теркинында» сабантуйны тәртипсез бер мәҗлес дип аңлата.

— Кызык. — Заһир дәвам итте. — Сезнең дә бу хәлне сынаганыгыз бар икән. Ә хәзер тормышларыгыз ничек?

Барсы өчен Галимҗан җавап бирде:

— Тормышлар, Заһир, русчалап әйткәндә, дай бог каждому, тамак тук, өс бөтен, дигәндәй, ару гына дөнья көтеп ятабыз.

Заһир элекке мәктәп урынын хәтерләде.

— Бик матур һәйкәл салып куйгансыз икән...

— Булат эше. Ягур очында яңа мәктәп салгач, ул монда бакча утыртырга бөтен халыкны күтәрде. Иң шатланганы әби-сәби булды: иртән, көтү кугач шунда җыелышып, ирләрен, малайларын искә алалар, елашып, укынып утыралар.

— Ә үзегез соң, үзегез? — диде Хәмдия елмаеп.

— Ә нәрсә үзебез?

— Һәр кичне диярлек шунда мыңгырдашып утырасыз түгелме?

Булат җитдиләнеп китте:

— Изге урынга әйләнде. Анда сөйләшеп утыру — кайта алмаганнарга отчет биргән кебек. Икенче көнне илһамланыбрак, җилкенебрәк эшлисең.

Кичә Заһир, күптәнге дусларын очраткандай шатланып, Уфада чыккан газета-журналларны укыды, коттеджда булган китапларны актарды. Булатның әлеге сүзләре хәтердә калган шигырь юлларын кабатлагандай иде. Үз буыны турында шагыйрь Әнгам Атнабаев — безнең кордаш булса кирәк?! — шулай дигән:

Яндырдылар — янмый чыкты,
Тундырдылар — туңмады;
Чигенгән чак булса булды,
Җиңелгән чак булмады.

Җилкәләрдә — заман йөге,
Тау артында тау әле,
Таулар аша юллар ярып
Барасылар бар әле...

## 20

Ишектә ике егет күренде, берсе бая Заһир белән сөйләшеп утырган Мансур иде. Аларның кыяр-кыймас кына исәнләшүе булды, Гөлзаһира озын буйлы, киң йөзле, заманча итеп үстергән чәчлесен, аркасыннан сөеп, Заһир янына китерде.

— Менә безнең төпчек.

Заһир торып кул сузды.

— Мәхмүт,— диде егет. Аннары Мансурга күрсәтте.— Ә бу Мансур.

— Мансур белән без таныш. Я, клубта эшләр ничек?

— Анда, ни, шәп инде, — диде Мансур. — Бишкаеннан кыллы квартет килгән. Шундый уйныйлар! Тик бигрәк тавыш — электрогитаралары белән колакны тондырдылар.

Мәхмүт, көлеп, әле утырып та җитмәгән тавыш белән өстәде:

— Энерговооруженность югары аларда. Түзмәдек, шым гына чыгып тайдык. Олылар нишли икән дидек.

— Әйдә, ашагыз, балалар, — Гөлзаһира яшьләр алдына ит куйды.

— Без буфетта капкалап алдык инде, әни. Кунакларны сыйла. — Мәхмүт Заһирга текәлеп карап торды. — Ә мин сезне примерно шулай күз алдына китерә идем дә,— диде.— Безнең өйдә сезне еш телгә алалар. Особенно эти, әз генә кызып алдымы, мактана башлый: «Вот без идек» тә, «Вот без йөри идек!» Сөйләвенә караганда, колхозның нәсел айгырын сез Чишмә чабыр өчен генә тотканнар мыни! — Ул этисенә карап көлде.

— А как же! — Галимҗан канәгатьләнеп мыегын сыпырды. — Йөри белдек инде, не то што...

Гөлзаһира аны бүлдерде:

— Ярый, ярый, кибәк очырырга гына торма. Әнә, кунакларны кара.

— Очырасы-нитәсе юк, яшь чак — заман чак. Ә син, улым, кунаклар хөрмәтенә бер сыздырып җибәрсәң шәп булыр иде.

Мәхмүт кайдандыр курай чыгарды.

— Вот, молодец! Ә мин сиңа кушылырмын, — Хәлим өстәл астыннан гармунын алды. Гөлзаһира аны бүлдереп:

— Заһир, баядан бирле сорарга кыймый торам,— диде,— гармуның исәнме? Яраланып кайтканда яныңда юк иде.

— Ул гармун юк, фронтта аны мина ярчыгы теткәләп ташлады. Мин башта пулеметчы идем бит, «Максим»да. Пулемет ячейкасына мина туры килде, гармун да шунда иде. Ә без читтәрәк ашарга әзерләп калдык...

— Ярый әле үзең шул ячейкада булмаган.

— «Максим» шәп нәрсә иде ул!— Инде кыза башлаган Галимҗан табынга аңлатты.— Гармуның, малай, солдат үлеме белән үлгән. Гатаулла-парторг аны юкка гына «культура фронты коралы» димәгән икән.

Булат нидер хәтерләп сорады:

— Әтиең гражданнар сугышында шул гармун белән йөргәнме?

— Әйе.

— Менә бит, малай, гармун да, ике сугышта катнашып, окопта һәлак булсын инде! Фронтовик дус кебек кызганыч булып китте.

Заһир Гөлзаһирага карады:

— Хәзер дә гармуным бар. Урта Азиядә хезмәт иткәндә дуслар, иске тальянга яңа корпус эшләтеп, туган көнемә бүләк иттеләр. — Моңсу көлемсерәде. — Вакыт-вакыт, эч пошып киткәндә, уйнап, шыңшып утырам. Картлык якынлашкан саен яшь чактагы көйләр дә моңлырак, кадерлерәк була икән. Әллә инде һәр кайсын үзенчә бер тарихка бәйләп уйнаганга?!. — Заһир уйчан карашын Хәлимнең гармунына ташлады. — Бая тауда уйнаган гармун шулмы?

— Әйе. Синең көеңне без алай җиренә җиткереп уйный алмыйбыз. Йөрәкләрне кузгаттың бит! Әллә тагын бер сыздырасыңмы?

— Рәхмәт. Мин үзем дә ул көйне бик сирәк уйныйм хәзер. Яшьләрне тыңлыйк. — Заһирның яңадан йөрәген кузгатасы килми иде — бо-

лай да соңгы тәүлек бушка үтми бугай шул — йөрәк дигәнең үзен сиздерә башлады.

Мәхмүт кураен иренена терәде. Ул кирәкле тонны тапкач, аңа Хәлим кушылды. Верандада инде онытылып барган «Кара урман» моңы агыла! Табындашларның йөзләре үзгәреп, җитдиләнеп китте. Җырның кушымта өлешенә җиткәч, Булат, башын каера төшеп, уң кулын болгый-болгый җыр башлады:

Карурманны чыккан чакта
Кисеп алдым кушкаен...

— Ә-ә-ә-әй! — дип, аны кунаклар күтәреп алды:

Аерылышмыйк, дускаем!
Ә-ә-әй, аерылышмыйк, дусларым!

Кушымта кабатлангач, улының иңбашына кулын салып кунакларга елмайды да матур гына тавыш белән Гөлзаһира, сузып җырлап җибәрде:

Кара да гына урман,
Караңгы төн...

Галимҗан аңа кушылды:

...Яхшы атлар кирәк үтәргә...

Аннары бөтенесе бергә:

Карурманны чыккан чакта,
Кәккүк кычкырган чакта...

Ә-ә-әй!.. дип алгач җыр тагын сузылды:

Сагынам сезне шул чакта,
Ә-ә-әй, сагынам сезне шул чакта.

Заһирда бу җыр Озынтау урманын хәтерләтә. Әле дә күз алдына шул килеп басты.

Аны юкка гына Озынтау димәгәннәр: юл берничә чакрым үргә менә дә куе урманга килеп керә, аннары Бишкаен уйсулыгы башлана.

Сугыш башланган елда укытучыларның август конференциясенә алар бергә барырга булдылар. Галия иртүк үз каеннары янында көтеп торды, ә Заһир ат җигеп килде. Галимҗан атны, тарантасны үзе сайлап җикте: «Бер фарсит итеп кайтыгыз»,— дип озатып калды.

Озынтау урманына кергәндә, кояш әле яңа чыгып килә иде. Иртәнге урман — әкият дөньясы кебек: матур да, серле дә. Сергә — сер, ямьгә ямь өстәп, Галия үзенең көмеш тавышы белән җыр башлады:

Кара да гына урман...

Кошлар сайравыннан туктап, урман тынып калгандай булды. Заһир, чиксез илһамланып җырлаган Галиясенең күзләренә карап, гаҗәпләнүеннән, үзе дә сизмәстән, дилбегәне тартып атны туктатты: сөйгәненең күз каралары мәһабәт каеннар, зәп-зәңгәр күк белән тулы, ә керфекләрендә яшь иде. Көтмәгәндә, гомерендә беренче мәртәбә ниндидер аңлашылмаслык сызлану аның йөрәген кинәт кисеп үтте: Галия бу минутта аңа искиткеч якын да, ничектер кызганыч та иде. Башына шомлы уй килде: «Әгәр мин аны югалтсам...»

Армиягә китү мәсьәләсе хәл ителгән, эш тик срогы ачыклануда гына иде инде. Ополчение отрядлары комиссарлары кинәшмәсендә Заһир үзен фронтка җибәрүләрен сорап язган гариза язмышын белергә теләгәч, районның хәрби комиссары аңа: «Чират җитә, чак кына сабыр ит», диде. Ә Галия ул турыда белми, «Синең елгылар быел китмәс, ә аннары сугыш та бәлки бетәр», — дип үзен юата иде.

Бүген дә йөрәкне шундый сызлау ярып-ярып үтә. «Белгән булсам,

шунда туйганчы, күз кабакларым талганчы карап калган булыр идем. Ә мин, тойгыларымнан уңайсызланып, шаярган булдым: «Ат та сине тыктап тыңлый, Галия, конференциягә соңлыйбыз ич». Бишкаенга җиткәнче дәшми уйланып барды. Әгәр белгән булсам...»

Кояш баер алдыннан ишектә вертолет командиры күренде.

— Саумысыз! — Ул Заһирга честь бирде.— Иптәш генерал, китәр булсак, кузгалырга вакыт.

— Рәхмәт, хәзер китәбез.

Кунаклар, шаулашып урыннарыннан торды.

— Күргән кебек тә булмадык...

— Кунып кына китеп булмыймыни?

— Рәхмәт, дуслар. Миңа иртәгә Мәскәүдә булырга кирәк, — Заһир бер тын дәшми торды. — Күргәннәремне, ишеткәннәремне сүз белән генә әйтеп бетерә алмыйм. Сезнең шулай яшәвегезне, барлыгыгызны тою минем өчен язмышның зур бүләгедер инде. Хушыгыз, дуслар!

Бөтенесе җыелышып аны озата китте.

*
* *

Заһир вертолетка менәр алдыннан Булат аны, култыклап, озатучылардан читкә алып китте. Бераз сөйләшми баргач, ул авыр сулап, карлыккан тавыш белән:

— Заһир, гафу ит, малай,— диде.— Беребезнең дә сорарга тел бармады: Галияң кайда синең?

Заһир көрсенде:

— Галия юктыр, ахры, Булат. Күп эзләдем — таба алмадым. Радистлар курсын тәмамлагач, ул дошман тылына җибәрелгән булган. Шунда эзе югала. Группа турында, аның кире кайтмавыннан тыш, бер ни дә билгеле түгел. Күпме гомер үтте...

— Да-а. Кызганыч...

— Бик кызганыч, тик ни хәл итәсең...

Заһир Булатның беләген кысты.

* * *

Вертолет салмак кына күтәрелде. Кул яки яулык болгаучылар, бәләкәйләнгәннән-бәләкәйләнә барып, каршы таулар тезмәсе белән капланды, Лена үзәне, сузылып, кайдадыр зәңгәр офыкка шуышты. Баеп барган кояш нурлары, ак болытларны сөңге булып кисеп, «Галия каеннары»на тоташты.

Хуш, Лена, хуш, Чишмә, хушыгыз, дуслар!

Озак еллар күрешергә өметләнеп, киләчәктә зур шатлыклар кичерәсен тоеп типкән йөрәкне боек сагыш чорнап алды.

Хуш, Галиям — чибәр кызыкай! Гомер булып, тагын монда килеп чыгасы, каеннарың шаулавын тыңлыйсы иде...

Заһир, мотор тавышына кушылып, эчтән үз көен көйли башлады. Ул һаман дәртле дә, моңлы да иде. Һаман нидер аңларга да, аңлатырга да тырыша, шашынып, кемнедер чакыра да, куа да, шатлана да, үксеп елый да...

*1978.*

Равил Фәйзуллин

*Соңгы елларда мине татар музыкасы тарихы кызыксындыра. Бай дөнья, әле аз өйрәнелгән дөнья. Үткән еллар сәхифәләрен актарган саен гыйбрәтле вакыйгаларга, күренекле шәхесләргә тап буласың. Халыкның сөекле композиторы Салих Сәйдәшев әнә шундый шәхесләрнең берсе. Шактый еллар буе мин С. Сәйдәшевның тормышын һәм иҗат юлын өйрәндем. «Атаклы кешеләр тормышы» сериясендә чыга торган әсәрләргә охшаш проза китабы язарга иде ниятем. Әмма хәзергә поэма рәвешендәге шактый күләмле әсәр туды. Журнал укучыларына шул поэманың кайбер өзекләрен тәкъдим итәм.*

*АВТОР.*

# СӘЙДӘШ

## Тукталыш

Әкертен, җил, монда кабер,
монда анам күмелгән!..

*«Анам кабере янында» җырыннан.*

...«Сәйдәш» тукталышы. Ашыгып төшәм.
Беркем көтми. Мин болай гына...
Гашыйк сыман хисләнсәм дә ярый —
үз ягым ла, татар ягы ла!

«Сәйдәш» тукталышы — ул минем чат.
Шуннан китә урамы башы.
Һәр тәрәздән ул карыйдыр кебек,
Искә төшерә һәр нигез ташы.
Иркенәеп йөрим, рухым белән
шушы якта торганга күрә.
Йомыш белән түгел, күңел белән
килгән төшем булганга күрә.

Кешегә кирәк кайчак тукталу —
тукталып торып, уйланып алу.
Тукталган төшең иманлы булса,
туктап тору да — ул алга бару!
Бар — күңелләрнең тукталышлары.
Бар — гомерләрнең тукталышлары.

Безнең тукталыш — Идел туфрагы.
Үзәге — Казан — аның бер ягы.
Үзенә җыя төрле тарафтан
үз кавеменә гашыйк җаннарны.
Безнең тукталыш — шул Казан инде.
Күп язмышларны кайнаткан кала.
Елаткан кала, юаткан кала,
утлардан алып, суга аткан кала!

Әй, син дә, кардәш, күңелең салып,
туктап тыңла бер шушы урында.
Әйтер сүзем бар — халыкның бөек,
Олы язмышлы улы турында.

## Гасыр башланганда

Кара урман шаулый, ирек даулый,
Ирек даулый качкын егетләргә!
*«Кара урман» җырыннан*

Ул — Сәйдәшев, Җамалетдин улы
Салих булыр — егет солтаны.
Еллар үткәч, шушы гади исем
дөнья гизәр, булыр ил даны.
Әтисе аның — Җамалетдин агай,
Дәбъяз ягы, Өбрә авылыннан.
Ә әнисе — чибәр Мәхүпҗамал —
Казан кызы, Идел ярыннан.
Чигүче ул. Күпме гөлбизәкләр
калфакларга чигелеп калгандыр!
Күпме җыры, хыяллары — чигү
җепләренә ияреп баргандыр!
Җамалетдин — байда мал йөртүче.
Шәһәрдә дә атын җуймаган.
Арба-чаналардан эз калдырып,
нужа чиккән озын юлларда.

...Әйдә, агай, тарттыр дилбегәңне! —
уйнасын җил ат ялларында!
Ни пычагым булсын, кешеләрне
алдап җыйган бай малларына!
Маллар түгел, дөнья үзе дә әле
тезгененә эләгеп чак тора!
Эшче халкы күтәрелгән саен,
хаким сыйныф тора калтырап!

. . . . . . . . . . . . .

Менә шулай, Җамалетдин ага,
улың туа гасыр башында.
Һәрбер дәвер, үз сынавы белән,
һәр туганның — баса каршына.
Туа шундыйлары — җаны белән
ия булып илаһ көчләргә —
үз халкының рухи рәсемен ясый
сүздә, авазларда, төсләрдә.
Безнең халыкның да тиештер бит

рух куәтен җиһан күрергә!
Күпме талант ничә гасыр буе,
бугазлары киселеп, күмелгән...
Бу гасырда бәлки чыга алыр,
күренә алыр безнең егетләр?
Алда — революция, алда — хөрлек,
акланырга тиеш өметләр!

...Әйдә, агай, каула-ку атыңны!
Җырлап җибәр халык көйләрен!
Җамалетдин әле белми, улы
туганчы ук үзе үләрен...

## «Я сәүдәгәр булсын, я мулла!»

Идел буе яшел таш...
Ник елыйсың, яшь туташ?
Мин еламый кем еласын —
Үзем ятим, үзем яшь.

*Халык җырыннан*

Ятимлекне кемнәр татымаган! —
гаиләдәме, дәүләтендәме...
Ярдәмне бик күрмәсә дә ятим,
күп күрә ул өйрәтүләрне.
Салих инде шәкерт. Буй-сын үсә.
Сыйныфлар да үтелә берәмләп.
Тик өйт кенә, шытырдатып укыр
һәр сүрәне сиңа корьәннән!
Сабак вакытлары тиз үтә шул!
Ә аннан соң нишләр бу бала?
Ярым ятим бала үстергәндә
нинди уйлар уйламас ана!
«Мәхүпҗамал, улың үсеп килә!
Эшкә кертик, яшьли өйрәнсен!
Приказчиклар янына урнаштырыйк,
күрә торсын кибет тирәсен...»
«Мәхүпҗамал, киңәш: улың Салих
дин сабагын ныграк өйрәнсен!
Безнең нәселдән дә берәр мулла
чыгып куюы бар, белмәссең!»
Төрле яктан төрле киңәш ява:
«Мәхүпҗамал килен, нык уйла!
Улыңны син кеше итим дисәң,—
Я сәүдәгәр булсын, я мулла!»

Туган-кардәш әйтмәс начарлыкка,
киңәшләре дөрес тә төсле...
Ә җизнәсе тагын ни дияр бит,
җизнәсе бит укыган кеше!
Әйтте Шиһап [1]: «Син анасы аның,
ни теләвең, әлбәт, синең эш.

[1] Шиһап — Шиһап Әхмеров — педагог, мәгърифәтче, татар мәдәнияты тарихында якты эз калдырган шәхес. Ул, шулай ук, Салих Сәйдәшевнең шәхси тормышында һәм композитор булып китүендә хәлиткеч роль уйнаган.

Мондый чакта хәтта ана да әүвәл,
бала күңелен тыңларга тиеш!»

Ә Салихның күңеле бүтәндә шул,
башка юлда гаме, уйлары...
Кичә Ташаякта [1] күреп кайткан
бер останың гармун уйнавын.
Күз алдында һаман: ярминкәнең
утырганда бер почмагында,
яше-карты, сихерләнгән сыман,
җыелышып тора янында.
Әй, уйный соң! Бар бит кешеләр!
Кеше генә микән соң алар?

...Салих төштә күрде: күктә гармун
уйнап йөри фәрештә җаннар!

Ә уянса... нинди могҗиза бу?—
өстәлендә тора чын гармун!
Үрелеп ал да, теге оста күк,
уйнап җибәр көйләр, чыгар моң!
Бар икән ул бәхет, бар, әгәр
хыялдагы килеп, чын булса!
Әйдә, Салих, уйнап җибәр әле,
күңелеңдә ташыр моң булса!

## Шәрыкъ клубы

Җанга якын йортлар калалмыйлар
макет-фотоларга төшеп тә...
Бульдозерлар — көчле. Төртә — ишә.
Тигезли дә куя. Эш бетә...

Түрәләрдән бик озак рөхсәт даулап,
искә алып байлар көен дә,
рухи ихтыяҗдан туган бина
әверелгән халык өенә.
Патша сарае күк түгел инде,
Шамил йортына [2] да җитә алмас...
Изге эш дип, садә җаннар уйса,
гади таш та, гүя чын алмаз!

Гали сүзләр белән дөньяга
сабый бала аваз салгандай,
монда янә тавыш бирә башлый
халык рухы, терелеп яңадан.
Евангелийский [3] урамында
(бер исеме генә ни тора!)
Мәшһүр Болгар белән күрше генә
өч катлы бер җыйнак йорт тора.

---

[1] Ташаяк — революциягә кадәр Казан суы буенда, хәзер цирк урнашкан тирәләрдә мәшһүр Ташаяк ярминкәсе уздырыла торган булган.

[2] Шамил йорты — мәшһүр шәех Шамилнең оныгы, генерал-майор Заһид Шамил торган йорт күз алдында тотыла.

[3] Евангелийский — хәзерге Татарстан урамы.

Бу тирәдән, белмим, кемнәр, ничек,
нинди уйлар уйлап узадыр...
Аванпосты Олы Яңарышның,
ул — учагы милли узаңның!
Монда — театрның башлангычы,
яңа чоры — әдәбиятның.
Монда — көрәш, яшьнәү рухы сеңгән
кирпеченә кадәр һәр катның!
«Сәйяр»[1] тамашасы, Тукай сүзе,
Әмирханлы милли кичәләр,
Мулланурлар чыгышы... Уйлап баксаң,
күп шәхесләр искә төшәләр.
Талантларны бергә җыйган клуб,
яшь көчләрне чакырып эндәшкән.
Монда иң беренче сынау бирә
безнең герой — япь-яшь Сәйдәш тә.

«Аккош маршы»[2]н уйный безнең Салих,
Бөтен бер зал — аның хөкемендә.
Бик күпләрнең әле, сагынып-сагынып,
хәтерләре кайтыр бу көнгә!

Алгы рәттә утыра Кариев[3].
Күңеле аның нинди уй-гамьдә?
«Мондый көйле халык — бөек халык,
мондый халык үлмәс!» — ди мәллә?
Фатих Әмирханның үз уйлары:
«Бу малайда очкын-ут яна!
Болай булса, Шәрык йоклап ятмый,
Шәрык тора, Шәрык уяна!»
Галиәсгар[4] агай ни ди? Шөкер,
дустанә бер нур бар күзендә.
Канәгатьтер, ахры, бу сынаудан
Заһидулла[5] әбзый үзе дә.
Тукай исән булса, бик ихтимал,
шатлык балкыр иде йөзендә.

...Баш игәндә, аның Тукай белән
карашлары очрашалмады.
Заманалар килгәч, чорлар аша
тоташырлар бергә урамнары!
Зур сәхнәдән бүген аваз салды
горурлыгы килер көннәрнең.
Ораторлар әйтер бер көн: «Сәйдәш —
Тукае ул безнең көйләрнең!»

## Көзге ачы җилләрдә

Ком бураны, ком бураны,
Оренбурның урамы.
Илдә көрәш барган чакта
Өйдә ятып буламы?

*«Ком бураны»* **җырыннан.**

Оренбур ул — татар-башкорт җире.

---

[1] «Сәйяр» — тәүге татар театр труппаларының берсе.
[2] «Аккош маршы» — атаклы скрипкачы Хәйбулла Әхмәдуллин әсәре. Революциягә кадәрге елларда бик популяр булган.
[3] Кариев — Габдулла Кариев.
[4] Галиәсгар — Галиәсгар Камал.
[5] Заһидулла — Заһидулла Яруллин.

Оренбур ул — кәрвансарайлы.
Ул — Европа һәм Азия чаты,
ул — капкасы чиксез даланың.
Бөтен илне ут ураган чакта
бер Оренбур гына каламы?
Быел гына аны төрле яктан
ничә тапкыр яулар камады!
Саклар өчен көрәш казанышын,
яшь көчләрне ала ил дәшеп.
Оренбурда хәзер кызылармеец —
Казан егете Салих Сәйдәшев.
Таңны ярып, «вакыт торырга!» дип,
быргы кычкыртучы кем дисез?
Бөеклеге түгел, исеме дә
күпләр өчен әле билгесез.
Ул —бер солдат. Яше — унтугызда.
Үзе теләп килгән фронтка.
Сыный аны тормыш, сыный көрәш,
бер суларга кертеп, бер утка.
Алда — поход... Канлы, тузанлы юл...
Газаплар да анда, җиңү дә.
Ир-егеткә солдатлыкта йөрү —
бер чыныгу була кемдә.

. . . . . . . . . . . . . .

Туплар тынып торган араларда
Киң Төркстан далаларында,
нинди генә уйлар килми дисең
Җир-әнкәнең балаларына!
Дары төтеннәрен читкә куып,
килә моң да, килә сагыш та.
Сөйгән ярлар, туган якның ае,
дулкынланып торган арышлар...
Безнең яктан, ахры, бу ак болыт?
Безнең җирдән, ахры, бу кош та!
Бик ямансу булып китте әле,
сузып җибәр әле, әй, дускай!

«Йөгереп китәрдәй булам ла,
Кайтып җитәрдәй булам,
Күзгә ачы җилләрдә ләй,
Туган үскән илләргә!..»

Моңлы җырны ялгыз тыңлау яхшы,
ә бу җырны — кирәк күмәкләп!
Солдат сагышы бу. Җырлаганда
үрсәләнеп тибә йөрәкләр!

...Туп ухылдап аваз салган чакта,
әйтәләр бит: Муза тын торыр.
Сугыш түгел, Яшәү мәңгелек бит,
бу кан кою туктар, бер тыныр.
Тыныр.
Хезмәт халкына соң ни кыйбат?
Азат тормыш, тыныч ил кыйбат!
Шуның өчен дә бит революция!
Шуның өчен дә бит инкыйляб!

Сугыш соңы безнең Салихны да
Оренбурга янә ташлады.
Ике-өч елда нинди генә мәхшәр
күрмәде икән солдат башлары!
Әй, Оренбур! Ирек, хөрлек җире!
Бер кардәшне сыендыр әле!
Күңеленә кулай хезмәт биреп,
илһам биреп сөендер әле!
Ил даны өчен яралган җанны
яңа казалардан сакла син!
Казаннарга барып ярышырлык
шәхесләрне биргән як ла син!

Эшкә чумды Салих. Вакыты җитми —
белем дә ал, рәттән эшлә дә...
Оркестрны ничек көчәйтергә?
Бу ансамбль белән нишләргә?
Әле анда чыгыш, әле монда...
Сусаган ил җырга-көйләргә.
Яшьләр бурычы — яңа тормыш ямен
яңа җырлар белән сөйләргә!
Чакыралар агитбригадада
Азиягә — Ташкент ягына.
Салих күңелендә, очар коштай,
туар җырлар канат кагына.
«Озын сәфәр» туды, «Татар вальсы»...
Болай булса, эшләр барачак!
Күңел ташый. Агыла моң да, дәрт тә —
килде, ахры, күкрәр, янар чак!

## Театр

«Театраль чаткылар
Яңа Кояшның беренче нурлары».

*Мулланур Вахитов*

Татар халкын кәмит-тамашасыз
күз алдына китерү кыен хәл.
Сәйдәш дөньясын син белим дисәң,
Театрны аңла иң әүвәл!
Театр ул — халык рухының
тантанасы, шатлык-кайгысы.
Егерменче еллар театрын
күз алдына китерә алмыйсың
Сәйдәшсез син. Сәйдәш — театрны,
ә театр — аны үрләткән.
...һәм ул еллар — күпләр хәтерендә
Саклана лар газиз бүләктәй!

. . . . . . . . . . . .

Күр бишенче еллар яңгырашын!
«Сәйяр» чыкты, «Нур»лар балкыды!
Набат какты заман: вакыт җитте!
Яула, расла рухи хакыңны!
Шифа җилләр күмелергә яткан
күпме талантларны калкытты!
Ыргылдылар алар яктылыкка!
үзләренә әйдәп халыкны.

Хөррият килде! Золым карачкысы — зур
сәмругъ кош канда тончыкты!
Ирек килде! Кара мунчалардан
скрипка, гармуннар чыкты.
Җиң эченнән кубызлар чыкты,
итек кунычыннан — курайлар!..
Тиздән менә спектакльне дә
оркестрлар белән куярлар!

...Оренбурга — Салих Сәйдәшевка
Хәбәр килде беркөн Казаннан:
Дәүләт театры оешкан, ди,
шунда эшкә чакырып язганнар.
Дәүләт театры! Уен мени!
Уйлата да, кызыктыра да.
Труппалар, димәк, сукбайлыктан
чыгып, хәзер яңа юл яра!
Туган яктан килгән чакыруга
сагынулар килеп кушылды.
Анда — әнкәй, дуслар, анда Идел...
Әй, Оренбур! Сау бул, хуш инде!

Ә театр чынлап яңа икән!
Артистларның уен, рух бөтен!
Тинчуринга — үрнәк театрны
оештыру йөкләнгән икән.
«Кәбәм, Салих, безнең уртак эшне
«Башмагым»нан башлап карыйбыз.
«Башмак» яхшы чыкса, белеп булмый,
бәлки, бергә ерак барырбыз!»
Тоя, сизә Салих — ышаналар,
өмет күзе белән карыйлар.
Ышанычны тою яхшы да бит,
аклый алсаң аны ярый ла!
Яшь чакта ук бер хакыйкать аның
нык урнашты күңел аңына:
улы булып, сөеклесе булып
керә аласың халык җанына,
фәкать шул чак: үзең — халкыңны
фидаича яратсаң гына.
Тудырасы иде шундый көйләр! —
халык йөрәгенә үтәрлек!
Булсын иде шундый көч аларда —
ерак гасырларга күтәрлек!
Олы максат җанда — игелек кылу.
Уйлар чиста. Күңел җилкенә.
Күпләр хәзер аңа эндәшәләр
«композитор Сәйдәш» дип кенә!
«Казан сөлге»ләрен билгә урап,
кулга «Зәңгәр шәл»ләрне тотып,
йөри Муза «Кандыр буйлары»нда
«Сүнгән йолдызлар»ны яктыртып!
...Ул бүген дә әнә театрда.
Театрның алгы фоэсында.
Китмәскә дип килеп утырган ул
мәрмәр креслога, таш сында.
Тамашачыларны каршылап, ул:

«Хуш киләсез! Әйдүк!» ди мәллә?
«Зәңгәр шәл»гә диеп килгәннәрдән
берәр танышын ул эзли мәллә?
Әйе, үз йортында — театрда ул
мәрмәр креслода, таш сында.
Инде ничә буын, юксынып үзен,
башын иеп үтә каршыннан.

## Хатыннар

Зур иткән дә хатын,
Хур иткән дә хатын.

*Мәкаль.*

. . . . . . . . .

...Зәңгәр күзле, сыны килешле,
сөеп туймас ап-ак маңгае...
Кемнәр бәхетенә үстердең син,
Мәхүпҗамал җиңги, малаең?
Урамнарга чыкса, аңа хәзер
Такташ Алсулары күз ата.
Асыл бу егетнең аяз күзе
сылуларның бәгырен кузгата!

Ә Салихның инде үзенең дә
мәхәббәтән шашкан чаклары.
«Валя! Валя! Валентина![1] Синнән
сөйкемлерәкләрне тапмамын!»
Кавыштылар алар. Җәй башында
Салих булды башлы-күзле дә.
Каршы төшмәделәр — әнисе дә,
әтиседәй Шиһап җизни дә.

Әй, ул яшьлек канатында күкрәп
бәхет катларында очулар!
Икәвеңнең бер җан була алуы —
гаилә сәгадәте шушыдыр!
Гел шат көйләр җанда, гел дәрт канда,
гел яшисе килә, эшлисе!
Иҗат ургый! Тою рәхәт: син бит
кешеләрнең кирәк кешесе!
Өйдә — шатлык. Эштә — алга барыш.
Сөенерлек мең-мең сәбәпләр.
Әнә, театрда, техникумда
гөрләп үсеп килә сәләтләр!
Валя әйтә: (нинди шатлык!) тиздән
яңа тавыш аваз саласы!
Үз бәхете белән туа күрсен
мәхәббәт һәм сөю баласы!

Шатлык белән Кайгы гел янәшә —
Тормышныңмы диалектикасы?
Исән калды — нәни баласы.
Ятып калды — бала анасы...
Үкси Салих. Үкси яшь әти.
«— Ятим идем. Тагын бер ятим...»

[1] Валентина — Сайдашевның хатыны Валентина Федоровна Мухина. 1926 елда үлгән.

## Сәяхәт

Шаулый диңгез...
Җил өрәдер...
Җилкәнен киргән кораб!

*Дәрдмәнд.*

Бу дөньяда ике шәп табиб бар:
берсе — Вакыт аның, берсе — Юл.
Вакыт безгә бәйсез. Ә менә юл —
сәфәр эше — безнең кулда ул.
Җирләр гиз син, айка дөньяны!
Бер тынычлык тапмасмы җаның?
Бу елларда Сәйдәш театр белән
гиздe илнең байтак юлларын.
Юллар төрле алар. Ә монысы —
кабатланмый торган сәяхәт.
Зур әдипләр белән йөргәнеңне
искә төшерүе дә бик рәхәт!
Иҗат кешеләре бердәм булса,
Уртак учак янар дәртлерәк.
Бер-берең була алсаң терәк —
Сәнгать үрен яулау җиңелрәк!
Чыккан юлдашларың кемнәр дисең,—
Кәрим абый, Такташ, Нигъмәти,
Шәриф Камал, Кутуй, Кави Нәҗми...
Һәрбер исем олы, хикмәтле...
Эш уң булыр бөек якташ Горький
фатихасын алган сәфәр лә!
Алда — ил күрүләр, очрашулар,
яңа җирләр, яңа шәһәрләр...
Алда — ике диңгез, Каф таулары...
Яңа тәэсир, яңа кичерешләр.
Алда — Кырым. Галимҗан Ибраһимов.
Сөйләшүләр, эшләр, киңәшләр...

...Ят якларга китсәң, Туган якның
чүплеге дә ямьле тоела.
Татар өчен, кая китсә дә ул,
кайда Казан — шул як кыйбла!
Каспий буйлап йөзә тимер кораб,
Дулкыннары ярга кагыла.
Кайсы яктан иссәләр дә җилләр,
уйлар оча Казан ягына.

Бер хатирә: Мансур[1] белән икәү
төшкән идек гармун уйнатып,
көймә белән Балык базарына[2]
Ташаяктан Болак буйлатып!
Болак-безгә олы елга иде,
Кабан инде — Казан диңгезе!
Ант итешкән идек без ул кичне
ташламаска бер-беребезне.

---

[1] Мансур — Мансур Мозаффаров.
[2] Балык базары — Казанның «Кольцо»дагы хәзерге «Балалар дөньясы» универмагы урнашкан тирәләр.

Озак итеп шунда тып-тын гына,
карап торган идек Кабанга.
Көймәләрдән яңгыраган көйләр
ишетелә кебек һаман да!

...Диңгез шавы — ул бөтенләй башка!
Дулкыннары бүтән, ярсуы!
Монда — чишмә, инеш, елга суы,
монда яңгыр, монда кар суы...
Челтерәү дә, ярсу, пышылдау да —
Тавышларның монда һәммәсе!
Бу халәтне биреп бетерә алмас
биш тавышлы «кытай гаммасы»...
Киңәйтергә кирәк, көчәйтергә!
Нигә полифониядән качарга?
Музыка бит тиеш — тавыш белән
күңелләрдә бәйрәм ясарга!
Чөнки тормыш — бәйрәм. Яшәү — бәйрәм.
Көрәш — бәйрәм. Хәтта — Үлем дә!

...Уйлый Сәйдәш. Уй — күп. Диңгез үзе
сыеп бетмәс кебек күңеленә.
Гамьле җанны эш күрсәткән саен,
яңа борчу, яңа уй баса.
Бер карасаң, борчылырлык түгел,
эше гөрләп бара лабаса!
Яраталар үзен. Казанда — үз.
Бу якта да ят түгел икән.
Бакуда ул алган алкышларны
башка берәү күрдеме икән?
Яңгырады көньяк күкләрендә
«Шәрык биюе» дә, «Марш» та...
Аңа ничек тәэсир итте әле
бу саф гөлләр, дәррәү алкышлар?!

. . . . . . . . . . .

## Җыр

Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә,
һәм үләргә кыю ир булып!

*Муса Җәлил*

Халыкларның җаны — ул җыр, диләр.
Җыр диләр дә бездә — моң, диләр.
Телгәләсә, киссә бәгырьләрне —
татар җыры инде шул, диләр.
Моңда баскан, изгән, туглаган... Юк,
безнең җырлар — киңрәк, тирәнрәк!
Ничек тоташ хәсрәттән торсын
хезмәт дәрте тулы бу йөрәк!
Җиң сызганып эшли белгәннәрдә
күпме куәт, күпме ярсу бар!
Каннар кайный икән, димәк, бездә
мәхәббәт бар, сөю, ачу бар!
Сәйдәш иҗатыннан син һич кайчан
табалмассың көйләр — беркөнлек.

Халык рухы кебек сәламәт ул,
юк аларда — шыңшу, мескенлек.
Яшәү тантанасын, хезмәт дәртен,
күңелләрнең җилкенүләрен
әйтә, раслый һәрбер аккордында
фани дөньяның ул бар ямен.
Чалгычылар чалгы янаганда,
шахтер егет күмер чапканда,
монтер егет утлар кабызганда,
кызлар өмәләрдә чакларда —
без һәммәбез алар белән бергә,
бер адымда, бер үк сулышта.
Кешеләр белән берлегеңне тою —
үзе — бер бәхет бит тормышта!

Җыр язмышы — халык язмышы ул,
ил язмышы белән берләттән.
Ил яулаган һәрбер үр-биеклек
көйләр-җырлар белән береккән.
Илне яңа сафка бастырганда,
ашкынулы бишьеллыкларда,
күмәк хуҗалыклар төзегәндә,
Днепрогэс, Магниткаларда
Сәйдәш тә бар. Төзүчеләр белән,
коручылар белән бер иңдә.
Зур сәнгатьнең — масса сәнгатенең
өлеше бар һәрбер җиңүдә!

Сәйдәш рухы йөрде фронтларда,
окопларда, алгы сызыкта.
Туплар булып яңгырады «Марш»
фашизмга каршы, коллыкка!

Шифа-өмет булып кунды Сәйдәш
әсирләрнең туңган җанына.
Җиңү булып, яшьнәп керде Сәйдәш
Бранденбург капкаларыннан!

Сәйдәш — җыя бергә, туплый, әйди,
йокымсыраганны да кузгата.
Якты рух өсти. Кешеләрдә
кешелекле аһәң уята.
Эчке тоем белән рухка үтү —
Сәйдәш талантының иркендә.
Җырлары аның — шәхси үзенеке дә,
шул вакытта — һәркемнеке дә!

## Идел буйларында Чирәмлек...

Без кабызган утлар сүнмәс алар,
сүнмәс алар хәтәр җилләрдә.

*Кәрим Тинчурин*

«Кызыл байрак» — җанга якын авыл.
Хыялланыр өчен җай авыл.
Идел кырыенда балкып торган
татар авылы тагын кайда ул!

Ә җәйләрен Сәйдәш шунда хәзер.
Иҗат итә, шунда ял итә.
Үзеңне бер җир баласы итеп
тою шатлыгына ни җитә!
Уйландыра Идел, уйландыра.
Дулкыннары бәрелә күңелгә.
Әрнетә дә: алтын, көчле чаклар
офыкларга кереп күмелгән...
Салмак аккан зур салларга карап,
елыйсылар килә кайчакта!
Язмыш миңа мәрхәмәтле булды,
рәхимсез дә булды бер яктан...

. . . . . . . . . . . . .

Җанны савыктырыр еллар килде.
Җылы инде хәзер дөньялар.
Җирдә гаделлекләр арткан саен,
матуррак җырлар туалар.
Арабызга кайтты Тинчуриннар,
Галимҗаннар кайтты, Җәлилләр...
Татар шагыйренең шигырьләрен
таңга калып сөйли күп илләр.

Уйландыра Идел, уйландыра.
Бу дулкыннар кая ашыга?
Төрле-төрле уйлар килә икән
иллене узган ирләр башына!
Иллене узу — инде ил узу ул.
Борылып карау ярый үткәнгә.
Нинди игелекле хезмәтең бар
билге итәрлек яшәп киткәнгә?
Булган ахры, яктырак — гомернең
яшьлек ягындагы өлеше.
Финал өчен яңгырарлык булган
иҗатымның башы, кереше.
Яулар истәлеге булды бугай
«Совет Армиясе маршы».
Әйтте күпләр: сугыш вакытында
ул — калалар йөргән алышып.
Әле дә якын — «Галиябану» белән
«Наемщик»ка язган көйләр дә.
Бүләк сәгать, шинель белән йөргән
чаклар калды сагынып сөйләргә!

Уйландыра Идел. Уй — киңәя.
Идел үзе дә бит киңәя.
Егетләрчә эшләп чыга алдыммы
музыкада үземә тигәнне?
Заманына күрә оркестрлар
оештырдык. Шунда уйнадык.
Халыкны без бераз симфониягә
күнектерәбез дип юандык.
Спектакльләргә көйләр язып,
җыр-биюне түргә менгездек.
Әкеренләп шулай салынды бит
балет-опералар нигезе.
Без башладык кына... Алга таба
олы юлга бүтәннәр чыгар.

Бу мәңгелек хәят күчешендә
Сәнгать — диңгез. Без — тик тамчылар...

...Сузып кычкыртты да ак пароход,
уе, ахры, калды бүленеп.
Ерак уйлар эреп таралуга,
яңалары килә өерелеп.
Исәп тә күп. Эш тә. Бу арада
«Җырларым»[1]ны язып бетерәсе.
Республикабыз юбилее көнне
оркестрлап концерт бирәсе...

Беркем сизми әле Әҗәл угын
төбәгәнне аңа каратып.
Иреннәргә килә актыккы җыр.
Якынлаша соңгы пароход...

## Сискәнү

Бармыни бездә гомумән чын кеше кадрен белү,
Без аны кайдан белик, мискин үлеп аңлатмагач?!

*Габдулла Тукай.*

И, декабрь! Егерменче көнең.
Күңелдә — боз. Күздә — кайнар яшь.
Меңәүләрнең телләрендә бер сүз:
Сәйдәш...
          Сәйдәш...
                    Сәйдәш...
И, декабрь! Син тудырып аны,
бүләк иткән идең Иленә.
Кайчан гына әле... Мәңгелеккә
алып китәргә дип килдең дә...

Урам тулы халык. Балконнарда,
түбәләрдә, тәрәзәләрдә...
Мондый хәлне Казан моңарчы бер
күргән булган Тукай үлгәндә.

. . . . . . . . . . . . . . . .

...Агайлар да килгән авыллардан
үрәчәле чаналар белән.
Озатырга чыккан чал әбиләр
оныклары — балалар белән.
Бәгырьләрне кисә «Сакай маршы»!
Мәрсияләр алар — гомерле...
Сирәктер ул, ак чәчәкләр белән,
үз көйләрең белән күмелү.
Саубуллаша халык... Керсәң иде —
һәрберсенең гаме-уена!
Нинди хисләр, сүзләр юктыр! Җыйсаң —
үзе булыр иде поэма!
Шагыйрь уйлый: «Күзем бәйле килеш,
дөнья читләрендә адашсам,
Туган илемне мин табар идем
Сәйдәш көйләренең моңы аша!»

[1] «Җырларым» — С. Сәйдәшевнең М. Җәлил сүзләренә язган соңгы җыры.

Уйлый галим: «Сәйдәш иҗатының
сихри көче нидә дигәндә —
Дәртле көе, якты моңы белән
ул — яшәргә өнди, җиңәргә!»
Агайларның сүзләр — күзләрендә:
«Ул — безнеке иде, үз иде!...»
Әнә шулай илне тетрәтә ул —
бер зур рухи чылбыр өзелү!

...Туфрагына кайта беркөн адәм.
Әҗәл хәлләренә юк дәва.
Җирдә берни булмагандай, күктән —
күбәләктәй ап-ак кар ява...

. . . . . . . . . . . . .

## Укучының күңел дәфтәренә

### Осетин мәкальләре һәм әйтемнәре

*Кылый кешегә бар бәла бер сукыр күздән килә.*

*Батыр йөрәге — иң көчле корал*

*Кешене кеше яшәтә.*

*Яшь борыч ачырак була.*

*Мыраулаган мәче тычкан тотмый.*

*Сөрелмәгән җиргә чүп түгәләр.*

*Кыска яңгыр — көн күрке.*

*Хатынсыз ир — мөгезсез үгез.*

*Күңел күркеннән матур нәрсә юк.*

*Сыңар кисәү учак була алмый.*

*Бал тәмен беренче булып умартачылар татый.*

*Начар эт арттан килеп тешли.*

*Ышанычны акламау — үлем белән бер нәрсә.*

*Хаклык көчтән көчлерәк.*

*Буш орлык суда батмый.*

*Кара тауда ак таш була алмый.*

*Егылып үлгән ишәкнең дагасын куптармыйлар.*

*Каракныкын урлау — караклыкка керми.*

*Дошманыңны дус итсәң дә, дусыңны дошман итмә.*

*Елның көче — көз көне.*

*Корыч утта чыныга, кеше көрәштә ныгый.*

*Үзеңне мактап җырласаң, кеше сине тыңламас.*

*Аюдан качып бүрегә тарган.*

*Яхшы аучыга зур таулар да тар.*

*Үз хатаңны кеше күзендә күр.*

Әхәт Гаффар

# ЯЗЛАР МОҢЫ

ИКЕ БҮЛЕКЛЕ ДРАМА

Катнашучылар:
Фәрданә
Сәгыйдулла
Сара
Ярми
Люция
Хөрмәт

Безнең көннәр һәм үткәннәр. Авыл.

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

## *СУГЫШ ҖЫРЫ*

Кыш. Өй. Кыңгырау чыңы.

Фәрдәнә. Бар дөньяны яңгыратып чыңлый!

Сәгыйдулла пәйда була.

Сәгыйдулла. Без кыңгыраусыз гына өйләнешкән идек. Мәгәр гомер моңлы узды. *(Югала.)*

Фәрдәнә. Артыгы белән моңлы.

Ярми күренә.

Ярми. Дөнья уртасында торган кыңгыраулар булып, заманында безнең йөрәкләр сулкый-сулкый чыңлады. *(Югала.)*

Люцияне күтәреп Хөрмәт керә.

Хөрмәт. Яңа ел бүләге алып кайттым сиңа, Фәрдәнә әби!

Люция *(Хөрмәткә)*. Ул биреп чыгарды түгелме соң әле мине сиңа?

Фәрдәнә. Әҗәткә түгел, бөтенләйгә!

Хөрмәт. Бөтенләйгә. Бүләк әҗәткә бирелми ул.

Фәрдәнә. Кем кемгә бүләк — тормышыгыз әйтер. Бер-берегезгә бүләк булып яшәгез! *(Аяк асларына мендәр сала).*

---

Минзәлә Татар дәүләт драма театры репертуарында. Сәхнәгә 1978—1980 еллар сезонында 300 дән артык мәртәбә куелды.

Хөрмәт. Инде — туй! *(Люцияне төшерә.)*

Люция. Әти-әни килеп төшәр менә...

Хөрмәт. Кем диярмен икән мин аларга?

Люция. Әти, әни диярсең... Яшьләр әле.

Хөрмәт. Чит кешеләрне алай атау авырдыр ул. Гомергә бер әйтеп карамагач.

Фәрдәнә. Гомергә бер дә әйтмәү авырraктыр.

Люция. Документыбыз артты, Фәрдәнә түти. Тагын бер таныклык. Инде икенчесе.

Хөрмәт. Икенчесе?

Люция *(көлә)*. Беренчесе бүген синеке булу өчен егерме өч ел элек дөньяга килүем турында иде. Бусы — син минеке булу турында.

Хөрмәт. Аңа калса, кеше гомеренә өч туй тиеш. Минеке бергә ким: бәби туемны уздырырлык әти-әни булмаган. Үчен шушы туебыздан алам. Үткәрәбез шундый итеп — иң соңгы туебыздан соң башкалар сагынып сөйләрлек булсын!.. Кыңгыравың өчен рәхмәт, әби. *(Кыңгырау суза.)* Чыңнарыннан агачларны сарган бәсләр авыл буйлап коелып калды.

Фәрдәнә *(узалдына)*. Башта коела да кире куна ул чәч бәсләре булып. *(Аларга.)* Әйтәм кар тузгый — бәхетегез күккә тигәнгә икән. Юлыгызга ак җәймә булып түшәлсен.

Хөрмәт. Инде — туй!.. Кара әле, Люция: минем яктан да кода-кодагыйлар табыйк әле.

Люция. Эзлисе юк — әнә, Фәрдәнә түти.

Хөрмәт. Кунакларга кодагый бул әле, Фәрдәнә әби. Анам кебек итеп.

Фәрдәнә. Булдыра алсам. Хакым булса шунар.

Хөрмәт. Хакы булмаганнар, сиңа килеп, әҗәткә алсын. Аларга өләшкәннән соң калганы да синдә минем кебекләрнең йөзәвенә җитә. Синең шикелләләр хакы җитми әле бу дөньяга!

Люция. Риза, риза, әме, Фәрдәнә түти? Әх, бер... кодалы да булсак!

Фәрдәнә. Кешеләр тиң яратылган кана... Бәхеткәйләре генә ким таратылган аның. «Уф!» дигән тыннарың белән тартып алыр хәл калмаган... Эзләгән-эзләгән — парлыларны табыгыз инде. Беләсезме, оланнар, дәшегез әле түбән өч Сәгыйдулла абзагыз белән Сара астаегызны.

Люция. Ә без дәштек инде. Менәселәр.

Хөрмәт. Тик Сәгыйдулла абзый авырып тора бугай.

Фәрдәнә. Шуңа әйтүем дә. Җилкенеп бер менсен әле. Мәҗлескә дисәң, күңеле көр; уен дисәң, теле җор аның.

**Сара керә.**

Люция. Йөз яшәрсең, Сара түти!

Фәрдәнә. Килен төшергән мәлгә туры килдең. Бәхет өстенә.

Люция *(аңа)*. Синең өчен килене белән кияве бергә инде.

Хөрмәт. Ни булды, Сара апа?

Сара. Сәгыйдулла абзагыз вафат.

Фәрдәнә. Аһ!

Хөрмәт. Бәхет — хәсрәт күршесе икән.

Люция. Яңа елга каршы төндә үләләр димени? Бүген безнең туй көне ич!

Сара. Шуңа мендем. Кеше җибәрсәм, аңламассыз дип.

Хөрмәт. Булмады инде.

Сара. Булмасын иде шул...
Люция. Нәрсә «булмасын иде»?
Фәрдәнә (*сак*). Туймы?
Сара. Боздык. Тик бездән торамыни? Үпкәләмәгез инде.
Хөрмәт. Үлем үпкә сәбәпчесе түгел.
Сара. Бүгенгә кичектереп тормыйсызмы?
Люция. Гомергә бер килгән бәхетнеме?
Сара. Үзегезгә үк читен булыр, кызым. Югыйсә, урамның бер очында — үлем, икенче очында — туй.
Люция. Без — сак кына, сабыр гына: рөхсәт ит, Сара астай.
Хөрмәт. Тукта, чү, Люция. Бәлки шулай кирәктер.
Фәрдәнә. Тел әйләнми — Сәгыйдулла вафат!..
Сара. Вафат...
Фәрдәнә. Авыл тарихында үлем-китем белән туй итү бергә туры килгәне хәтердә юк. Бала табулар булды. Анысы аңлашыла — дөньядан китү дә, дөньяга килү дә сорап алынмый. Ә туй...
Сара. Мин китим алайса. (*Китәргә юнәлә.*)
Люция. Хөрмәт, Хөрмәт! Әйт инде бер сүз!
Хөрмәт. Ул бит Сәгыйдулла абзый, Люция!
Люция. Күпме кунак килеп төшәчәк.
Хөрмәт. Өлкәннәрне рәнҗетмик.
Фәрдәнә (*аларга карап торгач*). Йөрәк ышанмый. Ә бит үлгән артыннан үлеп тә булмый, Сара.
Сара. Ни диюең?
Фәрдәнә. Миннән түгел, үзеңнән сора.
Сара (*туктап кала*). Туегыз канатсыз булыр ич. Сәгыйдулла рухы да риза булмас.
Фәрдәнә. Һәммәбезгә дә шунда барасы. Тик әле берәү дә исәннәргә җырламагыз да биемәгез дип әйтеп китмәгән.
Люция. Китмәгән бит, әйеме, Хөрмәт?
Сара (*кисәк борыла*). Ә китсә?
Фәрдәнә. Шулай дип китәр идектер, әгәр дөньяга үләр өчен генә килә торган булсак... Яшәргә дип киләбез ич, Сара! Сәгыйдулла гына алып китә алмый үзеннән соң килгән туйларны.
Люция. «Без китәрбез, сез каласыз! — дип җырлармын. Җәсәдемне туфрак берлә күмгәндә дә»... Әнә ич, Тукай: җырлармын диган!
Сара. Монда сүз сезнең йөзегез турында.
Люция. Тукай халык күңелендәгене әйткән ләбаса — авыл халкы гаеп итмәстер... ихтимал.
Сара. Мин яхшылык белән мендем. Яманлыкка алмагыз, оланнар... Яшьләр — яшьләр инде: сиңа килешмәс ич, Фәрдәнә...
Фәрдәнә. Сәгыйдулла сүз әйтмәс иде.
Сара. Сәгыйдулланың сиңа атап ни әйткәнен мин житкерермен әле.
Фәрдәнә. Мине искә алган икән әле. Онытмаган. Рәхмәт.
Сара. Ничек кенә искә алды әле! Житкерермен... (*Люциягә.*) Әллә аңлата алмадым, әллә аңлый алмадыгыз, оланнар?
Хөрмәт. Алай димә әле, Сара апа. Без тагын бер уйлап карарбыз.
Фәрдәнә. Мин әйткәнчә булыр, Хөрмәт улым.
Сара. Бүрек ташлап котылмыйлар бүредән, Фәрдәнә! Соңаргансың. Яшьләрдән оял әзрәк. (*Китәргә борыла.*)
Люция. Без нәрсә... Кирәк икән...
Хөрмәт. Инде юк — ясыйбыз туйны!
Люция. Дөрестән дә: ихтимал, килешмәстер, Хөрмәт.

Хөрмәт. Килешмәс иде... әгәр мин Сәгыйдулла абзый белән Фәрдәнә әбине белмәсәм. «Нишлик?» дигәнгә, Сәгыйдулла абзыйның «Туй» диясенә ышанмасам.

Сара. Күп беләсез... үзегезгә күбрәк ышанасыз шул сез, яшьләр.

Хөрмәт. Сәгыйдулла абзый риза-бәхил булыр иде. Чөнки җырлап яшәгән кеше җылап үлми. Сара апа... Әзерләнә торыгыз, Люция.

Люция. Кая, нәрсәгә?

Хөрмәт. Туйга.

Люция. Ә син?

Хөрмәт. Озатышып кайтам. Җирләшеп... Әйдә, Сара апа.

Сара. Ялгышмыйсызмы, оланнар?

Хөрмәт. Туй көненең кай төше ялгыш, Сара апа? Туй көне — тормыш көне.

Сара *(үзалдына)*. Сәгыйдулла, ни диярсең?

Сәгыйдулла күренә. Гармун тоткан.

Сәгыйдулла. Үз тәнемне генә алып киттем. Дөнья гаменә шатлыгы-кайгысы белән исәннәр хуҗа. *(Китә.)*

Люция. Инде нишлибез, Фәрдәнә түти?

Фәрдәнә. Инде нишлибез? *(Үзалдына.)* Ярми исән булса, әйтер иде.

Ярми күренә. Ефәк күлмәк таратып җибәрә.

Ярми. Без әйтеп бетердек. Мәгънәсен кылган гамәлләребездән эзләгез. *(Югала.)*

Сара *(Хөрмәткә)*. Әллә, оланнар, сез хаклы микән?

Люция *(Фәрдәнәгә)*. Хата ясыйбыз түгелме, Фәрдәнә түти?

Хөрмәт. Хаклык — хатасыз, хата — хаксыз дип әле һичкем әйтмәгән. Шуны аерырга өйрәнер өчен яшибез.

Караңгылык. Туй шавы. Люция белән Хөрмәт килеп чыга. Үбешәләр.

Люция. Шушымыни инде, шушымыни?!

Хөрмәт *(кисмәккә таяна)*. Әгәр мин сиңа... сөюем шушы кисмәктәге су сымак... гел мылкып, ташып торыр дисәм, ышанма! Төрле чак булыр.

Люция. Ни диюең бу? *(Шаярып.)* Төбендә өч тамчысы калса, миңа шунысы җитәр. Бер дә калмаса, иң элек үзең коргаксырсың иң.

Хөрмәт *(уенга бирелә)*. Картаеп, инде йөздән, кыяфәттән сөюемне берничек таный алмый башласаң да, ышан: коргаксымам. Антым дип бел. *(Чүмеч белән су алып эчә.)*

Люция. Салкын тияр.

Хөрмәт. Детдом баласынамы? Эч әле син дә! Менә шушы сусыз тора алырлык булсаң, миннән бизсәң дә ярый. Бер сүз әйтмәм.

Чүмеч белән су алып Люциягә бирә.

Люция. Матур әйттең. *(Эчә.)* Чур — хәзер мин!.. Инде мине тыңла!

Урыннарын алмашалар. Хөрмәт аңа су чәчрәтә.

Күзгә итеп шушы суга кара әле. Күрәсеңме? Битемдәге бу су тамчыларын күз яшьләренә әйләнерлек итсәң... хәтереңдә яшьлегеңә кайта алмый адашып йөр!

Х ө р м ә т. Хәтерсез кеше — сусыз мичкә кебектер ул әйеме? Жаны коргаксыйдыр.

Л ю ц и я (*чүмечне күтәреп*). Коргаксымас өчен!

**Көлешә-көлешә, алмаш-тилмәш су эчәләр. Зур җиз самавар күтәреп Фәрданә чыга.**

Ф ә р д ә н ә. Тамакларыгыз киптемени — шул хәтле сыйлашасыз? Әйдәгез, табынга чәй куям.

Х ө р м ә т. Ай-яй, әби! Нинди көчен белән күтәрәсең моны? *(Самоварны ала.)*

Ф ә р д ә н ә. Шушыннан эчкән сулар көче белән, Хөрмәт улым.

Х ө р м ә т. Бер Иделлек кенә су үткәндер моннан! (*Кереп китә.*) Чәй, җәмәгать!

Ф ә р д ә н ә. Безнең йөрәк януларын шул — Иделлек сулар гына басса басты инде.

Л ю ц и я. И, мәшәкатьләдек тә инде сине, Фәрданә түти!

Ф ә р д ә н ә (*кисмәктәге суга кырын карап куя*). Кеше, кызым, үз гомерендә җиде кешене гүргә озатсын диган, ә мәшәкать димәгән.

Л ю ц и я. Ә күпме кызны кияүгә бирсен диган?

Ф ә р д ә н ә. Анысын әйтмәгән.

**Стенага эленгән баланның бер тәлгәшен сындырып ала.**

Л ю ц и я (*аның балан бөрчегәнен карап тора*). Тегендә кереп эч, түти! Кеше белән.

Ф ә р д ә н ә. Анда да әлгәшербез. (*Чәйнекгән чәй ясый.*)

Л ю ц и я. Ник балан белән эчәсең? Авырыйсыңмы әллә?

Ф ә р д ә н ә. Балан хикмәтле ул, бәбкәм. Матурлыгы — сезнең туй сымак. Әчесе — тормышның кайгы-хәсрәте ише. Әнә ич: үлем белән башланган көн нинди ямьле туй белән очлана.

Л ю ц и я. Балан — шуңамыни: Сәгыйдулла абзый үлгәнгә?

Ф ә р д ә н ә. Синең язмышыңа язган әчеләрне ашавым. Сезгә дөньяның җиләкләре генә калсын. (*Чәй эчә.*)

Л ю ц и я (*карап тора, кинәт елмая*). И бүләкләр, Фәрданә түти, бүләкләр! (*Кереп китә, эчтән.*) Тутырганнар! (*Чыга, бер төргәк сутә.*) Карале, түти, нинди эчке күлмәк! Кайсысының бүләге икән? (*Көзге каршына басып карый.*)

Ф ә р д ә н ә (*күлмәкне капшый, үзенә үлчәгәндәй итә*). Сау тәнеңдә тузарга язсын, бала... Без яшьлектә боларсыз да хәйран булдык. Буып-кысып йөрмәдек, алай да ерак иде — ни житте куллар житкермәдек... Әүвәле, кызым, кием затлылыгыннан битәр, җан сафлыгы кыйммәт иде.

**Эчтә «Әче!» кычкыралар. Хөрмәт чыга, аларга карап тора.**

Л ю ц и я. Хәзер дә шулай, түти.

Ф ә р д ә н ә. Булмыйча! Тормышның алмашка күлмәге юк. Бар киеме — сафлык. Ә аның тамыры бездә — хатын-кызда. Тормышның кияре сафлык булсын, кызым.

Х ө р м ә т. Чакыралар, Люция... Әйдә син дә, әби!

Л ю ц и я (*күлмәкне җыя*). Түзәрсең, эш бар әле!

Х ө р м ә т. Фәрданә әбине кызлар итеп киендерәсеңмени? Кара аны, бутап куймагаем!

Л ю ц и я. Алайса, егетләр итеп киендерәм!

Ф э р д э н э. И оланнар! Булмагез. Без заманында буленгэн. Эллэ безне гел шушылай булган дип беләсезме? (*Кулын югары күтәрә. Күлмәк җиңе кайтарылып, беләзеге терсәгенә кадәр шуып төшә.*) Бу билдәрле көмеш беләзек беләккәйләргә таман гына иде, оланнар!.. Хәзер бөтен кул буенча шуып йөри. Кулга киеп, баштан салырлык.

**Хөрмәт Люциянең беләгенә карап тора да кереп китә.**

Л ю ц и я. Фәрдәнә түти, куркам мин.

Ф э р д э н э. Уйлама, кызым. Картлык ул кеше башына сиздерми генә килеп төшә. Язгы сулар кар астыннан төшкән шикелле.

Л ю ц и я. Мин ул турыда түгел. Моны әйтәм, Хөрмәтне. Укытучы булганым өчен генә өйләнмәдеме икән?

Ф э р д э н э. Шушы матурлыгың беләнме? Сөбханалла! Укытучылыгыңны уйлап торгандыр тагын.

Л ю ц и я. Сөйләшми дә.

Ф э р д э н э. Пычак йөзеннән күренә, егет кеше — сүзеннән. Андыйлар саескан шикелле гел такылдамас. Сандугач шикелле бер сайрар. Бусы фал хакыйкать, кызым.

Л ю ц и я. Тормышка исе китмәс күк.

Ф э р д э н э. Тормыш башлауның яме пар кашык белән тар ястыкта.

Л ю ц и я. Безнең «пары» белән «тары» да юк ич әле.

Ф э р д э н э. Менә ич, ындыр шае. Түшәк-ястык бар. кашыклар күп. Йокыгыз түр караватта булыр.

Л ю ц и я. Рәхмәт инде, түти.

Ф э р д э н э. Беттеме кияүне яманлар сүзең?

Л ю ц и я (*көлеп*). Бетте, бетте.

Ф э р д э н э. Әле дә ярый, былтыргы шикелле, ялгыз башым кыш чыгасы итмәдем. Каладан яңа агроном белән яңа укытучы кайта дигәнне ишеткәч, кайсыгызны кертим икән дип уйга калган идем. Хөрмәтне кертсәм, ягарга утын, кәҗәгә булса да печән, тавыкларга бодай-мазар табарга булышыр иде дим... Сине сайладым. Хөрмәтка әби генә булыр идем... Сиңа ана күк буласым килде.

Л ю ц и я. Түти! (*Аңа килеп сыена.*)

Ф э р д э н э. Бәхеткәйләр ташып чыкты: икегез дә миңа тидегез. Шулай ул дөнья, кызым... Сәгыйдулла гына үлде менә. Өлгермәдем, өлгермәдем.

Л ю ц и я (*сак*). Нәрсәгә?

Ф э р д э н э. Бәхилләшеп чыгарга. Ул авыргач, коймак пешереп кертермен дигән нәзерем таулар булып иңемдә калды...

**Эчтә «Әче!» кычкыралар. Хөрмәт чыга.**

Х ө р м ә т. Люция!

Л ю ц и я. Чуеп тор әле.

Ф э р д э н э. Бар, кызым. Яңа гадәтегез шундый.

Х ө р м ә т. Фәрдәнә әби, син дә кер.

Ф э р д э н э. Баланлап чәй эчәм әле.

**Хөрмәт, Люция түр өйгә узалар. Эчтә «Әче!» кычкыралар.**
**Фәрдәнә балан өзеп каба.**

Ф э р д э н э. Әче шул. (*Җырлый.*)

**Балансукай куаклар балансу,**
**Баланнарын җыйгач, ямансу.**
**Ел шаенә еллар туры килми, —**
**Килде быел еллар ямансу...**

**Эчтә тавыш: «Җәмәгать, Люция җырласын әле! Уйна, Хөрмәт!»**

Люция күренә. Хөрмәт чыга, баянда уйный.

Люция (*җырлый*).

**Күптән инде, күптән очраткан юк.**
**Хәтерлимсез бергә чакларны?**
**Күңелләрдә йөргән татлы сагыш —**
**Шул чакларның моңлы ядкаре.**

**Уртак иде хисләр, айлы кичләр —**
**Без кертмәдек анда ятларны.**
**Күңелләрдә йөргән дуслык хисе —**
**Шул чакларның моңлы ядкаре.**

**Бергә откан өмет тулы җырны**
**Йөрәк инде мең кат атлады.**
**Үткәннәрдән бары шул җыр калды,**
**Ул җыр безгә — яшьлек ядкаре.**[1]

**Кереп китәләр. Фәрдәнә, тәрәзә төбеннән алып, кыңгырау чыңлатып карый.**

Фәрдәнә. Үткәннәрнең ядкаре... Бергә утырып, соңгы мәртәбә чәй дә эчелми калды.

Сәгыйдулла күренә.

Сәгыйдулла (*кисмәккә таяна, чагылышын карый*). Үткәннәрне искә алыр идек.

Фәрдәнә. Күңелдән бөтен хәсрәт юшкыннарын юып.

Сәгыйдулла. Хәсрәт түгел. Үткәннәрдән калган безнең ядкарь — киләчәккә очкан хәтеребез кошы мәллә?

Фәрдәнә. Мәшәкатьләр артыннан куып, картлык соңарды. Хикмәт диген: бүген иртән бөтен дөньяны тутырып килде дә төште.

Сәгыйдулла. Яшьлеге дә әллә ни ерак түгел. Хәтерлә генә: сандыгың шикелле ачылыр да күз алдыңа җәелер... (*Суга иелеп, үзен күзәтә.*)

Фәрдәнә. Ерак булмаган кая... Мыегың әнә: әллә нинди, күрмисеңмени?

Сәгыйдулла. Нинди?

Фәрдәнә. Кунык кунган. Яшел.

Сәгыйдулла. Ә синең битеңдәге теге борчак кадәрле генә чокыр торамы әле?

Фәрдәнә (*битен капшый*). Билдәрле беләзек... беләк буйлап шуып йөри.

Сәгыйдулла. Зират сукмагына җил кар тузгыта. Күмелгәнче, китим.

Фәрдәнә. Киткәнче, әйтеп кал әле. Нинди васыять ул?

Сәгыйдулла. Сара әйтер.

Фәрдәнә. Ул инде әйтте. Әле ишетмәдем генә.

Сәгыйдулла. Ишеткәндә колагың белән түгел, күңелең белән тыңла.

Фәрдәнә. Авыз белән әйткәнне күңел ишетер иде дә... Сара ым белән генә белгертте шул.

Сәгыйдулла. Ымның мәгънәсе меңләгән. Минеке меңнән берсе генә. Хәтер көзгеңдә шунысы чагылсын. (*Чыгып китә.*)

Хөрмәт белән Люция чыга.

Люция (*җырлый*).

**Бергә откан өмет тулы җырны**
**Йөрәк инде мең кат атлады.**
**Үткәннәрдән бары шул җыр калды,**
**Ул җыр безгә — яшьлек ядкаре.**

[1] Ф. Әхмәтов музыкасы, Р. Вәлиев шигыре.

Фәрдәнә (*кисмәккә карап*). Үткәннәрдән бары шул җыр калды... Аккан сулар белән ярыша-ярыша уза икән гомер... Җиле кузгаткан дулкыннан камыш кына тавыш сала... баштагы хәтер шикелле кыштыр-кыштыр...

**Сара керә. Яулыкка төргүле төенчек тоткан.**

Хөрмәт. Әйдүк, Сара апа!

Сара (*тынлыктан соң*). Инде менә Сәгыйдулла абзагызны да җирләдек.

Люция. Яңа елга каршы төндә, ә? Бүген безнең туй көне инде.

Фәрдәнә. Балаларны рәнҗетмик, Сара.

Сара. Шуңа мендем. Иртән аңламагансыздыр дип. Кеше генә җибәреп әйттерер идем, әллә минемчә әйтә, әллә юк.

Люция. Бик яхшы аңладык, Сара астай, рәхмәт.

Хөрмәт. Кичектереп булмады инде туйны, Сара апа. Бик аңлыйбыз да бит... Син дә аңла инде, битәрләмә.

Сара. Ни сөйлисең, олан? Урамның бер очында — үлем, Икенче очында — туй. Тормыш шулай булмаса, ничек яшәр идең? Йөрәк кабул итми бүтәнчә.

Фәрдәнә. Бу ни диюең?

Сара. Миннән түгел, үзеңнән сора.

Фәрдәнә. Риза түгел... риза түгел бу эшеңә, Сара.

Сара. Мин бүтәнне әйтәм шул. Һәммәбезгә шунда барасы. Җырламагыз да биемәгез дигән сүз белән йөрмим бит.

Люция. Әйләле, утыр, күңелең күтәрелмәсме.

Фәрдәнә. Чишен. (*Булыша.*)

Сара. Җәяүле буран кузгалды. Берәз җылынам да китәм. (*Төенчеген Люциягә суза.*) Мәле, кызым, алып куй түргәрәк.

Люция. Юк, юк. Зинһар, кирәкми. Безгә синнән бүләк кирәкми.

Сара (*Фәрдәнәгә*). Алып куй бер төшкә... Сине искә алды. Соңгы мәлендә дә искә алды. Сиңа әйткән васыятеннән йөрәккәйләрем өшеп китте менә.

Фәрдәнә (*әкрен*). Исән чагында кыланмаганны да кыланган икән. Куй үзең анау урындыкка. Җиткерергә бүтән вакытын тапмам дип курыктыңмыни?

Сара. Әллә аңлата алмадым, әллә аңлый алмадың, Фәрдәнә. Иртәгә дә менә алган булыр идем, күңелең елап, әчең пошып тормасын иртәгә чаклы дип уйладым. Яшиселәр дә бар ич әле.

Фәрдәнә. Уз. Балалар, сез барыгыз, бәйрәм итегез.

Люция. Без нәрсә... Кирәк икән... (*Керәп китәләр.*)

Сара. Кеше гүргә киткәндә иртәнге өчен үпкә тотма инде.

Фәрдәнә. Анысы шулай... Әйдә, чәй эчик әле. Сөйләшик. Таш булып, күңелдә калмасын.

**Чәй эчәргә утыралар.**

Бал кап.

Сара. Тирләтер. Кайтасы бар.

Фәрдәнә. Кун димим. Кунаклар күп.

Сара. Өйне ничек ялгыз калдырасың? Балалар көтеп калды.

Фәрдәнә. Киленең ник кайтмаган?

Сара. Бала табу йортында, ди. Балалар һәммәсе кайтып житте, сабыр гына озаттылар.

Фәрдәнә. Ә безнең Габделхарис кына өлгермәде... Күңеле белән безгә якын да бит, эше белән дөнья читендә. Сәгыйдулла җир җимертә иде әле. Узган атна кич төзелештән кайтып килә. Балтасына агач

башы элгән. Шул кичне төш күрдем. Имеш, ана казымны күтәреп, аның янына килгәнмен дә: «Суеп бир әле»,— мәйләм. Ә ул: «Ана казны суймыйлар»,— ди.

Сара. Миһербанлы булды.

Фәрдәнә. Чәй эч. Балан кабып кара әле, тамагыңа каптыртмас-мы әзрәк.

Сара. Ничек кенә күнегелер инде ул юклыкка.

Фәрдәнә. Күнегелмәс. Ир күмү — ярты җанны күмү.

Сара. Син инде икенче кат. Башта Ярмиеңне...

Фәрдәнә. Өченчесе. (*Тынлыктан соң.*) Сәгыйдулла ике тапкыр үлде ич.

Сара. Вилдан мине калага алып китәм, ди.

Фәрдәнә. Хәерлегә булсын... Мине күпме чакырдылар. Ул Габделхарисым инде... Шәһәрдә яшисе килмәде, таш астындагы бака күк. Кучтәнәчләре, болай, пөхтә йөри йөрүен.

Сара. Балаларга ата-аналарның хәсрәтен күрмәү яхшы. Безнең бәхет шунда — белмәсеннәр. (*Фәрдәнәнең күзенә карап.*) Берсен дә белмәсеннәр, Фәрдәнә... Йөзгә чыгармадык, тату яшәдек. Үпкә тотмадык, шөкер. Беребезгә бер бурычлы калмадык. (*Төенчеккә ымлый.*) Менә: соңгысын алып менүем.

Фәрдәнә. Нәрсә соң ул шул хәтле дә серле, Сара?

Сара. Сәгыйдулла язларының моңы.

**Төенчекне чишә. Урындыкта гармун ятып кала. Сара орынгач, кыңгыраулары чыңлап куя. Фәрдәнә читкә борыла.**

Фәрдәнә. Ник күтәреп йөрисең аны?

Сара. Сәгыйдулла кушты.

Фәрдәнә. Васыяте шулмыни?

Сара. Шушы. Син алып биргән ич аңар бу гармунны.

Фәрдәнә (*тәрәзәгә карый*). Салкынайтты. Бакчы, тәрәзәләргә нинди боз куна.

Сара. «Гармунны Фәрдәнәгә менгез»,— дигәч, үзем дә өшеп киткәндәй булдым.

Фәрдәнә (*сак*). Үч итеп эшләде микәнни ул моны?

Сара. Юк, Фәрдәнә. Башта минем дә исләрем китте. Аңлагач, бәхетеңнән көнләп куйдым. Мине шул өшетте. Мә, алып куй. Күз алмасыдай саклап яшәде.

Фәрдәнә (*гармунны ала*). Рәхмәт. (*Борылып.*) Хәтерлисеңме, Сәгыйдулла? Өйләнешеп, башка чыккан көзне Йөзен базарыннан алып кайткан идем. Төп йорттан килгән ун баш казның җидесенә алмаштырып.

**Сәгыйдулла күренә.**

Сәгыйдулла. Курка-курка гына.

Фәрдәнә. Сукага акча җыя идек. Ә мин гармун алып кайттым.

Сәгыйдулла. Куанып бетә алмадым, юләр. Күрсеннәр, янәсе! Кунак-төшем, туй-мазарда иң кадерле кеше мин хәзер дип...

Фәрдәнә. Искесен Габделхариска биреп, эңгер-меңгердә урам әйләндең.

Сәгыйдулла. Ә суканың кирәге чыкмады.

Фәрдәнә. Колхозга кердек, атны илтеп биргәнең өчен и еладым, и тиргәдем сине!

Сәгыйдулла. Куәскә дә күршегә чаба идең. Безне колхоз кеше итте. Ялгызың азапланган ише булдымы соң?

Сара. Газиз хатирәле бу гармун сиңа. Кайчандыр исемен гәҗитләрдән төшмәгән орденлы тракторчы Фәрдәнә Басыйрова иден — шуның истәлеге.

Фәрдәнә. Сәгыйдулланың ачы васыяте.

Сара. Ачы димәде.

Фәрдәнә. Димәде? Тилгән тавында ич: аның җаны белән минем җан өзгәләнүе тәкрарлек булып аваз салган иде. Өстә ул гармун уйный, аста, сазлык өстендә әйләнә-әйләнә, тәкрарлек кычкыра... Тикмәгә булмаган.

Сара. Урак ура идек.

Сәгыйдулла. Ә аңынчы минем үлгән хәбәр килгән. *(Югала.)*

**Караңгылык.**

Фәрдәнә. Яшәү ямен югалттым. Ялгыз ләкләк сыман гамем бетеп, алны-артны карамый йөргәч, йорт-җирем янды. Өй каршында үскән каен кара көйде. Карлыгачлар кайткач, икесе кара кисәүләр өстендә өзгәләнеп очтылар да югалдылар.

**Ярми күренә. Гимнастерка, галифе кигән. Бер җиңе буш.**

Ярми. Карлыгачларың оя тапмый, Фәрдәнә. Киттеләр.

Фәрдәнә. Кошлар яңа оя корыр. Мин генә менә кызым белән кая барыйм? Кошлар булмаганбыз ичмасам.

Ярми. Мин дә очар идем. Сыңар канат белән ерак китеп булмас. Синең оя юк, минем — канат... Сугышларга үч итеп яшиселәр бар әле. Чык кияүгә!

Фәрдәнә. Кемгә?

Ярми. Миңа.

Фәрдәнә. Минем ирем бар.

Ярми. Кайтыр дисеңме?

Фәрдәнә. Гел кайтмаса, бер кайтыр күк.

Ярми. Синең оя юк, минем — канат. Яшиселәр бар әле! Чык кияүгә! *(Күккә карап.)* Карлыгачларың оя кора, Фәрдәнә. *(Китә.)*

Фәрдәнә. Бау булып ишелепләр генә торган хәсрәтләрне төйни башлаган идек инде.

Сара. Ә ул кайтты да төште!

Фәрдәнә. Кыш көне күк күкрәгән шикелле.

Сара. Тилгән тавы кырында көлтә бәйли идек.

Фәрдәнә. Ә мин — тракторчы, комбайн тагып йөрим.

Сара. Төшлеккә туктап, бәпкә төпләренә хәл алырга яттык.

**Фәрдәнә, йөзен яулык белән каплап, бәпкә төбенә ята.**
**Сара тотып тора, Ярми чалгы суга башлый. Гармунда уйнап, Сәгыйдулла керә.**

Сәгыйдулла. Сәламәтләрме, хатыннар! Исәннәрмесез!

Сара. И-и-и, танымый да торабыз! Басыйрныкылар югаламы соң! Минеке генә ул... *(Фәрдәнәне уята.)* Фәрдәнә, Фәрдәнә... Тор! Сәгыйдулла...

**Ярми читкә китеп баса.**

Фәрдәнә *(көлмәгән сәдәпле, йокы аралаш)*. Нинди Сәгыйдулла?

Сара. Бердәү генә ләбаса ул синең!

Сәгыйдулла *(Фәрдәнәгә таба атлый)*. Әнкәсе! Сөбханалла!

**Фәрдәнә әкрен генә баса, кулына урак ала.**

Саумы, әнкәсе!

**Фәрдәнә аның каршына бара, тик кисәк борылып Ярми янына ташлана.**

Ф ә р д ә н ә. Ярми!..

С ә г ы й д у л л а. Кызлар диярсең — кара, кая качасың? *(Көлә).*

Сара аны читкә сөйри.

Тукта әле, ник сөйрисең?.. Ярми, кордаш, тот, җибәрмә! Тапкан уен...

С а р а (*Сәгыйдулланы сөйрәп чыгып китә*). Тоткан инде ул аны. Җил әле дим!..

Я р м и *(Фәрдәнәгә).* Ник чыраең качты?

Ф ә р д ә н ә. Үзеңнең соң!

Я р м и. Ат урламаган ла!

Ф ә р д ә н ә. Җан яралы, Ярми!

Я р м и *(Фәрдәнәнең чәчен сыйпый).* Җан... төзәлер. Җинаять кылмадык. Ахыры хәерле булсын. Күрәсең, бу сугышның ялкыны тәнне генә көйдермәгән. *(Фәрдәнәнең урагын ала, кылыч кебек итеп селтәнә.)* И-иәх!.. Дөньясын төбе-тамыры белән...

Бию көе уйнап Сәгыйдулла керә.

С ә г ы й д у л л а. Бас ярсуларны, хатыннар!

С а р а. Минем Ибраһимны күрмәдеңме, Сәгыйдулла?! Күкрәгенең сул ягында ясмык кадәрле генә ике миңе бар иде...

С ә г ы й д у л л а. Бие, Ярми! Бас ярсуны, бие!

С а р а. Кызган табадагы балык сыман итеп! (*Бии.*)

С ә г ы й д у л л а. Бие, Ярми! Миңа караганда да авыр булыр сиңа.

Ярми уртага чыга, торган саен ярсурак биергә керешә.
Чыгып китәләр. Бию анда дәвам итә.

Ф ә р д ә н ә. Молотилка барабанына таккан көлтәләр күк биеделәр. Егермеләп хатын, биш-алты ир. Ләкин җан авыртуының бер бөртеге дә коелып калмады Тилгән тавы басуында. Югыйсә, җир чыдамас иде: шыттырып чыгарыр иде безнең яраларны шул язларда. Яфраксыз карт агач итеп. (*Чыгып китә.*)

Җил авазы. Сәгыйдулла белән Сара керә.

С ә г ы й д у л л а. Шундый-шундый хәлләр икән монда, Сара.

С а р а. Фәрдәнә белән синең арадагы күперләр җимерелде.

С ә г ы й д у л л а. Әйе икән, Сара. Әллә юкка кайттым инде?

С а р а. Ничек юкка булсын?

С ә г ы й д у л л а. Үз каберемне күргән кебек булды әле.

С а р а. Чак кына аның каберенә кайтмадың.

С ә г ы й д у л л а. Ничек — каберенә... Сүз сөрешеңне тота алмыйм — контузия бәргән ише.

С а р а. Яшәр өмете киселгән иде Фәрдәнәнең. Ярми ялгады. Йөрәкне йөрәккә түгел, син уйлама нindидер гыйшык-мыйшык нәрсә булгандыр дип. Ярми аның сулган тормыш тамырына үз каны тамырын гына ялгады. Яшәр өчен. Бар үлемгә каршы торып яшәр өчен.

Пауза.

С ә г ы й д у л л а. Син китәсеңме?

С а р а *(тыйнак елмаеп).* Китәм.

С ә г ы й д у л л а. Китмә.

С а р а *(читкә тайпыла).* Фәрдәнәгә үч итеп әйтәсеңме? Көлмә. Көлмә син!

Сәгыйдулла. Көлмим. Чынлап әйтәм. Кем белә бит болай килеп чыгасын? Кем белә... Сара! Минем урында беләсеңме кем басып торырга тиеш иде бүген монда?

Сара. Үзеңнән гайре беркем дә түгел. Кимсетмә үзеңне. Яраларга вакыт дәва. Онытылыр. Синең урында булсам беразга китеп торыр идем мин.

Сәгыйдулла. Китеп...

Пауза.

Китсәң иде дә бит...

Сара. Кем тота?

Сәгыйдулла (*әкрен*). Син...

Сара. Мин?! (*Тыела алмыйча көлә.*) Ай-яй бу ирләр, ә? Әле кайтып бисмилласын әйтү түгел, кулын да юмаган... (*Көлә, читкә китә.*)

Сәгыйдулла (*гармунын ярсу ябып*). Көлмә, Сара! Ибраһимны күрдем мин.

Сара (*көлүеннән туктый алмыйча*). Ибраһимны?

Сәгыйдулла. Гозерен алып кайттым.

Сара. Гозерен? Гозерен... Нәрсәгә миңа аның гозере?!

Сәгыйдулла. Сиңа түгел, миңа.

Сара. Нишлим мин гозер белән... үзе булмагач? (*Көлеп һәм елап.*) Нишлим мин синең гозерең белән! Үзе кирәк. Миңа үзе генә кирәк! Үзе генә... (*Елый.*) Үзе!

Фәрдәнә белән Ярми йөгереп керә.
Караңгылык.

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

## САГЫШ ҖЫРЫ

Яз. Фәрдәнә белән сәнәк тоткан Сәгыйдулла очраша.
Фәрдәнә читтән үтеп китмәкче була.

Сәгыйдулла (*мыегын тешләп*). Саумы, Фәрдәнә.

Фәрдәнә. Бер көе.

Сәгыйдулла. Торасызмы?

Фәрдәнә. Торабыз... Бу капка төбендә... ешладың.

Сәгыйдулла. Сарага печән китердем. Чана чалулап, сәнәк төшең калган.

Фәрдәнә үтеп китә. Сәгыйдулла карап кала.
Фәрдәнә, берәз баргач, борылып карый.

Фәрдәнә. Габделхарисыбыз өйләнә. Хат язган. Кайта алмыйм дигән.

Сәгыйдулла. Үзең бармыйсыңмы соң?

Фәрдәнә. Кем белән?

Сәгыйдулла. Безнең малай өйләнә ич. Минем белән!

Фәрдәнә. Алайса — юк. Юл өзегендә ерак китеп булмас.

Сәгыйдулла. Иртәрәк өзелде безнең юллар. (*Сәнәген көч белән печәнгә батыра.*)

Фәрдәнә. Язы әллә нинди килде. Нурсыз, моңсыз, пычрак.

Сәгыйдулла. Моңланасың киләмени? Моңнары да булыр әле. Булыр! Пычракларны юар өчен.

Сара күренә, Фәрдәнә китә.

Сара. Кирәкмәс иде.

Сәгыйдулла (*печән кертеп чыга*). Ничек кирәкмәсен, ничек кирәкмәсен?!

Сара. Ни уйламаслар!

Сәгыйдулла. Ике балалы тол хатынга дүрт пот печән китергәнгә ни уйларлар икән? Каһәрен әз күрделәр мәллә сугышның алай уйларга?

Сара. Кирәкми. Синең өлеш кирәкми миңа!

Сәгыйдулла. Минеке түгел. Ибраһим өлеше. «Исән кайтсаң, минекеләргә дә булышкала, кордаш! Сараның миннән башка бер кеме дә юк. Онытма, кордаш, ярдәмеңнән калдырасы түгел Сараны, бел аны!» Үләргә калыр алдыннан менә нәрсә диде ул.

Сара. Тагын бер кат сөйлә әле.

Сәгыйдулла. Инде кырыкмаса кырык сөйләгән!

Сара. Тагын берне генә...

Сәгыйдулла. Нигә берне генә? Кирәк икән, тагын туксан тугыз мәртәбә сөйлим. Моны үлгәнче сөйләргә дә сөйләргә. Дога итеп сөйләргә! Ә бүтәннәргә сәҗдә кылган кебек тыңларга...

Сара. Син миңа шулай сөйлә генә. Китермә печән, алып кайтма утын, аны кисешмә, турашма. Кирәк түгел, түбә ябуларың, абзар-кура төзәтешүең дә... Балага итек басып бирүләрең дә кирәк түгел... Син миңа әнә шуны гына сөйлә тагын бер мәртәбә. (*Әкрен.*) Соңгы мәртәбә...

Сәгыйдулла (*утыра, тәмәке төрә. Тамак кырып алгач*). Төрле частьлардан җыйдылар безне. Унтугыз кеше. Иң гаярь разведчиклар дип. Карасам... Ибраһим! И-и ул күрешүне сөйләп кенә аңлатырлыкмы?! Ярар... Шулай... кердек немец тылына. Ерак кердек. Шунда, эчтә, дошманның яшерен аэродромын табарга куштылар. Сигез тәүлек йөрдек. Таптык, кирәген кирәкчә шартлаттык, тоттык бер «тел», кире борылдык... Безне куа киләләр булып чыкты... Тегеләрне тоткарлар өчен әле бер төркемебез кала, әле бер төркемебез. Унбиш кешедән алтау калдык. Тагын эзгә төштеләр безнең. Ә «тел»не ничек тә алып чыгарга кирәк. Ибраһим белән миңа калырга чират җитте. Менә ул шунда командир каршына чыгып басты да... (*Тынлыктан соң.*) «Икебезнең беребез кайтсын, иптәш капитан!»— дип ярып салды... Шул калудан калды... Аннары мин дә калдым... Бөтенләйгә каласым калган да бит. И-и-эх!

Сара. Рәхмәт, Сәгыйдулла!

Сәгыйдулла. Миңа ниткән рәхмәт!

Сара. Үзең дә ялгызың, аманәтен ташла инде. Җитәр.

Сәгыйдулла. Ир кеше. Каян килеп, кая китмәгән? Син хатын-кыз башың белән нужаның бугазыннан алып көрәшкәндә, мин биленнән генә алып, аркасы белән салмам мәллә?

Сара. Бүтән көчәнеп йөрмә инде. Сыерны сатам мин. Кәҗә житкән. Ике балага күпме кирәк соң ул?

Сәгыйдулла. Ишеттем. Авыр. Алай да сабыр ит. Менә бу печәнне ашата тор әле. Тагын тора-бара күз күрер. Минем нәрсә — бер кәҗә дә ике баш сарык. Ә җәе шәп килде. Печән күп миндә. Аларга да җитәр, синең сыерга да.

Сара. Нинди кызык дөнья! Мин, сыерлы була торып, печәнгә интегәм. Синең печән булып, сыерың юк.

Сәгыйдулла. Кешеләр дөньясы да шул, анасы коргыры!
Сара. Ничек — шул?
Сәгыйдулла. Ибраһим урынына үзем генә калсам соң! Кем белә бит болай килеп чыгасын. Син дә йөрисең кангырып... мин дә... Шул печән шикелле: ни сиңа, ни миңа юк дөнья яктысы.
Сара. Бәхет ике яклы, күрәсең... (*Печәнне иснн.*) Бөтнек исе... Эх, бөтнек исе!

**Сәгыйдулла, печәнгә авып, аны кочаклап үбә. Сара ычкына да аңа селтенә.**

Шушымыни гозер үтәвең?.. Бүтән берәү булса... Өзгәләр, сөякләренне ватар, маңгаең җиргә тигәнче... тибәр идем! Авыртудан түгел, тол хатын хәтерен калдырудан, оятыңнан сызланыр идең!
Сәгыйдулла. Йә, ялгыш... Кем белән булмас хәл...
Сара (*аягына баса*). Теләсә кем белән... минем белән кирәкмәс иде. (*Елап.*) Байтак исәрләрнең телен аркылы тешләткән!
Сәгыйдулла. Ялгыш дим. Хата.
Сара. Әллә кемнәрне эт итеп кудым, әллә кемнәрне төшләрдә күрдем... Ибраһимым булсаң икән әгәр!.. Бөтен авыл белән карап торсалар да... салкын дими... кар дими... оялмыйча...
Сәгыйдулла. Бар икән соң дөньяда изге җаннар!.. Бер-ике атнага утының җитәрлекме?
Сара (*өстен кага*). Йөрмә бүтән. Үзем. Үзем! Вилданым да эшкә ярый хәзер. Йөрмә бүтән...
Сәгыйдулла (*коры*). Алайса, менә ни... Сыерыңны миңа сатасың.
Сара. Сатам... Аны түгел, ярты җанымны сатам.
Сәгыйдулла. Ни күрәм — шуны алам. Сатулашып тормыйбыз, бәяне үзем куям.
Сара. Ә минем нием бар — шуны сатам. Киләчәкне яшереп булмый — сыер кысыр. Алдап ни мәгънә? Шуңа сатам да.
Сәгыйдулла. Миңа иткә кысыр сыер кирәк. Симертеп, берәзын ашарга, берәзын сатарга. Кайда ул, карап чыгыйм да...
Сара. Әйдә...

**Кереп китәләр. Берәздән яңадан чыгалар.**

Сәгыйдулла. Ялгыша күрмә, Сара. Сыерың бушка ашарга җыенмаган, буаз. Апрельләргә җиңеләясен көт тә тор. Кыз шикелле сыер тол хатынга ышанып кысыр каламы соң?
Сара. Каян килеп? Көтүче дә ул-бу шәйләмәгән.
Сәгыйдулла. Сыерың көтүче күзенә чалынырга оялгандыр.
Сара. Инде дә телен... Ибраһим шул булыр иде. Телең белән түгел, әллә нием белән сөйләшәсең шунда. Каян беләсең буаз икәнен?
Сәгыйдулла. Сатучы түгел, алучы әйткәч, ышан инде.
Сара. Сатып алучы кеше малын мактамый торган иде.
Сәгыйдулла (*акча саный*). Менә бер мең... ике... өч... дүрт булды... инде биш... Менә биш мең ярым тәңкә.

**Сара ул санаган көйгә баш кагып бара. Дүрттән узгач, карап кына тора. Аннары чирек литр аракы, стакан алып чыга, акча янына куя.**

Сара. Мәгәриче.
Сәгыйдулла. Рәхмәт. (*Салып эчеп куя.*)

**Сара акча саный.**

Ышанмыйсыңмы әллә — саныйсың? Ә-ә, сакланганны алла саклаган, сана, сана... Әзсенәсеңме? Шулай инде, нәфсенең төбе юк.

Сара аңа акчаның бер өлешен суза.

Сара. Болары — миң дә биш йөз тәңкәсе — артык. Дөрес әйтәсең, нәфес — чиксез. Тик артык акча түләү юмартлык түгел. Телең белән әйт син күңелеңдәгесен. Күңел теләгән акчага төрәсең.

Сара елый. Кулындагы акчалар аяк астына сибелә.
Сәгыйдулла, тезләнеп, җыярга керешә.

Сәгыйдулла (*башын күтәреп*). Ул — Ибраһим өлеше.
Сара. Ибраһим, Ибраһим! Ник чирканасың үз өлешем диярга?
Сәгыйдулла. Минем тормыш — Ибраһим үлеме. Бу аның гозерен үтәп, аның гозерен! Миңа синә я акча, я печән. Икесенең берсе. Кайсысын сайлыйсың?
Сара. Өченчесен.
Сәгыйдулла. Нинди өченчесен? Юк өченчесе.
Сара. Бар... Өченчесе — син.
Сәгыйдулла. Мин?!
Сара. Җаның әйбәт синең. Чиста, тымызык. Көз көнендәге инеш шикелле. Сыерымны бүтәннәргә сине күтеп сатмадым. Инде хәзер сиңа да сата алмыйм.
Сәгыйдулла. Ә мин сатып ала алмыйм. Буаз сыерны ничек итеп суймак кирәк? (*Карашлары очраша.*)
Сара (*карап тора да, елап, аның күкрәгенә каплана*). Көн дә чыккан кояшның җылысын биш ел буе сизмим бит инде! Җәйгән мендәрем тышыннан биш ел буе күз яше генә юам. Сыерым бирнәм булсын, Сәгыйдулла!

Пауза

Сәгыйдулла. Аңламый калдым: нигә соңгы мәртәбә сөйләттең Ибраһим турында?
Сара. Мәңге онытмас өчен. Миңа фатихасы итеп тыңладым.

Фәрдәнәләр өе. Ярми керә.

Ярми (*биштәрен сала*). Күперне сүтеп бетереп яталар. Бу якка чак элгешеп калдым. Самавар куеп җибәрсәң икән, тамак чатнады.

Фәрдәнә самавар куя.

Сиңа бер нәрсә алдым әле. (*Биштәрен чишә.*)
Фәрдәнә. Юк акчаны әрәм-шәрәм итмәс идең.
Ярми. Әрәм дип... Сиңа да язык түгел. Менә, күлмәк!

Ярми төргәк чишеп, зәңгәр ефәк күлмәк таратып җибәрә.
Фәрдәнә сөенечен яшерә алмыйча күзгә каршында бөтерелә.

Сабан туена кофтасын алмабызмы. Йонын... Аннары ни... Бәлкем, мәйтәм, күзләргә мамык кәҗәсе юнәтәсе түгел микән, дим. Кышын шәл бәйләрсең. Бәлкем үзегезгә дә артыр иде берәр шәллек. Үзем мин менә шушы сыңар кул белән дә өч шкаф ясап саттым бит. Икешәр йөз тәңкәдән. Игә килербез анысы, нәрсә аны. Җан тыныч булсын, җан.
Фәрдәнә. Елгада боз китә алмый торамы?
Ярми. Су аз быел. Игеннәр уңармы, юкмы — билгесез.

Гармун тавышы ишетелә.

Сәгыйдулла, ахры.
Фәрдәнә (*сагаеп*). Ул.

Я р м и. Эчте микәнни?

Ф ә р д ә н ә. Кем белгән?

Я р м и. Оста уйный, каһ-һәр!

Ф ә р д ә н ә. Яңа көй.

Я р м и. Әллә тагын. Кайда отты икән?

Ф ә р д ә н ә. Ишеткәндер бер-бер яртын да, кыз-кыркын отып алсын дип, урам әйләнүедер.

Я р м и. Салгандыр, шельма! Күз төрткесез караңгыда пычрак ерып йөрмәсә. Тукта әле, былтыр да үтте түгелме шушылай?

Ф ә р д ә н ә. Үтте.

Я р м и. Шуннан бирле уйнаганы хәтердә юк. Ни кунак-төшемдә, ни Сабан туенда уйнамады бугай.

Ф ә р д ә н ә. Уйнамады. Яшь-җилкенчәк аптыратып бетергән «өйрәт!» дип. Былтыргы яздан бирле уйнамаган. Менә, икенче кат.

Я р м и. Килешми инде болай малай-шалай сымак. Сарасы ник тыймый икән?

**Гармун тавышы якыная. Фәрдәнә тәрәзәгә елыша. Кинәт ялкын биеп ала. Фәрдәнә артка чигенә.**

(*Исе китеп.*) Карале, аҗаган! Яз тинтәкләнеп килә быел. Беренче көнен көтүгә чыккан кысыр сыер мыни!

Ф ә р д ә н ә. Көе миңа лабаса моның! Миңа!

Я р м и. Ничек — сиңа?

Ф ә р д ә н ә. Нигә газапларга булды икән? Йөрәгенең ташуы икән лә бу аның, Ярми!

Я р м и *(учына төкереп).* Ә мин аңа ташыйм менәтерә җаен табып. Шундый итеп ташырмын бер!!

**Караңгылык. Сәгыйдулла үтеп бара. Фәрдәнә аның каршысына килеп чыга. Чиләк-көянтә аскан. Аларны тәрәзәдән карый-карый, Ярми тәлинкәле репродуктор төзәтеп утыра.**

С ә г ы й д у л л а. Саумы, Фәрдәнә.

Ф ә р д ә н ә. Ару гына.

С ә г ы й д у л л а. Суыңны эчим әле, тамак чатнады.

Ф ә р д ә н ә. Чишмәгә кар суы төшкән, тәмле булмас.

С ә г ы й д у л л а. Кар сулары йөрәк талдырмый. *(Тезләнеп, Фәрдәнә чиләгеннән су эчә.)*

Ф ә р д ә н ә. Габделхарислар бәби алып кайткан.

С ә г ы й д у л л а. И-эх! Үтә гомер! Үз гомеребезнең читеннән карап кына узабыз шикелле.

Ф ә р д ә н ә. Тагын чакыралар. Гел юл өзелгән чакта туры килә.

С ә г ы й д у л л а. Кар күп быел. Тимерчелекне, зират почмагындагы каеннарга хәтле су басты.

Ф ә р д ә н ә. Басты.

С ә г ы й д у л л а. Ташу хәтмәле төшәрдер.

Ф ә р д ә н ә. Хәвефсез узсын иде.

С ә г ы й д у л л а *(күзен кыса төшеп).* Бүген я иртәгә инде.

Ф ә р д ә н ә. Нәрсә?

С ә г ы й д у л л а. Ташу.

Ф ә р д ә н ә. Бүген я иртәгә... Ел саен бүген я иртәгә. *(Узып киткәч борыла.)* Тагын үтәрсең микән?

С ә г ы й д у л л а. Ташкынга буа юк. Кар астыннан бәреп чыга да ташый ургып.

Ф ә р д ә н ә. Син!..

С ә г ы й д у л а *(кисәк борыла).* Нәрсә — мин?

Ф ә р д ә н ә. Ташулар җир битен юган чакта минем биткә корым ягып үтәсең! Җир яшәрә, мин каралам...

Сәгыйдулла. Ә минем күңелдән Тилгән тавы караларын нигә ди ташкын юар? Сиңа минем янган җанның көле генә эләгә. Көле генә.

Фәрдәнә (күккә карап). Мин ышанам аллага, әгәр аның җәһәннәме синең җанда дисәләр!

Сәгыйдулла. Нишләтим соң сүндерергә әмәл тапмагач? Сара мәллә дигән идем... Җан януларын кем кабызган — шул гына сүндерә ала икән...

Фәрдәнә (аяк астына карап). Соң... алайса... җанның утына мин су була алсам, халык күзе төшмәс берәр урыны бардыр бу дөньяның... Бер таптан кояш сүнмәс!..

Сәгыйдулла. Ә?! Бар микән андый урын безнең өчен? Булса, минем сиңа җәһәннәм булып тоелган җанның анда җәннәткә әйләнүе кемгә хаҗәт, Фәрдәнә? Ничек итеп җанны хыянәт пычагы астына салмак кирәк...

Фәрдәнә. Гомер буена дөнья хуры булып яшәгәнче, бер тапкыр мәхәббәт буры гына булырга риза!

Сәгыйдулла. Әгәр син минем моңлы дөньям икән — кирәк түгел миңа бүтән дөнья!

Фәрдәнә. Йөр алайса шул көең белән урам буенча шыңшып! (*Елый.*)

Сәгыйдулла. Җырның ертыгы юк... Шыңшысаң да, гаеп түгел, сөю җыры ул.

Фәрдәнә. Сөю?

Сәгыйдулла. Өч ел рәттән мин табышмак җырламадым.

Фәрдәнә. Табышмак!.. Җавабын үчлек дисәм, каршы әйтер идең мәллә?

Сәгыйдулла (*чигенә*). Юк, Фәрдәнә! Алай димә! Дистә еллык газабымның барысын җыеп атма кире минем җанга. Үчлек түгел, сөю иде. Фал хакыйкать. (*Ыңгырашып.*) Сөю иде! (*Китә.*) Үчлек түгел.

Фәрдәнә. Бер табышмак. Ике җавап. Кайсысы хак соң моның? (*Китә.*) Кайсысы хак?

**Караңгылык. Саралар өе.**
**Сара Сәгыйдулланы әткәләп чыгара, бүреген ыргыта.**
**Сәгыйдулла көлә, бүреген бик пөхтәләп кыңгыр киеп куя.**

Сара. Минем дә җан бар лабаса! Кешедән оят, билләһи!

Сәгыйдулла. Оят җир күрсәтеп йөрим мәллә?

Сара. Анысын эшләсәң, җиңелрәк булыр: бармак төртеп, дивана дип көләрләр иде дә эше бетте.

Сәгыйдулла. Теләсәм уйныйм, теләсәм мырлыйм!

Сара. Мырламыйсың — җанны тырныйсың.

Сәгыйдулла. Синекен түгел.

Сара. Ничә ел теләсең бит инде җанны, ничә ел! Җиткән кызыннан оял.

Сәгыйдулла. Көнчелек баса мәллә? (*Шаяртып үчекли.*) Елга бер тапкыр яшьлеккә кайту шәригатькә сыя.

Сара. Һ карт аю! Сәрхәнтәй! Күпме түзәр башкайларым?

Сәгыйдулла. Ә минеке?

Сара. Соң, Сәгыйдулла... Өз инде! Үчләнмә!

Сәгыйдулла (*бүкәнгә утыра*). Җан кылларын өзәр көчләр табып бир син миңа, Сара!

Сара. Күземнән юк булсаң иде, ярабби!

**Гармун алып чыгып ыргыта да кереп китә. Сәгыйдулла тотып кала.**

Сәгыйдулла (*көйли*).

> **Сусадым да, җаный, сулар кайда?**
> **Дәрья суларында юк файда.**
> **Урамнар да гизеп, җан тибрәтеп,**
> **Бер үтәлсәм, миңа шул файда.**

Нәрсә йөртә соң мине ташулы төндә кангыратып? Тозлы җил шикелле бушка өреп, яшьлек каядыр очып бара. Аратага бикләп куеп буламыни аны?.. Әй, кеше! Анасыз калган тай арата киртәсен кимергән күк гомер буе ник кимерәсең хәтереңне?! Ничек итеп акылга килергә дә ничек итеп әрнүләрдән арынырга, бу хисләрдән айнырга соң? Үз хаклыгымны аңлатырга тырышам, нинди көй чыгардым! Ни теләдем? Кеше кайгысына саңгырау булып ник йөрим соң мин?! Кайда минем урын: җирдәме, һавадамы... күк белән җир арасындамы? Яшәү кыйблам кайда? Карпат таулары аша туп күтәреп чыкканда ник булган да, хәзер ник юк соң ул кыйбла? Аңларга иде боларның һәммәсен. (*Күккә карап.*) Әй, кем бар анда? Әйт каян бу моң? Күк гөмбәзен кыңгырау итеп тагын бер тапкыр кагыйммы җырымны? (***Гармун аса, җырлый.***)

> **Биек тау башында ни күренә —**
> **Болытлардан узар күк атмы?**
> **Ялгыз атны адаштырган карлар**
> **Пар йөрәкне бозар куәтме?**
> **Челтәрле генә чана кузырлы,**
> **Ат ялларын ачы җил кисә.**
> **Кар бөртеге булып очар идем,**
> **Тауның башларында син дисә.**
> **Биек тау башында ни күренә —**
> **Карбыз чәчәк атадыр кардан ак.—**
> **Дөньяларга гына ла килсә икән**
> **Араларда ла йөрер аргамак.**
> **Челтәрле лә чана кузырлы,**
> **Ат ялларын ачы җил кисә.**
> **Кар бөртеге булып очар идем.**
> **Тауның башларында син дисә.**

**Ераклашкан кыңгырау тавышы.**

Җитте... Бүген соңгы көн. Соңгы кат, җитте!..

> **Яндырган ла шәмнәр сүнәрме,**
> **Җыр җырламый кеше түзәрме?**
> **Җырлар җырлап эчне бушатмаган**
> **Моңлы кеше егылып үләрме?.. И-иәх!**

(***Чыгып китә.***)

**Фәрданәләр өе. Ярми репродуктор төзәтә. Чиләк-көянтә күтәреп, Фәрдәнә кайта.**

Фәрдәнә. Ник ут кабызмыйсың? (*Лампочка кабыза.*)

Ярми (*ачулы*). Караңгысы да адәмнәр өчен яратылган. Караңгыда кеше күрми.

Фәрдәнә. Нәрсәне?

Ярми. Иң кимендә... синең шуның белән тел чайкап торуыңны.

Фәрдәнә. Иң кимендә? Ә артыгы ни?

Ярми. Эңгер-меңгер йөзегезне капламаса, телегез ни сөйләгәнен күзегездән белер идем.

Фәрдәнә (*су бушата*). Эчтә нинди авыру ятканын күбрәк телдән беләләр. Авырудан караңгыда ятып кына качып булыр дисеңмени?

Ярми. Авырудан?

Фәрдәнә. Эчебездә бер-беребезнең күңеленнән яшерен асраган авыру юк димсең? Ишетәсеңме? Буа өстеннән елга ташый! (*Су, кисмәктән ташып, идәнгә ага.*)

Ярми. Кисмәгең ташый ич.

Фәрдәнә. Кисмәк түгел, җан ташый шулай. Әнә, бүген тагын узам ди.

Ярми. Алай булгач, аның белән нишләп сөйләшеп торасың? Тор, тор! Болай да авыл күзе күрми сезне!..

Фәрдәнә. Ул яктан минем бәхетләр хәттин ашкан — үтә күренмәле! Көлмәк кенә каплап бетермәле түгел... Син дә яшисең тагын хатын белән! Бар дөньям белән кеше күзе-телендә булгач, нинди хатын соң мин сиңа?

Ярми. Бер мыскал да кыңгыр эш кылмый яшибез. Ә син караңгыда шуның белән сөйләшеп торасың. Әллә инде... ялындыңмы?

Фәрдәнә бәрәңге алып керә.

Шуңа тел әрәм итәмме соң, Фәрдәнә?.. *(Тыңлык.)* Бәрәңге шәп тора, ә?

Фәрдәнә. Бәрәңге шә-ә-әп... Әллә соң үзең сөйләшеп карыйсыңмы?

Ярми. Урамда дошман өргәндә, өйдә хатын гына уламасын иде! Син ашыңны кара җәһәтрәк — тамак ачты.

Фәрдәнә *(бәрәңге әрчи)*. Утын алып кер.

Ярми күнитек киеп чыгып китә. Утын күтәреп керә. Гармун тавышы ишетелә.

Ярми. Килә теге тәре баганасы. Кочагында җиз бакалы кәҗәсен бакыртып!

Фәрдәнә *(тәрәзәгә каплана)*. Төне нинди якты!.. Ул исән чагында, миңа яшәү юк күрәсең, Ярми! *(Кисәк борыла, Ярминең күкрәгенә капланып елый.)*

Ярми *(юата)*. Ихтимал. Ихтимал шулайдыр, Фәрдәнә... *(Өстәлдәге пычакны күнитек балтырына тыга.)* Кая, җибәр, чыгыйм әле каршысына шул газап дәрвишенең. *(Чыгып китә.)*

Фәрдәнә *(тәрәзәдән карый)*. Ай кан төсендә бүген.

Гармун тавышы. Фәрдәнә бәрәңге әрчергә пычак эзли, таба алмагач, йөгереп чыгып китә. Урам. Ярми почмакта басып тора. Гармун уйнап, Сәгыйдулла керә. Ярми аның юлына аркылы төшә.

Ярми. Син! Җан зәһиләңне... Туктыйсыңмы, юкмы?!

Балтырыннан пычак чыгара да Сәгыйдуллага кизәнә. Ул, кычкыртып, гармун күреген тартып җибәрә. Анда «Смерть фашистам!» дип язылган. Ярми туктап кала. Гайрәтен баса алмыйча, ыңгырашып, гармунга чәнчеп ала.

Сәгыйдулла. Ник туктадың? Када! Бу сүзләрне синең чалгы пычагың түгел, көче белән очкан пуля да алмады аны!

Фәрдәнә йөгереп чыга. Арттан Ярминең кулына асылына, җиргә төшкән пычакны читкә тибеп җибәрә.

Фәрдәнә. Минем өчен гөнаһ алма җаныңа. Йөрсен. Язгы көндә ат көтүенә җибәрелгән үгез кебек нишләрен белмичә үкереп!

Сәгыйдулла *(көлә)*. Гармундагы бу сүзләрне пулялар да читләтеп үтте, әйе! Җырга үлем юк аңа! Ул сиңа карт этәч түгел, суя алмассың!

Ярми. Ни күзең белән карыйсың син дөньяга? Кара үчле ул күзеңә кызган тимер басар идем, әгәренки хәлдән килсә минем!

Сәгыйдулла. Тилгән тавында ук көйгән инде алар, эш калмаган сиңа тамчы да!

Ярми. Чарлама телеңне кытыршы җаныңа ышкып.
Сәгыйдулла. Минем җанда ярсыган үгезне синең сыңар кул гына чылбырлый ала торган булса иде!..
Фәрдәнә. Кешеләргә дә божра кидерелгән. Сәгыйдулла! Кешеләргә дә! (*Китәргә юнәлә.*)
Сәгыйдулла. Божра?! Бусы ни тагын?
Фәрдәнә. Намус... Кеше кулындагы чылбырын күргәнче, алдан намусыңны барлар идең.
Сәгыйдулла. Башта синекен!
Фәрдәнә. Үчлегең кимергән сөяк булып калыйм алайса. Яшә игәп минем таш йөрәкне! (*Кереп китә.*)
Сәгыйдулла. Шул ташны эретәм дип йөрим ләбаса!
Ярми. Тел сукыр ул. Синең күзең сөйләсен. Тел әйтә дә кереп кача үз куышына... чагып, оясына качкан елан шикелле. Гармунның да шул...
Сәгыйдулла (*көлә*). Ә-ә! Чагамыни? Ча-га-мы?
Ярми. Күпме ашарга мөмкин кеше җанын?
Сәгыйдулла. Шушы гармун тузганчы, алла теләсә!
Ярми. Тузганчы?! (*Гармунга кизәнә*). Менә сиңа тузганчы.

**Каз кычкырган тавыш.**

Сәгыйдулла. Тәннәр черер, ә моң калыр!
Ярми. Хәсрәт кисәве булып көйрәгән моңмы калыр?!
Сәгыйдулла. Чалгы пычак белән кан агызып, шул кисәүне сүндермәкче булдыңмыни?.. Алай дисәң, егерме миллион корбан каны белән бөтен хәсрәт корымын юып булыр иде!..
Ярми. Бу сугышның хәсрәт капчыгын мондый җыр белән төйни алмыйсың, Сәгыйдулла. Бир тынгылык. Аңа, миңа. Үзеңә. Сара да бар — аңар да.
Сәгыйдулла. Һа! Тынгылык... Тынгылык! Җинаятькә җәза тиеш.
Ярми. Нинди җинаять?
Сәгыйдулла. Хыянәттән зурысын белмим!
Ярми. Их, Сәгыйдулла! Җырны шундый усаллыкка төрәләрмени? Бер генә яшибез дөньяда. Интектермә Фәрдәнәне.
Сәгыйдулла. Үзем генә газапланыйммы?
Ярми. Теләсәң нишлә.
Сәгыйдулла. Менә ич, теләсә нишлим.
Ярми. Ирлегең кайда соң синең?!
Сәгыйдулла. Шикләнмә, тиешле җирендә... Йөрәк мичендә хисләр яна терелә! Ялкыннарын аракы да басмый!
Ярми. Кем гаепле, кем?
Сәгыйдулла. Мин мәллә?
Ярми. Авыл хатыннарының да ни гаебе бар? Кем хокук биргән сиңа толларның, ирләре кайтырына өметен өзеп, тормышка чыкканнарның хәтерен болгатып йөрергә? Кем ике яшн, кем?
Сәгыйдулла. Мин. Мин ике яшим. Үлеп терелгән.
Ярми. Ник кайттың соң янгын басылгач? Ник, менә минем шикелле, кулсыз калып булса да кайтмадың — тик үз вакытында!
Сәгыйдулла. Күмер өстенә кайттым шул. Күмер өстенә... Көлләрне җил очырган иде! Җан менә пыскый әле! Пыскый, Ярми!
Ярми. Фәрдәнәнеке дә пыскысын дисеңмени? Ниме дип кыйнадың соң ул Гитлерны — монда кайтып, аны изалагач?
Сәгыйдулла. Бусы инде минем эш. Минем!
Ярми. Синеке микән?.. Синеке микән?
Сәгыйдулла. Шушы җырны улаклы чишмә итеп, соңгы сусавымны басмаммы дип тырышуым иде.

Я р м и *(папирос каба)*. Шырпыңны сыз әле.

**Сәгыйдулла шырпы сыза.**

(*Әкрен.*) Йөр алайса аның бәгырь капкасына дегет сылап. Дөньяга шуның аша кимсенеп каравын теләсәң. Бер килерсең әле кырырга дип. Үзең сылаган дегетеңне үзең юудан мәхрүм итәрләр.

**Фәрдәнә күренә. Караңгылыктан тыңлап тора.**

С ә г ы й д у л л а. Туйдым, Ярми! Сөлек булыпябыштым сезгә. Инде менә кайгыларга туйдым да үзем кубып төштем. Бүгенге җыр — ахыргысы иде.

Я р м и. Ахыргысы?

С ә г ы й д у л л а (*тирән сулап*). Ахыргысы...

Я р м и. Ник соң аны... тел чайкап... карышасың?

С ә г ы й д у л л а. Сөлек үзе туймыйча купмый ич, Ярми. Ә син пычак белән кубармакчы! Ни мәгънә бар сөлекне өзүдән, авызы белән җаныгызга кабып калгач?

Я р м и. Ул җырыңны кире костырыр көл бүтәнчә каян аласың?

**Фәрдәнә кереп китә.**

Туктале, көтеп тор... Утыр. Көтеп тор.

**Кереп китә дә чәйнек, стакан тотып чыга.**

Утыр әле. Менә мә, тот әле! Чиста балдан бу нәрсә.

**Бал салып бирә. Сәгыйдулла эчә.**

Яле, «Шахта» көен уйна әле бер! (*Җырлый.*)

**Сандугачым сайрап җибәр**
**Талларга басып кына.**
**Салкын сулар эчеп кенә**
**Йөрәгем сабырлана...**

С ә г ы й д у л л а. Шәп! Нинди шәп монда, Ярми!

Я р м и. Этләр өрә!..

С ә г ы й д у л л а. Миңа... улыйлар иде... кушылып.

Я р м и. Тукта әле... (*Тыңлый.*) Әнә, ташу буаны алып китте.

С ә г ы й д у л л а. Китсен... Китсен! Агызсын ташкын җир өстендәге бар шакшыны. Җир битенә утырып калмасын... Сал әле, сал! (*Җырлый.*)

**Тальян гармун телләрендә**
**Минем биш бармак кына.**
**Агач яфраклары кебек**
**Саргаям салмак кына.**

**Уйнап китә.**
**Сара өе. Сәгыйдулла кайтып керә, эскәмиягә утыра. Яланбаш. Сара күренә.**

С а р а. Кайттыңмыни?.. Кайттыңмыни дим?

С ә г ы й д у л л а. Ташу ага.

С а р а. Күңелең булдымы соң?

С ә г ы й д у л л а. Булып ашты, Сара.

С а р а. Инде ник мөкетләнеп утырасың? Кер.

С ә г ы й д у л л а. Бәхилләшәм, Сара.

С а р а. Кем белән?

С ә г ы й д у л л а. Гармун белән, Сара, бәхилләшәм... Тыңла әле — көе нинди иде, ә? (*Уйный.*) Соңгы мәртәбә сиңа уйнадым.

Сара. Син соңгы тапкыр үзеңә уйна. Үз эчеңдә чыгаргансың, үз эчеңдә сүндер дә. Кем кабызган, шул сүндерә.

Сәгыйдулла. Кем кабызган, шул... Әйе, әйе. Әйе! Әле дә ярый син аңладың мине, Сара. Инде бүтән уйнамыйм. Иөрәк кенә түгел, хәтта бармаклар да арыды.

Сара. Салкынчалатты. Башыңа ки.

Сәгыйдулла. Бер ерганак аша чыкканда бүрек төшеп калды. Агып китте.

Сара. Шул гына җитмәгән иде.

Сәгыйдулла. Баш агып китмәсен. Исән булсак, җылытыр. Җылыга борылды инде.

Сара. Бәрәңге пешердем. Суынадыр. Керик.

Сәгыйдулла. Җанның сөлекләрен кубарып аттым әле. Сара. Яраларын тегү — инде синңа. Карале, хатын...

Сара. Я?

Сәгыйдулла. Карале, мунча ягып җиб-бәр әле иртәгә, малай.

Сара. Чү!.. Атна ахырында гына керендең ләбаса!

Сәгыйдулла. Син як әле, як.

Сара (*гаҗәпсенеп*). Ярар соң.

Сәгыйдулла. Беләсеңме... Егет чакта алачык ярыгыннан бер кыз затының чишенгәнен карап торган искә төште. *(Көлә.)*

Сара. И-и чукынган!

Сәгыйдулла. Синең яшь чакны хәтерләмәк булып азапланган идем... Күз алдында — эссе әвеннәр, печән богыллары, ашлык кибәннәре, Сабан туйлары — син берсендә дә юк... йөзең төсмерләнмәде. Әнә шул кыз заты гына истә. Танадым — ул син икән.

Сара. Мин?

Сәгыйдулла. Әнә шул алачык ярыгыннан таныйм сине. Шуннан ачылды хәтер — янда Ибраһим да бар иде ул чакта. Мине ул нярткән иде. Төштә күргән күк кенә. Әнә бит ул дөнья нинди, ә? Яшисең, яшисең... Ә гомер күрелеп бетмәгән төш күк кенә икән... Карап бетерәсе килә.

Сара. Алачык ярыгыннанмы?

Сәгыйдулла. Алачык ярыгыннан. Синең аша. Бу дөньяга инде синең аша гына карыйсы калды.

Сара. Бәрәңге суынадыр.

Сәгыйдулла. Гомер үткәч икән кешенең бәясе.

Сара. Бәясе?

Сәгыйдулла. Ни... ярату дииюем. Менә кайчан килә икән ул бер-берең кадер. Рас килгән икән — сүрәнләтмә! Мунча кебек кайнар тот: яшә, чабын күпме җары бар. Суытырга дисә аунар кары, әкерен ятарга кабере бар... *(Керен китәләр.)*

**Фәрдәнә өе. Туй шау-шуы. Люция белән Хөрмәт йөгерешеп керә.**

Люция *(кисмәккә иелеп)*. Хәзер безнең уртак мәшәкатебез бар.

Хөрмәт. Ярату мәшәкатьмени?

Люция. Тормыш мәшәкате. Безнең әз генә мебелебез, ягар учагыбыз, кызыл чәчәк ата торган гөлебез бар. Тагын шул гөлгә су урынына сибеп торыр... яратуыбыз... Тагын ни кирәк, әйеме, Хөрмәт?

Хөрмәт. Тагын бер генә нәрсә кирәк — боларның берсен дә онытмаслык хәтер. (*Суга карый.*) Хәтер суында кешенең йөзе бүтәннәргә күренеп чагылып тора икән — бу дөньяда яшәгәнеңә үкенерлекме соң, шайтан алгыры!

Люция. Су ага да китә.

Хөрмәт. Аккан тавышы кала. Җыр булып.

Люция. Җырлар да онытыла.
Хөрмәт. Яңалары чыга.

Люция. Тик аларын һәркем ишетми... Сәгыйдулла абзый, әнә, безнекен ишетмәде. Без дә... ишетмәбез кемнекендер.

Хөрмәт. Ишетте Сәгыйдулла абзый.
Люция. Ишетте?
Хөрмәт. Фәрдәнә әби хәтерендәге Сәгыйдулла ишетте.
Люция. Шулай булгач, хәтер — яшәү белән үлем арасымыни?
Хөрмәт. Җыр белән җыр арасы. (*Җырлый.*)

**Биек тау башында ни күренә —**
**Карбыз чәчәк атадыр кардан ак.**
**Дөньяларга гына ла килсә икән**
**Араларда ла йөрер аргамак.**

Люция. Сәгыйдулла абзый җыры!
Хөрмәт. Каян беләсең?
Люция. Фәрдәнә түти белән минем арада тамчы да сер калмады.
Хөрмәт. Шул сер калмау — хәтер түгелмени?
Люция. Ә син каян беләсең ул җырны?
Хөрмәт. Өмет тулы бу җырны бергә отканбыз икән, онытмаска иде, Люция!
Люция. Йөрәк инде аны мең кат ятлады — онытылмас.
Хөрмәт. Үткәннәрдән бары тик җыр гына кала икән ич!
Люция. Ләкин ул җыр безгә — яшьлек ядкаре.

**Бергә җырлыйлар, вальс бииләр.**

**Бергә откан өмет тулы җырны**
**Йөрәк инде мең кат ятлады.**
**Үткәннәрдән бары шул җыр кала —**
**Ул җыр безгә — яшьлек ядкаре.**

Хөрмәт. Ник елыйсың, Люция?
Люция. Юк, еламыйм.
Хөрмәт. Әй, еласаң иде син бер, Люция. Җырдагыча!
Люция. Җырдагыча?
Хөрмәт. Әйтимме?
Люция. Я.
Хөрмәт (*көйләп*).

**Ике дәй генә түгел, ай, өч фонарь,**
**Фонарьлары саен шәм янар.**
**Ике каш арада сиксән керфек —**
**Керфекләрең саен яшь тамар.**

Люция. Яшь тамар?
Хөрмәт. Яшьтән куркасыңмыни?
Люция. Нинди кызны куркытмыйдыр ул? Фр-р!
Хөрмәт. Шатлык яше булса дамы?
Люция. Нәкъ шунысы кирәкмәс тә!
Хөрмәт. Нигә?
Люция. Андые аның бер мизгеллек... Бер бөртек.
Хөрмәт. Ташып торганы язсын алайса.
Люция. Анысы нинди?
Хөрмәт. Хәсрәтләре белән көйдерә торганы.
Люция (*аның авызын каплый*). Чү! Авызыңнан җил алсын!
Хөрмәт. Күз яшенең шундые татлы. Сөю, ярату дигән хәсрәт китергәне... Бусы гомергә бер генә. Иң бәхетлесе — шул.
Люция. Кем соң син, кем, Хөрмәт? Каян алдың бу ихласлыкны?

Хөрмәт. Синнән, Люция... (*Кисмәктәге суга карый.*) Кара әле, әле, безнең суга йолдыз чаткысы төшкән... Йолдызларның иң якыны ничек аталганын беләсеңме?

Люция (*иелеп карый*). Сириус. Сириус.

Хөрмәт. Юк. Иң якын йолдыз... синдер дип, мин беркайчан да әйтә алмас идем, әгәр бу дөньяда... Люция атлы кыз булмаса.

Люция. Төш... Төш күрәм кебек.

Хөрмәт. Мондый төш була димени, юләр... юләрем минем. Төш итеп әрәм итәрлекме соң сине? Сине...

Бии-бии чыгып китәләр. Фәрдәнә белән Сара керә.

Сара. Шундый моңнарны да җир күмә микәнни?

Фәрдәнә. Күмәме соң — әйләнәләр дә кайталар, әйләнәләр дә кайталар.

Сара. Әйт әле дөресен, Фәрдәнә: сиңа ул көй кара күк дәрьясында кычкырып йөргән козгын тавышы булып тоелмадымы ул язларда?

Фәрдәнә (*сискәнеп*). Козгыннарның кешеләрдә ни эше бар да кешеләрнең козгыннарда ни эше бар? Этләр өрә торды, ә без, менәтерә, чәй эчәбез әле! Соңгысы булмас! Вилданың чит җирләргә алып китсә дә, онытма безнең ничек торганны — дүртебез дә бер көйшәнкәгә береккән чикләвекләр шикелле яшәдек. Ә чикләвекләрнең берсенә-бер корт кертмәдек... Чәй ясыймчы, Сара?

Сара. Тутырмыйчарак кына.

Чәй эчәләр.

Кәефеңне боздым әле. Әллә нишләп каты сөйләштем.

Фәрдәнә. Үлем — йомшак нәрсә түгел инде ул.

Сара. Ник үлде соң бу Сәгыйдулла?.. Яши идек ич әле. Ару гына тора идек.

Фәрдәнә (*үзалдына*). Нигә мин әйтмим соң әле бу сүзләрне? (*Сарага.*) Һәр ярага вакыт дәва.

Сара (*уйчан*). Һәр ярага вакыт дәва... Вакыт җәрәхәтли дә ул. Язгы ташу елга ярын елның елында яңарта тора.

Фәрдәнә. Яңарта тора. Хак.

Сара. Сәгыйдулланың хәтере җәрәхәтле китте. Бер мәлне бу гармунны сорап мәктәп балалары килгән иде.

Фәрдәнә. Гыйбрәт алмагадыр инде.

Сара. Кайларда гына уйнамагандыр ул!

Фәрдәнә. Кайларда гына...

Сара. Ә ямаулары икәү генә...

Фәрдәнә (*гармунны әйләндергәләп*). Икәү генә. Сакланган.

Сара. И-и моның күргәннәре!.. Ике тапкыр яраланган. Гармунны әйтәм.

Фәрдәнә. Берсе турында сугыштан миңа язып җибәргән иде. Пуля тиде дип.

Сара. Икенчесе — пычак эзе.

Фәрдәнә. Уттан-судан күп саклады бу гармун үз иясен.

Сара. Баш киселсә дә, кешедән фәкать шул моң кала ласа. Сәгыйдулланы да шул моң саклагандыр.

Фәрдәнә. Синең бәхеткә.

Сара. Кемгә бәхеткә, кемгә үкенечкә.

Фәрдәнә. Бәхет белән үкенечне җир тигезли... Инде үлгәч кенә бүлешмик, авыр туфрагы җиңел булсын.

Сара. Әрләмә... Хәсрәтемнән.

Фәрдәнә. Зарланма, үпкәм юк. Ник дисәң, дөньяга янадан килсәк тә, нәкъ үткәнне кичәр идек. Бер мыскалын да чит бәхетләргә алмашмыйча... Чәй яңартыйм әле...

Сара. Юк, юк, юк... Рәхмәтләр яусын. Көтәләрдер. Кузгалыйм.

Фәрдәнә. Ташлашмаска инде. И онытканмын — сине бит Вилданың алып китә.

Сара. Кая алып китсен бармасам? Кая барсаң да, шул бер ич инде ул — шушы ил, шушы гамь.

Фәрдәнә. Кая барсаң да, бер җир, бер җыр кала анысы — үз иманың. Китмәссең микәнни?

Сара. Юк. Йөрешеп торыйк. Инде бергә булсын бар ваем.

Фәрдәнә. Бергә, Сара.

Сара. Монда туй, анда — өшеткеч буран. Аның җылы каберенә ятып, кар елыйдыр...

Фәрдәнә. Туйдан... шунда бара кеше, туйдан — шунда.

**Сара чыгып китә. Фәрдәнә ятсынып кына гармунга карый. Кулына алып, урындыкка утыра, каешын кулбашына сала. Бармагы белән берәм-берәм телләренә орына.**

Фәрдәнә. Бер... ике... өч... дүрт... биш... алты... җиде... сигез... тугыз... ун... унбер... унике... Унике. Унике тел. Мин гармун алып кайтканнан соң, Сәгыйдулла белән унике ел торып калдык. Курганым юш килгән ләсә. Җиде казга алмаштырып бергә үткән уникеләны алып кайтканмын ич Йөзен базарыннан... Сине саткан кеше кайларда икән хәзер? *(Җырлый.)*

**Санасам, санамасам да,**
**Гармун теле унике;**
**Уйласаң, уйламасаң да,**
**Яшь гомер килми ике.**

**Әкрен генә Сәгыйдулланың язгы ташуларда урам әйләнгән көен уйный башлый. Ишек ачыла, Хөрмәт белән Люция чыга. Тыңлап торалар.**

Бетте... Сүнде-сүрелде. Күкрәкләрен сандык итеп, бар моңнары белән китте-барды...

Хөрмәт. Әх, өздерәсең дә соң, әби! Бөтен җанга тулып яңгырый!

Фәрдәнә *(сискәнеп, оялып)*. Көлмә, олан. Җае чыкканда яңгыраткан чаклар, әй, бар ла иде бит кана! Кайчагында, шушының ише туйларда, бу гармунны кулга үзем дә ала идем... Әй! Яшьлегебез — авызлыксыз ат булды. Тезгененнән тотасыңмыни — җилеп үтте... Тузып калган тузаннарын сыпырып утыруым.

Люция. Гармунны... сандыгыңнан алдыңмыни, Фәрдәнә түти?

Фәрдәнә. Сәгыйдулла бабаңныкы. Васыять иткән.

Хөрмәт. Сара апа шуны меңгергәнме?

Фәрдәнә. Шуны. Тышта кар тузгый да эчтә хәтер тузгый минә.

Люция. Яңа елга каршы үлүен әйт...

Фәрдәнә. Пөхтә кеше иде. Яңа елны ваклап торасы итмәгән инде...

Хөрмәт. Зиһенендә көе калган бит.

Фәрдәнә. Бетте көй. Үзе белән алып китте. Аның моңнарын авыл хәтереннән язгы ташулар юды.

Хөрмәт. Һи, әби!.. Быел Туллинкә урманында печән чаптык Сәгыйдулла бабай белән. Төшлектә, мин печәнгә сузылып яткач,— йоклый дип уйлады күрәсең,— төп башына утырып, авыз эченнән генә бер көй сузды бу. Минем көйгә зиһен шәп, оттым мин моны. Бактың исә, сезнең көй булган икән.

Фәрдәнә. Теге... әле сез юк чакларны, ул аны гармунда гына уйный торган иде... Отуың — авызыннан ишетүең галәмәтедер... Күңеле белән генә түгел, теле белән дә әйтеп биргән ул сиңа.

Люция. Табышмаклы көй.

Фәрдәнә. Башта табышмаклы булды. Үткән гомер, йомгак сүткән кебек кенә итеп, чиште дә бирде, әкәмәт.

Хөрмәт. Мин отам дип тыңламадым. Шундый итеп көйләде ул аны! Алды да миңа салды инде менә!.. Үзенә баянда уйнап күрсәттем бер. Шаклар катып тыңлап торды да: «Хәерлегә булсын, уйна! Бер кабынган учак сүнмәсен!» — диде. Бир әле гармуныңны, әби!..

Эчтән тавыш: «Хөрмәт кайда, җәмәгать, Хөрмәт кайда дим!..»
Хөрмәт кереп китә. Эчтә гармун уйнап җибәрә.

Тавыш: Дөр-рес! Смерть фашистам! — ләгънәтләргә! Суз әйдә!

Фәрдәнә ишек янагына барып сөялә, таныш көйне тыңлап, тетрәнеп кала. Сара керә.

Сара. Ни... Фәрдәнә... гармун төргән яулык калган ич. Иртәгә менәрлек булмасын.

Көйне ишетә. Әкрен-әкрен чигенә, чыгып җитәргә дип, ишек тоткасына үрелә. Фәрдәнә кисәк аңа борыла.

Каян бу көй, Фәрдәнә?

Фәрдәнә. Аның көе...

Сара. Бер җирдә үлем... бер җирдә туй... Ике җирдә дә ул!

Фәрдәнә. Ул.

Сәгыйдулла пәйда була.

Сәгыйдулла *(Фәрдәнәгә)*. Бер кабынган учак сүнмәсен... Бер кабынган учак сүнмәсен. *(Сарага.)* Бактың исә — ул син икән... Әнә шул алачык ярыгыннан таныйм сине.

Сара. Сагыш көе... Васыятен генә алып мендем ләсә...

Фәрдәнә. Сугыш көе... Ул васыять — һәммәбезнең ямансу гомер истәлеге.

Сәгыйдулла. Әйшыләргә — матур көй.

Фәрдәнә. Аһ, колачы иркен дә соң!

Сәгыйдулла. Тилгән тавындагы арыш кыры, тәкәрлекле күл камышы шаулавы ул.

Сара. Сулышы җиңел дә соң! Торналар тавышы шикелле.

Фәрдәнә. Торналары әллә кайта, әллә китеп бара...

Сәгыйдулла. Кайта. Яз иде ич. Язлар, язлар, язлар...

Сара. Әллә җәйме? Бәпкә куя идек.

Фәрдәнә. Теге тәкәрлекне хәтерлисеңме?

Сара. Орден-медальләрен хәтерлим. Чулпы сымак чыңладылар.

Фәрдәнә читкә борыла. Икесе арасыннан, көйне тыңлап, Сәгыйдулла үтә. Сара урындыктан яулыкны алып чыгып китә. Хөрмәт керә.

Хөрмәт. Нәкъ су агышлары — әле салмак, әле бөтерелеп-бөтерелеп ташый бу көй.

Фәрдәнә. Моңың бар. Люция белән әйбәт торырсыздыр?

Хөрмәт. Мәшәкатьләдек, Фәрдәнә әби... Алай-болай әрләшсәкнитсәк, син ишетмәссең инде, яме?

Фәрдәнә. И, улым... Тормыш мамык түгел. Савыт-саба шалтырамаган дөньяның ни кызыгы бар?

Хөрмәт. Мәшәкать инде, мәшәкать... Җәйгә хәтле түзәрсең инде, Фәрдәнә әби.

Фәрдәнә. Гомергә торсагыз да сүзем юк.

Хөрмәт. Юк, юк, җәйгә хәтле генә. Председатель белән киңәшкән. Бүрәнә бирә, кирпеч...

Фәрдәнә. Җәйгә хәтле генәмени?

Хөрмәт. Ник елыйсың, әби?

Фәрдәнә. Ямансу булып китте. Ялгыз башым нишләрмен?

Хөрмәт. Телисеңме, әби, үз йортымны шушы нигезгә салам? Әүзеңне, әби, Рәсүл тырнагыдай кадерләп кенә тотарбыз.

Фәрдәнә. Теләгең изге, олан. Теләгең җегәреңә күчсен — мин риза. Син булмасаң нигезем кемгә калыр иде?

Хөрмәт. Мин булмасам, без бар; безнең нигезләр сездән калган туфракта гына торыр, Фәрдәнә әби. Сез корган нигез безнең торган нигез булыр... Ярый, мин теге якка керим әле... Әх, гармуны! Шөлдер таккан тай сымак: күкрәктә уйнап тора.

Гармунны куеп чыгып китә. Фәрдәнә сандыгы алдына тезләнә, ача. Люция керә.

Люция. Ни эзлисең, Фәрдәнә түти?

Фәрдәнә. Монау гармунны салып куйыйм дим.

Люция *(сандыкка карый)*. У-у, синең монда... Әллә нәрсәләр!

Фәрдәнә. Җыенысы бер нәрсә инде боларның, кызым.

Люция. Ни?

Фәрдәнә. Хәтер. Хәзер боларның бөтенесе хәтер генә инде. Мин монда, кызым, гомеремне салып тотам.

Люция. Баллы ис килә.

Фәрдәнә. Үлемтеккә куелган исле сабыннар, ислемайлар ул.

Люция. Сандыгы матур... Әүвәлге.

Фәрдәнә. Беренче кат кияүгә чыкканда аңа бирнәм малы төялеп төшкән иде. Икенче кат чыкканда монда сугыш әчесе иде инде... Беренче тормышның бар малы шул сугышта янды.

Люция. Янды?

Фәрдәнә. Янды... Сугыш яндырды. Әлеге көй булып, көле генә очып йөрде. Белдеңме? Икенче тапкыр Ярмигә чыкканда да пар кашык белән генә чыктым. Тик менә... ястыгы гына киң иде инде.

Люция. Ник? Нигә?

Фәрдәнә. Ишеттеңме көйне?

Люция. Соң?

Фәрдәнә. Ярми бабаң белән икебезнең арада әнә шул көй иде. Ни гомер кара мәче булып ятты. Менә сөлгеләр... *(Таратып сала.)* Сабан туйларында өчесен Сәгыйдулла бабаң көрәшеп алган иде. Беләсеңме ничек үтә иде безнең Әшнәктә Сабан туйлары!..

Фәрдәнә кинәт «аh» дип куя.

Люция. Ни булды, түти?

Фәрдәнә. Сөлгеләремне көя кискән ләбаса!

Люция. Иң өстә ятканнар шул... Каяле, инә күзе кадәр генә кискән ич, күренми дә...

Фәрдәнә. Күңелләргә кунса, тузан да зурая. Күптән таратып караган юк иде шул.

Люция. Нафталины беткәндер.

Фәрдәнә. Гүрләргә ни белән иңдерерләр, гүрләргә... Озаграк гомер итәм мәллә соң — үлемтегемә хәтле көя төшкән.

Люция. Сөлгеләреңне көя тагын кисмәсме соң? Иртәгә әйбәтләбрәк җыеп куйыйк.

Фәрдәнә. Инде өлгермәсләр.

Люция *(сак)*. Өлгермәсләр?!

Фәрдәнә *(сандыкны яба)*. Өлгермәсләр...

Люция. Нинди зур бәхет минем бүген, ә, Фәрдәнә түти?

Фәрдәнә. Бүгенгесе ләйсән яңгырың гына әле. Хатын-кыз бәхете бераз соңрак килә. Чия дә бит, кызым, пеште дигәндә дә ачы була әле.

Люция *(пышылдап)*. Нигә, нигә, нигә?

Фәрдәнә. Чия ул, кызым, бер төн караңгы карлы базда тоткач кына тәмам пешә... Чын бәхетең бераз соңрак килер.
Люция. Синеке шулай булдымыни?
Фәрдәнә. Шулай булды.

Эчтә бию көе ишетелә.

Люция. Биик әле, түти! Әйдә, биик әле!

Фәрдәнәне кочаклап, үзе белән биетә дә йөгереп кереп китә.

Фәрдәнә. Бәхет дигән нәрсә нигә бик соңгарып килә икән?

Сәгыйдулла пәйда була.

Сәгыйдулла *(кисмәк янына килә, суга карый)*. Агып киткән гомер суларында кешенең йөзе чагылып кала икән — бу дөньяда яшәгәнеңә үкенерлекме соң, шайтан алгыры?!
Фәрдәнә. Алай да бер үкенеч калган бу дөньяның.
Сәгыйдулла. Нинди?
Фәрдәнә. Бергәләшеп синең белән Сара, минем белән Ярми жырынны жырламаганбыз. Кайсыдыр бер ташулы язның айлы кичен яңгыратып.

Ярми күренә.

Ярми. Без жырладык. Сүзләре — тормыш иде, көе — безнең яшәү. Саф, гадел, үкенечсез яшәү.
Фәрдәнә. Юлда озаграк йөрим бугай — сандыгыма көя төшкән. Форсат барында, ул юлдагы иң соңгы күперне сезнең белән бергә үтим... Әле дә ярый, Сәгыйдулла, язгы моңнарыңны бу дөньяның авыр сират күперләрен үтү өчен корбан итмәгәнбез. Нигезебезнең кара туфрагына моңыбызны чәчеп калдырыр өчен бер жырлашыйк әле, газизләрем!

Сандык өстенә утырып, гармун каешын иңенә сала.

Сәгыйдулла. Кушылырлармы соң?
Ярми. Кушылырлармы соң?

Гармун озын кычкырып сузылып төшә дә Фәрдәнәнең иңендә асылынып кала.

Бокаллар тотып, Хөрмәт белән Люция чыга.

Хөрмәт. Яңа ел котлы булсын, Фәрдәнә әби!

Сәгать суккан тавыш.

Люция. Яңа ел тәбригебезне ал, түти!.. Галәмәт, йокыга киткән икән. *(Аңа озын ак тастарын ябып куя.)*
Хөрмәт. Аргандыр. Черем итә. Төшләре тәмле микән?
Люция. Тышта нинди жил!..
Хөрмәт. Без диңгездә жилгә каршы барган корабка утырдык бүген.
Люция. Безнең диңгез — шушы нигез, корабыбыз алар моңы булыр!

Караңгылык.

Пәрдә.

***1977—1978***

Мәхмүт Хәсәнов

# ЗӨБӘРҖӘТ

ХИКӘЯ

Зөбәрҗәт уянып киткәндә төн иде әле. Нindидер көч аны урыныннан күтәрде. Ул келәмдәге чүәкләрен аяклары белән капшап киде дә, кул сузымындагы урындык башына эленгән халатын җилкәсенә алып салды. Торышлый өстәл лампасын кабызды.

Ул тәрәзә янына килеп басты. Эре кар бөртекләре, яктыга омтылган төнге күбәләкләр кебек, тәрәзә пыяласына килеп сарыла, аннары, бүлмәгә үтеп керә алуларына өметләрен җуйгандай, кире очалар иде.

Зөбәрҗәт бүлмәгә йөзе белән борылды. Өстәлнең урта бер җирендә вазага утыртылган өч-дүрт ак чәчәк моңаеп утыра. Кичә алар ахирәт дусты Алмазиянең туган көнен уздырдылар. Алмазия дигәне, нәкъ Зөбәрҗәт кебек, тормышын кора алмаган чая гына бер ялгыз хатын иде.

Мәҗлестә нибары алты кеше булды. Алмазия белән Әсгать, тагын бер пар һәм Зөбәрҗәтнең яңа танышы — Хәким. Мәҗлес шактый җылы үтте, табында гөрләп утырдылар. Алмазиянең туган көне булуга да карамастан, Зөбәрҗәт адресына әйтелгән комплементларның да исәбе-хисабы булмады.

Соңыннан, кунаклар таралыша башлагач, Хәким үзенең калырга теләге барлыгын белдерде. Зөбәрҗәт, тел төбенә тирән мәгънә салып: «Теләк котырта, оят тыя дигән сүз бар, тәти егеткәй. Кешенең ялгызлыгын ихтирам итә белергә кирәк...», дигән булды.

Хәким дә үз чиратында: «Кирәгеннән артык акыллы хатын-кыздан да мәрхәмәтсез кеше бар микән?»,— диде. Аннары, сүзне уенкөлкегә борып: «Гомумән, андыйлардан куркам мин»,— дип өстәп куйды.

Саубуллашканда Зөбәрҗәт аның бу сүзләренә әллә ни игътибар итмәгән иде. Ә менә хәзер кинәт кенә: «Нишләп соң ул бик җиңел буйсынды, китте дә барды?..»— дигән уй чагылып узды.

Кинәт аңа күңелсез, ифрат та моңсу булып китте. Ул башка нәрсә турында уйларга тырышып карады. Эш урынын, хезмәттәшләрен күз алдына китерде. Ул да булмады, аның белән бергә электрон-хисаплау үзәгендә перфораторчы булып эшләүче бер яшь кенә кызның:

«Зөбәрҗәт апа, сезне кайчандыр Баһрам абыйның кәләше булгансыз дип сөйлиләр. Хакмы шул сүз?..» дигәне исенә төште. Кызның шефы Баһрам абыена үлепләр гашыйк икәнлеге ярылып ята иде. Бу сөйләшү моннан ике-өч көн элек булды.

Әйе, Баһрам теләсә кайсы хатын-кызны үзенә каратырлык ир хәзер. Зөбәрҗәт үзе дә аның артларыннан үкенечле бер соклану белән карап калгалый.

Баһрам! Бу мизгелдә Зөбәрҗәтнең уйлары, елларны кире чигереп, узган көннәргә алып киттеләр... Моннан унбиш еллар элек, алар унынчы класста укыганда, Баһрам гап-гади авыл малае иде. Баһрам ул чакта ук инде Зөбәрҗәткә гашыйк иде. Дөрес, тыйнак-басынкы Баһрам бу турыда тел тибрәтмәде, әмма Зөбәрҗәт моны күңеленең кай җире беләндер тоя иде. Утны һәм мәхәббәтне яшереп булмый, ди бит.

Әмма Зөбәрҗәт, класстагы барлык кызлар кебек, Илфатка гашыйк иде. Зифа буй-сынлы, бик чибәр егет иде ул. Һәрвакыт яхшы киенеп йөрер иде. Шуның өстенә Илфатка зур киләчәкләр юрыйлар, өмет белән карыйлар иде. Унынчы класста укыганда ук аның беренчә шигыре басылып чыкты. Конвертына газета һәм журнал штемпельләре куелган хатлар килә торган иде. Шул серле хатларның эчтәлеген беләсе килә иде Зөбәрҗәтнең. Күңеленең сөю котеп моңланган, тулган чаклары иде шул.

Аннары таралыштылар. Врач булырга хыялланган Зөбәрҗәт институтка керә алмады. Хыял канаты шунда сынды аның. Хәер, азмыни андыйлар. Хәтта уку отличнигы Илфат та теләгән җиренә керә алмады. Аның каравы Баһрам университетка, үзенең теләгән факультетына җиңел генә кереп студент булды. Математиканы яхшы белә иде шул.

Баһрам өченче курста укыганда алар Зөбәрҗәт белән очраша башладылар. Ә инде дүртенче курска күчкәч, бергә булырга вәгъдәләр бирештеләр. Башта Зөбәрҗәтнең әти-әниләре бу турыда ишетергә дә теләмәделәр. Карап туймаслык бердән-бер кызлары үзе кебек чибәррәк кешегә дә чыга алыр иде дип уйлаганнардыр инде. Аның каравы, йөрәк түрендә Баһрамга карата яшерен мәхәббәт саклап йөргән Кифая: «Бәхетле дә соң син, Зөбәрҗәт!» — дип, ихлас күңелдән тәбрикләде. Яшермәде, Зөбәрҗәтнең язмышына көнләве турында ачыктан-ачык әйтте дә салды.

Нәкъ менә шул көннәрдә уйламаганда-көтмәгәндә очраттылар да инде алар Илфатны. Класташлар әлеге шатлыктан дөньяларын онытып урам уртасында туктап калдылар. Бер-берсен бүлеп, сорау артыннан сорау яудырдылар. Илфат Урал шәһәрләренең берсендә яшә икән. Башы-аягы белән сәнгатькә чумган. Үзе режиссер, үзе драматург. Ә хәзер Казан каласында илһам алырга, яшьлеге белән очрашырга дип кайткан. «Казан» кунакханәсендә туктаган. Алар, култыклашып, урам буйлап киттеләр, беренче очраган кафега кереп утырдылар. Алар белән Кифая да бар иде. Ничектер шулай килеп чыкты ки, ул әлеге компаниядә үзенең артык кеше икәнен сизенде һәм, юк сәбәбен бар итеп, гафу үтенде дә, китеп барды.

Кафедан соң алар гостиницага, Илфат бүлмәсенә кайттылар. Бу очрашу куанычыннан тәмам исергән егет әле яңарак кына халык театры сәхнәсендә куелган әсәренең афишасын күрсәтте. Бу минутта ул Зөбәрҗәткә зур талант иясе булып тоелды. Ул арада Илфат каяндыр бер шешә эчемлек чыгарды. Очрашу хөрмәтенә дип, берәр рюмка күтәрергә тәкъдим итте. Сүз ияре сүз китеп, Зөбәрҗәт тә тиздән тормышка чыгачагы турында ычкындырды. Кенәгә икәнлеген ишеткәч, Илфат күзгә күренеп үзгәрде, чибәр йөзенә моңсу күләгә кунды. «Син аңар әрәм...», диде ул, кызның бу адымы белән килешергә те-

ләмәвен белдереп. Зөбәрҗәткә бу сүзләр таныш иде инде. Чөнки әнисе дә булачак кияүне бик үк өнәп бетерми. Хәер, Зөбәрҗәт үзе дә, күңеленең кайсыдыр почмагында шуңа охшашлы тойгы йөртә иде.

Исерткеч үзенекен итте. Илфат кыюлана төште. Укыган елларда ук сиңа үлеп гашыйк идем дип Зөбәрҗәткә йөрәген ачты. Сүзләренә караганда, әле һаман да оныта алмыйча иза чигә икән... Шунда ул Зөбәрҗәтне кочагына алып, шашынып үбә, иркәли башлады. Зөбәрҗәт тә үзенең хис-тойгыга бирелә, акылы томалана башлавын тойды. Әмма ул инде каршылык күрсәтә алырлык хәлдә дә түгел иде.

Ул кичне Баһрам Зөбәрҗәтне гадәттә очрата торган урында тапмый. Озак көтә. Ахыр чиктә, соң булуга да карамастан, Зөбәрҗәтләрнең өенә китә. Аның кайдалыгын сорагач, кызның әнисе: мин дә синнән нәкъ шул турыда сорамакчы идем, дип бик дорфа җавап кайтара һәм Зөбәрҗәтне табып алып кайтырга куша.

Баһрам эзли китә. Ахыр чиктә Кифаяларга барып чыга. Шунда ул Илфат турында ишетә, аның «Казан» гостиницасында туктавын белә. Администрациядән классташының кайсы бүлмәгә тукталганлыгын ачыклап, өске катка күтәрелә. Әмма дежурныйның: «Егет өйдә» диюенә дә карамастан, Баһрамның шакуына җавап бирүче булмый.

Ә инде Зөбәрҗәт, аңына килеп: «Ой-й, нишләдем мин?.. Нишләдем?!» — дип, өтәләнеп сикереп торып, җәһәт кенә киенеп коридорга чыккач, стена буендагы кресолоарның берсендә утырган Баһрамны күрә.

Егетләр салкын гына исәнләшәләр. Баһрам: «Тизрәк бул, әниең таптыра...» — дип, Зөбәрҗәтне өйләренә кадәр озатып куя. Шул озатудан соң алар очрашмый башлыйлар. Бер ай чамасы үткәч, искәрмәгәндә урамда очрашалар. Шунда Баһрам бары тик бер авыз сүз әйтә: «Бигайбә, Зөбәрҗәт! Тормышны аны хыянәттән башламыйлар...»

Шуннан соң Зөбәрҗәт тормышында үзгәреш артыннан үзгәреш булып кына тора. Үзенә бер төрле серлелек белән өртелгән әлеге тормышы баштарак ошый да иде кебек. Үзе кебек үк иректә ахирәтләр дә, җан атып торган дус-ишләр дә табылды. Үзен очар коштай хис итеп яшәве белән чак кына горурлана да иде. Ни әйтсәң дә, үзе баш, үзе түш. Эше дә менә дигән, квартирасы да теләсә кем кызыгырлык. Дус-ишләр яшәсен, алар барында дөньяның астын өскә әйләндерергә мөмкин. Зөбәрҗәт һичкайчан да үзен алданганга яки ташланганга санамады. «Нәрсә? Кем ташланган? Минме? Ха-ха!.. Мин үзем теләсә кемне ташлыйм!..» — дип башын артка атып көләргә ярата иде.

Еллар үтә торды. Баһрам белән Кифая, кавышып, менә дигән тормыш корып җибәрделәр. Хәзер, әнә, ике бала үстереп яталар. Баштарак Зөбәрҗәтнең моңа әллә ни исе китмәде. Үзен тиңдәшсез бәхетлегә санаган Кифаяны, ничектер, аңлап бетерми иде, «Бала-чага чүпрәге белән мәж килеп, ир көен көйләп нинди бәхет таба икән?» — дип уйлый иде ул. Әмма күңеленең кайсыдыр почмагында Кифаяның тигез тормышына көнләшү хисе барлыгын да тойган сыман була иде.

Тәрәзә артында әллә кар сирәгәйде, әллә яктыра башлады. Бераздан күрше-тирәдәге йортларның кар каплаган түбәләре, алар арасындагы төпсез булып тоелган бушлыклар аермачык күренә башладылар. Әмма Зөбәрҗәт тәрәзә яныннан китмәде. Бу минутта аның башында буталчык уйлар, күңелендә нәкъ өйләр арасындагы караңгылык сыман шыксыз бушлык иде.

Зөбәрҗәт кабат кичәге мәҗлесне күз алдына китерде... Менә җилъяклыгы белән даны чыккан ахирәте Алмазия утыра. Күптәнге танышлар алар. Очрашулары да мәзәк булды. Алмазия аның Зөбәрҗәт исемле икәнлеген белгәч, шаккатарлык сүз ишеткәндәй, куллрын шапылдатып: «Исемегез биргәк тә старомодный икән. Әйдәгез,

Зоечка дип үзгәртәбез»,— дигән тәкъдим ясаган иде. Зөбәрҗәт каршы төште. «Хет исемемне бозмагыз»,— дигән иде ул. Соңрак дуслаштылар. Алмазиянең үз фәлсәфәсе бар: «Бәхет — хискә бирелүдә, хиссез-тойгысыз бәхетнең булуына ышанмыйм. Шуңа күрә дә аларны яңартып тору ягында мин», — диярgә ярата ул, уенын-чынын бергә кушып. Ә Зөбәрҗәт менә ерык авыз ахирәтенең бәхетле булуына ышанмый. Тирәнтен уйлый, эчкә җыя белмәгәнгә генә шулай үз-үзен алдап яши торгандыр, дип уйлый иде ул.

Соңгы елларда Зөбәрҗәт бәхет, тормыш турында ешрак уйлана. Вакыты белән ялгызлык хисе җанын шундый китереп баса аның, чыдар чамасы калмый. Күңелендә шулай давыл кузгалган чакларда тормышын яңадан үзгәртеп кору теләге туа. Чыннан да, яшьлектә ясалган бер ялгыш адымны гомерлек юлдаш итеп, дуадак каздай япа-ялгыз яшәп булмый бит инде. Әнә, яшьлеге дә, элеккеге матурлыгы да торган саен әкренләп чигенә бара...

Соңгы елларда йокысы да тынгысыз аның. Төшләрендә ул гел каядыр чаба, ашкына, билетлар ала, каядыр олы юлга чыгарга кабалана. «Әллә, ходаем, үз башыма ашкынуыммы икән әллә?» — дип тә, уйлап куйгалый. Әлеге хәлнең гомеренең соңгы көненә кадәр сузылачагы турында уйлый-нитә калса,— бетте! Зөбәрҗәтнең күңеле өши башлаган сыман була. Бөтен барлыгын үзәк өзгеч эч пошуы биләп ала.

Теләр-теләмәс кенә көн туып килә. Шәһәр инде күптән уянган. Шул чак, уйларыннан арып-алҗып, башы катып торган Зөбәрҗәтне сискәндереп, звонок шалтырады. Бу аваз искәрмәстән булганга, телефон яки ишек звоногы икәнлеген абайламыйчарак калды. Бу вакытта кеше йөрмәс дип, телефон трубкасын алды.

Ахирәте Алмазия икән.

— Дускаем, бу мин идем. Йокыңнан уяттым мәллә? Тыңла әле...

Алмазия элеккеге җан дусларыннан кемнеңдер Кырымнан кайтып төшүе, сирәк очрый торган күчтәнәчләр алып кайтуы турында шалтырата икән. Бүген алар кичке мәҗлескә чакырулы икән.

— Ничек, барырбыздыр бит? — дип сорады Алмазия.

Күңелендә давыл кайнаса да, Зөбәрҗәт: «Юк, бер кая да бармыйм, җиткәндер, ниһаять»,— дип баш тарта алмады. Авыр итеп бер көрсенде дә:

— Ярар... Карарбыз,— дип җавап кайтарды.

**Камил Фасеев,**
филология фәннәре докторы

# ИРЕК-ХОКУКЛАР: ЧЫН ҺӘМ ЯЛГАН

## Уйдырмалар кемгә кирәк?

Хәзерге империалистик дәүләтләрнең информация чаралары турында сүз йөрткәндә, классик драматургыбыз Галиәсгар Камалга ияреп, болай әйтәсе килә:

Бу дөньяда тәкый гаҗәп хәлләр булгай,
Матбугатта төрле-төрле гайбәт тулгай.

КПСС Үзәк Комитетының «Идеологик, политик тәрбия эшен тагын да яхшырту турында»гы карарында әйтелгәнчә, империалистик пропаганда кешеләр аңына ярсулы һөҗүмне өзлексез алып бара, аларны совет чынбарлыгына яла ягу белән агуларга, социализмны яманлап, пычратып күрсәтергә тырыша. «Бозып күрсәтелгән информация, фактларны тенденциоз яктырту, әйтмичә яшереп калдыру, ярымдөреслек һәм әдәпсез ялган — барысы да эшкә җигелә».

Социалистик җәмгыятькә каршы идеологик һөҗүме тормышның бик күп якларына кагыла. Беренче планга исә демократия азатлыгы, кеше хокуклары мәсьәләсе күтәрелә. Дәүләтебезнең яңа Конституциясендә законлаштырып беркетелгән реаль демократик ирекләрне һәм хокукларны инкарь итеп, «СССРда гражданлык хокуклары таптала» дигән уйдырма тараталар. Бу хәл совет кешеләрен шаккаттыра гына түгел, җитди борчый, яла ягучыларга карата нәфрәт көчәйтә.

Әле күптән түгел генә булган ике вакыйганы искә төшерик.

Американың Мәскәүдәге дипломатия хезмәткәре Дж. Мэндел Дагыстанның Буйнак шәһәрендәге мәчеткә килә һәм андагы картлар арасында Совет власте белән канәгать булмаучы кешеләрне эзләп маташа. «Без, — ди ул, — беләбез, монда сезне җәберлиләр, кысалар, иркенләп дин тотарга, милли телегездә сөйләшергә мөмкинлек бирмиләр». Мәчет янында җыелган мөселманнар моңа гаҗәпләнеп, «әфәнде шаярта бугай», дип көлешеп таралалар, АКШ дипломатын кәкре каенга терәтеп калдыралар.

Инде Нью-Йорк аэропортында АКШ властьлары оештырган кабахәт фарсны алыйк. Акылга сыймаслык хәл булды: таланты белән американнарны шатландыру өчен чакырып китерелгән совет балеринасын үз иленә, өенә кайту хокукыннан мәхрүм итәргә тырыштылар. Аны мәсхәрәле сорау алуга тартып, куркытып һәм алдап Ватанына хыянәт иттерергә маташтылар. Син СССРга кайтма, анда синә ихтирам һәм иҗат ирекe юк, ә монда, Америкада, син чын ирек һәм бәхет табарсың,— АКШ разведчиклары совет гражданкасын өнә шулай үгетли. Ул мондый шантажга бирешмәгәч, салонында 112 кеше, шулар арасында 13 бала булган самолетны өч тәүлектән артык полиция кардоны эчендә тоткарлап, очарга рөхсәт бирми тордылар.

Гангстерларга, пиратларга гына хас явызлык бит бу! Моны намус, гуманизм, гаделлек һәм элементар әдәплелек төшенчәләрен тәмам оныткан бәндәләр генә эшли ала.

Моңа ошашлы фактларны тагын бик күп китерергә мөмкин булыр иде.

Шәхес ирекләре һәм хокуклары мәсьәләсе социализм белән капитализм арасында кискен идеологик көрәшнең мөһим объектына әйләнде. Капиталистик җәмгыятьне «азатлык дөньясы» дип атап, имеш, шәхес ирегe анда гына тәэмин ителгән дип шапырынып, империализм ялчылары «совет кешеләре барча ирек-хокуклардан мәхрүм» дип лаф оралар.

1978 елның март аенда Вашингтонда «Кеше хокуклары турында» махсус «симпозиум» үткәрелде. Сүз АКШның үзендә бүген гаять кискен төс алган проблемалар тирәсендә — раса дискриминациясе, бернинди гаебе булмаган кешеләрне үтерү, кулга алу, төрмәгә ябып кую, сүз һәм иҗат ирекен кысу, индеецлар, негрлар, пуэрторикан-

лылар, мексикалыларның хокуксызлыгы, миллионлаган кешеләрнең эш таба алмыйча ачлыктан интегүе һ. б. турында барыр дип уйларга мөмкин иде. Ләкин АКШның махсус вәкилләре һәм социалистик илләрдән куылган яки качып киткән җинаятьче элементлар Совет дәүләтенә, башка социалистик илләргә каршы агу чәчтеләр.

Бу антикоммунистик оркестрның баш дирижеры да бар: ул — АКШ президенты Картер иде. Җаваплы постта торучы бу җавапсыз кеше: «гражданлык хокукларын ихтирам итү турында Советлар Союзына басым ясарга кирәк» дип чыга. Аның кушуын үтәп, Европа илләре вәкилләренең Белградта очрашуында АКШ делегациясе башлыгы А. Голдберг хәтта «кеше хокуклары буенча комиссар» билгеләп, аңа Көнбатыш һәм Көнчыгыш Европада чикләнмәгән контроль хокуклары бирергә кирәк, диган дәгъва күтәрде. 1978 елның җәендә Англия парламенты депутатлары да бер айга якын «СССРда кеше хокуклары кысыламы, юкмы» дигән демагогия белән шөгыльләнделәр.

СССРга каршы юнәлтелгән бик күп мәкерле чаралар рәтендә, анда «шәхеснең кадере юкка чыгу», «кешенең иреге һәм хокуклары тапталу» турында уйдырмалар таратуны да алар үзләре өчен файдалы кәсеп дип саныйлар. Бу инде АКШ администрациясенең официаль политикасы төсен алды. Колумбия университеты профессоры Маршал Шульман әйткәнчә, АКШның йогынтылы политик даирәләре «кеше хокуклары проблемасын хәрби куәтне тизләтеп үстерү өчен беррәттән Советлар Союзына каршы яңа идеологик һөҗүмнең состав өлеше итеп кулланалар». АКШның җитәкче даирәләре шуңа барып җиттеләр ки, Вашингтонда, Конгресс китапханәсендә СССРга каршы юнәлтелгән махсус күргәзмә оештырдылар.

Андый күргәзмәне әмәлләү кыен түгел инде аның. Мәгаен, Америка корреспондентлары безнең берәр авылда яки шәһәрдә иске йортларны күреп төшереп алган да, совет кешеләренең һәммәсе шундый хәрабәләрдә яши, аларның яхшы торак урыныма хокуклары юк дип язып, стенага элеп куйгандыр. Безнең урамнарда әле очрый торган берәр исерекбаш та бәлки аның объективына эләккәндер һәм моңа «СССРда хезмәт хокукыннан мәхрүм кеше әнә шулай урамда аунап ятарга мәҗбүр» дип аңлатма бирелгәндер. Безнең хәтердә: шикле махинацияләр корып, яман аты чыккан Никсон әфәнде, әле АКШның вице-президенты булган чагында, Мәскәү урамында бер малайга 25 центлык акча суза, һәм шул күренешне аның нярчене фотога төшереп ала да, газеталарда «Мәскәүнең ач балалары хәер сорашып йөри» дип игълан итә. Бу фото һәм шуңа охшашлы башка күп «материаллар» әлеге күргәзмәдә, ихтимал, бардыр.

Совет дәүләте яшәгән елларда империалистик пропаганданың мондый мәкерле методларын без инде меңнәрчә тапкыр күрдек. Моның максаты — социализмга карата ышанмаучылык һәм дошманлык тарату. «Советлар Союзы турында аудиториянең җитәрлек хәбәрдар булмавына, тиз ышанучан укучы, тыңлаучы һәм тамашачыларга исәпләнгән шаблон уйдырмалар, оятсыз фальсификация һәм чеп-чи ялган әнә шуннан килә», — диде Л. И. Брежнев.

К. Маркс һәм Ф. Энгельс 1848 елда: «Европада шәүлә йөри — коммунизм шәүләсе» дип белдереп, шул чакта ук инде бу шәүләгә каршы иске җәмгыятьнең барча кара көчләре берләшеп сугыш ачуын әйткәннәр иде. Җир шарындагы халыкның өчтән бере бүген социалистик җәмгыятьтә яши. Империализм исә тирән һәм ерып чыга алмаслык кризис кичерә. Хәзер коммунизм идеяләренең таралмаган, коммунистик хәрәкәт йогынтысын белмәгән бер генә ил дә юк. Моны коммунизм дошманнары да танырга мәҗбүр. Мәсәлән, шуларның берсе Йозеф Бохемский: «Практикада коммунизм бүген һәркем өчен, аерата мәсләкыйль фикер йөртә белә торган кеше өчен, тормышчан әһәмияткә ия булды», — дип яза.

Социализмның кешеләргә чын мәгънәсендә азатлык, тулы хокуклар, иркен хезмәт, бәхет, тынычлык, иминлек китерүен аңлаучылар һәм шуңа омтылучылар саны һаман арта бара. Менә шушы хәл империализм реакциясенең ачуын күпертә дә. Социализмны корал көче белән җиңеп булмавын тормыш бик ачык раслады. Димәк, аның авторитетын төшерү, халыкларның бу якты җәмгыятькә омтылышын туктату өчен башка чарага — социалистик илләргә яла ягу, фактларны бозып күрсәтү чарасына ябышырга кала. АКШның «Политик информация комитеты» председателе генерал Джексон туп-туры әйтә: «Безгә дәрәҗәлек кирәк түгел, ә корткычлык хәрәкәте кирәк, ягъни советча яшәү рәвешен, иҗтимагый стройны пычрата торган провокацион хәбәрләрне — аеруча яшьләр һәм интеллигенция арасында — тарату кирәк, совет җитәкчеләренә, галимнәренә, язучыларына, хәрби хезмәткәрләренә, производство алдынгыларына яла ягу кирәк». Гаеп эзләүче бозык күңелләләр менә шундый махсус күрсәтмәдән чыгып эш итәләр. «Лондонда яшәгәндә, — дип яза «Правда» газетасының андагы корреспонденты В. Овчинников, — көн саен җирле газеталарны укыгач һәм телевидение тапшыруларын карагач, беренчедән, массакүләм информация каналлары буенча Англия халкына ургылган ташкынның антисоветизм белән сугарылган булуына, икенчедән, Советлар Союзына каршы өзлексез кампанияләрнең җентекләп координацияләнүенә, аларның билгеле бер моментка төгәл яраштырылуына шаккатасың».

Хормейстрлары хаким даирәләр булган әнә шул хор «социалистик дәүләтләрдә демократик ирекләр юклыгы» турында такмаклар көйли, ә үз илендә, Британия утравында һәм Ольстерда кеше хокукларының рәхимсез тапталуын, беренчи гөнаһсыз кешеләрнең төрмәләрдә черетелүен, газаплануын, үтерелүен яшереп кала.

Көнбатыш Германия язучысы Петер Шютт,

безнең илдә булып кайткач, «Себергә» дигән китап чыгарды. Анда ул СССР халыклары тормышын дөрес тасвирлый, ГФР кешеләренең антикоммунистик пропаганда белән томаланган күзләрен ачарга тырыша. Шул уңайдан Петер Шютт ГФРда антисоветизмның тирән тамырлар җибәрүен әйтә. «Мәсәлән, «Себер» төшенчәсе күбәүләр өчен һаман әле әсирлек, хәерчелек, башбаштаклык синонимы булып кала... Советлар Союзы күп милләтле дәүләт, анда йөздән артык милләт кешеләре бердәм семья булып яшиләр дигәч, кешеләр шаккаталар, СССР гражданы дәвалану, шифаханә, уку өчен үз кесәсеннән бер тиен дә бирми, киләчәктә пенсия алыр өчен регуляр взнос кертми дисәң, якташларым хәйран калалар. Советлар Союзында эшсезлек юк, рационализация эшчеләр интересына сукмый, реаль хезмәт хакы кимү юк дигән хакыйкать аларның башына да сыймый. «Күз алдыма китерә алмыйм» дигән сүзләрне миңа еш ишетергә туры килә».

Бу дезинформация нигә кирәк? П. Шютт моңа болай җавап бирә: «Күп кешеләр реаль социализм илләрендә ачлык, рухи бушлык, хәрби муштра һәм хәлдән тайдыргыч эш системасы булуына ышаналар икән, алар үз илендә җитди үзгәрешләр турында, социализмга бару юллары турында уйланырга сәләтсез булып калалар».

Империалистик реакция нәкъ менә шуңа ирешү өчен акылга сыймаслык мәкерлек эшләргә әзер. СССРга һәм башка социалистик дәүләтләргә каршы провокацион пропаганданы Мюнхендагы «Азат Европа» һәм «Азатлык» дип аталган радиостанцияләр бик тырышып алып бара. АКШ хөкүмәте аларның пычрак эшен көчәйтү турында аеруча кайгырта. «Көнчыгыш Европа блогы эчендә фетнәләр кабынуга ярдәм итү, анда социалистик стройны җимерү, совет җәмгыятенең «неокапитализм»га күчүенә булышу» — әйтелгән радиостанцияләрнең уставында әнә шундый максат куелган. «Совет халкының коммунизмга баруда һәр адымын бозып, ямьсезләп күрсәтергә тырышу һаман искечә дәвам итә,— дип яза Англия-СССР дуслыгы җәмгыяте Президенты Эидро Ротштейн.— Ләкин бернинди, хәтта бик шомартылган ялган да кешеләрнең аңын хәзерге заманның кискенч контрастларыннан, социализмның гуманистик асылы белән капиталистик стройның кешелексезлеген чагыштырып караудан читкә юнәлтә алмый».

Мәгълүм булганча, «салкын сугыш» бозлары эреп, СССР белән АКШ арасында мөнәсәбәтләр җайлаша башлаган иде кебек. Соңгы вакытта исә АКШның җитәкче даирәләре яңадан боз катырырга керештеләр. Моның сәбәбе нәрсәдә? Әйтергә кирәк АКШның да, башка империалистик дәүләтләрнең дә безгә каршы һөҗүмне беркайчан да туктатканнары юк. Алардан мондый мәрхәмәт көтү мөмкин түгел. Экономик, сәүдә, политик мөнәсәбәтләр өлкәсендәге разрядка социализм белән капитализм арасындагы килешмәүчән антагонизмны юкка чыгара дигән, идеологик көрәшне туктата дигән мәгънәне аңлатмый. Сүз, иҗтимагый стройның, идеологиянең капма-каршы булуына карамастан, кешелек дөньясы язмышы, җирдә тынычлык урнаштыру, халыкларның ирекләрен, законлы хокукларын, иминлеген тәэмин итү кебек гомуми мәсьәләләрне дәүләтләрнең тыныч сөйләшеп-килешеп хәл кылулары турында бара.

Бу өлкәдә уңай нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинме? Һичшиксез мөмкин. Тигез хокуклы партнерлар буларак, барлык дәүләтләр актуаль экономик һәм социаль-политик проблемаларны сугыш кырында түгел, талашып-ызгышып түгел, түгәрәк өстәл янында сөйләшеп хәл итәргә тиешләр. Халыкара мөнәсәбәтләрнең чын гадел, ленинчыл принцибы шундый. Моңа ачык мисал — Европа дәүләтләренең АКШ һәм Канада катнашы белән уздырылган киңәшмәсе һәм Хельсинкида кабул ителгән йомгаклау акты. Империалистик дәүләтләр исә бу хакыйкатьне сүздә таныган булып кылансалар да, чынында киресен эшлиләр.

Хельсинки киңәшмәсендә кабул ителгән документта барлык илләрдә кешеләрнең хокукларын аңлау турында махсус пункт бар. Бу очракта киңәшмәдә катнашучыларның күпчелеге нәрсәдән чыгып эш итте соң? Алар, әлбәттә, империалистик дәүләтләрдә, капитал йогынтысы астындагы илләрдә хезмәт ияләренең хокуксызлыгын, эшсезлек, ачлык, хәерчелек, җинаятьчелек, талау, үтерү, гөнаһсыз кешеләрне рәнҗетүкысу, демократик азатлык һәм гражданлык хокуклары өчен көрәшүчеләрне төрмәгә ябу һәм ерткычларча җәзалау, милли изү, раса дискриминациясе, баскаклык кебек коточкыч хәлләрне күздә тоттылар, шуларга чик куюны таләп иттеләр.

Бу документка АКШ хөкүмәте дә кул куярга мәҗбүр булды. Ләкин аны гамәлгә ашырырга һич тә ашыкмый, үз илендә е аяныч хәлләрне ничек тә булса «яшереп калып», социалистик илләрнең эчке тормышына тыкшына. Тагын шуны искә төшерик: кешенең гражданлык һәм политик хокуклары турында Берләшкән Милләтләр Оешмасы да пакт кабул иткән иде. Ул барлык социалистик илләр һәм башка күп кенә дәүләтләр тарафыннан расланды. АКШ исә әле моны бүгенгә кадәр эшләгәне юк. Кеше хокуклары турында барлыгы 19 халыкара килешү кабул ителде. АКШ шуларның бишесенә генә кул куйды һәм аларның да өчесен генә ратификацияләде.

Үзеннән-үзе сорау туа: кеше хокукларының, буш декларация килеш кенә калмыйча, һәр илдә тулысынча гамәлгә ашуына кем тоткарлык ясый? Җавапны эзләп торасы юк: Америка империализмы һәм аңа ияреүче илләрнең реакцион даирәләре. Бу — бөтен дөньяга билгеле һәм бәхәссез факт.

Франциядәге «Пари матч» дигән атналык газета күптән түгел генә чыккан бер санында дөнья картасын урнаштырган. Анда «кеше тулы ирекләр һәм хокуклар белән тәэмин ителгән дәүләтләр» — акка, ә «хокукларны һәм ирекләрне бик зур күләмдә бозучы» дәүләтләр карага буялган. Гражданлык хокуклары өчен көрәш ерткычларча бастырыла торган АКШ та, төрмәләрдә

азатлык өчен көрәшчеләрне җәзалау коточкыч киң күләм алган Төньяк Ирландия дә, раса дискриминациясе дәүләт политикасына әйләнгән, бик күп гарәпләрне азатлыктан мәхрүм иткән Израиль дә акка буялган. Родезия, Көньяк Африка республикасы, Парагвай сызыкланган, ягъни «хокуклар аз-маз гына бозылгалый» дип күрсәтелгән. Ә инде Советлар Союзы өчен газета кара буяуны кызганмаган...

Искиткеч әшәкелек шунда: ирек һәм хокук, гуманизм һәм кешегә ихтирам мәсьәләсен шул ук ирек һәм хокукларны аяк астына салып таптаучы, гуманизм идеясеннән күптән баш тарткан империалистик реакция күтәреп чыга. Винтовкадан, пистолеттан атып үзләренә ошап бетмәгән президентны, галимне, сенаторны, гаделсезлеккә һәм явызлыкка каршы сүз кузгаткан негрлар лидерын, прогрессив язучыны, журналистны, хокуклар таләп итеп демонстрациядә катнашкан эшчене, яшүсмерне, хатын-кызны, мәктәп ишеген атлап кереrгә батырчылык иткән негр баласын, гомумән теләсә кемне теге дөньяга озатып торучы бәндәләр «кеше хокукларын яклап», Тукай әйтмешли, күзләрен тәкерек белән чылатып, яшь түккән булып кыланалар.

«Артык дәрәҗәдә гуманлы» буржуаз политикларның фарисейлыгын фаш итеп, АКШ Компартиясе генеральный секретаре Гэс Холл болай яза: «Үзләре мораль принципларын сакламаучылар бөтен дөньяга мораль өйрәтәләр. Һәрвакыт кеше хокукларын таптаучылар бөтен дөньяга кеше хокуклары турында әхлак кагыйдәләре укыталар. Иң рәхимсез, иң кешелексез социаль-экономик система вәкилләре, икейөзләнеп һәм күперенеп, гуманлылык турында сөйлиләр. Бөтен кешелек тарихында иң рәхимсез раса коллыгын гәүдәләндерүчеләр, тәкъва булып, тигезлек турында сөйләргә батырчылык итәләр»...

Шушы икейөзлелек һәм алдашу Америка империализмының бөтен эчке һәм тышкы политикасын билгели. Ул бүген үзен «дөнья цивилизациясен коткаручы», «демократия өчен көрәшче» итеп күрсәтмәкче була. Ләкин безнең хәтердә: кешеләрне тереләй яндыру өчен Освенцим, Майданек, Бухенвальд крематорийларын корган палач Гитлер да «Россия халыкларын азат итәм», «демократияне коткарам» дип кычкырынган иде бит! АКШның реакцион даирәләре бүген шул эзгә бастылар.

1977 елның 13 августында «Нью-Йорк таймс» газетасы Вашингтондагы политик тикшеренүләр институты сотруднигы М. Клэр мәкаләсен басып чыгарды. Бу мәкалә АКШтагы империалистик даирәләрнең «кеше хокуклары» турындагы ялганын фаш итә. Үз өстенә бөтен дөньяның баш судьясы ролен йөкләп, диелә мәкаләдә, президент Дж. Картер күп кенә чит илләрдә котырынган репрессияләргә һич тә имеш катнашы юк дип ышандырмакчы була. Хәлбуки, АКШ хөкүмәте 1973 елдан 1977 елга кадәр Чили, Таиланд, Көньяк Корея, Уругвай кебек ун реакцион режимга 4,3 миллиард доллар акча, 17,5 миллиард долларлык корал биргән.

«Чилидәге демократик хөкүмәтне бәреп төшерү өчен, кешенең элементар хокукларын һәм ирекләрен басып таптаучы Пиночет диктатурасын урнаштыру өчен төп җаваплылык Кушма Штатлар өстенә төшә, — дип белдерде сенатор Э. Кеннеди 1978 елның 7 маенда.— Алай гына да түгел, АКШ бу илдә террор һәм җәзалау режимын ныгытырга булыша».

Америка империализмының кеше азатлыгына каршы җимергеч эшләре санап бетергесез. Ул мөмкин булган һәр җирдә реакцион көчләрне үстереп тора, демократик азатлык хәрәкәтен бастырырга тырыша. Анык турыдан-туры ярдәме белән Израиль баскаклары бик күп гарәп халкын элементар тормыш хокукларыннан мәхрүм иттеләр. Көньяк Африка халкын коллыкта тотучы расистлар да, Ливанның прогрессив социалистик партиясе председателе Камал Жумблатны һәм Конго Халык Республикасы президенты Мариан Нгуабины үтерүчеләр дә, Латин Америкасы илләрендәге шәфкатьсез диктаторлар да Кампучия, Вьетнам, Лаос, Әфганстан һәм Иран халкына каршы агрессия оештыручылар да АКШ хөкүмәтенең ачыктан-ачык булышлыгына таяналар. Буржуаз матбугатта чеп-чи ялган язып чыгучылар социалистик җәмгыять турында дәреслекне белми түгел, беләләр. Тик дәреслек аларга ошамый, алар дәреслекнең киң массалар аңына барып җитүеннән курка. Шуңа күрә СССР турында, башка социалистик дәүләтләр турында күрәлмәү уйдырма тараталар. Антикоммунизмның асылы — социалистик җәмгыятьне бозып күрсәтеп һәм хурлап, капиталистик стройны аклап калырга тырышу да. Антикоммунизмның бер төре — антисоветизм. Аны таратучылар «советология» дигән төшенчә астына яшеренеп эш итә. Сүзнең ялгырашына карасаң, Советлар Союзын өйрәнә, советча тормыш рәвешен тикшерә-ачыклый торган фән дип уйларга мөмкин. Ләкин аның фән белән һичнинди уртаклыгы юк, киресенчә, ул — социология фәнен пычрату, мәсхәрәләү. Советология — яла ягуга, акны кара итеп, чынбарлыкны бозып сурәтләүгә корылган, реаль таянычы булмаган, хакыйкатькә дошман идеология ул.

Социалистик җәмгыятьтә гамәлгә ашырылган чын демократия ирекләре һәм хокуклары — совет кешеләренең генә түгел, бөтен дөнья демократик җәмәгатьчелегенең горурлыгы, чөнки без узган юл — барлык илләр хезмәт ияләре узачак юл ул. Әнә шулай, тарихи процесс үзенекен эшли, империализм ялчыларын оятка калдыра. Ләкин алар «туктатырга һич мөмкин булмаган хәрәкәт көче» каршында объектив хакыйкатьне танып куйсалар да, социализмны гаепләү, пычратып күрсәтү максатыннан тәмам баш тартканнары юк әле.

Нил Юзиев

# «АЧ, ШИГЪРИЯТ, СЕРЛӘРЕҢНЕ!»

Уйласаң уй,
Җырласаң җыр,
Тыңласаң моң сызыла...

*С. Сөләйманова. «Уйласаң уй...»*

Сәҗидә Сөләйманова иҗаты турындагы сүзне татар поэзиясе тарихындагы гыйбрәтле бер вакыйганы һәм язмышны искә төшерүдән башлап китәсе килә. 50 елларның ахырларында Ленинградта Көнчыгышны өйрәнү институтының кульъязмалар бүлегендә эзләнгәндә әдәбиятчы Җәвад Алмазга искерә төшкән калын гына бер шигырьләр дәфтәре очрый. Гарәп графикасы нигезендә татарча язылган шигырьләр, җырлар... Кайберләре бик тә таныш, кайдадыр очраганы да бар кебек, ә күбесенең бер дә ишетелгәне, укылганы юк. Кызыксынып, укып китә галимебез һәм инде ахыргы битләренә җиткәнче ул юллардан аерыла алмый, бөтен дөньясын онытып, дәфтәргә каурый каләмнәр белән теркәлгән, кайгы-сагышлар белән тулы шигырьләр дөньясына чума. XIII гасыр шагыйре Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасының яңа нөсхәләрен эзләгән галим шул рәвешчә көтмәгәндә поэзия тарихындагы яңа бер исемгә тап була: XIX гасыр ахырларында, XX гасыр башларында яшәгән һәм иҗат иткән Газизә исемле талантлы шагыйрәне ача. Газизә Сәмитованың исеме дә, шигырьләре дә үз тирәлегендә мәгълүм булса да, киң укучылар массасына ул үзе үлгәннән соң байтак вакытлар үткәч кенә билгеле була: шигырьләре җыентык булып беренче тапкыр 1963 елны гына дөнья күрә.

Газизә шигырьләрен укыган бүгенге укучы үзе өчен яңа бер шагыйрәне генә түгел, ә тагын бер әһәмиятле тормыш хакыйкатен ачты: татар хатын-кызлары элек-электән үк эшчән, тырыш, уңган һәм бай күңелле генә түгел, ә шагыйрь рухлы да булганнар икән. Кешеләр алдында, ирләр алдында күп очракта тел яшереп торулар иске заманның мәҗбүрияте генә булган. Ж. Санд, Л. Украинка кебек киң танылган әдипләрнең элекке татар әдәбиятында булмавы һич тә татар хатын-кызларының сәләтсезлегеннән түгел. Аларның табигый әдәби сәләтләре шул заманның социаль-политик шартларына бәйле рәвештә тиешле дәрәҗәдә ачыла алмаган: тормыш кыравы тигән, иҗатлары бөре хәлендә сулып калган. Шигъри аваз биреп караган, тик тавышы зәгыйфь чыккан, үз тирәсендәрәк кенә яңгыраган. Ә күңелендәге ярсу тойгылар, сагыш-моңнары һәрчак сүзләргә әверелеп, җыр булып дөньяга чыгарга ашкынып торган. Татар хатын-кызлары, булган мөмкинлеккә таянып, үзләренең уй-хисләрен нигездә җырларда ачарга мәҗбүр булганнар. Шуңа да бездә халык лирикасы искиткеч бай. Бу тылсымлы мирасның гасырлар тирәнлегеннән камилләшә-камилләшә килүендә исемнәре билгесез хатын-кыз шагыйрәләрнең роле һичшиксез зур булган.

Хатын-кызларга ирләр белән тигез хокук яулап биргән Октябрь социалистик революциясе һәм гаделлеккә нигезләнгән яңа җәмгыять хатын-кызларның үзләрен дә, кү-

целләрен дә үзгәртте, рухи-культура дәрәҗәләрен баетып, әдәби сәләтләренә тулырак һәм күп яклырак ачылырга мөмкинлекләр тудырды. Шуның нәтиҗәсендә профессиональ язучы булып танылган хатын-кыз язучылар да үсте. Сәрвәр Әдһәмова, Ләбибә Ихсанова, Гөлшат Зәйнашева, Саҗидә Сөләйманова кебек язучыларның күп санлы китаплары хатын-кызларның әдәби процесстагы рольләре югары күтәрелүе турында сөйләргә мөмкинлек бирә. Шагыйрьләр хәзер бездә ялгыз түгел — алар күпләр һәм төрлеләр.

**Үз энҗемне эзлим һаман,**
**көн туса, йөрим йөдәп...**
**Ач, шигърият, серләреңне,**
**тылсымлы сүзләр өйрәт!**

«Ач, шигърият, серләреңне» исемле шигыре белән Саҗидә Сөләйманова 1960 елны шигърияткә шулай дип мөрәҗәгать иткән иде. Әлбәттә, бу аның беренче шигыре түгел. Моңа кадәр дә берничә ел буена ул шигырьләр язып килә, әмма поэзия аңа тиз генә ачылып китми. Поэзиядә үз сукмагын салганчы аңа башкалар йөргән сукмаклардан үтәргә туры килә. Үз энҗесен табарга тиешлегенә нык лап төшенү Саҗидә өчен эзләнүләр, тәҗрибәләр юлында үзе бер җыңү була. Хәзер инде Саҗидә шигырьләре татарча гына түгел, башка телләрдә дә яңгырый. Рус телендә дә берничә җыентыгы чыкты.

Саҗидәнең әдәбиятка килеп керүе күпләр өчен көтелмәгәнрәк һәм, хәтта, бераз сәеррәк тә булды шикелле. Хикмәт шунда: ул укытучы да, журналист та, гаилә йөген тартып баручы ир хатыны да, бала анасы да. Ире дә (Әдип Маликов) иҗат кешесе — шагыйрь. Татарларда исә электән килгән шундый бер язылмаган гадәт һәм әдәп бар: ир белән узышу макталмый... Әмма әдәп һәм гадәтләрне, тормыш басымын җиңәрлек көч таба ул үзендә. Яшәгән каласы Әлмәт хезмәт белән, иҗат белән, нефтьчеләр һәм язучылар белән кайнап тора. Шигырь белән мавыгу Саҗидә өчен үтеп китә торган вакытлы гына күренеш булып чыкмый.

Шигърият үз серләрен һәркемгә ачмый. Ул бик нык сайлый: күңел биографиясе һәм әйтергә үз сүзе булганнарны, тормыш агышына-моңына сизгер күңелләрне, шигъри күрүгә-ишетүгә ия булганнарны...

Поэзия Саҗидәне үзенә елдан-ел ныграк буйсындыра. Тора-бара бөтенләе белән биләп ала. Шигырь аның тормышына, җан сердәшенә әверелә. Шагыйрә үзе язганча:

**Хәләл-хәрамдырмы якыннардан**
**аерып алган сәер хөррият —**
**әсир итте сихри ул хөррият —**
**исеме аның — Иҗат, Шигърият.**

*(«Бүтән мәхәббәт»)*

Күңелдәге иманы, киләчәккә юлы турында сүз кузгатканда шагыйрә һәр вакыт коммунист әтисенең образын, аның тапсыз-кersез вөҗданын, көрәш юлын күз алдына китерә:

**Соңгы патрон әле атылмаган,**
**Онытылма, йөрәк, хушланма!**
**Гадел атлы әткәм аманәте —**
**Соңгы патрон — соңгы дошманга!**

*(«Соңгы патрон»)*

Бу образның Саҗидә әсәрләрендә кабат-кабат күренеп китүе һич тә очраклы түгел — чөнки аның кыйбласы да әтисенең көрәш юлы, идеаллары белән бәйле.

Тагын кемнәр? Җирне һәм балаларны, оныкларын тирән итеп ярата алган, җиргә нык береккән, түземле һәм сабыр, кешелекле һәм кече күңелле зур әнисе — нәнәсе

бар. Сажидәнең әтисе белән гомер буе бер юлдан атлаган, аның сүзеннән чыкмаган, тормыш авырлыкларында сүнеп калмыйча, балаларын олы юлга чыгара алган әнисе. Әнә шундый сабыр рухлы, түземле кешеләр кочагында һәм ышыгында үсә, тәрбияләнә Сажидә. Тормышы да үзе тыңлап үскән әкияттәге патша кызлары тормышыннан бик нык аерыла:

**Үскән чакта тормыш назламады,**
**бизәмәде кулны балдаклар.**
**Балдак-балдак булып сызылып калды**
**урак кискән эзләр бармакта.**
**Дус кызларым ефәк җепләр белән**
**каемады кара бәрхетне.**
**Сабан тотып кара җир өстеннән**
**эзләп киттек авыр бәхетне.**

«Авыр бәхетне» Сажидә әнә шундый авырлык белән таба. «Бу көннәрне әгәр күрми калсам ярлы булыр иде күңелем»,— дип язуы белән ул бик тә хаклы. Сугыш еллары турында гына түгел, аннан соңгы авыр еллар турында да, Әлмәт кебек өр-яңа шәһәр төзү, аны төзүчеләр һәм нефтьчеләр белән бергә яшәве турында да ул шул ук сүзләрне кабатлый ала. Ак ташлы шәһәр һәм җир астындагы нефть аның язмышына әнә шулай бик табигый рәвештә бәйләнеп китә. Ил биографиясе кайсыдыр ноктальарында — әтисенең яки замандашларының образлары ашамы, үз кичерешләре ашамы — шагыйрәнең үз биографиясе белән тоташа. Болар барысы да әсәрләрнең иҗтимагый яңгырашында ныклы җирлек булып торалар. Аның биографиясе яшьлекләре сугыш һәм сугыштан соңгы елларга туры килгән кордашлары чордашларының «авыр бәхет»ләрен сурәтли, авыл мохитендә туып үскән гади крестьян кызларының интеллектуаль дөньяны үзләштерүгә юл алып, интеллигент шәһәр кызлары булып әверелү процессы кебек гыйбрәтле һәм олы социаль күренешне ача. Ә шигырьләре гражданлык рухы белән тирән сугарылган. Укытучыга һәм журналистка хас тәгаллек, ачыклык белән ул акны карадан, караны кызылдан аерып бирә, үзенең мөнәсәбәтен ачык сиздереп бара. «Киләчәгең килә үткәннәрдән», «Эзләреңне саклый һәр буразна», «Марина Цветаевага», «Мәңгелек ут» кебек шигырьләрен генә алып карагандa да аның бүгенге көннең җитди темалары буенча укучы белән җитди сүз алып барырга хәзер булуы ачык күренә. «Марина Цветаевага» шигыре, мәсәлән, гаять катлаулы язмышлы талантлы рус шагыйрәсе белән отышлы диалог рәвешенә күтәрелә язган. Кыска гына ул әсәр үз вакытында революцияне һәм халык көрәшен аңлап җитә алмаган, туган иленнән аерылган шагыйрәнең фаҗигале язмышын күңелләргә үтәрлек итеп, көчле һәм отышлы метафорик образларда сурәтли:

**Шагыйрь күңеле кометалар кебек**
**парашютсыз очты йөзтүбән!**
**Туган туфрак, кара икмәгеңнән**
**киселгәнме сыник!— Киселгән!**
**Орбитадан чыкса, үзен тарткан**
**Җиргә бәрелеп яна җисемнәр.**

Мәгънәле юллар, тәэсирле сүзләр, таушалмаган сурәтләр! Бүгенге көн татар шагыйрәсе гасыр башларында, революция елларында яшәгән өлкән каләм остасының фаҗигасен аңлый һәм аны шул дәвердәге сыйнфый тетрәүләргә бәйләнештә күрә.

Ике чор шагыйрәсе, ике төрле язмыш. Үзе Җир орбитасыннан чыкмаган шагыйрә буларак, Сажидә үз карашын хатын-кызларга хас садәлек, ихласлык һәм беркадәр максимализм белән язып әйтеп бирә. Шуңа да әлеге шигырь авторның интеллектуаль рухи дөньясының киңлеген, дөнья культурасы белән бәйләнешен күрсәтү ягыннан да, сурәтләр палитрасының фәнни төшенчәләргә нигезләнгән метафораларга баюын күрсәтү ягыннан да игътибарны үзенә җәлеп итә. Күбрәк үз тирә-юне — Әлмәт, Татарстан турында рухланып, илһамланып язса да, аның кызыксынуы туган респуб-

лика рамкасы белән генә чикләнми. Аны бөтен җир — Марина Цветаевасы да, «бөркетләр нәселеннән» булган Кюхельбекер да, Себер һәм Урал киңлекләре дә, йөзләрен кара чадра каплаган гарәп кызлары һәм коянгы аяусыз чүл-сахралар да кызыксындыра. Бу олы дөнья белән әнә шундый якын кызыксыну аны ерак җирләргә һәм ерак илләргә сәяхәткә дә алып чыга.

Шигъри детальләрнең характеры да үзенчәлекле: Кояш, җисем, туфрак, туп кебек электән үк кулланышта килгән традицион образлар революция, комета, орбита, парашют дигән яңа характердагы сурәтләр белән бер үк шигырьдә аралашып киләләр. Шушындый контрастлы, чуар аралашу аның башка шигырьләрендә дә очрый: «Далаларда йөри манаралар: нефтьчеләр, җырлар, чатырлар». «Ике якта миләш, балан. Хушыгыз, хуш, пальма, банан!» «Машиналар чаба юлдан, машинада — атлар», «Сәтле шешә муенын сузган кайсысының сумкасыннан»; Кар гына шыгырдап кала бүленеп йокысыннан»... Мондый төрлелек — тормышның, көнкүрешнең үзеннән. Чынбарлыкта иске белән яңа янәшә, аралашып яшәгән кебек шигырьдә дә алар табигый янәшәлектә урнашалар. Аларның кайберләрен, яңа мәгънәви нагрузкалар йөкләп, Саҗидә шигъри сурәт дәрәҗәсенә күтәрә. Тормышның хуҗасы булуны тою, марксистик фән казанышларын үзләштерү шагыйрәне Цветаева, Нерислар газапланган эчке каршылыклар көрәшендә янудан, дөньяны һәм кешене аңлау гаҗизлегеннән коткара. Үзгәреп торган олы дөньяның барышы һәм агышы аның өчен ачык. Шуңа да ул ачык һәм аңлаешлы итеп сөйли, һәр сүзен кешеләргә ышаттерерлек итеп әйтә.

Ә менә шәхеснең эчке дөньясын аңлау тышкы дөньяга караганда күп катлаулырак булып чыга. Монда аның интонациясе дә үзгәрә төшә: кичереше тирәнәя, борчылулары күбәя, сораулары ишәя, җан тынычсызлыгы арта.

Саҗидә бүгенге шәһәрдә яши, ә чыгышы — авылдан: күп вакыты шунда, табигать кочагында үткән. («Җыр булып ташып чыгармын, чыгышым Агыйделдән»). Шуңа да аңа халыкның җыр стихиясе үтә якын. Сурәтләре якын, аһәңе үз. Байтак шигырьләренең җыр поэтикасына нигезләнеп язылуы, димәк, очраклы хәл түгелдер:

**Тау башлары, ай-һай, биек,**
**Тай буе карамалык.**
**Нигә, дустым, үзең менгәч,**
**Әйләнеп карамадың!**

С. Сөләйманова иярергә һәм кабатларга түгел, ә халык җырларының хисләргә муллыгына, сурәтләрнең ачыклыгына һәм тирән мәгънәлелегенә, шигырь юлларының аһәңлелегенә, авазларның ятышлылыгына омтылган шагыйрә иде. Аңарда җырларда күп кабатланган традицион образ да ниндидер яңа яклары, яңа төсмерләре белән ачылып китә. «Каен» шигырендә, әйтик, каен сурәте әнә шулай яңара:

**Булешик әле кайгыны,**
**Ак каен — сары толым.**
**Саргая торган аең бу,**
**Сагына торган елым.**
**Сөйләшик әле серләрне,**
**Ак каен — сары сагыш.**
**Сагынуны басар җырларны**
**Син табыш әле, табыш.**

«Серләремне сиңа сөйлим» шигырендә дә беренче карашка күп кабатланудан искерә төшкән агымсу, тал, төнбоек, сандугач сурәтләре Көнчыгыш хикмәтләре рәвешендәрәк корылган лирик сюжетта яңачарак җанландырып җибәрелә:

**Серләремне сиңа сөйлим,**
**Агыйделкәй, акмый тор.**
**Айкама да, чайкама да,**
**Төпләреңдә саклый күр.**

Агыйдел төбеннән көнгә чыккан төнбоеклар әлеге серне талларга, ә таллар сандугачларга, сандугачлар таң атканда ул серне җыр итеп бакчада сайрыйлар...

Сәҗидә лирик шигырьләрендә җыр стилен активлаштыру һәм баету белән бергә классик поэзиядән килгән шигырь төзү алымнарына да игътибарлы иде.

**Ут шикелле диләр,**
**кулы тисә — эш яна.**
**Ут булсам соң әллә сүнмәс идем!—**
**мин — кеше!**

*(«Кеше»)*

Бусы — публицистик рухта сөйләүгә-бәхәсләшүгә корылган шигырьнең бер рәвеше.

**Ярата, яратмый,**
**Ярата, яратмый...**
**Өзелгән канатлы.**
**Чәчәкләр кырларда,**
**Чәчәкләр юлларда!**
**Табышкан, кавышкан**
**Күп икән дөньяда.**

*(«Чәчәкләр аланда...»)*

Монысында үзәктә — лирик картина. Х. Туфанда шушыңа охшашрак күренеш («Ромашкалар»)— чәчәк йолку — фаҗигале кичереш белән тәмамланган иде. Сәҗидә шигыренең рухы да, ритмы да, аһәңе дә үзгә — аңарда табышу-кавышу рухы өстенлек итә.

**Күзең йомсаң, төнлә түшәгеңә**
**Күе томан булып үй ята.**

*(«Җырчыларның зәңгәр күгенә»)*

**Чатнады җандагы бозлавык,**
**Уятып, сызлатып кузгалды..**
**Сыкылы тынлык, хуш инде!**
**Чатнама суык кыш иде...**

*(«Сыкылы-бәсле...»)*

Геройның психологик халәтен мәгънәле детальләрдә, күренешләрдә ачу, җан хәрәкәтен сүзләр-авазлар хәрәкәте аша күрсәтү буенча да Сәҗидә уңышлы эзләнүләр алып барды, табышлары аз түгел.

Лирик шагыйрьләр күп очракларда үзләренең уй-тойгыларын табигатькә бәйләп ачалар. Сәҗидә дә лириканың шул хәсиятен яхшы үзләштергән. Ул үзен камап алган табигать матурлыгын гадәти фон буларак та күрә һәм шуны башкаларга да күрсәтергә омтыла. Үзендә туган җирен сагыну — җирсү тойгысы аеруча көчле булганга, шушы мотивны ул шигырьләрендә дә әледән-әле үстерә бара, табигать белән якынлыкны, кешене бизи торган матур сыйфат итеп күтәрә.

**Сагындым. Сиңа сарылыйм**
**Зәңгәр күк, яшел үлән.**
**Бәйгегә чыга йөрәгем**
**Яңгырлы яшен белән!**

*(«Табигать...»)*

Әмма табигать күренешләренең иң төп вазифасы — шагыйрә белән, аның уй-тойгылары белән аерылгысыз бер бөтен булып кушылу. Сәҗидә шигырьләрендә та-

бигать күп кенә очракларда берүк вакытта табигать тә һәм кеше аңының аерым халәтләре дә. Ул — шагыйрәнең уйлана, хисләнә торган үзенчәлекле шигъри теле.

Һәм мин яшим синең хакны хаклап
дулкыннарда, язда, күкләрдә..
Җыелмалы зонтигыңны күтәр —
баш өстеңә киләм күкрәргә!

Саҗидәнең төрле кичерешләрне — каршылыклы, өзгәләнүле, шатлыклы тойгыларны ачкан хис дөньясына ярашлы рәвештә аның шигъри теле, табигать сурәтләре дә күп төрле рәвешләргә керә, төрле аналогия һәм параллельләрдә күренә.

Мәгънәле этюдлар, хис белән тукылган күренешләр иҗат иткән шагыйрә олы шигъри полотнолар да яза. Аның «Фал китабы», «Җир-су», «Чәчәкле болын» кебек төрле язмышлар турында сүз алып барган поэмалары бар.

Шулай да әгәр: «Саҗидә кайсы өлкәдә — иҗтимагый-политик мотивларны җырлаучы публицист яки вакыйгалар тезмәсен сурәтләгән эпик шагыйрь буларакмы, әллә шәхеснең күңел тирбәлешләрен, йөрәк мизгелләрен ачучы лирик буларакмы көчлерәк?» — дип сорасалар, һич шикләнмичә мин үзем: «Йөрәк өлкәсендә — микромирда ул күп көчлерәк!» — дигән җавапны бирер идем. Аңарда олы иҗтимагый-политик мотивлар еш кына пафослы яңгырасалар да һәм чын күңелдән язылсалар да, вакыт-вакыт алар декларативлык һәм кайдадыр ишетелгәнне кабатлау, укытучылык рухын сиздереп куя. Бу, күрәсең, шагыйрьне бөтен поэзиягә, бөтен шагыйрьләргә йөкләтелгән бурычларның барысын да — заманны тирән чагылдыруны шигъриятнең бөтен төрләрендә хәл итәргә, чишәргә алынуыннан да килә торгандыр. Заманны тирән чагылдыруга омтылыш, әлбәттә, һәр шагыйрьдә булырга тиеш. Әмма ул әлеге олы бурычны үзенең булган мөмкинлекләренә таянып, үзен көчләмичә, табигый тавышын югалтмыйча (тенор икән — бас белән түгел, тенор белән) җырларга тиеш. Заман рухы яңа темаларны күзгатуда гына түгел, традицион дип аталган темаларны яңачарак яктыртудан да ачылырга мөмкинлеген Саҗидәнең кайбер шигырьләре дә ачык раслый.

Эчке күңел тирбәлешләрен җырлауда исә Саҗидә бөтенләй үз стихиясендә. Биредә ул чын мәгънәсендә виртуозлык дәрәҗәсенә күтәрелеп куя.

Бер ышаныйм әле бураннарга,
Үз-үземнән китеп югалыйм!
Ерагая барган якыным син,
Якыннарга салган ерагым!

Шушы дүрт юлда да никадәр бай хис-кичереш, тирән мәгънә! Тормыш катлаулыгы һәм катлаулы язмышка тарыган шәхес... Хәтта күп кенә очракларда шигырьнең шигырь икәнлеге дә, ничек оештырылуы да онытыла.

Күңел дөньясын ачудагы уңышлы эзләнүләр аның поэмаларында да ачык күренә. Вакыйгалар, характерлар иҗат иткән эпик әсәрләренә караганда аның лирик монологлары сәнгатьчә отышлырак, тәэсирлерәк яңгырыйлар («Җырланмаган җырлар», «Мәңгелек ут», «Сузган ике кулым»). Лирик стихия үзеннән-үзе беренче планга хис-кичерешләрне чыгара, вакыйга-персонажларны томанлы итеп артка күчерә. «Җырланмаган җырлар» әсәре әнә шул хасиятләре белән без күнеккән традицион лиро-эпик поэмалардан шуңа да нык кына аерылып тора. Бәлки аны поэма дип атау да уңышлы түгелдер. Биредә мәхәббәт җырлары җырлана, героиняның күңел тирбәлешләре җыр формасында ачыла. Шул яклары белән ул мәхәббәт турындагы шигырьләр-җырлар бәйләменә дә якын, әмма циклдан аерыла да. Биредә бәйләнешләр көчлерәк, тыгызрак. «Лирик соната» яки «Шигъри симфония» атамалары бәлки аның рухына ныграк туры киләдер? «Мәңгелек ут» әсәренең дә жанрын поэма дип кенә билгеләү аның характерын ачып бетерми. Биредә дә беренче планда хисләр өермәсе, кичерешләр дулкыны. Рус поэзиясендә шундый рухтагы әсәрләрне «реквием» дип атау очрый. Бу да бит бездә әлегәчә исеме табылмаган, жанр чикләре ачылмаган, әмма шигърият практикасында һаман саен очрый торган олы лирик формага карый.

Шигъриятнең бер сере — шагыйрьнең ихласлыгына карый. Саҗидә укый-укый, өйрәнә-өйрәнә, яза-яза әнә шул серне ача. Хисләрнең ихласлыкта, самимилектә ачылуы

исә күңелне үзенә җәлеп итә, үзенә ияртә, авторга карата ышану тойгысы уята. Күп кенә шигырьләрендә, әйтерсең лә, шагыйрь күңеле белән шигырь арасында бер нинди ара-ераклык, пәрдә юк. Эчке янулары, тетрәүләре, сыкраулары, ярсу, әзгәләнүләре — барысы да шигырьдә: халыкчан аһәңле шигырь юлларында, йөрәктән чыккан сүзләрдә, алай гына да түгел — юл һәм сүз араларында. Үзенең күңел дөньясын шулай тутырып ачуы белән, поэзияне сердәше итеп танып, аңа ышануы белән шагыйрә поэзиянең мәңгелек темасын — мәхәббәт темасын да яңача төсмерләре белән заманча һәм үзенчә итеп яңгырата алды. Аның шигырьләрендә дә мәхәббәт изге тойгы, кешене сафландыручы, биеккә күтәрүче, аның кешелек һәм әхлакый тойгылары югарылыгын билгеләүче олы хис, олы кичереш буларак сурәтләнә.

**Мәхәббәтне тирән яшерәләр,**
**Сиздермәслек итеп беркемгә,**
**Тирәнәйгән саен аның нуры**
**Керфек очларыннан сирпелә.**

Саҗидә әнә шул саф хисне, яшерелергә тиеш тыенкы хисне яшереп булмый торган бер халәтендә — янган, дөрләгән чагында сурәтли.

**Табигать... Җилләр, яфраклар**
**бер сулыш монда, бер тын.**
**Шәһәрләр, юллар, тузаннар**
**җуелган сихри бер төн...**
**Яфракта чыклар, керфектә...**
**Бер тирән сулыш, бер җан.**
**Тәрәзә ачык, күңелләр**
**Пәрдәсез аткан бер таң.**

Шагыйрәнең дә күңел тәрәзәсе ачык: ул сөю хисенең ләззәтен дә, шатлыгын да, утларга салуын да сөйли, кешенең борчулы-утлы-сагышлы эчке дөньясына алып керә. Бер шигырендә сөю кешене бәхетле иткән, күкләргә күтәргән ләззәтле бер тойгы булып сурәтләнсә, икенчесендә — аның капма-каршысы ачыла:

**Кем әйтә сөю ләззәт дип!**
**Дөресе, сөю — газап.**
**Йөгәнен өзгән йөрәгең**
**Әллә кол, әллә азат.**
**Ут белән су арасында**
**Тукталыр урын эзләп,**
**үрсәләнеп өзелә үзәк.**
**Дөресе, сөю — бизгәк.**

(*«Кем әйтә...»*)

Бу дөньяның олы мәхәббәткә ия кешеләре башкачарак күрәләр, башкачарак тоялар, ишетәләр, башкачарак эшлиләр. Саҗидә мәхәббәт иясенең әнә шул «башкачарак яшәү» тойгысын шигырь телендә дә оста итеп тасвирлый:

**Нигә соң эчәм җилләрне**
**көйгәнче иреннәрем!**
**Ник керәм утлар эченә**
**күргәнче күмерләрен!**

(*«Ел әйләнә...»*)

Мәхәббәт турында гомуми рухта язылган күп кенә шигырьләрдән Саҗидәнең мәхәббәт лирикасы бер шәхеснең күңел биографиясен ачуы белән аерылыбрак тора. Анда кеше тойгыларының хәрәкәтен күреп була, анда тормыш драмасы, сөю романтикасы, мәхәббәтне язмыш итеп сурәтләү бар. Хатын-кызның күңел серен бездә бе-

ренче буларак шундый тулылыкта, шундый бай төсмерләре белән: шатлык-ләззәтләре, «җан кыюлары» һәм өзгәләнүләре, моң-сагышлары белән, нәкъ үзләренчә кичерүләре белән Сәҗидә чиште дисәк, нәкъ аларча Сәҗидә сөйләп бирде дисәк, һич тә арттыру булмас.

Чикләүләр, читләтүләре!—
Бер кыюга мең тыю...
Ах, әллә сиңа рәхәтме
кеше җаннарын кыю!

Шушы рәвешчә тик хатын-кыз гына тузына ала: биредә барысы да хатын-кыз психологиясе, аның интонациясе, аның сүзләре... һәм сурәтләгән тойгылар бер шәхеснең кичерешләре генә булып калмыйча, күпләргә хас уртаклыкларны чагылдыру дәрәҗәсенә күтәреләләр.

Без күпчелек очракта поэзиядәге иҗтимагый-социаль мәгънәне турыдан-туры шундый эчтәлекне ачкан әсәрләрдән генә эзлибез. Шул нигездә иҗтимагый-политик рухтагы әсәрләрне алгы планга чыгарабыз да, төп игътибарны шуларга юнәлтәбез, мәхәббәт-сөю турындагы әсәрләрне бөтенләй читкә этәрәбез. Ә ныклабрак уйласаң поэзиянең социаль рухи эчтәлеге андый шигырьләрдә дә ачыла икән бит. Моңа Блок һәм Туфан шигырьләре, М. Цветаева, А. Ахматова, С. Нерис, Зөлфия лирикасы ышанычлы дәлил була ала. Татар шагыйрәсе Сәҗидәнең мәхәббәт лирикасы да бүгенге җәмгыятьнең социаль-әхлакый атмосферасында, шәхеснең үз-үзен тотышында туган үзгәрешләр турында сөйли. Дөрес, аның шигырь-җырларында үткән гасырларда һәм үзенә кадәр тасвирланган мәхәббәт авазы белән гомумилек һәм уртаклыклар да бар. Әмма бу уртаклык үткәндәге мәхәббәт, гыйшык сүзләренең гади кайтавазы гына түгел. Боларны гомум кешелеккә хас уртак сыйфатларның чагылуы гына дип карау дөресрәк булыр. Бүгенге татар кызы да бит күпмедер дәрәҗәдә сөю хисен Зөләйха яки Зөһрә кебек, Татьяна яки Изольда шикелләрәк кичерә. Шул ук вакытта аның үз-үзен тотышында күпмедер дәрәҗәдә бүгенге заман кешесенең характерына, дөньяны кабул итүенә бәйле яңарак хасиятләр дә бар. Сәҗидә шигырьләре, мәсәлән, әнә шул турыда уйланырга этәрә. Аларның лирик герое характерына гына игътибар итегез: ул үз хокукын, тормыштагы ныклы үз урынын яхшы белеп, төшенеп эш итә.

Язмышымы үзем язам мин,
Бәхетне үзем табам!

Менә аның тормыш фәлсәфәсе. Шуңа таянып ул үз бәхете өчен көрәшә, үз хакын мәхәббәттә дә даулый. Шигырьләре архивтан табылган Газизә бит болай дип әйтә алмаган, хисләрен дә, күңелен дә бу кадәр иркен итеп, пәрдәсез ача алмаган...

Шигърият! Сәҗидәгә серләреңне яшермичә ачуың өчен, аңа шигърият диңгезеннән шигъри энҗеләр табарга булышуың өчен мең рәхмәт!

# КЕЧКЕНӘ РЕЦЕНЗИЯЛӘР

**Татар иҗтимагый фикере тарихыннан.** Коллектив хезмәт (Рус телендә). Казан. Татарстан китап нәшрияты. 1979.

Татар иҗтимагый фикере тарихын өйрәнү юлында соңгы елларда сизелерлек казанышларга ирешелде. Әгәр элек игътибар конкрет мәсьәләләргә, аерым шәхесләрнең эшчәнлеген тикшерүгә юнәлгән булса, хәзер иҗтимагый фикеребез үсешен киң планда һәм әтрафлы рәвештә өйрәнергә омтылу сизелә. Мәсәлән, Я. Абдуллин, Р. Нәфиков, К. Фасеев һәм С. Михайловаларның билгеле монографияләре шундыйлардан. Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтында иҗтимагый фикер үсешен өйрәнү буенча махсус бүлек ачылгач, мондый киңлеккә омтылуның реаль мөмкинлекләре артты. Шуның бер мисалы рәвешендә «Татар иҗтимагый фикере тарихыннан» дигән яңа җыентыкны күрсәтергә мөмкин.

Китап Я. Абдуллин һәм Ф. Гаффарованың революциягә кадәр татар телендә чыккан марксистик әдәбиятка багышланган зур мәкаләсе белән ачыла. Анализланган материаллардан татарлар арасында марксистик тәгълиматның кайчан, ничек тарала башлавы, ничек үсүе һәм камилләшүе үзенчәлекләре хакында шактый мәгълүмат алабыз. Татар иҗтимагый фикерендә социалистик идеяләрнең формалашу үзенчәлегенә багышланган Р. Әмирханов мәкаләсе дә шушы өлкәдәге белемебезне арттыруга хезмәт итә. М. Фасеев мәкаләсендә исә 20 еллардагы татар иҗтимагый фикерендәге материалистик диалектика мәсьәләләре каралып, революциядән соң ирешелгән казанышлар күзәтелә.

Моннан соң килә торган өч мәкалә — Г. Дәүләтшин, Ш. Абилов, Р. Шәрипов хезмәтләре — безне татар иҗтимагый фикеренең борынгырак чорына алып керә. Аларның беренчесендә монгол яулап алуларына кадәрге бабаларыбызның кайбер космогоник (күк җисемнәренең килеп чыгышлары хакындагы) карашлары күзәтелсә, калган икесендә урта гасыр татар шагыйрьләре, беренче чиратта бөек фикер иясе Мөхәммәдъяр мирасындагы төп моментлар анализлана.

Ә. Хәйруллинның Габденасыйр Курсави эшчәнлегенә, М. Йосыповның Шиһап Мәрҗани һәм Хөсәен Фәезханов арасындагы хезмәттәшлеккә багышланган мәкаләләре укучыны бирерәк дәвергә — иҗтимагый фикеребез яңара башлау чорына алып килә.

«Җәдитчелек, аның социаль табигате һәм эволюциясе» дигән зур мәкалә философия фәннәре докторы Я. Абдуллинның катлаулы, шул ук вакытта гаять мактаулы эшкә тотынуын күрсәтә. Җәдитчелек турында моңарчы да төрле фикерләр әйтелде, әмма атама һәм төшенчәләргә карата кайбер кызыклы тәкъдимнәр ясалса да, мәсьәләне тирән хәл кылынган дип булмый әле. Я. Абдуллин да үз хезмәтен соңгы ноктаны кую максатыннан чыгып язмаган, киресенчә, ул әлеге мәсьәләне өйрәнү юлында яңа этап башлауны күздә тота.

Игътибарны барыннан да элек җәлеп иткән нәрсә шуннан гыйбарәт: әгәр моңарчы бу мәсьәләгә кагылган авторларның күпчелеге җәдитчелек хәрәкәтен төрле чорлар һәм илләр өчен уртак итеп карасалар, яисә аны буржуаз күренешләр белән бутап, әллә нинди «гомуммөселман» хәрәкәте сыйфатында бәяләсәләр, Я. Абдуллин, өйрәнү объектына конкрет тарихилык принцибы белән якын килеп, аның бары Россия җирлегенә генә хас күренеш икәнлеген исбатлый. Шул ук вакытта татар җәдитчеләре белән Урта Азия җәдитчеләре арасындагы аерманы да автор бик дөрес билгели. Гомумән, беренчел документларга таяну, фактларның тормышчан логикаларын марксистик-ленинчыл тәгълимат югарылыгыннан аңларга омтылу — барысы бергә хезмәткә киң колач һәм фәнни тирәнлек бирәләр. Әлбәттә, бу тема бер мәкалә белән генә чикләнмичә, махсус китап язуны сорый. Һәм бу бурычны Я. Абдуллин тиешле югарылыкта башкарып чыга алыр иде.

Филология фәннәре докторы Ә. Кәримуллинның милли китап төшенчәсенә багышланган мәкаләсе материалга байлыгы, «милли китап» дигән төшенчәне фәлсәфи планда хәл кылуы белән игътибарга лаек.

Профессор К. Фасеев җыентыкта халкыбызның иҗтимагый фикерен өйрәнү юлындагы кайбер актуаль мәсьәләләргә багышланган хезмәте белән катнаша. Мәкалә беркадәре историографик планда язылган, ләкин анда моңарчы нинди казанышларга ирешүләрне билгеләү белән бергә, киләчәктә җентекләп тикшерәсе проблемалар да билгеләнә.

Җыеп әйткәндә, яңа чыккан китап иҗтимагый фикер тарихыбыз буенча өйрәнү-

ләрнең активлаша, көчәя баруына, проблематиканың киңәя төшүенә шаһитлык итә. Иң сөенечлесе шул: бу җыентыкта без иҗтимагый фикер тарихыбызны өйрәнү эшенең оеша башлавын да, аның яшь көчләр исәбенә ныгый баруын да ачык күрәбез.

**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ.**

●

ХӘСӘН ХӘЙРИ. Язучы һәм тормыш. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1979.

Әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Хәсән Хәйри исеме киң җәмәгатьчелеккә яхшы таныш. Менә инде дүрт дистә еллар чамасы ул татар совет әдәбиятының үзәгендә кайнап, актив рәвештә иҗат итеп килә. Өлкән әдипнең «Язучы һәм тормыш» дип исемләнгән күләмле яңа җыентыгы, аерым алганда, шул озын һәм бай иҗат юлының үзенчәлекле бер чагылышын, сәсемтәсен хәтерләтә.

Китап биш бүлектән тора. Дөрес, «Театр тарихына зур өлеш» дип исемләнгән соңгы рецензияне махсус бүлеккә аерып куюның нигә кирәк булуын һич аңлап булмый. Ә инде калган дүрт бүлек чын-чынлап олы һәм әһәмиятле проблемаларга багышланып, әдәбиятыбыз барышының үзенчәлекле елъязмасын хәтерләтәләр дисәк тә арттыру булмас.

«Социалистик реализм юлы — киң иҗат юлы» исемле беренче бүлек, үзенең характеры белән өлкән тәнкыйтьче һәм әдәбият белгече иҗатына аеруча хас. Х. Хәйри социалистик реализм иҗат методы белән коралланган татар совет әдәбиятын озак еллар дәвамында төрле аспектлардан килеп, заманча актуаль һәм принципиаль мәсьәләләр күтәреп өйрәнеп килгән автор. Шуңа күрә тәҗрибәле тәнкыйтьченең теоретик принциплары һәм практик күзәтүләре нәтиҗәсе булган әлеге бүлеккә битараф калу мөмкин түгел. Бигрәк тә авторның даһи юлбашчыбыз В. И. Ленин образының рус һәм татар әдәбиятларында чагылышы, М. Горький мирасының социалистик реализм әдәбиятының нигезләнүе һәм үсешендәге роле хакындагы бай һәм кызыклы күзәтүләре үзгә бер җитдилек белән укыла.

Әдәбиятыбызның төрле жанрларын кайгыртып яшәгән тәнкыйтьченең прозага һәм бигрәк тә роман жанрына махсус игътибары бар. Ул соңгы елларда роман жанрының үзенчәлекләре, үсеш тенденцияләренә, татар совет романы үткән юлга аерым мөнәсәбәттә булды. Шул күзлектән китапның «Романнар дөньясында» дип исемләнгән бүлеге җанлы кызыксыну уята.

Өченче бүлектә сүз — күпмилләтле совет әдәбиятының актуаль мәсьәләләреннән халыклар дуслыгы темасы һәм интернациональ бәйләнешләр, әдәби бәйләнышлар хакында. Әдип татар әдәбиятының, барыннан да элек, үз җирлегендәге прогрессив традицияләргә нигезләнеп үсүен күрсәтү белән бергә, аның элек-электән бөек рус һәм башка тугандаш халыклар әдәбиятлары белән «тел вә ләгать алмашып», аралашып яшәвен конкрет иҗатлар мисалында чагылдырырга ирешкән. Аны укып чыккач, халыклар дуслыгы һәм интернационализм идеяләре татар совет әдәбиятының төп юнәлешен билгеләп килә икән дигән нәтиҗә тагын бер кат ясала.

И. Гази, Н. Баян, Г. Хуҗиев, С. Урайский, Ә. Еникәй, Г. Минский кебек язучы һәм шагыйрьләрнең күпкырлы әдәби эшчәнлеген өйрәнүгә багышланган иҗат портретлары һәм мәкаләләр дә китапны тулыландырып торалар, аңарга булган кызыксынуны бермәбер үстерәләр. Гомумән, китапка сүз башы язган Флорид Әгъзәмовка кушылып әйткәндә, Хәсән Хәйринең «бөтен иҗаты татар әдәбиятында социалистик реализм методының үсүен төрле җәһәттән тикшеренүгә багышланган. Бу иҗат әлеге методның партиялелек, халыкчанлык, гуманлык, интернационализм, тормыш белән элемтә кебек асыл принципларының сафлыгы өчен көрәш хисе, аларны үстерүгә омтылу рухы белән сугарылган».

●

ИЛДАР НИЗАМОВ. Ул кабызган утлар. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1980.

Ленин. Бу исем безнең күңелләргә ана сөте белән үк кереп йөрәкнең иң түрендә җылы урын алган. Шуңа күрә даһи юлбашчыбыз В. И. Ленин тормышы һәм биографиясенә нинди дә булса мөнәсәбәте булган һәр хезмәт һәм язма үзенә бер игътибар һәм, әлбәттә, таләпчәнлек белән кабул ителә. Моны аңлап әлеге изге темага мөрәҗәгать итүче язучы һәм шагыйрьләребез, публицистларыбыз үзләре дә, кагыйдә буларак, икеләтә-өчләтә җаваплылык белән килергә омтылалар. Һәрхәлдә тема шуны таләп итә.

Мәгълүм булганча, безнең якларда — Идел буе шәһәрләрендә һәм республикабыз башкаласы Казанда Владимир Ильич Ленин исеме, аның революцион һәм тормыш биографиясе белән бәйләнешле урыннар аеруча күп. Һәм, куанып әйтергә мөмкин, бу хакта әдәбиятта һәм вакытлы матбугатта аз язылмаган. Шулай да әле бу көнгәчә махсус игътибар ителмәгән, язучы һәм публицистларыбызның кулы җитмәгән фактлар да байтак. Әйтик, 1900 нче елның җәендә В. И. Ленин пароход белән Нижний Новгородтан Уфага сәяхәт итә. Аның максаты юл буендагы эре шәһәрләрдә тукталып марксизм идеяләрен пропагандалау һәм, беренче чиратта, «Искра» газетасына хәбәрчеләр туплау була. Әлеге китап авторын юлбашчыбыз биографиясеннән шул әһәмиятле вакыйга дулкынландырган һәм юлга чакырган. Публицист Илдар Низамов шул эзләрдән сәяхәт ясап, юльязма характерындагы яңа хезмәтендә бөек Ленин идеяләренең Идел, Кама, Агыйдел буйларында пар-

тиябез һәм халкыбыз тарафыннан ничек тормышка ашырылуын тасвирлый.

Китап конкрет факт һәм вакыйгалар эзеннән язылуга да карамастан, чын әдәби формага салынып, форма һәм эчтәлеге белән бер бөтен камил әсәр буларак кабул ителә, мавыктыргыч. Авторның Горький, Чебаксар, Казан, Чаллы, Уфа кебек индустриаль үзәкләр, автономияле республика һәм өлкәләрнең экономик җегәре, культурасы хакындагы бай фактик материалга нигезләнгән уйланулары, тулаем, бүгенге көн таләпләренә җавап бирердәй югарылыкта язылган. Алар укучыны кызыксындырган күп кенә актуаль мәсьәләләргә җавап бирер дип ышанырга урын бар.

Гомумән, соңгы елларда очерк жанрында аеруча нәтиҗәле эшләп килгән, кагыйдә буларак, үз язмаларында житди проблемалар күтәргән тынгысыз һәм сәләтле публицист Илдар Низамовның яңа китабы укучы өчен гыйбрәтле һәм шатлыклы очрашулар алып килә.

**Р. САФИН.**

●

---

**ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИН.** Ак яллы аргамаклар. Повесть, хикәяләр. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1980

---

Фаил Шәфигуллинның «Ак яллы аргамаклар» дип исемләнгән яңа китабы урта яшьтәге мәктәп балаларына тәкъдим ителә. Җыентыкка бер повесть һәм дистәдән артык хикәя тупланган. Әсәрләр, әйтерсең, бер-берсен тулыландырып торалар, китапка җөте ачык төсләр өстәп аны тагын да кызыклырак итәләр, баеталар. Чыннан да, шул яктан карагаңда, нәкъ менә шушы әсәрләрнең бергә тупланып, бер бәйләм кебек итеп бирелүе уңышлы чыккан.

Әсәрләрдәге геройлар, гадәттә, шигъри-романтик күңелле, хыялланырга яратучан, шул ук вакытта алар игелекле, ярдәмчел, сизгер җанлылар. Нинди генә катлаулы хәлләргә тарысалар да, коелып төшә, сер бирә торганнардан түгел. Бала чаклары сугыш чорына, сугыштан соңгы авыр елларга туры килгән малайлар, кызларның һәм бүгенге көн сабыйларының да күңелләрен еракта җемелдәгән хыял йолдызлары, төшләргә кереп йөдәтүче ак яллы аргамаклар оптимизм нуры бәркеп, яктыртып тора.

«Бер малай, өч аргамак» повестенда сугыштан соң әле яңа тернәкләнеп килгән авыл тормышы, аның ачлы-туклы яшәүче, хәлсез, ләкин эш яратучы, тырыш кешеләре, бишенче класска гына кучкән Рәсимнәре, Хәбирләре, аларның уй-хыяллары тасвирлана. Алар җәмәгать милкенә кул сузарга да күп сорап тормаучы таш бәгырьле Борһаннарга каршы барырга хәлләреннән килгән, әтиләренә алмашка үскән зур малайлар инде. Повестьның эчтәлегенә, рухына шулай ук түбәндәге юллар да хас: «Әни сәке читендә яткан житен тастымалны ачып җибәрде: кырыйлары кызарып килгән, йөзе алсуланып яргаланган... Татлы исе борыныма килеп тә керде, күзләремнән яшь атылып чыгып, яңакларым буенча агып китте.

— Ипи, — дип шатланып типте йөрәгем.

Бу кадерле аваз тәрәзә артындагы тубылгы куаклары аша, әти төшләреннән минем хыялларыма күчкән ак яллы аргамаклар эзе буйлап, тын басулар өстендә җемелдәшкән көмеш йолдызларга кадәр менде дә кичке җыр булып җиргә әйләнеп кайтты, кайтаваз булып яңадан йөрәгемә килеп керде:

— Ипи!»

Ф. Шәфигуллин повесть-хикәяләрендәге геройлар — туган җиргә, аның тылсымлы табигатенә гашыйк балалар. Алар, нигездә, яшьтән эшкә өйрәнеп үскән авыл балалары. «Миңа уйларга кирәк», «Ерык авызлы энекәшем», «Солдатлар кайта» кебек хикәяләр әнә шул хакта сөйли. «Хыянәт», «Акмөгез», «Верочка», «Бал» хикәяләре хис-кичерешләр киеренкелегенең тулы сурәтләнүе белән аерылып торалар, алардагы бер-берсенә капма-каршы булган образларның портретлары барлык йөз сызыклары, хәлык-фигыльләрендәге һәммә нечкәлекләре белән күз алдына килеп баса.

Әсәргә килеп кергән һәр нәрсә җанлана, кырмыска да, хәтта Ландыш исемле кызның җансыз курчагы да фикер йөртә, сөйләшә башлый. Әсәрнең җанлы теле моңа шул хәтле ышандыра ки, хәтта әлеге кырмыска яки курчакның бөтенләй сөйләшә белмәвен дә онытып кандай буласың.

Һәрхәлдә, «Ак яллы аргамаклар»ның яшь укучыга куаныч һәм яңа очрашулар шатлыгы алып киләсенә ышаныч зур.

**С. ФӘННУР.**

## ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

**Рәфыйк Нәфиков,**

тарих фәннәре докторы

# ЯҢА ДОКУМЕНТЛАР, ЯҢА БУРЫЧЛАР

Беренче рус революциясе патша самодержавиесенә гаять куәтле удар ясады — шул удардан соң царизм инде тәмам терелеп, кабат үзенең элекке хәленә кайта алмады. Цензурадан азат булган матбугатның тууы һәм яшәве дә шуның тирән бер чагылышы иде.

Беренче газета-журналлар чыгу 1905 елга кадәр үз көндәлек матбугатын чыгара алмаган Россия халыклары өчен аеруча зур вакыйга була. Чөнки матбугат милләтләрнең үзаңын, милли горурлыгын уята, халыкның иң алдынгы вәкилләренә пролетариатның гомумроссия күләмендә алып барган сыйнфый көрәшенә кушылырга ярдәм итә. Газета-журналлар марксизм-ленинизмны, халыклар дуслыгы, пролетар интернационализм, патриотизм идеяләрен киң пропагандалый, исемнәре моңарчы билгеле булмаган язучы һәм шагыйрьләрне мәйданга чыгарып, уртак Ватанның әдәбият-сәнгать хәзинәсенә яңа куәтләр өсти һәм аның гомумкешелек прогрессына керткән өлешен үстерә.

Россия халыкларының яшь, ирекле матбугаты элек артта калган милләтләрнең алдынгы вәкилләре арасында революцион-демократик идеология формалашуга этәргеч бирде, демократик характердагы төрле оешма һәм институтлар барлыкка килүгә ярдәм итте, буржуаз милләтчелек һәм шовинизмга каршы көрәштә милли демократик көчләрнең берләшүен тизләтте.

Революцион демократлар хезмәт ияләренең социаль аңын үстерү, аларны самодержавиегә каршы көрәшкә туплауда матбугат биргән мөмкинлекләрдән оста файдаландылар. Аларның каләме төгәл һәм үтергеч итеп суга да, чәнчә дә белә иде.

«Азат», «Азат халык» белән бергә, татар байлары һәм милләтчеләре өстенә ерак Уральскида Г. Тукай чыгарышкан «Уклар» ява башлый. Аның дүртенче санында үк басылып чыккан «Татар байларына ачык хат», мәсәлән, капкорсак байчураларны «милләт микроблары» дип тамгалый. Бу тамга, бюрократия алдында дер калтырап, ялагайланып көн күрүче царизм ялчыларына тагылган «сатлык татар» кушаматы кебек үк, татар әдәбиятына, аның Фатих Әмирхан кебек иң алдынгы вәкилләре иҗатына анык бер фикер юнәлеше, социаль позиция билгесе буларак кереп урнаша. Большевик Г. Сәйфетдинов 1909 елда «Әлислах» газетасында басылган «М. Сәйдәшевка ачык хат» исемле мәкаләсендә иң реакцион дини матбугат әһеле М. Сәйдәшевкә карата Г. Тукай һәм Ф. Әмирхан биргән билгеләмәне кабатлый. Татар театр сәнгате эшлеклесе И. Кудашев-Ашказарский ачык хатны үзенең репертуарына кертә, аны граммофон пластинкасына да яза [1].

Көндәлек матбугат органнары, мәгълүм ки, күп шәһәрләрдә барлыкка килә: Казанда, Мәскәүдә — «Азат», «Азат халык», «Әлислах», «Таң йолдызы», «Тавыш», «Тәрбиятеләтфал». Петербургта һәм Оренбургта — «Урал», «Карчыга», «Чүкеч», «Фикер», «Уралец», «Уральский дневник», «Яңа тормыш», «Туплар», Ташкентта «Тәрәккый» һ. б. Беренче рус революциясе елларында гына да татар интеллигенциясенең алдынгы өлеше тарафыннан 19 исемдә прогрессив һәм революцион-демократик юнәлешле матбугат органы — 12 газета һәм 7 журнал чыгарыла, шуларның икесе рус телендә басыла. Бу чор татар матбугаты үсешенең иң зур казанышы большевистик «Урал» газетасын чыгару булды. Ул газетаның бер үк вакытта казакъ һәм башкортлар арасында, Урта Азия һәм Әзербәйҗанда да тарала башлавы күп нәрсә турында сөйли.

---

[1] Кара: «Граммофон һәм патефон татар көйләре пластинкаларының мөкәммәл каталогы». Бәрадәран Кәримовләрнең сәүдә йорты нәшриятында Оренбург «Вакыт» газетасы типографиясе. 1912 ел, 32 бит.

Уральскида газета-журнал чыгару эшен башлап җибәрүчеләрдән берсе булган Тәхфәтуллиннар гаиләсе, Уральск шәһәре матбугат хезмәткәрләре белән башка шәһәрләр, шул исәптән Казан матбугаты эшлеклеләре, әдипләре арасындагы бәйләнешне өйрәнү кызыклы мәгълүматлар бирә. Аларның бу эшчәнлекләренең күп сәхифәләре инде билгеле. К. Мотыйгый-Тәхфәтуллин һәм Г. Тукай чыгарган газета-журнал материалларыннан да ул яхшы күренеп тора. Әйтик, «Әлгасрелҗәдид» журналы Казанда беренче татарча театр уены вакыйгасын бик тәфсилле яктырта[1]. Бу хәл татар иҗтимагый тормышында олы бер вакыйга итеп сурәтләнә. Театрны барлыкка китерүдә алдынгы яшьләрнең роле күрсәтелә, приказчиклар җәмгыяте залында 1906 елның 5 маенда уйналган «Кызганыч бала», «Гыйшык бәласе» спектакльләрен, тәнәфес вакытында «Тәфтиләү» кебек халык көйләре башкарылуын тамашачыларның ничек дәртләнеп каршы алулары бәян ителә. Журнал редакциясе Казанның мәдәни тормышындагы бу яңалыкны кайнар хуплавын белдерә. Журналда Х. Ямашев, М. Вахитовларга якын торган кешеләрнең мәкаләләре басыла. Ф. Әмирхан тәрҗемәсендә Париж коммунасы тарихы дөнья күрә. «Фикер» газетасының 1906 ел 8 май санында «Уклар» исемле журнал нәшер ителәчәге белдерелә. Аның «могайян мөхәррирләре» арасында «Шүрәле», «Сөйәемсез» белән басыла килгән авторлар бар. Боларның Г. Тукай һәм мәшһүр әзербәйҗан әдибе А. Сабир псевдонимнары икәнлеге сер түгел. Г. Тукай белән А. Сабирның үзара читтән торып танышлыгы шул вакытлардан башланамы? Монысын киләчәктәге тикшеренүләр күрсәтер, һәрхәлдә, Әзербәйҗанда Г. Тукайның «Уклар»ын яхшы белгәннәр[2].

Татар көндәлек матбугатында барган фикер көрәше рус матбугаты битләрендә дә чагылмый калмый һәм теге яки бу дәрәҗәдә гомумроссия укучысына да барып ирешә. «Молодой Татарин» псевдонимы белән газетада басылган мәкаләдә, мәсәлән, милләтче Сәйдәшевләрнең кайбер астыртын эшләре фаш ителә. «Тормыш алга атлый һәм аны буй-буй халат җиңе белән генә каплап калып булмый»,— дип яза автор[3].

Фатих Әмирханның ялкынлы публицистикасы рус матбугатында да чагылыш таба. Мәсәлән, аның «Әлислах» газетасында басылган «Казанның «педагоглары» һәм башка мәкалә һәм фельетоннары «Волжско-Камская речь» газетасында искә алына. 1908 ел 9 февраль санында бу газета, «Әлислахка таянып», мәгариф эше буенча сайланган комиссияләр эшенә бәя бирә, әлеге комиссия әгъзаларын мәгариф эшенә берничди катнашы булмаган «искечеләр» дип атый.

[1] «Әлгасрелҗәдид», 1906 ел, 15 сан.
[2] Бу хакта кара: А. Мирахмедов. Җәлил Мамедкулизадә (мулла Насреддин) һәм XX йөз башы Әзербәйҗан матбугаты үсеше мәсьәләләре. Филология фәннәре докторы фәнни дәрәҗәсенә дәгъва итүгә диссертация рефераты. Баку, 1973 ел, 46 бит.
[3] «Волжский вестник», 1905 ел, 20 май саны.

Ислахчылар тарафыннан оештырылган кичәләрдә үк инде халыклар бердәмлеге, интернационализм идеяләре тормышчан чагылыш тапкан. Аларда татар яшьләре, үз милли көйләре белән бергә, Россия халыклары җырларын да башкарганнар. Шундый әдәби-музыкаль кичәләрнең берсендә Ф. Әмирхан белән янәшәдә утырган кыргыз егете, мәсәлән, җырлаучыларның кыргыз түгел, татар шәкертләре икәнен белгәч, «көен шулкадәр дөрес итеп, бөтен төсмерләре белән җырлауларына бик тәгаҗҗеп» була[1].

Татар демократлары, интернационализм һәм патриотизм идеяләрен эзлекле төстә яклап, милләтчеләргә каршы аяусыз көрәш алып баралар, рус шовинистларын рус халкы белән тыңлаучыларне ачы тәнкыйтьлиләр[2]. Халыклар арасында үзара мөнәсәбәтләрнең сафлыгы өчен көрәшкән хәлдә, Г. Тукай һәм Ф. Әмирхан реакцион элементларның һәр адымын күзәтеп торалар.

Татар матбугаты өстеннән күзәтчелек итүче цензура әһелләре дә «Әлислах» газетасын әерым куеп, аның «прогрессив орган» булуын, «бай сыйныфлар мәнфәгатьләрен күз уңында тотучы матбугат органнары белән бәхәс алып баруын» әйтеп узалар[3]. Һәм шулай ук, Казанда нәшер ителә торган башка татар газеталарыннан аермалы буларак, «Әлислах» милли килешмәүчәнлектән азат, ул башка халыкларның хокукларына һәм аларның атаклы вәкилләренә хөрмәт белән карый», бу газета «татарларның руслар белән якынаюында бернкадәр эз калдырды, ул реаль белемнәрнең руслар аша, татар мәдрәсәләре өчен үрнәк булырга тиешле рус уку йортлары аша үзләштерелергә тиешлеген исбатлый», дип күрсәтәләр[4].

Ф. Әмирхан рус матбугаты битләрендә татар әдипләре иҗатына дөрес бәя бирелүгә нык игътибар итеп килә. «Волжский листок» газетасында Касыйм Уралец дигән кешенең Тукай иҗатына күләгә төшерү, аны кечерәйтеп күрсәтү нияте белән язылган язмасы күренүгә, Ф. Әмирхан «Татар шагыйрьләре» дип исемләнгән мәкаләсен язып, аны ачы тәнкыйть утына ала. «Бәлки, башка газеталарда күренсә, тар милләтче вә татар әдәбиятыннан бөтенләй хәбәрсез татар тарафыннан язылган бу мәкалә миңа ул кадәр гаҗәп тә тоелмас иде. Ләкин демократлык флагы астында чыга торган газетада бу мәкалә бөтенләй урынсыз күренеп, ул хакта үз фикеремне язарга мәҗбүр булам», — ди ул.

Реакцион даирәләр теләсә нинди юллар, чаралар ярдәмендә революцион демократларның массаларга йогынтысын киметергә, аларның абруй һәм дәрәҗәләрен төшерергә омтылалар. Моны «Бәянелхак» газетасының да һәр санынннан диярлек сизәргә мөмкин. Ачыктан-ачык идея көрәшендә

[1] Ф. Әмирхан. Сайланма әсәрләр. Икенче том, Казан, 1958 ел, 191 бит.
[2] Ф. Әмирхан. Сайланма әсәрләр. Икенче том, 201 бит.
[3] ТАССР Үзәк дәүләт архивы, 420 фонд, 150 эш, 48—49 кәгазь.
[4] ТАССР Үзәк дәүләт архивы, 420 фонд, 150 эш, 49—50 кәгазь.

оттыруларын сизгәнгә күрә, татар карагруһчылары, шовинистлар белән бер булып, революцион демократларга каршы халык арасындагы иң надан, караңгы элементларны, люмпеннарны котырталар.

«Волжско-Камская речь» газетасы 1908 елның 2, 4, 9, 12 февраль саннарында реакционерларның аерым йортларда җыелышлар җыеп, губернатор исеменә шикаять кәгазьләре язуларын, Ә. Сәйдәшев, А. Галиев, С. Галикәев, С. Хәсәнов ише карагруһчы һәм дини фанатикларның үз тирәсенә фикердәшләр туплавын күрсәтеп үтә. Прогрессив яшьләр белән реакция көчләре арасындагы көрәш газета битләре белән генә чикләнми. Реакционерларның казынулары алдынгы катлауларның кискен каршылыгына очрый. Болар барысы да Ф. Әмирхан, Г. Тукай җәеп җибәргән пропагандистлык эшчәнлегенең нәтиҗәле булуын исбат итә.

Үз нәүбәтләрендә жандармерия шымчылары Ф. Әмирхан өстеннән ялган донослар тезиләр. «Сатлык татар»ларның берсе Казан шәһәре жандармерия идарәсенә язган доносында Ф. Әмирхан, янәсе, төрек флоты өчен акча җыю белән шөгыльләнә, керем суммасын куен дәфтәренә терки бара, дип күрсәтә. Доносны тикшерү Казан полицмейстеры Шершневка йөкләтелә. Искәрмәстән килеп кереп, әлеге куен дәфтәрен тикшереп караганнан соң, Шершнев 1912 елның 13 ноябрендә түбәндәге документны төзи:

«Казан мещаны Фатих Әмирханов алты ел дәвамында аяк параличы белән авырый, үз аягында йөри алмаганлыктан, даими рәвештә өйдә утыра һәм мөселманнар өчен татар телендә төрле әсәрләр: романнар, хикәя һәм әкиятләр яза, аларны «Гасыр» китап нәшриятында бастыра. Ул шулай ук «Юл» газетасында мәкаләләр дә яза һәм болар өчен гонорар акчасы ала. Искәрмәстән тентү ясарга килгәндә, ул татар телендә хикәя язып утыра иде. Язган әсәрләре өчен алына торган акча суммасын Әмирханов ай саен хәтер дәфтәренә терки, соңгы биш айда «Юл» һәм «Гасыр»дан ул 161 сум акча алган. Хәтер дәфтәренә шуннан гайре берникнди дә язу теркәлмәгән, ул дәфтәр үзе берничә ел буе алып барылган» [1].

Патша чиновнигы нәкъ әнә шулай «искәрмәстән» кереп китап наширлары бертуган Хәсәновларның кесәләрен дә актарып караган. Ләкин законнан тыш җыелган берникнди акча таба алмаган.

Казан губернасы жандармерия идарәсенә 1912 елның 15 ноябрендә җибәргән яшерен җавабында Казан губернаторы Ф. Әмирхановның да, бертуган Хәсәновларның да төрек ярым ае файдасына акча җыю белән шөгыльләнмәүләрен, Казанда гомумән андый хәлнең булмаганлыгын хәбәр итә [2].

Гомерлеккә урындыкка беркетелгән Ф. Әмирхан, үпкәләренең савыгуына өмете калмаган, цензура тарафыннан даими эзәрлекләнгән Г. Тукай чын-чыннан батырлык үрнәге күрсәтәләр. Халык мәнфәгате, аның киләчәге өчен көрәшеп, алар соңгы сулышларынача халыкның тугрылыклы, фидакарь уллары булып калдылар.

Ф. Әмирхан, Г. Коләхметов, Ф. Мөхәммәдъяров, И. Кулиев, Ф. Агиев, Ш. Әхмәровларны самодержавие ялчылары дәүләт өчен куркыныч шәхесләр исемлегенә теркиләр [1]. Г. Тукайның һәр шигырь җыентыгы, һәр мәкаләсе цензура комитетында теркәлә бара, шул хакта жандармерия идарәсенә хәбәр ителә тора, аның әсәрләренә арестлар салына. Жандармерия күрсәтмәсе буенча патша цензурасы шагыйрьне еллар буе, соңгы көненә кадәр эзәрлекли [2].

Әлбәттә, эзәрлекләнүчеләр өчен болар җиңел генә узмаган. Ләкин халык кайгыхәсрәтләрен үз кайгысы, аның сагыш-газапларын үз күңел ярасы итеп кабул иткән кешеләрне ул дәһшәтләр туктатып кала алмады.

Ф. Әмирхан «Аң» журналының 1912 ел 1 санында басылган «Шәрык йоклый» исемле мәкаләсендә тирән җан ачысы белән болай дип язган иде: «Аның кайчандыр Ибне-Синалар, Фарабилар, Ибне Рәшедләрне тудырган гакылы вә гыйльми көче йоклый, пәсләнеп, ниндидер мөлгунь кара кабыкларга чолганып йоклый...»

Язучы биредә дә үзен кыска хикәя, новелла остасы итеп күрсәткән хәлдә, әсәрен тарихи йокыга талган халыкларның уянуына чиксез ышаныч белән тәмамлый: уяну никадәр генә авыр, үкенечле булмасын, әмма ул киләчәк...

Рухи бердәмлеккә, теләктәшлеккә сусаган татар демократик интеллигенциясенә, революцион демократларына алдынгы рус җәмәгатьчелеге, социал-демократлар ярдәмгә килде. РСДРПның Казан комитеты члены А. Пинкевич рус җәмәгатьчелегенең прогрессив көчләре консерваторлар белән көрәштә татар яшьләренә нык ярдәм күрсәтә алырлар иде, дип язды һәм алдынгы яшьләрнең җиңеп чыгачагына ышаныч белдерде [3].

А. Пинкевичның икенче бер мәкаләсе бөтендөнья мөселман съезды мәсьәләсен яктыртуга багышланган. Бу мәкаләне ул шул чордагы татар көндәлек матбугаты материалларыннан файдаланып яза, үзеннән кайбер аңлатмалар да өсти [4]. Тәгәлрәк әйткәндә, А. Пинкевич биредә «Казан мөхбире» газетасының 1908 елның 18 февралендә «Барлык илләрнең бай мөселманнары, берләшегез!» дигән сарказстик исем астында Г. М. инициаллары белән басылып чыккан мәкаләгә таяна. (Безнең уебызча, Г. М.— Х. Ямашевның якын дусты Габдрах-

---

[1] ТАССР Үзәк дәүләт архивы, 199 фонд, 2269 эш, 146 кәгазь.

[2] Шунда ук, 148 кәгазь.

---

[1] ТАССР Үзәк дәүләт архивы, 3610, 3482, 3484 эшләр, 199—200 кәгазь h. б.

[2] Шунда ук, 420 фонд, 172 эш, 1517 кәгазь; 179 эш, 143—145 кәгазь; 180 эш, 57 кәгазь, ЦГИАЛ, 821 фонд, 133 тасвирлама, 472 эш, 125 кәгазь; 451 эш, 8 кәгазь, 35 кәгазь; 776 фонд, 31 тасвирлама, 91 эш, 49 кәгазь, 776 фонд, 21 тасвирлама, 260 эш, 2—3, 9 кәгазьләр.

[3] А. Пинкевич (газетада — А-т. П.) «Мөселманнар тормышыннан». «Волжско-Камская речь», 1908 ел, 27 февраль саны.

[4] Шунда ук, 1908 ел 3 март саны.

ман Мостафин булырга мөмкин). Автор мөселман капиталистларын, панисламизм идеологларын үткен фаш итә. Ул мәкалә хакында «Волжско-Камская речь» газетасы 1908 елның 27 февраль санында хәбәр иткән.

Бу мисаллардан Х. Ямашев, Ф. Әмирхан, Г. Тукайның җирле рус матбугатына булган йогынтысы күзаллана. Татар публицистикасының интернационализм идеяләре белән сугарылган иң яхшы үрнәкләре бөтенроссия укучысына барып ирешә.

Алдынгы рус культурасының яшь татар зыялыларына йогынтысы шулай ук зур булган. Моны реаль тормыш фактлары раслый. 1908 елның 8 мартында «Яңа клуб» бинасында демократик рус җәмәгатьчелеге тарафыннан оештырылган «Халык университеты» инициативасы белән шәрык музыкасы кичәсе үткәрелә. Кичәнең беренче өлешендә курайда һәм скрипкада халык көйләре башкарыла. Скрипкада шул чорның күренекле музыканты, татар көйләрен махсус өйрәнгән виртуоз скрипкачы И. Козлов уйный. Мәкаләдә Россия халыкларының музыкасы матурлыгы ягыннан шул чорда бик модада булган Көнбатыш Европа һәм Америка көйләреннән һич калышмый, диелә.

Кичәнең икенче өлешендә Бородин, Глазунов, Кюн, Чайковский, Мусоргский, Римский-Корсаков, Григ һәм башка атаклы композиторлар эшкәрткән шәрык көйләре тәкъдим ителә.

Татар һәм башкорт көйләрен башкаруы белән тамашачылар күңелендә Г. А. Трейтер ханым аеруча тирән эз калдыра. Бу хакта «Волжско-Камская речь»ның 1908 ел 11 март санында Г. Берг (Казан матбугатында даими язышып килүче Герман Тельберг) мәкаләсендә әйтелә. «Волжско-Камская речь»та басылган бу ике хәбәрнең мәгънәсе шушы ук кичә хакында газетаның 12 март санында урнаштырылган күмәк хат белән танышкач тагын да тирәнәя. Ул хатка кул куйган егерме дүрт кеше «җомга көнне «этнографик кичәдә» татар көйләрен башкаруы белән гаять зур рухи ләззәт бүләк итүе өчен» Гликерия Алексеевна Трейтерга рәхмәт белдерәләр. «Ул без инде үзебез онытып бетергән милли көйләрне яңартты, татар моңнарының рухын сәнгатьчә камил җиткерә алды. Безнең моңарчы күңелебезгә якын ул көйләрне әнә шуның кебек матур итеп хатын-кыз башкаруында ишетүгә ирешә алганыбыз юк иде, чөнки безнең хатын-кызларыбыз халык алдында җырламыйлар. Шуңа күрә хөрмәтле Г. А. Трейтерга чын күңелдән рәхмәтебезне белдерәбез»[1].

Бу хат безгә иң күренекле татар шагыйрьләре һәм язучылары, публицистлары тормышының мөһим бер сәхифәсе белән танышырга мөмкинлек бирә. Рус культурасы вәкилләренең йогынтысы шифалы һәм дәртләндергеч була, халыклар арасында үзара аңлашу һәм дуслык бәйләнешләрен ныгытырга ярдәм итә.

Рус телендә язылган бу документка беренчеләрдән булып Г. Тукай кул куйган. Рәттән үк Г. Камал, С. Рәмиев, Г. Кәрам, В. Апанаев, Ф. Агеев фамилияләрен, Г. Коләхметовның туганы С. Коләхметова һәм башка исемнәрне очратабыз.

Шул ук газетаның 4 апрель санында «Әлислах» оештырган икенче бер кичә турында хәбәр ителә. «Г. Трейтер сәхнәгә чыгуга мөселманнарның шатлыгы иң югары ноктасына җитә... Аның тавышы матур, акценты ачык сизелеп торса да, көйне бик нечкә тотып ала. Аны бик каты кул чабып озаталар. Аннары ул хорга кушылып «Ашказар» көен башкара. Гаять тә моңлы көй... Ислахчылар чәчәк бәйләме, язулы альбом бүләк итәләр»,— дип яза рус хәбәрчесе.

Автор шулай ук кичәдә чыгыш ясаган шагыйрьләр Г. Тукай, С. Рәмиев исемнәрен атый, аларны «ихлас күңелдән алкышлыйлар» ди. Шунда ук үзбәк җырлары, рус биюләрен башкару хакында әйтелә.

1909 елның 20 мартында Казанда большевик В. А. Александров җитәкчелегендә Н. В. Гогольнең тууына 100 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә оештырыла. Кичә рус һәм татар телләрендә бик җанлы уза. Татарлардан анда шагыйрь С. Рәмиев чыгыш ясый[1].

Шушындый ук кичәләрдә Г. Тукай да катнаша. Мәсәлән, 1908 елның 27 мартында үткән әдәби-музыкаль кичәдә ул үзенең шигырьләрен укый[2].

Татар матбугатына багышланган бер мәкаләсендә большевик Г. Сәйфетдинов (әлбәттә, исем-фамилияләрен атамыйча) Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камал, Г. Ибраһимовларның революцион эшчәнлеге, татарлар арасында караңгылык һәм наданлыкны бетерү, бөек рус культурасы казанышларын халыкка якынайту өчен кыю көрәшүләре хакында язды.

Татар студентлары да азатлык хәрәкәтеннән читтә калмыйлар. Студентларның әдәби-политик түгәрәкләре җитәкчеләреннән берсе большевик Хөсәен Ямашев була. Жандармнар аны әлеге түгәрәкнең эшене социал-демократик эчтәлек кертә дип саныйлар.

Х. Ямашев татар яшьләре һәм интеллигенциясе арасында большевистик идеяләрне киң тарату максатын куеп эш итә, аның тырышлыгы белән студент-юристлар түгәрәге оештырыла. Х. Ямашев белән бергә түгәрәк эшенә учитель Г. Коләхметов, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камал, М. Дулат-Али, Г. Сәйфетдинов, Г. Хәсәнов һәм башкалар ярдәм күрсәтәләр. Х. Ямашевның ул чорда большевиклардан В. А. Александров, В. В. Адоратский, Н. Е. Сапрыгин, А. И. Догадов, М. П. Жаков, М. М. Золина-Вилонова белән хезмәттәшлек итүе мәгълүм. Казан большевиклар оешмасы

---

[1] «Волжско-Камская речь», 153 сан

---

[1] «Волжско-Камская речь», 1909 ел, 22 март саны

[2] «Казан мөхбире», 1908 ел, 31 март. Г. Кариев Тукай турындагы истәлекләрендә аның әле Уральскида яшәгән елларында ук рус җәмәгатьчелеге вәкилләре оештырган кичәдә шигырен укуы хакында әйтә («Мәктәп» журналы, 1913 ел, 4 сан). Г. Тукайның шулай ук рус операсы солистлары Рудаков, Панфиловлар җырлаган катнаш рус-татар концертында шигырь сөйләве билгеле. Кара: «Йолдыз», 1911 ел, 18 январь

китапханәсе каршында, Х. Х. Хәсәнов сүзләре белән әйткәндә, «Хөсәен Ямашевның якыннан торып катнашуы һәм җитәкчелегендә 125 китаптан торган татарча әдәбият бүлеге оештырыла»[1]. Әмма архив материалларыннан без Х. Ямашевка кагылышлы фактларны таба алмадык.

Бу тема алга таба җитди тикшеренүче таләп итә. Мәсьәләне, күрәсең, киңрәк планда алып карарга кирәктер. РСДРПның Казан комитеты яшерен китапханәсе каршындагы әлеге бүлекне оештыруда М. Вахитов, Ф. Әмирхан, Г. Тукайның катнашлыгы булмаганмы?

Китапханәдә «беллетристика», «политэкономия», «философия» бүлекләрен аерып алырга мөмкин. Беренче бүлектә Горький, Андреев, Бунин, Вересаев, Короленко, Некрасов, Серафимович, И. Франко, Чириков һәм башка әдипләрнең әсәрләреннән тәрҗемәләр күрәбез. Икенче бүлектә, нигездә, Көнбатыш марксистлары һәм социал-демократларының хезмәтләре тупланган. Философия бүлегендә Коммунистлар партиясе манифестын, Ф. Энгельсның «Анти-Дюринг», «Людвиг Фейербах» исемле хезмәтләрен, Ф. Меринг, Лафарг әсәрләрен, шулай ук рус социал-демократлары брошюраларын очратабыз. Татар китаплары арасында Г. Камал һәм Әхмәтгәрәй Хәсәни басмалары күпчелекне тәшкил итә. Бу хәл шулай ук күп нәрсәгә ишарә була ала: Х. Ямашевның Г. Камал белән дуслыгы күптән мәгълүм. Бертуган Хәсәновлар — Әхмәтгәрәй һәм Бари да М. Вахитов, Ф. Әмирхан, Г. Тукай белән арадаш булганнар.

Татар бүлегендәге әсәрләрнең күп өлеше — рус теленнән тәрҗемәләр. Ә тәрҗемәчеләре (С. Рахманкулов, И. Богданов, Г. Мостафин, Г. Кәрам, А. Газакаев) шулай ук Х. Ямашев, М. Вахитов, Г. Тукайга якын торган кешеләр. Биредә Ә. Хәсәни тәрҗемәсендә Лункевичның «Күк һәм йолдызлар» китабы игътибарны җәлеп итә. Бу китап М. Вахитовның шәхси китапханәсендә дә булган һәм ул аны иптәшләренә укырга биреп торган.

Китапханәгә кергән басмалар арасында безгә шактый еллар элегрәк тә таныш булган бер брошюра очрады. Сүз 1907 елны басылып чыккан «Казакъ ахвалендан» дигән басма турында бара. Китапта казакъ халкының тормыш-яшәеше турында бик төгәл мәгълүмат бирелә, казакъ милли эпосының байлыгы күрсәтелә.

Х. Ямашевның китапханәне оештыруга катнашлыгы хакында сөйләгәндә аның күп кенә басмалар авторы булуы ихтималын да онытмаска кирәктер. «Казакъ ахвалендан» брошюрасы да шундый хезмәтләрнең берсе булуы мөмкин. Китапханә исемлегенә теркәлгән аерым газета саннарын тәфсилле тикшереп чыгу да бик файдалы булыр иде. Әйтик, шуларның берсе — «Вакыт» газетасының 1909 елның 5 декабре саны. Монда халыкара хәлгә, аерым алганда, Якын Көнчыгыш вакыйгаларына күзәтү урнаштырылган. Газета-журналларның аерым саннарын китапханә фондына, мәкалә авторлары үзләре тапшырган булуы да мөмкин. «Әлгасрелҗәдид»нең, мәсәлән, бары тик бер саны китапханәгә кергән, әмма Г. Тукайның бөтен Россиягә таралган «Соры кортларга» исемле шигыре нәкъ менә шул санда дөнья күргән бит.

Китапханәдә тупланган басмаларның даими төстә файдаланылган булуында шик юк. Эшчеләргә, мәсәлән, махсус сайлап алынган матур әдәбият китаплары да бирелгән[1]. Приказчиклар арасында большевик В. В. Адоратскийның эшләве билгеле. В. А. Александров югарыда әйтелгән «Казан сәүдә хезмәткәрләре җәмгыяте» җитәкчесе булган. Комитет членнары В. И. Ленин белән элемтә тотканнар[2].

Китапханәдәге китаплар исемлегендә Х. Ямашев һәм Г. Сәйфетдиновның [(псевдонимы Г. Баязитов)] тәрҗемәләре, «Урал» редакциясенең һәм Г. Камалның басмалары булуы, әлбәттә, аны оештыруга Х. Ямашевның да катнашканлыгы хакындагы фикерне куәтли. Китапханәдә икешәр данәдә Г. Тукай, С. Рәмиевнең шигырь җыентыклары, З. Бигиев, Г. Камал, Ф. Халиди әсәрләре дә булган.

РСДРПның Казан комитеты членнары өязләрдә (мәсәлән, Чистай, Малмыж өязләрендә), төрле шәһәрләрдә яшәүчеләр белән дә элемтә тотканнар. Троицк шәһәрендә яшәгән Хәсән Имамбаев — әнә шуларның берсе. Аның белән бертуган А. И. Имамбаев — Казандагы революцион подпольеда да актив эшләгән кеше, Г. Кариев, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимовларның танышы. Казан университетыннан куылганнан соң, губернатор күрсәтмәсе буенча, ул анда кире кайта алмый. Амангельды Имановның якташы булырак, ул бәлки аның үзе белән дә таныш булгандыр? Әмма билгеле булган кадәресе дә Казан большевикларының милли азатлык хәрәкәте вәкилләре белән бәйләнеш тотканлыкларын исбатлау өчен ныклы нигез бирә.

Казан большевигы В. А. Александров фатирында тентү вакытында татар телендә язылган төрле зурлыктагы кәгазь битләре табыла. Жандармнар Чистайдан «Болгар» номерларында яшәүче Харрас Фәхретдиновка җибәрелгән бер хат та табып алалар. Хатка «1908 елның 13 августы. Казандагы «Шәрык» клубы» дигән штемпель сугылган була.

Менә бу фактларны Х. Ямашев аша Г. Тукай, Ф. Әмирхан һәм башка революцион-демократлар да белмичә калмаганнардыр. Большевикларның шәһәр комитеты кассасына акча кертү максаты белән әдәби-музыкаль кичәләр оештыруда алар да катнашкан бит. Архив документларыннан күренгәнчә, шушындый юл белән табылган сумманың бер өлеше большевик-

[1] Х. Хәсәнов. Революционер-интернационалист. Большевик Хөсәен Ямашевның тормышы һәм эшчәнлеге. Татарстан китап нәшрияты. Казан, 1971 ел, 169 бит.

[1] Нафигов Р. И. 1907—1914 елларда Казан социал-демократлар оешмасы. Рус телендә. Казан дәүләт университеты нәшрияты, 1961 ел, 90 бит.

[2] Татарстан Үзәк дәүләт архивы, 199 фонд, 2332 эш, 251 кагазь.

ларның узәк газетасы «Звезда»га, ә соңрак «Правда»га язылу өчен тотылган[1]. Большевикларның Прагада үткән партия конференциясенә делегат итеп А. И. Догадовны да шундый ук акча хисабына җибәргәннәр. Патша жандармнары һәм полицейскилары берннди хәйлә белән дә большевистик подполье оештырган шушы эшләрнең төбенә төшә алмый кала...

«Волжский листок» газетасы саннарының берсендә тарихчыларга да, әдәбият галимнәренә дә моңарчы таныш булмаган бер хат табып, безгә куанычлы хис кичерергә насыйп булды: Сүз «Әлислах» газетасы редакциясе исеменнән язылган «Редакциягә хат» турында бара.

«Волжский листок» газетасы әлеге хатның «редакциядә уздырылган тентү вакытында конфискацияләнүе сәбәпле» бераз соңга калып басылуы хакында хәбәр итә[2]. Һәм менә бүген без үзләрен хаклы рәвештә «Әлислах»ның төп хезмәткәрләре дип санаган Ф. Әмирхан, Г. Тукай, Г. Коләхметов, В. Бәхтияров, К. Бәкер, Г. Мостафиннарның үз куллары белән язган юлларны укый алабыз.

«Бәянелхак» газетасында язышып килгән Н. Ф. Юшков атлы берәү, реакцион нашир алдында ялагайланып, революцион демократларга яла якмакчы була. Әмма, Сәйдәшев ишеләргә кушылып, «Әлислах» театрны, аның файдасын танымый, дигән уйдырманы кабатлаудан уза алмый.

Әлбәттә инде, «Әлислах» редакциясенең «төп хезмәткәрләре» үз урын-дәрәҗәләрен бик белеп, артык вакланмыйча гына, Юшков әфәнденең «дәлилләрен» сүтеп ташлыйлар, аның «тел төбен» чишәләр.

«Татар яшьләренең прогрессив-демократик өлешенә караган һәм, Юшков әфәндесенең белдерүенә капма-каршы, мөселман халкының милли театрга ихтыяҗы үсә баруын һәм аның файдасын берсүзсез таныган кешеләр буларак, без, әлбәттә, татар җәмгыятенең Сәйдәшев әфәнде газетасы хезмәт күрсәткән даирәләре хөрмәтенә дәгъва кылмадык һәм беркайчан дәгъва кылмабыз да. Без шулай ук әлеге газета хезмәткәрләренең хөрмәтенә лаек булырга да тырышмыйбыз... Татар җәмәгатьчелегенең консерватив элементлары белән мәгълүм прогрессив тенденцияләрне алга сөрүче орган булган «Әлислах» арасында инде күптән антагонизм хөкем сөрә», — дип язалар ислахчылар һәм болай дәвам иттерәләр: — «Бәянелхак» газетасын консерватив тенденцияләрне яклауда гаепләүгә каршы ни дә булса җавап итәргә хәленнән килмәгәч, Юшков әфәнде үткән елда, янәсе, «Әлислах» хезмәткәрләре ул газетаны прогрессив орган дип саныйлар иде, ә хәзер консерватив дип исәплиләр...» Хат авторлары «Әлислах»ның, хәлбуки, нибарысы биш ай яшәгәнлеген күрсәткәннән соң, Сәйдәшев әфәнденең «мактаулы» органына беркайчан да мөнәсәбәтләре булмаганлыгын» әйтеп үтәләр.

[1] Татарстан Үзәк дәүләт архивы, 199 фонд, 2332 эш, 251 кәгазь.

[2] «Волжский листок», 1908 ел, 22 февраль саны. «Редакциягә хат. Н. Ф. Юшков адресына», «Әлислах редакциясе», дип кул куелган.

«Редакциягә хат» демократлар белән милләтчеләр арасында упкын ятуын, берберсенә капма-каршы булган бу агымнарны якынайту, килештерергә тырышуның файдасыз икәнлеген күрсәтә.

«Әлислах» хезмәткәрләре менә шушы хакыйкатьне патша күзәтчеләреннән дә, беркемнән дә курыкмыйча рус һәм татар укучылары алдында ачыктан-ачык ярып салалар.

Димәк ки, без Ф. Әмирхан һәм Г. Тукайның тоткан мәсләкләрен, аларның фикер сөрешен, шул чор татар дөньясындагы идея юнәлешләренә мөнәсәбәтләрен аларның үз сүзләреннән чыгып бәяли алабыз. Әлбәттә, болар әлеге хат табылганчы ук билгеле иде. Тик шулай да ул, рус һәм татар җәмәгатьчелеге алдында революциондемократларның үз-үзләренә биргән бәясе һәм таныклыгы буларак, чиксез әһәмиятле документ. Әле бүген дә безне көндәлек эшчәнлегендә Ф. Әмирхан кискен социаль бәя бирүләрне, контрастлыкны өнәмәгән, Г. Тукай исә политик платформа эзләү белән генә мәшгуль булган дип ышандырырга тырышучы кайбер тикшеренүчеләр, шушы хат белән танышып, үзләренең хаклымы-түгелме икәнлекләрен тагын бер кат күрә алалар.

Хат ахырында авторлар сәнгать мәсьәләләрендә үзен зур белгеч санап, һавалы һәм катгый тон белән «Әлислах»ка сабак бирергә тотынган Юшков әфәндегә тиешле җавабын бирәләр. Алар татар иҗтимагый хәрәкәтләре турында дөрес фикер йөртү өчен шул халыкның тормыш-яшәешеннән, җәмәгатьчелек фикереннән хәбәрдар булырга, аның матбугатын һәм телен өйрәнергә тиешлекне искәртәләр.

Буржуазия ялчылары халыкның иң алдынгы улларына яла ягарга, аларның намусын тапларга тырышканда, татар демократларына җирле рус демократик матбугаты һәм интеллигенциясе вәкилләре, Әзербәйҗанда чыга торган «Мулла Насретдин» журналы ярдәмгә килә.

Тикшеренүләрдән ачыкланганча, рус матбугатында «Татарин-театрал» псевдонимы белән татар театры, татар һәм әзербәйҗан халыклары арасында культура бәйләнешләре, Лев Николаевич Толстой иҗаты хакында әледән-әле чыгып килгән мәкаләләрнең авторы Х. Ямашевның якын кешеләреннән берсе Р. Меликов булып чыкты[1]. Шул ук автор «Байгыш» кушаматы белән Казаннан «Мулла Насретдин»га да материаллар җибәреп торган.

«Волжский листок» газетасы «Мөселман тормышыннан» дигән даими рубрика ача, татарларның мәдәни тормышы, театр түгәрәкләре, Шәрык» клубындагы яңа спектакльләр хакында хәбәрләр бирел бара, реакцион руханилар белән прогрессив интеллигенция арасында барган көрәшне яктырта.

[1] Кара: «Волжско-Камская речь», 606 сан, 1910 ел, 7 ноябрь. Мәкалә «Татарский юбилейный спектакль» дип атала. Тагын: 1910 ел, 19 декабрь саны, «Татарская драма» дигән мәкалә.

«Болгар» номерларында, — дип яза газета, — тыйнак кына мөселман клубы урнашкан. Шапырынусыз-нисез, рекламалар чәчмичә, клуб үзенең культура эшен башкара һәм, күрәсең, ул инде мөселманнарның гына түгел, рус кешеләренең күңелен яулый килә» [1].

Каты авырудан җәфаланып, соңгы көннәрен яшәгән Г. Тукайга үзенең җәмәгать эшчәнлеге белән горурланырга мөмкин иде: алар эше торган саен киңрәк колач ала, төрле милләтләрнең прогрессив көчләре елдан-ел ныграк берләшә.

Г. Тукай шигъриятендә тәрбияләнгән, большевик Х. Ямашев тараткан идеяләрне үзләштергән яңа буын көрәшчеләр үсә. Остазларының үлеме фаҗигасе аларның бәгырен көйдереп алган һәм ул гали затларның кайберләре алдында алар халык бәхете өчен изге көрәшне дәвам иттерергә ант биргәннәр иде. Шулар арасында Советлар власте, пролетариат диктатурасы өчен кораллы көрәшкә чыккан гражданнар сугышы геройлары Камил Якуб, Хөсәен Мавлютов, Якуб Чанышев, Хәсән Ризвановлар бар.

[1] «Волжско-Камская речь», 1913 ел, 9 январь саны.

Йомгак итеп, шуны әерып әйтәсе килә: алдынгы интеллигенция вәкилләре, укучы яшьләр ул елларда сан ягыннан бик ишле булмаса да, аларның киң җәмәгатьчелеккә ясаган идея йогынтысы ифрат та көчле була. Гомерләрен бер максатка багышлаган кешеләр, алар милләтнең йөзек кашлары. Фактларны барлаудан туган тагын бер нәтиҗә шул: яшьләрнең демократик өлеше социал-демократлар ягына нык тартыла, аның рухи йогынтысын тоеп үсә, монархия һәм буржуаз милләтчелеккә каршы көрәштә ышанычлы таяныч була.

Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камал, Г. Кариев, Н. Сакаев һәм башка олы әдипләребез, сәнгать эшлеклеләребезнең гомумроссия вакыйгаларына катнашлыгы хакында, 1912 елда Прагада үткән партия конференциясенә Казаннан большевик делегатны җибәрүгә ярдәм итүләре турында сөйли торган яңадан-яңа мәгълүматлар тапканда һәм тикшергәндә хаклы рәвештә бер горурлык хисе кичерәсең.

## Укучының күңел дәфтәренә

**Осетин мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Карсыз кышны терлек үрчеми.*
*Кешегә суксаң, үзең дә саклан.*
*Кара төндә черек тә якты.*
*Зур белемдә — зур акыл.*
*Кыйнашны куркак башлый.*
*Кышкы юлга иртә чыгалар.*
*Кунак киләсе өйнең ишеге ачык була.*
*Ярты төндә таң атмый.*
*Җил биргәнне җил ала.*
*Су агып утә, ә ташлар кала.*
*Хәмер — көчле кул кебек: сукса, аяктан ега.*
*Бурычка күп алган бүре — тиресе белән түли.*
*Агач очыннан башлап кибә.*
*Озынны кыскартып була, ә кыска озынаймый.*
*Чукрак кешегә дөнья телсез.*
*Яңгырлы көн кояштан курка.*
*Яхшылыкны үлчәр өчен начар бизмән ярамый.*
*Үз маең белән үзеңне майлый.*
*Биек агачның тамыры тирән.*
*Ике дошман бер-берсенә бер мылтыктан ата алмый.*

## С. СӘЙДӘШЕВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ ТУЛУ АЛДЫННАН

# УЛ ЯУЛАГАН ҮРЛӘР

Салих Сәйдәшев Октябрь давыллары, Октябрь дулкыннары белән күтәрелеп чыккан беренче татар композиторы иде. Аның музыкасы тирән оптимизм, тормышка чиксез мәхәббәт һәм нечкә лиризм белән сугарылган. Хис-фикер байлыгы, халыкчан моң — Сәйдәшев иҗатының көчле һәм үзенчәлекле сыйфатлары асылда әнә шулар. Бу иҗатта ул татар халык музыкасына һәм профессиональ музыка сәнгатенең төп кануннарына таянды, совет чорында туган массовый җырлардан, вальслардан оста файдалана белде. Пентатоника алымнарын баету һәм киңәйтү белән бергә, ул рус һәм дөнья музыкаль культурасы куллана торган җиде авазлы музыканы (диатоника), аның мажор, минор системаларын, хроматик ярым тоннарын үзләштереп, татар музыкасын моңа чаклы күрелмәгән яңа бер баскычка күтәрде.

Дөрес, Салих Сәйдәшевка кадәр дә кайбер музыкантларыбызга рус халык көйләренең, бытовой романсларның уңай йогынтысы сизелә иде инде. Мәсәлән, Заһидулла Яруллинның «Җәмилә», Шакир Гармоньчының «Ай былбылым» кебек көйләрен күрсәтергә мөмкин. Хроматик ярым тонда яңгыравы белән татар традицион музыкасыннан шактый аерылып торсалар да ул көйләрне халык бик яратып, зур яңалык итеп каршылады. Салих Сәйдәшев та халык музыкантларының әнә шушы тәҗрибәсенә таянды. Рус революцион җырларына хас ритм байлыгы, күңел күтәренкелеге кебек уңай сыйфатларны татар музыкасына алып килүе аның иҗатын яңа аһәңнәр һәм яңа эчтәлек белән баетырга ярдәм итте. Композитор яңа чор сулышын, илебезнең, халкыбызның якты киләчәген музыка теле белән дөрес чагылдыруга ирешә.

Композиторның төп чыгышы — Дөбъяз районының Әбрә авылыннан. Аның әтисе Җамалетдин абзый бик яшьли «бәхет кошы» эзләп Казанга килә, байга эшкә керә. Әмма авыр хезмәт ныгып җитмәгән баланың сәламәтлеген нык какшата. Кырык яшенә җиткәндә ул кинәт кенә үлеп тә китә. Ялгыз башы калган хатыны Мәхүпҗамал апа, бу фаҗигале вакыйгадан соң ике атна үтүгә дөньяга бер ир бала китерә. Аңа Салих дип исем бирәләр. Салих кечкенәдән атасына охшап, җыр-музыка яратучы һәм эшчән бала булып үсә.

Ул заманнарда һәр яз саен Казанның ике Бистә арасын су баса торган булган. Шунда яшьләр көймәдә йөргәннәр. Торган йортлары Кабан күле кырында булганлыктан, бу күренешләрне Салих ел саен кызыгып күзәтә. Кичке кояш нурлары төшкән су өстендә яңгыраган моңлы көйләр нечкә хисле баланың күңеленә нык кереп урнашалар, тирән мәхәббәт уяталар. Аның да әтисе шикелле шәп гармунчы буласы һәм үзенең хис-тәләкләрен музыка белән белдерәсе килә. Ул бик кечкенәдән кулына гармун ала, үзләреннән үзләре уйныйбыз дип торган бармаклар шул чорда киң таралган «Баламишкин», «Тәзкирә» көйләрен эзләп таба. Күп тә үтми, Салих инде кечкенә музыкант булып күрше-тирәнең теленә керә башлый. Малайның зур сәләтен күреп, Әминә апасы белән җизнәсе Шиһаб Әхмәров[1] аны һәм әнисен үзләрендә тәрбияләргә алалар. Салихка җизнәсе бер иске пианино сатып ала. Үзлегеннән генә уйнап маташкан балага өйрәтүче кирәклеге көн кебек ачыклана. Беренче татар халык музыкантларыннан берсе Заһидулла ага Яруллин Салихка дәресләр бирә башлый. Яруллин ул чорда «Шәрык» клубы каршындагы инструменталь ансамбль белән җитәкчелек итә.

[1] Ш. Әхмәров үз заманының мәгърифәтле кешеләреннән берсе, Тукайның дусты.

Шиһаб Әхмәров үзе белән бергә «Шәрык» клубына Салихны да алып килгәләгән. Салих бу ансамбльнең чыгышларын зур ихлас белән тыңлый һәм шул арада үзе шикелле үк музыка яратучы Мансур[1] исемле бер нәни иптәш тә таба. Ул да Салих шикелле ятим калып, җиһазсендә тәрбияләнә икән. Үсмерләр бик тә тиз дуслашалар. Клубтан чыккач Салихларга кайтып, берсе гармунда, икенчесе пианинода уйнап, «ансамбльләрен» оештыралар.

Яшь Салихның музыкага мәхәббәте шулкадәр көчле була, хәтта ул яраткан велосипедын сатып, өйдәгеләргә сиздермичә генә, профессор Радзеевич өенә фортепиано буенча дәресләр алырга йөри башлый һәм тиз арада зур уңышларга ирешә. Фортепианода матур уйнавы, рус классларына укырга йөрүе 14 яшенә җиткәндә аңарга Казан музыка мәктәбенә керү мөмкинлеге бирә. Сәйдәшев бөтен дәртен, күңелен биреп укый. Нәтиҗәдә 1915 нче елны «Шәрык» клубы каршындагы инструменталь ансамбльгә пианист булып эшкә керә. 1911—1916 елларда «Сәйяр»да пианист булып эшләү дәверендә Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Кариевлар белән еш очрашу, соңрак татар мәдәниятының алдынгы вәкилләре белән бергә эшләү, һәрвакыт алар белән тыгыз бәйләнештә булу аңарда, художникның халык каршындагы зур бурычы, гомумән, сәнгатьнең җәмгыять алдындагы изге миссиясе турында ачык караш тәрбияли.

Беренче бөтендөнья сугышы башланып китү сәбәпле Салихның укуы бүленеп кала. Ләкин ул музыканы ташламый, үзлегеннән укуын дәвам итә. 18 яшьлек егет революциянең беренче көннәрендә үк Казанда яңа ачылган «Коммунистлар» клубында кыллы оркестр оештыра. Бу оркестр татар музыка сәнгатендә моңа кадәрле күрелмәгән рәвештә күп тавышлы итеп төзелә.

1919 нчы елны Гражданнар сугышы кискен төс ала башлагач, Салих үзе теләп фронтка китә һәм Көнчыгыш фронт гаскәрләре белән Бохарага чаклы барып җитә. Шунда йөргәндә үзенең «Озын сәфәр» исемле беренче әсәрен иҗат итә. Ул көйне җырлап кызыл сугышчылар дошманга каршы көрәшкә барганнар. Салих армия сафында да оркестр оештыра, аңа җитәкчелек итә һәм үзе трубачы булып катнаша.

Билгеле булганча, Төркестан фронты хәрбиләре Оренбургка кайтып озак вакыт тора. Сәйдәшев бу очрактан файдаланып, яңа ачылган музыка мәктәбе укытучысы Балашовтан труба буенча, Петроградтан килгән укытучы Генальскаядан фортепиано һәм теория дәресләре ала. Яшь кызылармеец Салих болардан тыш Оренбург шәһәренең көндәлек культура эшендә дә актив катнаша: музыка түгәрәкләре оештыра, концертларда дирижер һәм концертмейстер була. Генальская Петроградка кайтып киткәч, аның урынына педагог итеп Сәйдәшевны калдыралар.

1922 нче елның язында армия хезмәтеннән демобилизацияләнгәч, аны Оренбургның «Шәрык» музыка мәктәбенә директор итеп куялар. Салих Сәйдәшев инициативасы белән мәктәптә тынлы музыка кораллары бүлеге ачыла, тынлы оркестр өчен ул үзе репертуар хәзерли. Шунда фортепиано өчен беренче вальсын яза. Директорлыктан тыш педагог, дирижер һәм концертмейстер булып та эшли. Озак та үтми, Казанда яңа гына оештырылган «Кызыл Октябрь» Татар дәүләт драма театрының директоры Кәрим Тинчурин Сәйдәшевны музыка бүлеге мөдире итеп эшкә чакыра һәм иҗат дәрте белән янучы яшь егет 1922 нче елның декабрендә Казанга кайта. К. Тинчурин белән С. Сәйдәшев арасында зур иҗади дуслык дәвере башлана. Композитор иҗатының гөрләп чәчәк аткан чоры да нәкъ менә шушы елларга туры килә. Мәсәлән, 1923—1932 елларда татар сәхнәсендә аның музыкасы белән «Башмагым», «Казан сөлгесе», «Хан кызы», «Галир тәңкә», «Урал суы буенда», «Сүнгән йолдызлар», «Таһир-Зөһрә», «Яшь йөрәкләр», «Балдызкай», «Зәңгәр шәл», «Асылъяр», «Күмелгән кораллар», «Дим буенда», «Күк күгәрчен», «Ил», «Шлем», «Данлы чор», «Камил», «Кандыр буе», «Ашказар», «Наемщик» һ. б., кыскасы, кырыкка якын спектакль куела.

Дөрес, татар спектакльләрендә музыка 1915 елларда ук яңгырый башлый. Ләкин анда әле җыр-көй эпизодик төстә генә катнаша. Ә музыкаль драма жанры өчен музыканы сәхнәдә киң куллану характерлы.

Театрда музыка бүлеге мөдире һәм дирижер булып Сәйдәшев эшләгәндә исә музыка спектакльнең органик бер өлешенә — аның эчтәлеген ачуда, идеясен билгеләүдә катнашучы төп компонентларның берсенә әверелә. Театрда оркестр, хор оештырыла,

[1] Соңыннан атаклы композитор булып танылачак Мансур Мозаффаров.

жырчылар булдыру көн тәртибенә куела. Шул чорда Рокыя Кушловская, Сара Садыйкова, Мәрьям Рахманкулова, Галия Кайбицкая, Асия Измайлова,Ситдыйк Айдаров, Фәхри Маннапов, Әхәт Хисамов кебек беренче татар сәхнә жырчылары, талантлы музыкантлар сәхнәгә күтәрелә. Шул елларны Сәйдәшев житәкчелегендәге оркестрда эшләгән рус музыканты Друтин болай яза: «Аның музыкасының тәэсире шул чаклы көчле иде ки, драматурглар үзләренең пьесаларын Сәйдәшев музыкасына ышанып язалар иде. Чыннан да, театр сәхнәсеннән яңа гына ишеткән көйләрне яшьләр урам тутырып жырлап кайта торган булды... Сәйдәшев жырчыларның тавыш мөмкинлекләрен дә, оркестрдагы инструментларны да яхшы белә иде. Шуның өстенә ишетү сәләте бик әйбәт, музыкаль хәтере дә искиткеч шәп. Ул еш кына концертларда партитурасыз дирижерлык итә иде...»

Татар дәүләт драма театры эшли башлагач, «Сәйяр» труппасыннан калган традиция буенча, артистлар өчен ял кичәсе оештырыла. Шул кичәдә Фәтхи Бурнаш үзенең моңлы, матур тавышы белән «Казан сөлгесе»н жырлый. Кәрим Тинчурин шул моңлы, самими жырлардан илһамланып, биш көн үтүгә, яңа гына язылып беткән «Казан сөлгесе» пьесасын Сәйдәшевның өстәленә куя. «Казан сөлгесе» сәхнәдә зур уңыш белән куела башлый. С. Сәйдәшев үзенең иң беренче эше булган «Башмагым» комедиясе өчен халык көйләрен генә эшкәртә. «Казан сөлгесе» спектаклен татар музыкасында моңа чаклы күренмәгән дуэт, трио, увертюра һәм балет музыкасы белән баета.

1925 нче елны куелган «Зәңгәр шәл» драмасына язылган көйләрне халык беренче тыңлаганда ук яратып кабул итә. «Зәңгәр шәл» көе пьесада Мәйсәрә белән Булатның мәхәббәт темасы булып яңгырый: увертюрада һәм спектакльнең барлык лирик күренешләрендә кабатланып, әсәрнең лейтмотивына әверелә. Композитор халык көйләреннән дә оста файдалана. Алар сәхнәдәге вакыйгалар белән бик тыгыз бәйләнештә ачылалар. Болардан тыш күп кенә яңа көйләр дә иҗат ителгән. Мәсәлән, соңгы пәрдәдәге «Кара урман» көе шул чаклы образлы язылган, аның тирән, мәһабәт яңгырашлы беренче аккордлары белән үк күз алдыңа иксез-чиксез кара урман килеп баса. Ирек даулаучы качкыннарны үзенә сыендырган кара урман туган ил образын гәүдәләндерә. Бу жырның оркестр өчен партитурасы да бик уңышлы язылган: Салих Сәйдәшев катлаулы гармонизацияләр белән мавыкмый һәм формалистик тенденцияләр дә аңа ят. Биредә инде без лейтмотив, увертюра һ. б. кебек операга хас компонентлар белән дә очрашабыз. Әнә шул рәвешле гражданлык мотивы, халыкның яңа тормыш өчен көрәше музыкада да бик дөрес чагылыш тапкан.

К. Тинчуринның «Ил» музыкаль драмасы (1927) музыкага тагын да баерак. Вакыйгалар С. Сәйдәшев язган оригинал көйләр, биюләр белән бәйләнештә бирелә.

Еллар үтү белән, композиторның иҗат активлыгы да үсә, ул яңа үрләр яулый. 1928 елны Таҗи Гыйззәт белән иҗади дуслыкта язылган «Наемщик» пьесасы да образлы һәм тирән мәгънәле музыка геройларының характерларын, эчке тойгыларын ачуга ярдәм итә. Без халыкның кайгы-хәсрәтен, көрәшкә булган ихтыярын, җиңелмәс рухи көчен тоябыз. Мәсәлән, беренче пәрдәдәге кол крестьяннар хоры. Талгын, тигез аккордлар белән актив ритмда язылган бу көйдә халык өстенә төшкән кайгы-хәсрәт авазы яңгырый, ләкин ул төшенкелек белән түгел, ә халыкның бердәмлек хисләре белән өретелгән. Һәм шушы көй финалда — крепостнойлар восстаниегә күтәрелгән чагында яңадан яңгырап уза: баштагы темага бөтенләй капма-каршы булып, ачык колоритлы яшь егетләр, яшь кызлар темасы яңгырый. Анда халыкның тормышка булган кайнар мәхәббәте, көчле оптимизм, күңел күтәренкелеге, шаянлыгы, зирәклеге ачыла. Батырҗан арияләре, халык хорлары зур ихтыяр көче, кискен революцион тойгылар белән сугарылган. Татар халык көйләренә хас форма һәм ритм үзенчәлекләрен иҗади гомумиләштерүнең гүзәл мисалын без Гөлйөземнең беренче ариясендә күрәбез. Ул ариядә озын көйләрдәге киңлек, хис тирәнлеге, кыска көйләрдәге ритмик импульс бик табигый берелгән. Үзенең музыкаль драматургиясе белән операга бик якын бу әсәрдә композиторның иҗаты яңа югары баскычка күтәрелә.

Кандыр елгасы буенда Татарстанда беренче колхоз электростанциясе салына башлагач, Салих Сәйдәшев белән Кәрим Тинчурин велосипедларга утырып төзелешне карарга баралар. Шул тәэсирләр жирлегендә «Кандыр буе» (1932) музыкаль пьесасы иҗат ителә. Композитор бу әсәре өчен илдәге бөек төзелешләргә, совет кешеләре-

нең якты язмышына дан җыры булырдай яңа интонацияләр эзли. Ул дүрт көн эчендә 20 гә якын көй яза. Ачык, саф яңгырашлы, кыю, үткен ритмлы әлеге көйләр пьесага киң пафос һәм тантаналы күтәренкелек бирә. Аларның байтагы, заман үтү белән, мөстәкыйль җыр булып яши башлыйлар. Сәйдәшев үз иҗатында халык көйләрен турыдан-туры файдаланмады диярлек. Аның әсәрләрендә халык көйләренә якынлык, халык традицияләренә таяну һәрвакыт дөнья классик музыка алымнары белән бергә үрелеп бара. Салих Сәйдәшевның инструменталь музыка өлкәсендәге хезмәте дә татар совет сәнгатенә зур хәзинә булып керде. Музыкаль теленең демократик, форма ягыннан гади булуы композиторга инструменталь әсәрләрен халык арасында тиз һәм җиңел популярлаштырырга ярдәм итте.

Кызыл Армиянең ун еллыгына багышлап язылган «Кызыл Армия» маршы (хәзерге «Совет Армиясе маршы»), мәсәлән, художество кыйммәте һәм профессиональ югарылыгы ягыннан, композиторның иң яхшы әсәрләреннән берсе булып исәпләнә.

1932 елны Кызыл мәйдандагы Беренче Май парады Салих Сәйдәшевның шушы маршы белән башланып киткән иде. Бу әсәр өчен композиторга Ворошиловтан бүләк итеп язулы алтын сәгать һәм почетлы кызылармеец исеме бирелә.

Сәйдәшевның инструменталь әсәрләре һәм алардагы халык көйләре симфоник оркестрда беренче тапкыр башкарганда ук аларда озын һәм кыска көйләрне контраст итеп кую, матур гармонизацияләр белән бизәү, төрле музыка коралларының тавыш тембрларын уңышлы куллану — шуларның барысы да татар тыңлаучысы өчен яңа матур яңгыраш бирде. «Галиябану» драмасына увертюрада, мәсәлән, дәртле, күтәренке рухтагы беренче кисәк аллегреттодан соң бик ягымлы — йомшак «Галиябану» көе яңгырый һәм әсәр халык көйләренә авааздаш бию көе белән тәмамлана.

1941 елны Мәскәүдә үткәреләсе Декада программасына Салих Сәйдәшевның «Наемщик» операсы да кертелә. Бу турыда композитор үзе 1940 елның 10 октябрендә «Красная Татария» газетасында болай дип яза: «Операны мин июньдә яза башладым. Бүгенге көнне беренче акт клавирда әзер инде. Бернничә көннән икенче акты да әзер булачак, чөнки финалын гына язасы калды... 1941 елның беренче январена операның клавирын тулысы белән театрга тапшырырмын дип уйлыйм... Рус һәм Европа классик операларының иң яхшы традицияләре татар музыкаль теленең үзенчәлеге белән матур, табигый бәйләнештә булган әсәр язасым килә...» Кызганычка каршы, сугыш башлану белән бу эш өзелеп кала.

Гомеренең соңгы елларында С. Сәйдәшев «Юлбашчы турында җыр», «Комсомолка Халисә», «Яшьлек җырым син», «Чишмә буенда» кебек матур көйләр иҗат итте. Аның соңгы әсәре ничектер символик: ул Муса Җәлил сүзләренә «Җырларым»ны язды.

Салих Сәйдәшев — беренче татар дирижеры да. Аның дирижерлык эше Кызыл Армия сафларында башлана, ә соңыннан Татар дәүләт академия театрында һәм концерт залларында дәвам итә. Ленинград консерваториясен тәмамлаган музыка остасы, Татарстанның халык артисты Ильяс ага Әүхәдиев әйткәнчә, «ул оркестрның тигез, чиста, матур яңгырашына күп санлы репетицияләр ярдәмендә генә түгел, ә бәлки музыкага булган тирән хисе, мәхәббәте, сизгерлеге белән ирешә.

...Ул оста пианист та иде. Аның уйнавы бәрхеттәй йомшак, көй — матур агышлы, төрле нюансларга бай, техникасы искиткеч пөхтә. Салих уйнаганда фортепиано ничектер үзеннән-үзе җырлыйдыр сыман тоела иде».

Кыскасы, халыкны төрле жанрда язылган музыкаль әсәрләр тыңларга да оста өйрәтте, аларның музыкага мәхәббәтен тәрбияләүдә дә актив катнашты. Композитор үзенең иҗаты белән тормышның алгы сызыгында, көрәшчеләр белән бер сафта булды.

Салих Сәйдәшевны соңгы юлына озатканда Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Ширияздан Сарымсаков: «Безнең татар халкында талантлар бик күп. Ләкин халыкның йөрәгенә үтеп керү, аның тирән мәхәббәтен казану Сәйдәш шикелле сирәк талантларга гына бирелә»,— дигән иде.

Әйе, Сәйдәшев иҗаты — ул безнең тормышка мәхәббәтебез, Сәйдәшев музыкасы — ул безнең бүгенге көнебез. Аның исеме һәркайда һәм һәркайчан тирән ихтирам, зур мәхәббәт белән искә алына һәм алыныр.

Фатыйма **ВӘЛИЕВА**.

*Александр Блок*

## СКИФЛАР

Сез — мильоннар. Без — дөм урман, урман...
Кайда безне җиңәр бәдәннәр?!
Без — скифлар, әйе, азиатлар!
Кысык, комсыз күзле адәмнәр.

Сезнең гасыр — безгә сәгать кенә...
Ялчылардай күндәм булган без.
Европаны монгол расасыннан
Калкан сыман каплап торганбыз.

Гасырларны кичкән карт быргыгыз
Күкрәүләрне басып масайган.
Әкият булган сезгә, хур ителгәч
Җимерелеп Мессина һәм Лиссабон.

Җыеп, эретеп безнең энҗеләрне,
Мәшрикъка сез һаман күз текkән.
Туп авызын төскәп ачар мәлне
Сез көлешә-көлешә гел көткән!

Җитте вакыт! Канат җилпеп Афәт
Кара рәнҗеш өрә тиктомал.
Тик килер көн — сезнең Пестумнарның
Эзләре дә калмас, ихтимал.

И карт дөнья! Талчыкканда татлы
Газапта син, уй да кирәктер:
Табышмаклы Сфинкс эргәсендә
Эдип сыман туктал, зирәк бул.

Россия — Сфинкс. Шаулап, моңаеп кайчак
Йөзсә дә ул каннар эчендә,
Мәхәббәт һәм кара нәфрәт белән
Карый, карый, карый ул сиңа.

Әйе, сездә булмаганча күптән,
Шулай сөя белә безнең җан.
Көйдерә дә, үтерә дә торган
Сөю барын сез бит оныткан!

Без сөябез салкын сан утын да,
Ялкын бизәген дә — һәммәсен.
Чәнечкеле галл сүзе дә, кырыс
Герман даһие да яшәсен.

Хәтерлибез Париж тәмугларын,
Венециянең җиләс тынлыгын,
Ерак лимон куаклары исен,
Һәм төтенле Кельн зурлыгын.

Тән сөябез — тәмен аның, төсен,
Тончыктыргыч ис тә сирпе әйдә...
Ләкин авыр, назлы кулыбыз кочып
Умырткагыз сынса — бигайбә.

Күнеккән без: чапкан атларны да
Тиз тыябыз тотып — куллар нык.
Сындырабыз кайчак очаларын,
Иярлибез кире колларны.

Килегез безгә! Сугыш дәһшәтеннән
Кочакларыбыз шәбрәк — белегез.
Соң түгел һич, кынына керсен кылыч,
Иптәш, туган булыйк — килегез!

Килмәсәгез, берни югалтмабыз...
Бездән соңгы, чирле токымнар,
Явызлыкка безне этәрсәгез,
Йөз гасырлар ләгънәт укырлар.

Ерак түгел купшы Европагыз —
Чыгып караурманнар аша без,
Азиат битебезне сезгә ачып,
Каршыгызга тезелеп басарбыз.

Килегез Уралга сез. Кыргый монгол
Ордалары сыман, интеграл
Сулыш алган төштә, сугыш өчен
Мәйдан арчый мотор... Карт Урал!

Ә үзебез — инде калкан түгел,
Хак татыгыз төмен яуларның.
Кысык күзләребез күзәтер тик
Үлем сугышы ничек кайнавын.

Селкенмәбез — анда кансыз һуннар
Мәет кесәләрен тентесә,
Кала яндырганда, чиркәүләрдә
Ак туганнар итен пешерсә.

Соңгы кабат — һушыңа кил, карт дөнья! —
Дошманлыктан хезмәт туена уз.
Соңгы кабат туганлыкка дәшә
Варвар суры — безнең лирабыз!

*1918*

ӘХСӘН БАЯНОВ *тәрҗемәсе.*

# АВИАТОР

Корыч кошка кеше бирде ирек,
Ул, селкетеп ике канатын,
Диңгез пәрие суга кергән кебек,
Һава дулкыннарын таратты.

Пропеллер чыңлый кыл шикелле,
Күр: очучы белми куркуны.
Күкне бораулаган очыш белән
Ул кояшка таба омтылды.

Инде акыл җитмәс биеклектә
Балкый двигатель бакыры.
Шуннан чак-чак кына ишетелә
Пропеллерның ялгызак җыры.

Аннан — күзләр юкка эзләнәләр —
Күктә эзе дә юк, юлы да.
Саф су кебек һава аяз, зәңгәр —
Бинокльдә фәкать шул гына.

Аста рәшә дулкынланып тора,
Болын өстенә сөрем оешкан.
Ангарлар, кешеләр — бар да болар
Җирнекеләр, җиргә елышкан.

Менә тагын нурлар томанында
Җирдә булмаганча бер аккорд.
Якыная ул, кул чабалар монда.
Тагын да бер кызганыч рекорд.

Канатлары белән җилеп-җилеп,
Һава ярып төшә нур аша.
Менә кинәт йөрәкләрне телеп
Ямьсез шыксыз тынлык урнаша.

Тынган пропеллерлы җансыз җәнлек
Асылынып тора — аяныч.
Үзенең тоныкланган күзе белән
Буш һавада эзли таяныч.

Юк, соң хәзер, болын үләнендә
Ватыклары ята ялтырап.
Очучы кулы рычаг тимерендә
Бар җансыздан монда җансызрак.

Батыр, нигә күккә омтылдың син
Беренче һәм соңгы мәртәбә?
Бер аксөяк фахишәнең күзе
Юнәлсен дипме тик сиңа таба?

Әллә татыдыңмы үз-үзеңне
Онытуның шомлы ләззәтен,
Шашып теләдеңме егылуны
Һәм туктаттың очкычың винтын?

Әллә килер сугышлар күренеше
Агу булып керде миеңә?
Кара төндә җиргә үлем илтер
Очкыч чагылдымы күзеңә?..

*1910 — январь, 1912*

**ӘНВӘР ДАВЫДОВ** *тәрҗемәсе.*

# ЕЛЛАР ЯКТЫСЫ

*Эдуард Касыймовка 50 яшь*



Елларны, чорларны кеше яктырта. Үзенең мөкатдәс эше белән җирдә якты эз калдыра ул. Киләчәккә ядкарь итеп һәйкәлләр, гөлбакчалар, яңа шәһәрләр, заводлар төзеп калдыра... Еллар үткәч, килер буын әнә шул хикмәтле «җимешләрнең» нәтиҗәсен — тулы канлы матурлыгын, камиллеген генә күрә ала. Ә шул матурлыкның эшләнү, туу процессын фәкать фараз гына итеп карый. Язучы шушы процессны һәм күңелләр диалектикасын образлы тел белән, сәнгатьчә тасвирлап бирә. Ул укучысы алдына үткен проблемалар куя, яшәешебездәге берсеннән-берсе катлаулырак булган мәсьәләләрне теге яки бу дәрәҗәдә хәл итәргә омтыла, укучыны шулар хакында бергәләп уйланып карарга чакыра. Әдәби әсәр күңелләрне сафлык, яктылык дөньясына дәшә, туган җиребезнең, табигатьнең чын хуҗасы булып яшәргә, аны кадерләргә, «телен өйрәнергә» өнди...

Эдуард Касыймов үзенең хикәя-повестьлары, романнары белән әнә шундый язучы буларак хәтергә уелган. Аның геройлары — гади эшчеләр, инженерлар, авыл кешеләре, хискә бирелүчән, кайнар йөрәкле яшьләр, акыл һәм тәҗрибә туплаган өлкәннәр. Алар конкрет кешеләр булып безнең тирә-юнебездә яши, безнең белән бергәләп елмая, көлә, елый. Аларның уйланулары, борчылулары, шатлык-сагышлары, көндәлек мәшәкатьләре безгә дә һич ят түгел.

Димәк, автор чын мәгънәсендә тормышчан образлар тудыра алган. Алар ышандыра, борчуларга сала. Чөнки язучы әлеге образларны күктән эзләмәгән, ә бәлки тормышның үзеннән детальләп җыйган, чынбарлыктан тапкан.

Э. Касыймов «Татар халык әкиятләрендә сатира һәм юмор» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклаганнан соң, башта Алабугада, аннары Чаллы шәһәрендә яши, язылачы китапларының геройларын — борынгы Чулман-Кама, Бондюг химия заводы һәм КамАЗ кешеләрен якыннан торып өйрәнә.

Аның беренче хикәяләре, очерклары 1950—1951 елларда вакытлы матбугат битләрендә күренә башлады. Тәүге уңышлар яшь авторны яңа хикәяләр, повестьлар язарга җилкендерде. «Кызыл маяклар» (1959), «Кояш көн дә чыга» (1963) кебек китаплары дөнья күрде. Э. Касыймов әсәрләре укучы күңелен торган саен ныграк били барды, әдәби тәнкыйть әдәбиятка өметле прозаик килүен билгеләп узды.

Ләкин шулай да язучыга чын уңыш китергән әсәре тирән эмоциональ көчкә ия булган «Гомер ике килми» романы булды. Роман геройлары — партия әшенә искиткеч тугрылыклы коммунистның балалары. Тормыш аларны төрле катлаулы хәл-әхвәлләргә куеп, төрлечә сынап, чын кешелеген тикшереп карый. Ләкин яңа тормыш төзергә килгән, изге максат һәм хыяллар белән рухланып яшәгән яшьләрнең канатын сындыра алмый язмыш. Алар ныклы адымнар белән, иманнарын какшатмыйча, этиләре юлын дәвам итәләр.

Э. Касыймов нинди генә темага алынмасын, аның әсәрләрендә кеше, кеше күңеле якты фонда алгы планга килеп баса. Авыл яшьләре («Кояш көн дә чыга») яки фән кешеләре («Сорбонна профессоры һәм без») турында язамы ул, Бондюгтагы химия заводын, андагы характерларны тасвирлыймы, — һәрвакыт шәхес, аның кичерешләре, хыял-уйлары калку сурәтләнә.

Соңгы вакытта әдәбиятта завод-фабрикалар, производство коллективлары тормышына игътибар бермә-бер үсте. Э. Касыймов әнә шундый мактауга лаек эшкә алтмышынчы елларда ук алынды. Аны үзенең бай тарихы, данлы үткәне, матур традицияләре белән аерылып торган Бондюг заводы үзенә тартты. Республикабызда химия промышленносте көннән-көн үсеп, аның халык хуҗалыгындагы башка тармаклар һәм өлкәләр белән бәйләнешы шактый ныгып килгән чор иде бу.

Билгеле, әдип Бондюг заводы тарихын язуны максат итеп куймады, ул «Томан аша» һәм «Һаваларда тургай» дип исемләнгән романнарында заводның бүгенгесен сурәтләде. Ләкин шунысын да әйтергә кирәк, бу романнарны укыганда, заводның ерак үткәне, Менделеев эшчәнлеге белән бәйле чорлар да шактый ачык күзаллана. Әлеге романнарда тарих белән бүгенге көннең бәйләнеше өлкәннәр, хезмәт ветераннары белән яшь буын арасындагы мөнәсәбәтләрдә, геройларның гыйбрәтле язмышларында чагыла. Әсәрләрдәге геройларга хас шундый төп сыйфатларны атап үтәргә мөмкин: нәселдән-нәселгә күчә килгән эшче горурлыгы, беренче нәүбәттә завод мохитындагы хәл-әхвәлләрне кайгырту, аның мәнфәгатьләре белән яшәү, тормышның, хәятның олылыгын, изгелеген эшкә мөнәсәбәт белән үлчәп карау.

«Һаваларда тургай» әсәрен «Томан аша» романының дәвамы дип әйтергә дә мөмкин. Әлбәттә, без монда яңа персонажлар белән дә танышабыз, шул ук вакытта, үзебез яратып өлгергән геройлар белән дә кабат очрашабыз. Әмма яңа әсәрдә тормыш хәлләре инде үзгәргән, ягъни тагын да куера, кискенләшә төшкән. Шуңа күрә беренче романдагы танышларыбыз яңачарак шартларда хәрәкәт итәләр, яңа хыяллар белән янып яшиләр. Нәтиҗәдә «Һаваларда тургай» романы мөстәкыйль әсәр төсен алган.

Язучының «Чулман — оныклар елгасы» романы художество эшләнеше буенча да, күтәргән мәсьәләләре белән дә чын мәгънәсендә игътибарга лаек. Ул, республика чикләрен узып, ил күләмендә яңгыраш тапкан әсәр. Укучы аны көтеп алган китабы итеп, яратып каршылады.

Э. Касыймов җырларда җырлангач бөек төзелешләр шәһәре Чаллыда яши, дидек. Зурлыгы һәм әһәмияте белән бөтен дөньяда мәшһүр урыннарның берсен тоткан завод эшчеләрен көн дә күреп, алар белән сөйләшеп тора. Заводның искиткеч зур проблемалары, кешелек алдына заман куйган олы бурычлар үзәгендә кайный ул. Әнә шул мәсьәләләрнең асылын төптән актарып, эзләнеп һәм табып иҗат итә.

КамАЗ — республикабыз өчен яңа төр завод. Ул зурлыгы, бөеклеге белән генә түгел, яңалыгы белән дә кешеләр күңелендә яңа киңлекләр тудырды. Димәк, иҗат кешесенә дә яңа эзләнүләр өчен мәйдан, яңа мөмкинлекләр ачылды. Һәм мондый төбәктә үз язучың булу үзе бер бәхеттер әле ул. Шуңа күрә дә укучы аңардан күп-не өмет итә, күпне көтә, җиң сызганып эшләр вакыты җиткән әдипкә яңадан-яңа иҗади уңышлар тели.

**ФӘННУР САФИН.**

Лирон Хәмидуллин

# ЧЫҢГЫЗ ТАУЛАРЫНЫҢ БӨРКЕТЕ

Мохтар Әүезов... Күп милләтле совет әдәбияты күгендәге якты йолдызларның берсе. СССР Дәүләт һәм Ленин премияләренә лаек булган әдип тә, төрки әдәбиятлары тарихының күренекле белгече, академик дәрәҗәсенә ирешкән галим дә иде ул. Чорыбызның танылган җәмәгать эшлеклесе—СССРның Тынычлыкны яклау комитеты члены, СССР Ленин премияләре комитетының эшлекле бер вәкиле булды. Азия һәм Африка илләре прогрессив язучыларының дуслыгын, үзара бердәмлеген ныгыту эшенә күп көч куйган зур шәхес иде. Берничә тапкыр Казагыстан ССРның Верховный Советы депутаты итеп сайланды.

Мохтар 1897 елның 28 сентябрендә казакъ даласының иң көнчыгышында, Алтай таулары итәгендә урнашкан Семипалат өлкәсе, Чыңгыз өязендә туа. Унбер яшенә чаклы авыл мәдрәсәсендә белем ала. 1908 елны атасы үлгәч, ул агасы Касыймбәк тәрбиясендә кала. Агасы шул ук көзне, туганнарының ризасызлыгына да карамастан, аны Семипалат каласындагы махсус рус мәктәбенә илтеп тапшыра. Соңыннан әдип бу хакта: Касыймбәк агам, остазы Камалетдин хәзрәт бәддогасы белән дә исәпләшеп тормастан, мәдрәсәне ташлап рус мәктәбендә белем алган. Мине дә, Чыңгыз өязе стипендиясе хисабына, шунда урнаштырды. Бу биш класслы училище җирле халыктан патша хезмәтенә яраклы толмач һәм башка төрле вак чиновниклар әзерли иде. Әлеге уку йортын тоту өчен халыктан өстәмә налог җыела. Тик халыкта ул мәктәпкә кырын караш яши, чукындыру нияте белән ачылган, дип тиргиләр. Шуңа күрә анда укучыларны мәҗбүри төстә җыялар. Кайвакытта хәтта бала атасына күпмедер «йолым да түләнә иде... Табигый, безнең бабай, улларына һәм оныкларына бирегә укырга юл куйганы өчен ырудашларыннан шелтәне аз ишетмәде»,— дип язды.

Бу училищены уңышлы тәмамлаганнан соң да Мохтар укуын дәвам иттерергә уйлый. Семипалаттагы укытучылар семинариясенә керә һәм аны 1919 ел башында тәгәлләп чыга.

1919 ел. Бөтен ил язмышында, бигрәк тә Дала тормышында аеруча авыр чак бу. Тескә борылышлар чоры. Урта Азиянең күп өлешендә әле контрреволюцион «Төркстан автономияле республикасы» хакимлек итә. Семипалатта шулай ук контрреволюцион Алаш Урдачылар, төрле атаманнар, ак гвардиячеләр белән тәхет алмаша-алмаша, җирле халыкка баш булырга теләп карыйлар. Әмма инде ирек, азатлык, революция төшенчәләрен аңлап, үз күргән халык аларга иярми. Губернада Совет власте өстен чыга.

Менә шушы бик катлаулы көннәрдә— авылларда әле тулаем байлар һәм ыру башлыклары хөкемлек иткән, яңалык алып килүчеләргә төрлечә каршылык күрсәтеп торган бер заманда яшь Мохтар Әүезов, шул дәвердә аякка баскан казакъ интеллигенциясенең башка күренекле вәкилләре Сәкен Сәйфуллин, Сабир Шәрипов, Баимбәт Майлин һ. б. бик күпләр кебек, хөррият өчен, революция өчен барган көрәшнең алгы сафында була.

«Шәһәрдә укып кайткач, дала тормышының иске гореф гадәтләре, сыйнфый тиңсезлекләр, хатын-кызга карата җәбер золым күзгә тагын да ташлана төшә иде... Артта калган тормышның шушы караңгы яклары әле шул кадәр көчле булып, Казагыстанда Совет власте урнаштырылгач та җәмәгатьчелеккә, кешенең хокукына карата борын заманнан ук килгән караш, гадәт һәм шәригать кануннарына ябышып ятучы байлар, ыру башлыклары белән нык көрәшергә туры килде»,—дип искә алды әдип ул елларны.

Революциянең беренче көннәреннән үк ул актив җәмәгать эшлеклесе, беренче Совет учреждениеләренең хезмәткәре. Егерме яшен әле генә тутырган Мохтарны Семипалат губерна Советы башкарма комитетына җаваплы эшкә билгелиләр. Бик хәтәр вакытлар булуына да карамастан, ул, өяздән-өязгә, авылдан-авылга йөреп, яңаның искене җиңүенә булыша, оештыру эшләре алып бара. Шушы көрәш елларында аның язучылык таланты да ачыла. Авыл тормышын кискен дөреслеге белән тасвирлаган беренче хикәяләре языла.

Аның күңел тетрәткеч вакыйгага корылган «Ятимә язмышы» хикәясе (1921) күп еллар буе казакъ хикәясенең асыл үрнәге сыйфатында төрле җыентык һәм хрестоматияләргә кертелә. Шуннан соң аның искелекне, торгынлыкны фаш иткән, казакъ халкының элекке авыр язмышын һәм якты, яңага омтылышын сурәтләүгә багышланган «Өйләнү», «Барымта», «Батыр кабере янында», «Сары ерткыч», «Көчләү», «Ятим» һ. б. хикәяләре бер-бер артлы дөнья күрә.

М. Әуезов үзенең беренче әсәрләреннән булган «Енлик-Кебек» исемле шигъри драмасын һәвәскәр башкаручылар көче белән сәхнәләштерү бәхетенә ирешә. Трагик эчтәлекле бу әсәр нигезендә казакъ һәм башка төрки халыкларының борынгы дастаннарына ияреп, шуларга охшатып иҗат ителә. Пьесаның төп геройлары Кебек батыр белән Енлик, мәгълүм Козы-Көрпеш һәм Баян-сылу, Айман белән Чулпаннар кебек, феодализмның традицион каршылыкларына, хатын-кызның хокуксызлыгына риза булып яшәмәүләрен белдерә һәм һәлак булалар. Шулай итеп әсәр, борынгы дастан алымында язылып та, Мохтар яшәгән көннәрнең көрәш рухын чагылдырган әсәр булып кабул ителә. Һәм биредә инде традицион шәрык әдәби мирасының гына түгел, бәлки алдынгы рус әдәбиятының да яшь әдипкә йогынтысын чамаларга була. Тора-бара М. Әуезовның бу ике зур мирасны — урта гасырларда чәчәк аткан шәрык мәдәнияты белән соңгы йөз еллыкларда көч алган Европа культурасын бик яхшы өйрәнеп, үзләштереп, үз иҗатында бик белеп файдалануын, аларны үстерүен Вс. Иванов, А. Фадеев, Л. Соболев, И. Андронников һәм Н. Тихонов кебек танылган әдипләр билгеләп үтәләр.

Унҗиденче ел революциясе алдыннан казакъның туып килүче яңа чор интеллигенциясе, үз араларында яшәгән алдынгы карашлы тугандаш татар халкы вәкилләре— мөгаллимнәр, писарь һәм приказчиклар белән берлектә, әдәбият-сәнгать түгәрәкләре оештыралар, төрле кичәләр уздыралар. Мондый түгәрәкләр тиздән Троицк, Оренбург, Уральск, Кустанай, Петропавел кебек «юл чатындарак» урнашкан шәһәрләрдә барлыкка килә. Мохтар аганың яшьлек дусты Галиәкбәр Түрәбаев хәтерләвенчә, «Енлик-Кебек»не беренче мәртәбә халык алдында Семипалатның «Ес-аймак» түгәрәгенә берләшкән һәвәскәр артистлар уйный.

Соңыннан, 1925 елда, Оренбург һәм Семипалат һәвәскәр труппалары нигезендә беренче Казакъ дәүләт драма театры туа. Ул М. Әуезовның «Енлик-Кебеге» белән ачыла. Әйтергә кирәк, бу шигъри драма кат-кат уйнала, автор тарафыннан яңадан эшкәртелеп, камилләштерелә бара. 1958 елны Казакъ дәүләт драма театры аны Мәскәүдә узган гастрольләренә дә алып килә. Шулай итеп бу әсәр Мохтар аганың гомерлек бәхет юлдашы, әдәби уңышы итеп кабул ителергә бик хаклы.

Мохтар Әуезов олы иҗат юлына баскаччы остазлары Абай Кунанбаев белән Ибрай Алтынсариннарның әсәрләрен җентекләп өйрәнә. Ул алдынгы карашлы чордашлары Әсфәндияр Кубеев, Солтан-Мәхмүд Торайгыровлар, яшьтәшләре — ерак Казан басмаханәсендә «Үткән көннәр» исемле шигъри җыентык (1914 ел) чыгарырга өлгергән Сәкен (Сәдвакас) Сәйфуллин, Троицк төбәгендә хөр фикерле «Айкап» журналын чыгарышып килгән Бәимбәт Майлиннар иҗаты белән дә яхшы таныш булган. Бу хәл аның әдип буларак иртә җитлегүенә зур йогынты ясый. Шуның өстенә ул, әйткәнебезчә, рус культурасын, рус әдәбиятын җентекләп өйрәнгән, Урта Азия халыклары арасында киң таралган Г. Тукай, М. Гафури, Ф. Әмирхан, Дәрдмәнд, Г. Ибраһимов иҗатларын яхшы белгән. Хәтта рус әдәбияты белән беренче танышуым да татар әдәбияты аша булды, ди ул тел галиме Г. Мусабаев белән бер әңгәмәсендә. Аннары «Тукай прогрессив һәм горур поэзиясе белән ислам диненең катып калган кануннарын, аның фанатизмын нык гаепләдә, үз халкының алдынгы җәмәгать эшлеклеләрен икеләнмичә рус культурасы казанышларын үзләштерергә чакырды... «Тукай чын халык шагыйре иде»,— дип яза.

Бу урында олы әдип тормышындагы тагын бер кызыклы моментны хәтергә төшереп үтик. М. Әуезов, егерменче еллар башында казакъ-кыргыз Үзәк Башкарма комитетына эшкә алынгач, 1920—1925 елларда Казагыстан башкаласы булган Оренбург шәһәренә күчә. Эш белән бергә ул әдәби иҗатын да дәвам итә, журналистикада да көчен сынап карый. Ул чакта Оренбургта татар телендә «Юксыллар сүзе» газетасы, казакъча газеталар чыга. «Юксыллар сүзе»нең җаваплы секретаре татар шагыйре Һади Такташ була. Даими язышып торучылар арасында комсомолец Муса Җәлил дә бар. Татар театр һәм музыка дөньясының да бик җанлы бер чоры, әледән-әле әдәби-музыкаль кичәләр оештырылып тора. Чөнки бу вакыт Оренбургта татарның өч күренекле композиторы — С. Сәйдәшев, Җ. Фәйзи, А. Ключарев бергә туры килгән, көйче һәм җырчы Газиз Әлмөхәммәтов та әледән-әле булгалап тора. Анда шагыйрь Такташ, Ченәкәй, Мусалар шигырь сөйли...

Билгеле, шул җанлы тормыштан тугандаш казакъ халкының ирек-бәхеткә омтылган алдынгы яшьләре — Сәкен Сәйфуллин, Мохтар Әуезов, инде шигърият дөньясына керергә өлгергән рабфак студентлары Габит Мөсрепов белән Сабит Мокановлар да читтә калмаганнар, ул кичәләрдә катнашкан, яңа чор татар мәдәнияты вәкилләре белән аралашканнардыр. Сүз уңаеннан әйтергә кирәк, С. Сәйфуллинның якын дусты, көрәштәше, соңыннан мәгълүм язучы һәм Казагыстанның күренекле җәмәгать эшлеклесе Сабир Шәрипов та чыгышы белән безнең Әгерҗе ягыннан, димәк, бу хәл үзе генә дә Сәкен аганы татар мәдәниятына якынайткандыр, диясе килә. М. Җәлилгә багышланган кайбер истәлекләрдән дә бу бәйләнешләрнең ныклыгын төсмерләргә була. Мусаның казакъ шигъриятен, казакъ

җырларын яхшы белүен сөйлиләр. Урта Азия халкын, казакъ телен Такташ, Ченәкәйләрнең дә яхшы ук белгәнлеге билгеле.

Тагын шунысы да бик кызыклы — ике халыкның булачак зур әдипләре, сүз кеуешкандай, бер үк вакытта Оренбургтан университетлы Ташкентка юл алалар. Такташ татар әдәбиятын укытучы булып һәм үзе дә ирекле тыңлаучы сыйфатында Коммунистик университетка урнаша, үз тирәсенә бик күп интеллигенция вәкилләрен туплаган «Белем йорты» журналының җаваплы секретаре булып та эшли башлый. Мохтар Әүезов та университетның ирекле тыңлаучысы, көндәлек матбугатка якын торучы яшь әдип. Алар бу чорда һәрхәлдә бер-берсен белгәннәрдер дип уйларга кирәк.

Зур уку йортына керү теләге М. Әүезовны Ленинградка алып китә. 1923 елдан 1928 елга кадәр ул Ленинград университетының тарих-филология факультетында белем ала. Аннан соң яңадан Ташкентка кайтып университет каршындагы аспирантурага урнаша. Бер үк вакытта университетта казакъ әдәбияты буенча дәресләр бирә. Бу елларда инде ул танылган язучы булып җитлегә. Аның «Енлик-Кебек», «Көндәш хатыннар»ы сәхнәдән төшми уйналып килә. Хикәя һәм очерклары, әдәбият тарихына караган зур мәкаләләре укучыга даими ирешә тора. Тәрҗемә өлкәсендә дә ул беренче сынауларын үтә. Казакъ совет әдәбияты аның тәрҗемәсендә В. Шекспир, А. Островский драма һәм трагедияләре, И. Тургенев, М. Горький һәм башкаларның классик әсәрләре белән баетыла.

М. Әүезов кырык биш елга якын иҗат дәверендә утызлап пьеса һәм либретто иҗат итә. Аларның бик күбесе хаклы рәвештә казакъ сәнгатенең алтын фондына керәләр. 1934 елда казакъның икенче, килечәктә Абай исемендәге опера һәм балет театры булачак сәхнәсе дә Әүезовның «Айман-Чулпан» исемле музыкаль әсәре белән ачыла. Бу әсәрне сәхнәләштерүгә якташыбыз, танылган композитор Латыйф Хәмиди зур өлеш кертә. Соңыннан Л. Хәмиди язучының «Кобланды батыр», «Төнге сарын», «Абай» пьесаларына да музыка яза. «Абай» пьесасы либретто итеп эшләнгәч, Л. Хәмиди, Уральскидан чыккан танылган композитор Әхмәт Жубанов белән берлектә, аңа опера музыкасы яза. Менә утыз биш ел инде ике тугандаш халыкның дуслык җимеше булган бу кызыклы опера сәхнәдән төшми уйналып килә.

Күренекле шагыйрь, мәгърифәтче Абайның тормышы һәм иҗаты Мохтар Әүезовның бөтен гомерен яктыртып үтә сыман. Чөнки Мохтар бала чагыннан ук үзләренең Чыңгыз таулары итәгендә күченеп йөргән Тобыкты ыруының горурлыгы Абай Кунанбаев (1845—1904) йогынтысында тәрбияләнгән.

Мохтар мәктәптә укыганда ук бөек якташы турында зур роман язарга хыяллана башлый, аның иҗатына, тормышына караган истәлекләрне тупларга керешә. Казакъ Фәннәр Академиясенең булачак президенты Каныш Сатпаев белән бергәләп алар Семипалат шәһәрендә 1914 һәм 1924 елларда шагыйрьгә багышланган ике зур әдәби кичә уздыралар. Ул шунда Абайны белүче бик күп кеше белән таныша, хатирәләрен язып ала. Шагыйрьнең хатыннары Дилдә һәм Айгеремнәр белән очраша, Абайдан берничә яшькә олырак Әүез бабасыннан бик күп нәрсә ишетеп кала.

Билгеле булганча, М. Әүезовның дүрт томлык «Абай» һәм «Абай юлы» романнары укучылар тарафыннан бик җылы каршыланды, югары бәяләнде. Әдәбият белгече З. С. Кедрина «Абай» эпопеясын казакъ даласының мәгълүм бер чорына багышланган иң тулы энциклопедия дип атый. «Абай» китабы өчен Мохтар Әүезов 1949 елны Бөрenче дәрәҗә СССР Дәүләт премиясенә лаек булган иде. Романның «Абай юлы» китабы 1956 елда тәмамлана. һәм авторга бу китабы өчен 1959 елны илебезнең иң югары бүләге — Ленин премиясе бирелде.

Роман тиз арада рус теленә, аның аша бик күп башка телләргә тәрҗемә ителеп бөтен ил, бөтен дөнья буйлап таралды. Аны хәзер төрле кыйтгаларда яшәүче халыклар үз телләрендә укый. Романның бер өлеше казакъ телен яхшы белүче Сәрвәр апа Әдһәмова тәрҗемәсендә татар укучысына да ирешкән иде (1957).

Шулай итеп, Мохтар Әүезов иҗаты безнең әдәбият хәзинәсенә дә кушылды.

Боларның барысы да Казагыстанның һәм аның Коммунистлар партиясенең быел билгеләнә үтелгән 60 еллыгы бәйрәменә — халыклар дуслыгы Сабантуена матур бүләкләрнең, әдәбиятлар дуслыгына һәйкәлләрнең берсе бит!

*Жубан Молдагалиев*

*Казакъ шагыйре*

## АКЫННАР АГАСЫ

*Мохтар Әуезовка*

Заманның булсак та без гел бабында,
Бигрәк читен без яшь дию Сез барында.
Күкрәгенә кысып коча Үзегезне —
Сез сөекле ярты галәм кызларына.

И агабыз, бер гаҗәеп чын кеше Сез,
Соң аңласак, кичерегез — бездә гаеп.
Урын түрдән Сезгә Парнас сараенда,
Акынлыкның тәхет-таҗы Сезгә лаек.

Шигырь үре омтылышлы һәм күңелле,
Чыгарыр ул үзе барда түргә кемне?
Бу бик ачык, әйтәмен тик, Мохтар ага,
Ул да Сезгә баш июен күргәнемне.

Тумыштан шигырь көйләп чәч агарган,
Үлгәнгәчә шагыйрьдә шул теләк-арман,
Сез барында сүз патшасы шигърият тә
Сездән алда узмас иде бусагадан.

*1957*

## АЛМАТА БУЙЛАП

Машина шуып акырын
Илтә безне — юл такыр.
Мәскәүдән килгән шагыйрьнең
Йөрәгендә яңа җыр.

Шәһәр бу, хәзергә мәгәр
Күрмәде бер йорт та ул —
Тирәдә биек тирәкләр,
Урам — яшел коридор.

Алда ак башлы Алатау,
Тауга үрләп барабыз.
Олы кунакта аптырау;
«Ә кайда соң калагыз?»

Ашыкма, дустым, ашыкма,
Җәяүләп бер йөрерсең,
Син гашыйкка яшел пәрдә
Ачылганын күрерсең.

Сиңа шат кочагын җәеп,
Алмата бер хуш алыр,
Кулыңнан юмарт, гаҗәеп
Киң күңелле дус алыр.

Аңларсың һәр тел, һәр кемне,
Саклап исгә сүзләрен,
Сакларсың истә һәр көнне,
Казакъның кара күзләрен.

Ишетерсең уен-көлке,
Көмеш арык челтерен.
Опера тыңлап, белерсең
Җибәк-кызның син серен.

Моң көйләр алар сиңа да
Яшәү, хезмәт турында,
Күтәрер үрләргә, тауга, —
Хис туктамый юлында.

Күрерсең багларның рәхәт,
Җофар исле чакларын:
Чияләр балланып рәт-рәт,
Апорт чәчәк атканын.

... Машина шуып акыртын
Илтә безне, юл такыр.
Мәскәүдән килгән кунакның
Йөрәгендә яңа җыр.

**Нури Арсланов**
тәрҗемәсе.

# ДЕКАБРИСТ ЯКТАШЫБЫЗ

Дмитрий Иринархович Завалишин декабристлар хәрәкәтендә иң күренекле урын тоткан һәм серле шәхесләрнең берсе санала. Ул моннан 175 ел элек, 1804 елның 13(25) июнендә туган. Үз сүзләренә карап, моңарчы аны Астрахань шәһәреннән дип исәплиләр иде. Күптән түгел Хәрби-Диңгез флоты Үзәк дәүләт архивында бер кызыклы документ — Завалишинның Диңгез корпусына кабул итүләрен сорап язган үтенече табылды. Ул әлеге документта «Казан губернасының Спас округына кергән Жедяевка авылында» туган итеп күрсәтелә. Бу авыл ул заманда аның атасы ягыннан әбисе Екатерина Федоровна Завалишина биләмәсе булган.

Завалишинның балачагы Астраханьда, Могилев губернасында һәм Тверьда үтә. Ул 1816 елда Петербургтагы Диңгез корпусына укырга керә. Завалишин иң яхшы гардемариннарның берсе була һәм инде 13 яшьтә уку-өйрәнү кораблендә вахта белән командалык итә, ә 14 яшендә корпуста югары математика һәм астрономия укыта. Инде 1919 елда ул Диңгез корпусын тәмамлый һәм шунда укытырга да кала.

Атасы зур урында эшләгәнгә һәм үги анасының югары катлау кешеләре белән дуслык элемтәләре булганга күрә, Завалишин һәр урында хөрмәтле кунак була, күренекле дәүләт эшлеклеләре белән аралаша, дәүләт эшләрен хәл итүгә катнаша. «Мин дөньяны гүзәл итеп күз алдына китергән идем. Мин барлык кешеләрне дә хакыйкатькә, күмәк бәхетлелеккә мәхәббәт белән яналар дип уйладым,— дип яза соңыннан Завалишин.— Ләкин, дөньяга караш ташлагач, җәмгыятьтәге хаксызлык, алдау, караклыкны күрдем. Намус, закон, гаделлек сүзләре күз буяу өчен генә хезмәт итә иде. һәр урында комсызлык, изү... Мондый күренеш минем йөрәгемне ачу белән тутырды». Шулай итеп, Завалишинда дөньяда хаклык, тәртип һәм гаделлек урнаштыру теләге уяна.

Үзенең күпчелек замандашлары кебек, Завалишин иҗтимагый тормыштагы барлык тискәре күренешләрнең сәбәбен наданлыктан һәм әхлаксызлыктан дип белә. Ул, барлык кеше христиан диненә чын күңелдән табынмый торып һәртөрле дәүләт переворотлары файдасыз булачак дип саный. 1821 елда ул — 16 яшьлек мичман — Александр I гә Дөньяны Яңарту Ордены дигән бөтендөнья яшерен оешмасы төзү турындагы серле тәкъдим белән мөрәҗәгать итә. Әлеге Орден, мәгърифәтчелек эшен киң җәелдерү һәм әхлакны «торгызу» юлы белән, дөньяны үзгәртеп корырга тиеш була.

Аның фантазиясе матур хыяллар иҗат итә... Имеш, Александр I аңа булышлык күрсәтер, ул хыялланган Орден оештырылыр, киңәер, барлык илләргә таралыр... «Югары әхлаклы» монархлар халыкларны изүдән туктар, «югары әхлаклы» хөкүмәтләр үз илләре белән халык мәнфәгатьләрен күздә тотып идарә итә башларлар... Революционерлар, үзләренең барлык теләкләренең хөкүмәтләр тарафыннан тыныч юл белән хәл ителүен күреп, көрәшүдән туктар... һәр илдә хөкүмәтләр һәм халыклар, илләр һәм барлык кешеләр арасында мөнәсәбәтләр киеренкелеге кимер, бөтен дөньяда тынычлык һәм бәхетле тормыш урнашыр...

1821 елда Завалишин император янына керә алмый кала. 1822 елның 17 августында мичман Завалишин «Крейсер» фрегатында дөнья тирәли сәяхәткә чыгып китә. Ул Лондоннан Александр I гә хат җибәрә, императордан үзе янына дәшеп алуын сорый һәм томанлы сүзләр белән ниндидер бер сер ачарга җыенуы турында яза. Александр I Завалишинны Петербургка чакырып алырга боерык бирә.

Завалишин сәяхәт вакытында команданың ихтирамын һәм ышанычын казанып өлгерә. Ул, лейтенант Кадьянның кансызлыгына түзә алмыйча ике тапкыр баш күтәргән матросларны тынычландырырга ярдәм итә. «Крейсер» командасы Аляска ярларында икенче тапкыр «фетнә» кубаргач, Завалишин команда яклы була һәм бу юлы матрослар сөйми торган Кадьянны фрегаттан куып җибәрәләр.

Сәяхәт вакытында Калифорния белән танышкач, Завалишин үзенең Дөньяны Яңарту Орденын биредә нигезләмәкче була. Ул шул чакта Калифорнияне Россиягә кушу ягында торган берничә испанлыны үз Орденына кабул итә. Охотскида хезмәт итүче Н. В. Головин һәм А. И. Ленже дә Орденга керергә ризалык белдерәләр.

Завалишин 1824 елның маенда, император боерыгы белән, «Крейсер» фрегатыннан китә. Ул, Себерне буеннан-буена узып, көзен Казанга кадәр килеп җитә.

XIX гасыр башында Завалишиннарның Казанда йортлары була, тик 1815 елдагы көчле янгында ул яна. Әбисе Екатерина Федоровна янгыннан соң, кечкенә генә йорт салып, үзенең тол калган кызы Мария Ивановна Львова белән бергә яши башлый. Дмитрий Иринарховичның үги анасы Надежда Львовна Завалишина һәм аның туганы Екатерина Иринарховна үзләренең Лаеш өязендәге (Чирпахи авылы) биләмәсенә кайтышлый-барышлый биредә тукталалар. Казанда әбисе өенә килеп кергәч, Завалишин көтмәгәндә сеңелесе һәм үги анасы белән очраша. Мәскәүдән, яңа кайтып төшеп, үзләре турында туганнарына хәбәр иткәннәр дә кунак көтешләре икән. Килеп туктаган экипажны күргәч, Екатерина Иринарховна беренче кунакны каршы алырга чыга. Әле бу вакытта Аляска ярлары буйларындагы «Крейсер» фрегатында булырга тиешле абыйсын күргәч, ул гаҗәпләнүдән телсез кала.

— Син кайдан?— дип сорый ул көчкә генә.

— Себердән.

«Себер» сүзен ишеткәч, Екатерина Иринарховнаның йөзе караңгыланып китә. Ул эшнең нәрсәдә икәнен аңлап бетерми, абыйсын себергә сөрәләр, шунда барышлый гына бирегә сугылган дип уйлый.

— Нәрсә өчен? Нәрсә өчен? — дип борчулы тавыш белән кабатлый ул.

Завалишин тагын бер елдан соң Казанга отпускага кайткач, сеңелесе аңа, былтыргы көтелмәгән хәлдән соң, абыйсын һаман тиздән Себергә алып китәрләр кебек тоелуы турында әйтә.

Казанда Завалишин университет профессоры Симонов белән очраша. Профессор аңа Кронштад буенча, Антарктида экспедициясендә катнашучы буларак таныш. Дусларча әңгәмәдән тыш, Себер гимназияләрен тәмамлаучыларның университетта ничек укулары турында эшлекле сөйләшү дә алып бара. Себер администрациясе үтенече белән, ул шушы турыда Казан уку округы попечителе Магницкий белән дә сөйләшә.

Завалишин диңгездәге сәяхәте вакытында этнография коллекциясе һәм «табигать тарихына караган сирәк очрый торган әйберләр» коллекциясен җыя, аларның күп өлешен Казан университетына тапшырырга җыена. Юлда тоткарланмас өчен, ул бу коллекцияләрне тиздән Казанга барырга тиешле сәүдәгәргә калдыра. Тик бу сәүдәгәр үз вәгъдәсендә тормый, коллекцияләр Казанга китерелми.

1824 елның 3 ноябрендә Завалишин Петербургка бара. Ул үзенең «дәүләтне органик рәвештә яңарту турындагы кыю һәм ихлас күңелдән сөйләячәк сүзләре» императорга көчле тәэсир итәр дип уйлый. 1824 елның 7 ноябрендә башкаланы су басу аркасында император белән очрашу булмый. Үзенең телдән әйтергә теләгән сүзләрен махсус язма белән тапшырырга кала. 1842 елның ахырында адмирал А. С. Шишков Завалишинга «галиҗәнап идеяне кызыклы, тик тормышка ашыру өчен уңайсыз дип тапты» дип белдерә.

1842 елның башында Завалишин К. Ф. Рылеев белән таныша. Ул аның Александр I гә яшерен хаты турында ишеткән була. Рылеевтан Төньяк җәмгыяте турында ишеткәч, Завалишин аны Дөньяны Яңарту Орденын төзү өчен файдаланмакчы була. Үзен инде нык тамыр җәйгән куәтле Орден командоры дип игълан итеп, Завалишин Төньяк җәмгыяте җитәкчелегенә үтеп керергә һәм аның эшчәнлегенә йогынты ясарга, әгәр барып чыкса, Орденга барлык «төньяклылар»ны кабул итмәкче була.

Завалишин Рылеевка үзе төзегән Дөньяны Яңарту Ордены уставын һәм Орден верховный идарәсенең командор Завалишинга биргән хуплау документы дип, үзе үк

язган кәгазьне дә күрсәтә. Бу документлар «төньяклылар»ны кызыксындыра кала. Рылеев күрсәтмәсе белән, А. А. Бестужев һәм А. И. Одоевский Яңарту Ордены уставын күчереп алалар. Аны башта Төньяк җәмгыять думасында тикшерәләр, аннары, 1825 елның урталарында Көньякка җибәрәләр. Рылеев Яңарту Орденының җитәкчелеге, көче һәм планнары турында күбрәк белергә тели, Завалишин аннан Төньяк җәмгыяте турында сораша. Икесе дә әңгәмәдән канәгать булып калалар, ләкин алар бер-берсеннән күп нәрсәне яшергәнлекләрен дә аңлыйлар...

1825 елның язында Завалишин Петербургта тагын бер кечкенә генә оешма яшәгәнен белеп ала. Бу аның өчен көтелмәгән хәл була. Әлеге оешманы гвардия экипажы офицерлары Антон Арбузов белән Александр Беляев төзи һәм җитәкли. Завалишин аларга дөньяны Яңарту Ордены турында сөйли һәм көз көне бу офицерларны үз Орденына ала. Шулай итеп, аның яшерен оешмасы тагын берничә кешегә арта. Завалишинга үзенең матур хыяллары тормышка аша башлады сыман тоела...

Аның үз карашлары да үзгәрә башлый. Рылеев янында еш булып, «төньяк»лыларның политик темага фикер алышуларын тыңлый, гвардия офицерлары белән дә аралаша. Нәтиҗәдә Завалишин крестьяннарны тизрәк азат итү һәм яңа конституция кертү өчен Төньяк оешма әзерли торган восстаниенең кирәклеге хакында уйлана башлый.

...1825 елның язында Төньяк җәмгыять членнары һәм аңа якын кешеләр, А. И. Одоевский янына җыелалар да, А. С. Грибоедовның «Акыллылык бәласе» комедиясен күчереп язалар. Завалишин да шунда була. Петербургка килгән Грибоедов ул вакытта Одоевскийда яши.

Якынлашып килгән декабрь вакыйгалары хакында берни дә сизенмәгән Завалишин 1825 елның октябрендә Идел буена ялга китә. Ул үзе белән Грибоедовның кулдан язылган берничә данә комедиясен дә ала, берничәсен башта Мәскәүдә, калганнарын Казанда калдыра. Мәскәүдә инде бу комедияне беләләр, Завалишин алып килгәне тулырак һәм төгәлрәк була. Казанда исә «Акыллылык бәласе» белән беренче мәртәбә танышалар һәм аны кулдан-кулга күчереп тараталар. Завалишин алып килгән комедиянең күчермәсен күптән түгел Казан галиме В. Аристов табып өйрәнә.

Казанда Завалишин политик темаларга әңгәмәләр алып бара, шулай итеп, кала җәмгыятенең сәяси үсешенә булышлык итә.

Ул Чирпахи авылына, аннары үги анасы һәм сеңелесе белән атасы биләмәсенә Сембергә китә. Аны шунда кулга алалар.

Верховный суд Д. И. Завалишинны беренче разрядлы дәүләт җинаятьчеләре рәтенә кертә һәм «башын чабып, үлем җәзасына тартырга» диган хөкем карары чыгара. Үлем җәзасы мәңгелек сөрген белән алыштырыла, бу срок соңыннан 13 ел итеп билгеләнә. Барлык декабристлар кебек үк, Завалишин сөргендә Чита һәм Петровск заводында була. 1839 елда ул Читага күчерелә.

Завалишин 1850—1860 елларда Себер администрациясен фаш иткән мәкаләләр яза һәм исеме тагын да таныларак төшә. Көнчыгыш Себер губернаторы М. С. Корсаков таләбе белән Д. И. Завалишин 1863 елда Читадан... Мәскәүгә сөрелә. Ул гомеренең соңгы көннәренә кадәр (1892— елның 5 февралендә Мәскәүдә вафат була) «иҗтимагый явызлыкка» каршы публицистик эшчәнлеген туктатмый яши.

А. ШЕШИН,
СССР Үзәк дәүләт тарих музееның фәнни хезмәткәре.

Габдулла Шәрәфи

# КҮРШЕ МАЛАЕ

Повесть

## Үзәкләре нык



Айдарларның Идел буенда гына дачалары бар, җәйне шунда үткәрәләр. Ә быел, дача сезоны күптән башланса да, чынлап торып күчкәннәре юк иде әле, кайта-килә генә йөрделәр. Айдарны калдырыр кеше булмады. Инде менә авылдан әбиләре килде, малай хәзер көне буе дачада. Ярата да соң Айдар әбисен. Ниләр генә сөйләми ул аңа, ниләр белән генә сыйламый. Ә сые гел диярлек бәрәңгедән була. Чөнки Айдар үзе шуны тели. Айдар гынамы соң, этисе дә үлеп китә бәрәңге дигәндә. Бер көнне боткасын пешерсә, икенче көнне пәрәмәченә тотына әбиләре. Аннан өчпочмак, аннары бөккән... Ул да түгел, этиләре тагын берәр нәрсәне искә төшерә:

— Кыстыбый пешерсәң иде, эни...

Тик әбиләре аны, никтер «күзикмәк» ди. Гомумән, кызык сөйләшә Айдарның әбисе. Этиләре «кыстыбый» дигәч, китте берзаманны тезеп:

— И, и килен, тәмам тилмерткәнсең икән үзләрен. Иртә бәрәңге, кич тә бәрәңге, учакта бәрәңге. мичтә бәрәңге кирәк шул боларга. Әйдә рәхәтләнсеннәр генә, мәшәкатең кимрәк булыр.

— Болай да кимен куймыйлар, эни җаным, — ди Айдарның әнисе. Кайчагында, дежурда каласы көннәремне, әйтеп китәм олы юләренә, балаларны ач тотма, кайнар ризык пешер, дим, анысын-монысын әзерләп тә калдырам. Юк бит, һаман үзенчә, я духовкага бәрәңге тәгәрәтә, я булмаса, кабыгын да әрчемичә, ярып кына табага куя. Шуңа күрә әнә үзе дә... Элеп киптергәннәрмени! Кешедән оят, ирен карамый диярләр.

Моңа каршы әбиләре кет-кет көлә генә.

— Димәсләр, килен, димәсләр, бер дә исең китмәсен. Аның каравы эчке дәфтәрләре сау аларның, үзәкләре нык... Бабалары да шуның шикелле бер бубыла иде. Инде җитмешен узды, кулыннан балтасы төшкәне юк әле. Озак тормассың дип калган ие, инде нишләп йөридер.

— Килсен иде соң ни чакырып...

— Килер, килер, түзмәс, килеп җитәр әле, күзен майландырып...

Дәвамы. Башы 10 нчы санда.

Әбисенең күп кенә сүзләрен Айдар аңлап та бетерми. «Эчке дәфтәрләре» дип нәрсәне әйтә икән? Күзенә май сөртеп килер микәнни бабасы? Кайчагында, кайта-кайта сорап, малай әбисен алҗытып бетерә. Ә әбисе бүтән төрле итеп әйтә белми, аңлатып-аңлатып карый да, аптырагач, утырып бер көлә. Ә көләргә исә җае чыгып кына тора...

Дачалары Идел буенда булгач, үтеп-сүтеп йөрүче балыкчылары да күренгәли. Балыкчылар булган җирдә, әлбәттә инде, сатучылары да табыла. Айдар белән әбисе шулардан балык алып калганнар иде. Икәүләшеп чистарттылар-юдылар да, тышкы яктагы өстәлдә калдырып, верандага керделәр. Әбиләре, газ плитәсенә ут кабызып, таба кыздыра башлады. Ә Айдар тәрәзәдә чәбәләнгән күбәләкне тотарга азаплана. Шуның белән мавыгып, әбисенең чыгып китүен сизми калган. Хәзер менә малай тышкы яктан үзен чакырган тавышны ишетеп алды:

— Улым, чык әле монда тизрәк. Әнә, теге Васә дигәнең бер балыкны алып китте. Әй, йөзе кара!..

Айдар йөгереп бакчага чыкты.

— Кайда ул, әби?!

— Әнә, куралар арасына кереп китте.

— Хәзер табам мин аны, алам балыкны...

— Ярар инде, улым, барыбер пычратты. Хәер исәбеннән булсын. Җан иясе ич, йөзе кара.

Айдар, йөгереп барып, кура куакларын аралый башлаган иде, Васяның сузып-сузып мыраулавын ишетте. Галәмәт тә зур, саргылт йонлы усал мәче ул. Күрше дачадан. Бер генә дә кара җире юк. Бите дә аклы-сарылы. Ә нигә соң әбисе аның йөзе кара дип әйтте икән? Әллә карага буялганмы Вася, күрим әле, дип, Айдар мәчегә якын ук килде. Ә Вася тагын да катырак мырауларга тотынды. Балыкка теше-тырнагы белән ябышкан да мыраулавын белә. Малай, иелә-иелә караса да, йөзеннән бернинди үзгәреш тапмады, һаман да шул килеш — аклы-сарылы.

Мәчене калдырып, бармагын уа-уа, Айдар әбисе янына килде. Әле генә ваемсыз күренгән малай уйчанланып калган иде.

— Нишләдең, әллә мәче тырнадымы ул бармагыңны? — диде әбисе.

— Ю-ук, — дип сузды Айдар, — тырнамады, курадан чәнечке керде.

— Әйтәм аны, сөмсерең коелган.

Айдар, текәлеп, әбисенә карап тора башлады. Карчык битен сөртеп куйды.

— Нигә болай карыйсың миңа, улым? Әллә битемә корым йоккан-мы?

— Юк, йокмаган. Әби, әллә синең күзең начар күрәме?

— Ник алай дисең?

— Васяның йөзе кара дисең ич. Ә мин карадым, карадым, бер дә кара түгел.

— И-и, сабыем, сабый шул әле син, — дип көлә-көлә карчык оныгының аркасыннан сөя башлады.

Айдарга бик рәхәт, бик тә җиңел булып китте. Тик барыбер әбисен аңлап җиткерми әле ул. «Сөмсерең коелган» диюе тагын нидер?.. Аңлар әле Айдар, аңлар. Аңлар да иксез-чиксез тел дәрьябызда әбисе, бабасы кебек колач салып йөзә башлар.

## Дошманнар

Багираның дачага әле беренче тапкыр аяк басуы иде. Килү белән ул, як-ягына карангалап, кая сугылырга белмичә, веранда уртасында байтак кына утырды. Аннары, бүлмәдән бүлмәгә йөреп, барысын да әй-

ләнеп чыкты, иснәнмәгән җире, төртелмәгән төше калмады. Озак та үтми, песи тәмам үзләште, әйтерсең шушында туган да шушында үскән — теләсә кая менә, теләгән җиренә сикерә.

Кайчагында, өйдә кеше-кара булмаса, Вася да кергәләп чыга. Тик ул хәзер ишек төбеннән ары уза алмый, чөнки Багира бик уяу, Вася күренү белән сыртын кабартып, ысылдарга тотына. Тегесе карап-карап тора да, «әй, сиңа бәйләнгәнче», дигәндәй, кергәндәге кебек үк мыштым гына күздән югала. Ә инде бакчага чыгып, юллары кисешсә, Васядан яхшылык көтмә, пыр туздыра Багираны, бичара дача өенә атылып керүен сизми дә кала. Килгән шәпкә Вася Багирага әнә шулай һич көн күрсәтмәде. Чөнки ул моңарчы янәшә торган өч-дүрт дачаны бер итеп йөри иде. Кергән бер җирдә үзенә ни дә булса бирәләр, бирмәсәләр, җайсызрак яткан тәм-томны чәлдертергә дә күп сорамый. Читтән килгән мәчеләр, хәтта юашрак этләре дә бу тирәне әйләнебрәк үтәргә тырышалар. Шуңа күрә Васяга караш та ике төрле: дачаларны саклавы өчен мактыйлар, сыйлыйлар, урлашканы өчен сүгәләр, ә өстендә тотсалар, бәргәләп тә чыгаралар.

Багираны ул баштан ук яратмады. Чөнки тегесе элек Вася хуҗа булып йөргән җирдә әлләкем кебек кылана. Кая инде ул өйгә керту, әле янына гына килә башласа да сыртын кабарта. Айдар барында бигрәк тә батырайган була. Ә үзе, Вася бер мыраулап кую белән, чебен тимәс чер иткәндәй, чатыр чабып малай янына элдертә.

Шулай итеп, Вася хәзер Багираны очраткан саен җәберли алмый башлады. Теләсә-теләмәсә дә, яшь хуҗа белән исәпләшергә туры килә. Исәпләшмәс иде дә, Айдар бар, ә ул узынырга ирек бирми. Ләкин Багираның Васядан кала да дошманнары байтак булып чыкты. Хәер, монысына инде ул үзе гаепле.

Бакчада бакалар күп. Берәрсен ачыграк урында туры китерсә, бер алдына, бер артына төшеп, мескенне тәмам алҗытып бетерә. Бака, ничек кирәк алай, үлән арасына кереп яшеренгәч кенә, Багира икенче бер кызык эзләп китә. Я ул, чәчәктән чәчәккә очып, чуар канатлары белән күзен кызыктырган күбәләкне куа башлый, я булмаса, алмагачка кунган берәр кошны күреп, шуның артыннан үрмәли. Тик берсе дә тоттырмый — очалар да китәләр. Ләкин Багирага моннан ни зыян, үзенә тимиләр ич. Шуңа иялләнгән иде песи, һәр шуклыгы җәзасыз үтүгә күнеккән иде. Әмма дөнья бу, иркен булса да, законнары кырыс аның, ни кылансаң шул ярый димәгән, киртә сикерергә алай ук ирек бирмиләр.

Йөри торгач, Багира көрәктер, китмәндер ише бакча кирәк-яраклары саклана торган сарайга барып керде. Керде дә, гадәтенчә, әле бер, әле икенче почмакка төртелә башлады. Шул чагында, дыңгырдатып, стенага сөяп куйган иске самавыр торбасын аударды. Торбадан башта корым тузгыды, ә аннары эчтә нидер гүләгән тавыш ишетелде. Мәче, бу ни булыр бу, дип сагаеп калды. Һәм менә торба авызыннан, яман да хәтәр безелдәшеп, шөпшәләр тузгыша башлады. Багира, ни кылангасын үзе дә белмичә, элек сыңар тәпие, аннары икесе белән дә селтәнергә тотынды. Селтәнә торгач, бер тәпиен һәм колагын чагып та алдылар. Көтелмәгән бу хәлдән имәнеп, мәче идәнгә тәгәрәп китте. Ә тирәсендә шөпшә болыты куерганнан-куера бара, ул да түгел, безелдәшә-безелдәшә, үзен үк сыра башладылар. Ниһаять, Багира эшнең кая баруын чамалап, тизрәк таю ягын карады. Сарайдан атылып чыкты да түтәлләргә шланг белән су сиптереп маташкан Айдар янына чапты. Килеп җитүе булды, әле башы, әле гәүдәсе белән малайның балтырына «сырпаланырга» тотынды. Айдарга бу бик сәер тоелды, чөнки су сиптергән чакта, сырпалану түгел, мәче якын да килми торган иде. Шулай дип уйлавы булды, балтырын нидер чәнчеп тә алды. Иелеп караса, Багираның йоннары арасында өч-дүрт шөпшә чәбәләнә. Айдарны чакканы да, күрәсең, шуларның берсе булгандыр. Ул арада баш очыннан да, ук кебек

сызгырышып, шөпшәләр оча башлады. Кая карама анда — шөпшә. Малай верандага, ә Багира ачык тәрәзәдән туп-туры өйгә атылды. Айдар тиз генә веранда ишеген һәм бөтен тәрәзәләрне ябып куйды. Әмма йөгергән чакта бер шөпшә аның иренен дә чагып өлгергән иде.

Озак та үтми, яулыгы белән битен-күзен томалап:

— Менә галәмәт, менә галәмәт, тәмам котырганнар. Битемне чакты бит берсе, битемне чакты, котырганнар... — дип сукрана-сыкрана әбисе дә кайтып керде.

— Шөпшә ул, әби, шөпшә, — ди Айдар, иренен капшап. — Мине дә чактылар. Багираны да...

Малай үзе көлә, үзенең күзеннән яшь ага.

— Шул Бәһирәң эшедер әле бу, гөнаһ шомлыгы. Күреп калганием аны кереп киткәнен. Яле, мәэмә итим әле үзен!

Шөпшә чаккан тәпиен ялап утырган песи, үз исемен ишетүгә, әбинең тавышындагы кырыслыкны да сизеп, тиз генә икенче катка менеп китте.

— Мәчеңә берни булмас, ялар да бетәр, әнә үзеңнең иренең шешә. Беләсең ич сарайга шөпшә оялаганын, ник ишеген ябып йөрмисең... Кирәк чакта гына көмеш тәңкәсе дә юктыр әле аның, — дип сөйләнә-сөйләнә, карчык чөйдә эленеп торган плащ кесәсеннән акча эзли башлады.

Ләкин акча белән басуның бер файдасы да тимәде, шешәсе җирләр барыбер шеште, эштән кайткан әтисе белән әнисен Айдар кабарган ирен, әбиләре бүлтәйгән яңак белән турсаешып каршыладылар.



## Балыкчылар, аучылар

Вакыт уза торды. Шешләр кайту белән шөпшә вакыйгасы да онытылды. Ул арада Айдар балык тотарга бик һәвәсләнеп китте. Бакча башларында гына Иделдән кергән тыныч бер култык бар. Үтереп тә каба инде шунда вак балык. Айдарга ияреп Багира да йөри. Малай: «Багира, әйдә балыкка!» — дисә, тегесе алдан ук чаба. Белә ул балык белән сыйланасын. Тоту белән үк беренчесен Айдар Багирага бирә. Ә аннары, өйгә кайткач, олылар алдында малай песиен мактый, әбисенең «кулы җиңел», «аягы җиңел» дип сөйләшүенә охшатып, «Багираның тәпие җиңел аның», — ди. «Шулайдыр шул, югыйсә...», — дип өйдәгеләр көлешәләр. Чөнки сәбәбе бар иде.

Көннәрдән бер көнне Багира каяндыр тычкан тотып кайтты. Айдар икенче каттагы бүлмәләрендә пластилиннан нидер ясап утыра иде, астан әбисе кычкырды:

— Улым, Бәһирәң әнә тычкан тоткан!

— Тычкан?!. Багира, монда мен!

Айдарның тавышын ишеткәч, мәче туры өскә менеп китте.

Әбисе тагын кычкырды:

— Нигә анда чакырасың аны, чыгарып ташла тычканын!

— Әти белән әнигә күрсәтәм мин аны, әби. Аннары ташларбыз.

Чыннан да, ничек инде ул алар күрми калырга тиеш, ди. Күрсеннәр. Бигрәк тә әнисе. Югыйсә, һаман ачулана, Багираң әйберләрне тырный, ди. Айдарның уйларын, әйтерсең мәчесе дә белеп тора, менде дә авызындагы тычканын малай янына куйды.

— Молодец, Багира! — дип Айдар мәченең башыннан сыйпады һәм, тычканны бер почмакка илтеп, өстенә кәгазь каплап куйды. Корбанын башта бик ансат кына бирсә дә, күзеннән яшергәч, Багира бер дә риза түгел, һаман тычкан янына бара, тагын эләктереп, каядыр алып китмәкче була. Шуннан соң Айдар, бүлмәнең ишеген ябып, песине дә калдырмыйча, аска төшеп китте...

Әтисе белән әнисе кайтуга ук Айдар каршыларына атылып чыкты:

— Эти, Багира тычкан тотты!!!

— Китче!.. Кара син аны, ә... Әйттем бит тырнагын чарлый дип.

— Әйдәгез күрсәтәм, — дип Айдар әтисе белән әнисен югарыгы бүлмәгә ашыктыра башлады.

Кәгазьне күтәреп карасалар... Тычканнан җилләр искән иде.

— Хәйләкәр тычкан булган ул, улым, — диде әтисе. — Әнә бит икегезне дә алдаган. Бәлки, аңгырайган гынадыр, әрләнә шикелле...

Күпмедер вакыт үткәч, әбиләре сөйләнгәли башлады:

— Баһирәң алып кайткан тычканның аягы җиңел булды, улым. Моңарчы ул-бу сизелми иде, хәзер әнә шаяралар, шүрлектәге ярма кабын тишкәләп бетергәннәр...

Әллә шулай, әллә юк, һәрхәлдә бу гаеп барыбер Айдар белән Багирага тагылып калды. «Тәпие җиңел», — дип, малай песиен мактагач, олыларның көлешүе шуңа бер ишарә иде.

Айдар белән йөри-йөри Багира да чын балыкчы булып китте. Дөресрәге, балык җене кагылды. Башта ул, Айдар кебек үк, калкавычка күзен текәп, сабыр гына утыра. Балык чиртә башладымы, тәмам әсәрләнә, колакларын торгызып, муенын калкавычка таба суза. Ләкин иң кызыгы балык капкач була. Каян сизә диген, Айдар әле балыкны чыгарырга гына җыена, ә мәче инде, үрле-кырлы сикереп, артка чаба. Белә бит сабый, балыкның нәкъ шунда килеп төшәсен белә. Айдар барып җиткәнче, көмешсыман ялтырап, чирәм өстендә бәргәләнгән чабакны кабып та өлгерә. Малай, кармактан ычкындырыйм дип, мәче авызыннан балыкны кире алмакчы була. Ә тегесе, «кит әле моннан, бергә тоттык ич» дигәндәй, усалланып мыраулый-мыраулый, аны чыбыгы-ние белән һаман читкә сөйри.

Шулай итеп, талаша-талаша ике-өч балык ашагач, Багираны син күр дә мин күр, койрыкны сыртка салып, дачага кайта да китә. Ә инде малай: «Багира, син кая?» — дип артыннан кычкырса, песи, аңа таба башын борып, бер мәлгә туктап кала. Янына Айдар килә башласа, Багира баскан урынында бер сикереп ала да әйдүк тагын үз юлына.

Кайтып җиткәч, веранда алдына утыра да әле бер, әле икенче тәпие белән битен ышкый-ышкый ялманырга тотына. Аннары рәхәтләнеп бер киерелә һәм, дүрт аягын бер уңайга җибәреп, шул ук баскыч төбенә сузылып ята. Кәрә-чыга йөргән әбиләре аны, аяк очы белән төрткәләп:

— Кара син моның ятуын, кара син бу ялкауны... Абыеңны ник калдырып кайттың? — дип шелтәләгән була.

Багира, күзен кыскалый-кыскалый тыңлап ята да, башын күтәреп, «мияу» дип куя.

— Нәрсә, мин уяу дисеңме? Уяу булсаң, бар әнә, тычкан тот. Үзең алып кайттың ич.

## Сабак

Айдар белән әтисе, бик матур сыерчык оясы ясап, әле яз башында ук дача түбәсенә беркетеп куйганнар иде. Шуңа күрә малай сыерчыклар килүен быел аеруча зарыгып көтте. Ә инде бер көнне, оя түбәсенә куныл, җилпенә-җилпенә сайрашкан пар сыерчыкны күргәч, шатлыгы эченә сыймады.

Әтисе дә малайдан ким куанмаган иде, күзлеген бер салып, бер киеп сыерчыкларга карап торды да, Айдарны кочаклап, җепшек кар өстенә ауды. Тотындылар тәгәрәшергә... Куеннарына, итек балтырларына кар тулганчы аунадылар. Аунамыйча, быел беренче тапкыр сыерчык күрүләре ич, йоласы шундый. Ә нигә шундый, монысын Айдарның әтисе дә белми бугай. Борынгылардан калган, ди. Малай бик төпченеп караса да:

— Анысын инде әбиеңнән сорарсың, — дип көлде генә.

Чыннан да, ник алай итәләр икән? Кыр үрдәкләре килә, торналар, киек казлар кайта, тик аларны күрү белән берәү дә җиргә ятып аунамый бит.

Озакламый кар да китте, агачлар бөрегә тулыштылар, үләннәр яшәрә, сап-сар тузганак чәчәкләре күренгәли башлады. Шул чагында Айдарлар бакча казырга тотындылар. Агачларның шәрә ботаклары арасында чыпчыклар, песнәкләр чыркылдаша, баш өстеннән генә, шаулашып, каргалар, чәүкәләр очып китә, ә казылган җир өстеннән сизелер-сизелмәс кенә дерелдәп, үтә күренмәле пар күтәрелә. Ул да түгел, сиртмә койрыклар очып төшә, өркү-куркуны ни дип тә белмичә, парлы җир өстендә мәш киләләр. Алар инде монда дача салынганнан бирле оялыйлар, бала чыгаралар, күрәсең шуңадыр, бакчаны тәмам үз итеп бетерделәр. Айдарны да танымыйлар микән әле. Шулай булмаса, бу кадәр әрсезләнеп, көрәк астына ук кермәсләр иде. «Кайбер җирдә аларны чәперчек дип тә йөртәләр», — ди әтисе. Әмма Айдарга «сиртмә койрык» күбрәк ошый. Дөрестән дә, ничек белеп әйткәннәр, койрыклары нәкъ сиртмә кебек, гел селкенеп торган чагы. Бу кошларны малай Идел буенда да күргәли, кайчагында, йөгерешкән җирләреннән туктый алмыйчамы, суга да кереп чыккалыйлар. Ә бер вакытны Айдар, сыерчыклар кайтып күпмедер узгач, күрше дача янында сөйләшеп торган агайлардан: «Менә сиртмә койрыклар да килде, инде боз кузгалыр», — дигән сүзләрне ишетеп калган иде. Шул хакта ул әтисеннән дә сорады:

— Әти, нигә боз сиртмә койрыклар килгәч кенә китә?

— Үзең дә күрдең ич елга өстендә чабышып йөрүләрен, — диде әтисе.— Койрыклары белән суккалап шулар вата инде бозны.

Монысын ул, әлбәттә, шаяртып кына әйтте. Айдар да аны чынга алмады. Әмма боз кузгалу белән сиртмә койрык арасында бәйләнеш бар икән шул. Әтисе сөйләп биргәч, малай моны үзе дә аңлады. Чыннан да, иртәрәк килсәләр, ни ашарлар, ничек туенырлар иде. Ул чагында әле кортлар да, бөҗәкләр дә юк, анда-монда яшеренгәннәрен үзебездә кошлаучы канатлы дусларыбыз чүпләп бетергән була. Шуңа күрә сиртмә койрыклар елга-күлләр ачылыр вакытка туры китереп кайталар, боз астыннан чыккан су бөҗәкләре, су кортлары белән туеналар икән. Ә соңрак азык кайдан да табыла.

Көннәр шулай бер-бер артлы уза торды, алмагачлар, чияләре апак булып чәчәк атты, кура, карлыган куакларына кинәт кенә, дәррәү генә яшеллек үрләде, алардан калышырга теләмичә, көязләнеп, сирене дә аксыл-зәңгәр шәлен бөркәнде. Һәр агачта, һәр куак һәм һәр чәчәктә бал кортлары безелдәшә, бакча башындагы каенлыкта өздереп-өздереп сандугач сайрый, кайдандыр ерактан, тынык кына, моңсу гына булып, кәккүк кычкырганы ишетелә. Хәйран вакыт, хәйран мәлләр!.. Әкиятләрдә сөйләнә торган күк капусы ачылгандай, бар дөньясы сихри нурга, илаһи бер якты моңга күмелеп калды.

Ләкин табигатьнең бу фасылы да сиздермичә генә авышты, тирә-як тынып калгандай булды. Инде сандугачлар да сайрамый, кәккүк тавышы да ишетелми. Аның каравы хәрәкәт артты. Кошлар бала чыгардылар, бала туйдыралар. Ашыга-ашыга пырылдашып кайтып керүләрен, шулай ук ашыгып чыгып та китүләрен күзәтергә Айдар бик ярата. Әниләре кайту белән ояларда чыр-чу куба. Сыерчык оясында да, сиртмә койрык оясында да шул ук хәл.

Айдарларның дача түбәсе шифер белән ябылган. Сыртына да, улак каплагандай итеп, буйдан-буйга шифер салып чыкканнар. Сиртмә койрыкларның оясы нәкъ әнә шул улак астында. Шәп урын тапканнар, мәчеләр дә, кем дә тиярлек түгел, керәләр дә югалалар, берни дә күреп булмый. Ә менә сыерчыкның ничек итеп балаларын ашатканны Айдарның күргәне бар.

Бервакытны шулай нидер алып кайткан сыерчык оя тишеге астына ясап куйган кучкарга төшеп кунды. Кунуы булды, тишектә ике кошчык күренде һәм, авызларын зур ачып, шундук чыйкылдашырга тотындылар. Ә авыз дигәне аларда шөкер генә, һич менә ялгансыз, әгәр теләсә, шул бүрәнкәдәй ачылган авызлары эченә әниләре баш белән үк кереп чыга алыр иде. Берсе бигрәк тә комсыз күренә, егылып төшәрен дә белмичә, туганын кысрыклый-кысрыклый, һаман тышкарак сузыла. Сыерчык аны томшыгы белән төрткәләп, кире кертмәкче була. Ә ул, үҗәт, тишек кырыена чытырдап ябышкан, ояда яртылаш күмелә дә тагын чыга. Күрәсең, чиратсыз кылануы булгандыр, әнисе аңа берни дә бирмәде, авызындагын сабыррак баласына каптырды да тиз генә очып китте...

Озакламый кошлар бала очыра башладылар. Әмма очырганчы аларны өйрәтәсе бар бит әле. Көннәрдән бер көнне Айдар сиртмә койрыкларның нәкъ менә шул эш белән мавыккан чакларына туры килде. Хәер, Багира булмаса, малай моны бәлки күрми дә, сизми дә калыр иде. Ул көнне аңа әбисе варенье кайнатыр өчен җиләк чистартырга кушкан иде. Айдар янында ук — ачык тәрәзә төбендә — Багира да утыра. Шулай тыныч кына утырган җиреннән песи кинәт сагаеп калды. Аннары, тәрәзә төбенә сеңәрдәй булып, ал тәпиләренә ятты һәм, башын бакчага таба сузып, катып калды. Ул да түгел, мәче, атылган ук кебек, тәрәзә каршысындагы балан төбенә сикерде. Шул ук мәлдә куак астыннан бер бака һәм тагын нидер — икесе ике якка сикерештеләр. Айдар тәгаен күрде, икенчесе бака түгел иде, чөнки анысы шактый еракка барып төште, бака алай ук сикерә алмый. Ләкин Багира бака ягына әйләнеп тә карамады, җиргә елыша-елыша, ерактагысына таба үрмәләде.

Шул чагында каяндыр сиртмә койрык очып төште дә, койрыгын селкеткәләп, мәченең борын төбендә үк әрле-бирле йөренергә тотынды. Багираның бөтен игътибары хәзер шуңа күчте, шунысын тотарга чамалый. Ләкин кош та бик уяу, мәче чак кына кузгалу белән читкәрәк йөгерә.

Күгәрченнәр генә түгел, Багира ишеләрне сиртмә койрыклар да алдый белә икән. Эшнең нидә икәнен Айдар бик тиз чамалады, балан төбеннән ераккарак сикергәне, әлбәттә, бала коштыр. Малай, эшен ташлап, тиз генә бакчага чыкты һәм, йөгереп барып, Багираны тотып алды. Ә сиртмә койрык, куркыныч узганны сизептер, шундук баласы янына очты. Анысы да ерак түгел, шул тирәдә генә үлән арасына поскан иде. Кош, баласы катында бераз торды да, өй янындагы алмагач ботагына кунды. Тик озак юанмады, кире кошчыгы янына төште. Аннан тагын очты, тагын төште... Күренеп тора, син дә шунда оч, шунда кун дию иде бу. Ләкин кошчык, талпынып-талпынып караса да, андый ук биеклекне алдыра алмады. Шуннан соң сиртмә койрык икенче бер түбәнрәк ботакка оча башлады, нәкъ баягыча, бер кунаклый, бер төшә. Күп тырыша торгач, ниһаять, кошчык та әнисе юл күрсәткән ботакка очып кунды. Әмма инде хәле тәмам беткән иде, авызын ачкан килеш, бер алга, бер артка таба түнеп-түнеп китә. Ояларына кадәр әле ничаклы ара.

Айдар мәчесен күтәреп өйгә керде һәм, аны өске бүлмәләренә ябып, кабат бакчага чыкты. Ул арада инде кошлар тагын да югарырак ботакка күчеп өлгергәннәр иде. Агач башына менеп җитсәләр, түбәгбер генә талпынасы да бит... Ә хәзер... Ай-һай, ерак шул.

Малай карап-карап торды да әбисенә дәште:

— Әби, баскычны түбәгә сөятеп куйыйк әле!

— Нишләмәкче буласың анда менеп, егылып төшәргәме?! — дип сөйләнә-сөйләнә әбисе дә Айдар янына чыкты.

— Кош баласы егылып төшкән... Багира тота язды.

— Булыр ул юлардан, булыр. Кайда соң кошың?
— Әнә ич... Әнисе дә шунда.
Карчык, каш өстенә кулын куеп, иелә-иелә ботак араларын караштырды да:
— И-и улым, менәләр болай булгач, үзләре дә менәләр. Очарга өйрәтә бит ул аны. Куркытма гына син аларны, мәчеләрдән сакла,— диде.
Әмма Айдар саклап кына бетерә алмады шул. Кыҗырап йөри торгач, сиртмә койрыкның җиргә төшкән бер баласын тәки каптырды Багира.
Әтисе белән Айдарның балыкка җыенып йөрүләре иде. Әтиләре өй түрендә кармакларны рәтләп маташа, ә малай бакча башында суалчан казый. Шул чагында, авызына нидер кабып, Багира йөгереп кайтты. Кайтты да ачык тәрәзәдән генә туры өйгә кереп китте. Әтиләре моны юньләп күрми дә калды. Тик Багира өйдә озак тормады, инде әчке яктан кабат тәрәзә төбенә сикереп менде. Мәченең авызында кош баласы иде. Айдарны эзләве булдымы, үзе һаман як-ягына карана. Кошчыкны коткарырга теләп, әти кеше тиз генә Багирага үрелде, әмма тегесе тоттырмады, сикереп төште дә өй артына таба чапты. Шуннан соң әтисе Айдарны дәште:
— Айдар, кил әле тизрәк, Багираң кош тоткан!
Тик малай килеп тормады, бакча башыннан бер генә кычкырды:
— Багира!!
Тавышын ишетү белән песи шундук Айдар янына йөгерде.
Шуклыгы бик хәтәр булса да, Багирага алай ук каты бәрелмәделәр, чөнки мәче кошчыкның бер генә җирен дә имгәтмәгән иде. Айдар аны уч төбенә куеп, җиңелчә генә чөеп җибәрү белән, канатларын җилпеп, очты да китте.
Айдар еш кына уйга кала: «Әллә аңлы микән бу Багира? Кайчагында нәкъ кешеләрчә кылана ич!» Әле беркөн генә, әбисенең күзенә чүп кергәч, Айдарны каршысына утыртып, шуны караткан иде. Чүпне чыгаргач, карчык: «Әй, улым, зур булгансың инде син»,— дип малайны сөя башлады.
— Үзе зур ди, ә үзе... Бәби мени мин!
Айдар әбисе ягыннан тизрәк китү ягын карады. Ә ул:
— Я инде, туйганчы бер сөйим әле үзеңне,— дип тупылдатуын белде.
Моны күреп торган Багира тиз генә Айдар алдына сикереп менде һәм, тәпиләре белән малайның битенә үрелеп, ишетелер-ишетелмәс кенә «мияу» дип куйды. Нәкъ инде менә: «Әби кыйнады ич, бик авырттымы?» — диюе иде, ахры, бичараның.
Ләкин сиртмә койрыклар кошчыклары өчен Багираны гафу итмәделәр. Теге юлы, әле тота гына язып калганда, алай ук дошманлык күрсәтмәгәннәр иде. Монысында инде тәмам ярсыдылар. Айдар кошчыкны очыртып җибәрү белән, каяндыр дүрт-биш сиртмә койрык килеп чыкты да, уйнаклашып, чыр-чу килеп, Багираның баш өстеннән генә очарга тотындылар. Аларга сыерчыклар килеп кушылды, бакчада, нәкъ Багира тирәсендә хәзер әйтерсең лә аклы-каралы яшеннәр уйный. Мәче кайсына карарга, кайсыннан сакланырга да белми. Өйгә таба йөгерә башласа, кыеклатып каршысына төшәләр. Шулай эзәрлекли торгач, арадан берсе очкан шәпкә мәченең башын чукып та алды. Багира тәгәрәп бер әйләнде дә, алдына-артына карамыйча, өтәләнеп, карлыган куаклары арасына сикерде. Бу галәмәткә Айдар да тәмам аптырап, югалып калган иде. Шундый бәләкәй кошлар шундый да батыр булсыннарчы!
Ләкин әле моның белән генә бетмәде. Багира бакчада күренү белән, сиртмә койрыклар һаман шулай аның тирәсендә уйнаклаша торган булып киттеләр, теге чактагы кебек үк зәһәрләнмәсәләр дә, күзләреннән

һич тә югалтмыйлар. Мәче үзе дә гаебен бик сизә, бакчага чыгасы булса, я веранда баскычыннан, я ачык тәрәзә төбеннән башта тирә-якны күзәтә. Әле чыккач та, тагын ябырылмасыннар диптер, ышыграк җирдән йөрергә тырыша. Бу дошманлык, бу читләшү кошлар бала очыртып бетергәнче дәвам итте.

Алай да шәп сабак бирде кошлар Багирага. Хәер, Багирага гына микән әле?

## Яз хәбәрчеләре

Озакламый бакчада карлыган өлгерде, аның артыннан ук кура җиләкләре пеште. Айдар белән әбисенә хәзер эш муеннан, я анысын, я монысын җыеп, көне буе мәш киләләр, баш күтәрергә дә аралары юк. Хәер, баш күтәреп тә ни күрәсең, сыерчыклар, сиртмә койрыклар инде каядыр таралыштылар, бакча тирәсендә әллә нигә бер күренеп алалар да тагын китеп югалалар.

Бу хәлгә күнегеп кенә килгәндә, ничектер күзе төшеп, Айдар оя түбәсенә кайтып кунган ялгыз сыерчыкны күреп алды. Шул чагында кылт итеп яз көне әтисе белән карда аунаганнары исенә төште һәм җиләк җыйган җиреннән:

— Әби, сыерчык күргәч нигә карда ауныйлар? — дип сорап куйды.

— Менә сиңа мә, тора-торып, — диде әбисе. — Каян исеңә төште әле ул?

Шуннан соң карчык озак кына дәшми торды. Аннары, башын күтәреп, күләргә тотынды...

— Шул әтиеңдер әле, олы юләр... Бергә аунадыгызмы?

— Ә син каян беләсең?

— Белмичә соң... Үзеннән сорыйлар аны.

— Әйтмәде ич, әбиеңнән сорарсың, — диде.

— Кара син аны, әле онытмаган икән.

— Нәрсәне, әби, ә, нәрсәне онытмаган ул әти?

— Безнең якта, улым, шундый гадәт бар, беренче тапкыр сыерчык күргәч, җиргә ятып ауныйлар. Әле синнән дә кечерәк чагында, малайлардан күрмәкче, әтиең дә шулай иткән ие. Тик ул бичара карга түгел, суга ятып аунаган.

— Нигә алай иткән соң?

— Бала ич әле ул чакта, олыраклары котырткан. Сыерчыкны кай җирдән күрәсең, шунда ятып аунарга кирәк, дигәннәр. Ә әтиеңнең балтырдан суда килеш, көймә йөздереп уйнаган чагы булган. Тоткан да аунаган шунда. Бабаң кертеп бирде аннары. Җилкәсеннән асып. Бер генә дә коры җире калмаган ие. Ә үзенең авыз ерылган. Нишләтәсең инде ул тилене, тиз генә чишендердем дә, йомшак җиренә бер-икене чәпәп, мич башына менгереп җибәрдем.

— Ә ник ауныйлар икән соң?.. Сыерчык күргәч?

— Анысын кем белгән инде аның. Хәер, бер нәрсә ишеткәнем бар ие. Әллә кайчан инде ул, әле үзем дә кечкенә чакта.

— Сөйлә әле шуны, әби, ә?

— И-и улым, без инде болай да...

— Нигә, күп җыйдык ич инде.

— Ярый алайса, озак түгел ул. Кайчандыр бик борынгы заманнарда дөньяның бөтенләй рәте киткән, ди. Яз белән кыш, җәй белән көз тәмам буталып беткән. Безнең якларга сыерчыклар да, торналар да, кыр казлары да кайтмый башлаган, ди. Иген чәчсәләр, тишелми, тишелсә дә юньләп үсми икән. Ачлыктан, суыктан куркып, кешеләр, күп кенә җәнлекләр, хайваннар, төркем-төркем булып, җылы якка китә башлаганнар, ди. Ә бер көнне, нәкъ яз башланыр чакта, дөньялар рәтле вакыттагы ке-

бек, сыерчыклар кайтып төшкән. Алар кайткач, кешеләр чынлап торып яз киләсен, җәйнең дә, көзнең дә элеккечә буласын сизгәннәр һәм, шатлыктан нишләргә дә белмичә, җиргә ятып ауный башлаганнар, ди. Сыерчык күргәч җирдә аунау гадәте әнә шул заманнардан калган дип сөйлиләр.

— Дөрес микән ул, әби?

— Дөрес булмыйча соң... Син дә аунагач, дөреснең дә дөресе инде ул, — дип, карчык Айдарның җилкәсеннән сөеп куйды.

— Әби, суда аунагач, эти авырмадымы?

— Юк, авырмады үзе... И-и улым, аннан элегрәк тә бер котымны алган ие ул этиең.

— Ник?

— Ник дип... Анысы озак инде аның, улым, икенче сөйләрмен. Әнә, әниеңнәр кайтыр вакыт та җитеп килә, аш сала торыйк.

## Акбай

Әбисенең аш салып, әрле-бирле килеп йөрүен Айдар баштa сабыр гына күзәтеп утырган иде. Менә-менә эшен бетерер дә бая бүленеп калган сүзен дәвам итәр дип уйлады. Тик әбисе, әллә онытты шунда, малайны бар дип тә белмичә, инде бәрәңге әрчергә тотынды. Ниһаять, Айдар түзмәде:

— Сөйлә инде, нишләде соң ул эти? — дип әбисенә ялына башлады.

— Кайчан? Нишләсен ул этиең?

— Үзең әйттең ич. Карлыган җыйганда.

— Ә-ә, аны әйтәсең икән. Хәзер үк дисеңмени? Күрәсең ич, эш бар.

— Ә син әрче дә, сөйлә дә. Мин дә булышам.

— Зиһенем чуалып тора бит әле, улым. Бакча, дача ди-ди, инде ни гомер авылга кайтканыгыз юк. Бабаң әнә үпкәләгән ди анда. Бармыйм, үзләре кайтсыннар дип җибәргән.

Айдарга кызык булып китте. Гел шаяртып, гел елмаеп кына сөйләшә торган бабасының ничек итеп үпкәләвен малай берничек тә күз алдына китерә алмады. Шуннан соң әбисеннән сорады:

— Бабай ничек үпкәли ул, әби?

— Әй, анысын болай гына әйтүем инде. Берәр эш тапкандыр әле шунда. Тик тора беләмени ул... Туктале, тукта, улым. Болай итеп бәрәңге әрчиләрмени? Яртысын юнып барасың ич! Юкарак әрче. Менә шулай... Менә. Таяк түгел лә ул синә.

— Булмый ич.

— Булыр, булыр, ялкауланма гына. Әнә шулай, әнә бит... Юкарак алдырсаң, кабыгын бер дә өзмичә, бөтен бәрәңгене әрчеп бетереп була. Кыз чагында без, ярыша-ярыша, бәләк-бәләк бәрәңгеләрне шулай әрчи идек.

— Хәзер дә әрчи аласыңмы, әби?

— Ник алмаска, белгән эш онытылмый ул, улым. Менә кара алайса.

Карчык иң олы, иң шома бер бәрәңгене сайлап алды да, урындыгын чигеребрәк утырып, җайга гына әрчи башлады. Әрчи торгач, кабык очы идәнгә үк төшеп җитте, ә бәрәңгенең әле яртысына да җителмәгән иде. Аннары әби аягүрә әрчергә тотынды, аннары чигенә-чигенә... Бәрәңге әрчелеп беткәндә ул инде веранда ишеге төбенә барып җитә язган иде.

— Күрдеңме инде, ышандыңмы? Ә син булмый дисең. Әнә, хет Бәһирәңне арканлап куй. Сикермәсен бөтен җиргә.

— Мин дә шулай әрчеп карыйммы, әби?!

— Син ашыкма әле, улым. Башта болай гына әйбәтләп. әрчергә өйрән. Әнинең эштән кайтканчы әрче дә куй, әрче дә куй. Вәйт була инде шуннан соң. Шаккатсыннар әле бер.

— Алайса, сөйлә инде, эби.

— Сиңа шул әйт кенә. Чатябышасың. Тигәнәк шикелле. Я, тыңла алайса, үзләре кайтып кергәнче...

Бер этебез бар иде безнең, Акбай исемле. Элекке исеме ничек булгандыр, белмим. Монысын без куштык. Бабаң кала юлыннан ияртеп кайткан иде аны. Ул чагында куна-төнә йөриләр иде калага.

— Нинди җир соң ул кала, эби?

— Соң, Казан инде, Казан каласы. Шәһәр дисәң дә ярый. Бездә кала диләр. Авылны сала дип тә йөртәләр.

— Һе... Кызык икән — кала-а, сала-а...

— Ник көләсең? Менә алып китәрмен дә үзеңне дә сала малае итәрмен. Кайтасыңмы соң минем белән? Ул этиеңнәрне көтсәң...

— Ә Багира нишли?

— Ул да кайтыр безнең белән.

— Алайса, ярый. Бабайны да сагындым. Сөйлә инде.

— Соң, үзең бүлдерәсең ич.

— Ә син дөрес итеп сөйлә.

— Карасана... Каян килгән бу кәттә мулла?!

— Менә ич тагын!

— Нәрсә — тагын?

— Кем соң ул кәттә мулла?

— Кем булсын, синең шикелле күпне белүче... Менә бит, бер бүлдергәч... Ни дигән ием әле мин?

— Бабай эт алып кайтты, дигән идең.

— Ә-ә, ие шул. Яшь эт ие әле ул. Алай да эре сөякле, зур эт буласы ие. Бөтен җире кап-кара. Тик муен тирәсендә генә ак сызыгы бар ие. Муенса шикелле. Аннары тагын бер колагы да койрык очы ак ие. Башта нинди исем кушарга да белмәдек. Булгандыр да инде аның исеме, кем дә булса кушкандыр. Әйдә соң, дим бабаңа, Муйнак дип кушыйк, ак сызыгы бар ич муенында, дим. Юк, ди бабаң, ярамас, ди, бер очка ике Муйнак күбрәк булыр, ди. Аннары үземнең дә искә төште: күршеләрдә бер Муйнак бар ие шул инде. Алайса, Акбай булсын, дим. Көлә бабаң, кара чикмәнгә ак пута икән, ди. Әмма каршы килмәде.

— Эти турында сөйләмисеңмени?

— Бәй, сөйләп торам түгелме соң!

— Акбай турында ич.

— Ашыкма, әүвәле тыңлап бетер. Инде дә акыллы булып чыкты шул Акбай. Әллә нинди генә бер исәр сарыгыбыз бар ие безнең. Каршы чыгып алмасаң, үзе кайтып кермәс ие бер дә. Көтү кайткан саен капка төбендә калкынам ие. Югыйсә, эзли-эзли алҗып бетә иек аннары. Беркөнне тәрәзәдән бабаң кычкырды: «Кер әле тизрәк, казан ташый!» — ди. Кереп киттем йөгереп.

— Ник үзе чыкмады соң?

— Ничек чыксын, чабата кайтарып утыра ич, тезенә җүкәләр бәйләгән ие.

— Һе... Этинең дә чабатасы бар. Караңгы бүлмәдә эленеп тора.

— Торамыни әле? Торсын шул. Югыйсә... Үзем казан тирәсендә, үзем тышны күзәтәм. Башта сыер кайтып керде, аннары сарыклар. Ә тегесе хәерсезе юк. Кайтамы соң! Тагын чыгып киттем. Чыксам, ни күрим, Акбай урам бетереп сарык куып йөри. Шул, безнең сарык. Кая сугылса да Акбай каршы төшә. Тәки куып кертте үзен. Аннары аяк очыма килеп утырды да, башын күтәреп, миңа карый, булдырган бит, янәсе. Әйткән, кушкан кеше юк. Акыллы түгел диген син аны. Исем китте. Тотып сөйдем үзен бер. Шуннан соң янымнан китте дә бу, капка авызына ки-

леп, «hay-hay» дип куйды. Сарыкны кисәтә имеш, икенче кайтмый кара, янәсе.

Рәхәтләндек шуннан соң. Капканы ачып куям да:

— Акбай, бар, көтү кайта, — дим. Чыга да китә капка төбенә, куып кертә сарыкны.

— Мин дә чыгар идем Акбай белән, әби, әйеме?

— Чыгар иең шул, ник чыкмаска. Күңелле ич ул көтү каршылавы. Бабаң да бик ярата ие аны.

— Көтү каршыларгамы, әби?

— Нишләп, Акбайны дим ич... Бабаң ат җигә башласа, гел шуның янында булыр ие. Җөгәнен, камытын киертер ие дә бабаң, атны лапаста калдырып, үзе ишегалдына чыгар ие. Аннары арба яныннан Акбайга кычкыра: «Акбай, Кашканы алып кил!» — ди. Акбай, тезгеннән кабып, атны алып чыга башлый. Тегесе бер-ике адым атлый да, колагын шомартып, туктап кала. Акбай тарта, ә Кашка бармый. Шуннан соң Акбай тезгенне ташлый да, ат каршысына басып, усалланып өрә башлый. Шулай карыша-тартыша, әрепләшә-әрепләшә арба янына килеп җитәләр. Ат җиккәннәрен карап тора иием шулай, кызык була торган ие.

— Эти дә карап тора идеме?

— Әтиең юк ие әле ул чакта, алып кайтмаган иек.

— Кайдан, әби?

— Чишмә яныннан дим.

— hе... Ә мине әни больницадан алып кайткан.

— Ие шул, сине бүлнистән алып кайттык.

— Син дә бардыңмыни?

— Бардым, бармыйча. Шул чагында ук әйткәнием, алмыйк бу малайны, тел бистәсе булыр бу дигән ием. Әниең ич, кай җиреңә кызык кандыр... И-и улым, җитте, җитте, әртил казанына җитәрлек булды бу бәрәңге. Бигрәк шәп әрчи башладың син дә. Инде юып турыйк та әниеннәр кайтарак салып җибәрербез.

— Мин дә өйрәнгәнне әйтмәссең, әби, яме.

— Юк, юк, ник әйтим. Өйдә үзең генә әрчерсең, кызык булсын әле әниең эштән кайтканда.

— Әби, Кашка хәзер дә бармы ул?

— Ю-ук, улым, әллә кайчан юк инде. Шул гомердән бирле. Аннан әтиеңне алып кайттык. Ул тәпи йөри башлады. Акбай инде бик картайган ие. И-и гомерләр, ни арада узып киткән. Югыйсә, әле бүген генә шикелле, улым.

Карчык плитә өстендә кайнап утырган кәстрүлгә карый-карый моң су гына елмаеп куйды.

— Ник көләсең син, әби?

— Юк, улым, болай гына... Бигрәк дуслар ие шул Акбай белән. Бер вакытны сәке кырыена утырттым да әтиеңне, яңа пешкән ипидән бер телем кисеп, өстенә бал ягып бирдем. Башта кабар-капмас кына ялманып утырды бу. Аннары: «Төсәм, төсәм, Акбай биям», — ди-ди, сәке йөзлегенә корсагы белән ятып, шуыша-шуыша идәнгә төшә башлады. Акбай бал ашамый, үзең аша, дим. «Асый» дип һаман үзенекен итмәкче. Алайса, мә, Акбайга монысын бирерсең дип икенче кулына ипи йомшагы тоттырып чыгарып җибәрдем.

Күп тә үтми, тышта әтиең җылый башлады. Ул да түгел, тәрәзә каршына килеп, Акбай өрергә тотынды. И дә каты өрә инде. Йөгереп чыктым ишегалдына. Ни булган дисәм, умарта кортлары сыра башлаган боларны. Бал исен сизеп килгәннәр. Әтиеңнең бите балга буялып беткән. Үзе һаман кулын болгый. Анысы да чат бал. Тик кенә торса инде. Күтәреп алдым да моны, алъяпкычыма төреп, өйгә йөгердем.

— Чакканнар идеме, әби?!

— Чакмыйча соң. Кулын да, битен дә чакканнар ие. Өйдә этиең жылый, тәрәзә каршында Акбай шыңшый.
— Аны да чакканнармы?
— Юк, аны чакмаганнар ие. Әтиеңне жәлли шулай. Аннары Акбайны да керттем өйгә. И сырпалана этиеңә, и кулларын ялый. Юатмакчы була. Теле генә юк инде менә.
— Багира да шундый, әби, әйе бит?!
— Ул да акыллы шул. Тик яшьрәк әле Бәһирәң, улым, дөньяны белеп бетерми. Шуңа күрә үзенә дә эләгеп кенә тора. Я чагалар аны, я чукыйлар. Ә Акбай карт ие инде ул чакта. Беркөнне шулай, печәнне бетереп, болыннан кайтып кердек. Бабаң Кашканы тугарды да, коендырам дип, Ашытка алып китте. Колхоз двурына илткәнче, бабаң шулай гел коендыра ие аны. Бик тирән ие әле ул чакта Ашыт суы. Ә этиең ишегалдында Акбай белән калды. Үзем өйгә кереп аш әзерли башладым. Бераздан ишегалдына чыксам, Акбай да, этиең дә юк. Анда сугылдым, монда сугылдым, юк болар. Алай да бик курыкмаган нем әле, бабаң артыннан Ашытка киткәннәрдер дип уйладым. Безнең бакча башында гына ич ул. Аннары күрәм, Кашканы житәкләп, өй түреннән бабаң узып бара, атны колхоз двурына илтеше.
— Акбай белән малай кайда, ник калдырдың үзләрен генә? — дим.
— Кайда калдырыйм мин аларны? — ди бабаң.
Юк икән шул, бабаң янына бармаганнар. Эзләмәгән жирем калмады. Ашыт буеннан да әйләндем. Аннары бабаң кайтып керде. Ул да шулай, лапасны, мунчаны, баз өсләрен әйләнеп чыкты. Күрше-тирәне калдырмадык. Юк булгач, юк инде. Житмәсә караңгы төшеп килә. Баскыч төбенә утырдым да жылыйм мин. Ә бабаң каядыр китте, һаман эзли әле. Аннары кайтты да әйтә бу:
— Я, жылама, баягынак әнә зират янында күргәннәр, — ди.
Зират бездән биш-алты йорт аша гына, авыл башында ук. Йөгердек шунда. Зиратның үзен дә, тирәсен дә әйләнеп чыктык. Күренмиләр.
— Болай булгач, урманга кергән инде болар,— ди бабаң.
Урманы да шунда гына бит аның, зиратка тоташам дип кенә тора. Төнгә каршы нишләр ул бала, дип, үлдем дә киттем.
— Я, я, Акбай белән бергә ич,— дип бабаң мине юатмакчы була. Күрәм инде, үзенең дә коты алынган. Калын урман ла ул, очы-кырые юк. Акбайның яшь чагы булса, әле бер хәер ие, ә хәзер аңа ышанып булмый, үзе дә чак-чак кына йөри. Нишлисең, киттек урманга. Йөрдек-йөрдек тә, аптырап, буш кул белән тагын .авылга кайттык. Аннары, күрше-тирәне жыеп, этиеңне, Акбайны дәшә-дәшә, төне буе эзләдек. Тәки табылмыйлар. Акылдан шашам дип торам. Бер усакны кочакладым да жылыйм да жылыйм... Аннан таң атты, кояш чыкты, кошлар уяндылар. Урман яктырып, жанланып китте. Ә халык тып-тын, сүрәннәр, инде дәшмичә, кычкырмыйча гына эзлиләр.
— Аюлар да, бүреләр дә бармы ул урманда, әби?
— Бар ие әле ул чакта, улым, күргәлиләр ие.
— Шуннан, әби... Таптыгызмы?
— Менә тыңлап бетер әле син. Шулай, усакны кочаклаган килеш, торам да торам. Инде яшь тә чыкмый, эчтән генә жылыйм. Берзаманны минем исемне әйтеп, кемдер кычкыра башлады. Каян хәл кергәндер, «Мин монда!» — дидем дә, агачларга бәрелә-сугыла, тавыш килгән якка йөгердем. Озак та үтми, куакларны чаж-чыж китереп аралый-аралый, каршыма күрше егете килеп чыкты. Йөзе балкыган жанашымның, «Таптым, чибәр жиңги, таптым, Әхтәмең йоклый!» — ди.
Китте шуннан соң урманда тавыш, «Табылдылар!», «Исәннәр!» дип ду килә халык. И куандым, и шатландым, нишләргә дә белмим. Аннары борчыла башладым, «Куркып уянмасын, өянәкле булып кал-

масын!» — дип эчем «жу» итеп китте. Хәзер мин дә кычкырам:

— Шауламагыз, баланы уятасыз бит! — дим. Ә үземнең әле этиеңне күргәнем юк. Сырып алдылар да мине:

— Төне буе кычкырдык ич, бөтен авыл белән, уянмадылар,— дип көлешәләр.

Юан гына нарат төбенә менеп, бөгәрләнеп яткан да, ике кулын яңак астына салган килеш, изрәп йоклый ие этиең. Төп янында Акбай да ята. Мине күрү белән торып утырды мескенем. Аннары, арт аякларына басып, әкрен генә шыңшый-шыңшый, ал тәпиләрен төп өстенә куйды. «Менә ул монда...» — диюедер инде бичараның. Күземә яшьләр килде.

— Сез кычкыргач, Акбай ник өрмәгән соң, әби?

— Анысын каян беләсең инде аның. Я этиең уянмасын дигәндер, я инде хәле булмагандыр. Шул көнне үк үлде ич Акбай. Кешеләр дә әйткән ие аны, үләргә дип киткән ул урманга, дигәннәр ие.

— Үләсен белгәнмени?

— Белә дип әйтәләр ич этләрне. Мәчеләр дә, тагын ниндидер киекләр дә шулай икән.

— Алайса ник өйдә генә үлмәгән?

— Күрсәтәсе килмәгәндер. Күңелле хәл мени үлем?

— Аннан уяттыңмы соң этине?

— Юк, улым, шул килеш күтәреп кайттым. Өйгә кайткач, үзе уянды. Уянды да, күзен ачар-ачмас, «Акбай, Акбай» — дип, кулы белән як-ягын капшалый. Урманда да шулай иткәндер, мескенем, Акбай кулын ялагач, тынычланып тагын йоклап киткәндер. Сөя-сөя, үбә-үбә генә торгыздым аннары. Торгач та һаман як-ягына карана, Акбайны эзли. «Хәзер керә ул, улым»,— дим. Үзем шулай дим, ә үзем Акбайның кайда икәнен дә белмим. «Хәзер, улым, хәзер»,— дип, ишегалдына чыктым да бабаңнан сорыйм:

— Акбай кайттымы соң ул? — дим.

Бабаң да аптырап китте:

— Ник, кайтмады микәнни ул безгә иярепʔ! — дип ишегалдын караштырды да урманга йөгерде. Күтәреп кайтты аннары Акбайны, шул ук нарат төбенә ятып үлгән мескенкәем. Бик кадерләп мунча каршысына күмде бабаң. Инде дә юксынды этиең, әллә ни гомергә хәтле йокы аралаш һаман «Акбай» дип саташты. Шуннан соң бабаң:

— Әйдә, улым, Акбайга агач утыртыйк,— дип, көрәк тотып, этиеңне урманга алып китте. Шуннан бер яшь имән төпләп кайттылар. Безнең мунча янындагы имән этиең белән бабаң утырткан шул имән инде ул. Бәләкәй чиләккә су салып бирә ием дә, этиең көн саен су сипкән була ие. Үзе үсә төшкәч, инде чын-чынлап карый башлады. Хәзер әнә нинди зур, мунча бөтенләй имән астында калды. Әтиеңнең бер дә сөйләгәне юк мени соң?

— Синең шикелле сөйләми лә ул. Бабаң белән бергә утырткан идек, дип кенә әйтте.

— Кара син аны, агач авыз булмаса соң. Ник сөйләмәскә ди. Оныткан микәнни? Туган нигезләренә күбрәк кайтсалар, исләренә төшәр ие. Әллә нәрсәләре дә...

# БУ УКЛАР КЕМГӘ ТИЯР?

*Гамил Афзал*

* * *

Хур кызларың йөрер уңда-сулда,
План да юк анда, стимул да,—
Мин оҗмахка кермәс идем, раббем...
Мин Әлмәттә җайлы «бизнес» таптым!

* * *

Баш булырга план корасың син,
Көчсезләрне чукып.
Иң алдынгы сафта торасың син
Олы кашык тотып.

* * *

Башлыклар һәм массалардан качып,
Баш тезәткәч Сәйфетдинов Апуш,
Саф йөрәген курсәткән иде ачып —
Таланган сейф кебек буп-буш.
Менә син аны
Халыкка хезмәт итәргә куш!

* * *

Кешеләрдән, сүздән, эштән туеп,
Өстәленә кәгазь, каләм куеп,
Эшлекле кыяфәт чыгарып чырайга,
Кабинет саклый ул... шөкер ходайга.

* * *

Пафос белән кызыл сүзләр чөя:
«Ура кычкыр!
Трибунада кайнар нотык талкы!»
Ә эшендә, сәгать үтсен диеп,
Селкенәсең илке-салкы.

### БЕР ШАГЫЙРӘГӘ

* * *

Пегасың юк синең, кәҗәң генә,
Ул да карак, мәлгунь,
«Ялгыш» кереп күрше түтәлендә
Йөрүләре мәгълүм.

* * *

Бакыр акча кебек вак «дөреслек»,
Газетадан откан дежур фикер,
Ә тормышта мәнсезлек тә этлек...
Аллага шөкер.

* * *

«Мин әйбәт, мин әйбәт, мин әйбәт!» дип
Көн саен ант итеп торганчы,
Аркылы ятканны торкылы борсаңчы,
Үскәнем, берәр эш кырсаңчы.

* * *

Көлә-көлә күз уйната, сүз уйната,
Яңагында алсу уймак бата-калка,
Йөзендә нур, күзендә нур, телендә бал...
Йөрәгендә йомарланып елан ята.

* * *

Ярый әле, Адәм белән Һава
Курыкмаган «нельзя» дигән сүздән,
Югыйсә мин кайдан килер идем,—
Дип сорыйсы килә сездән.

*Зәки Нури*

**ҮЛЧӘВЕ ЮК**

Ул үлчәүгә басты. Әмма үлчәү
Берни әйтми — йөзме, иллеме?..
Үлчәү — гадел! Үлчәнүче затның
Буш җан икәнлеге билгеле.

**СӘНГАТЬ ҺӘМ ТОРМЫШ**

Кухня краныннан
Аккан суга карап
Рәсем ясый берәү:
Диңгез... Йөзә кораб...

**ЗАМАНЧА МЕЩАН**

Берәр бәла кичергәндә башың,
Ярдәм көтмә аны чакырып:
Читләтеп ул сине җәяү узмас,
«Жигули»да үтәр чаптырып.

**ТӘНКЫЙТЬЛӘРГӘ КИРӘК**

— Тәнкыйтьләргә кирәк директорны
Каты итеп — түзсен, чыдасын.
Эшлә шуны, Мәрьям апа! — Син бит
Пенсиягә инде чыгасың.

**ЗУР БАКЧА**

— Бакчаң бик зур, әби. Эше күптер?
— Үстерергә көчем җитә лә!..
Ә уңышын... Казаннардан килеп
Ул-кызларым җыеп китәләр.

**КЫЕН ОЧРАК**

Музыкага ничек ябыштың син,
Бу теләккә кем соң «хуп!» диде?
— Әтиемнең чөнки бүтән вузда
Таныш-белешләре юк иде.

**БҮТӘН БЕРНИ ӘЙТӘЛМӘДЕ**

— Шул хәлеңдә рульгә утыргансың,
И тилекәй, син бит — лаякыл?!.
— Утырдым шул... басып торалмагач...
Син «лаякыл» дисең, сай акыл!

**КЫЗНЫҢ ҮЗ КЫРЫГЫ КЫРЫК**

— Укудан соң өч ел эшсез ят ди...
Намус кирәк! Берәр йөккә җигел!..
— Нинди намус! Ни сөйлисең, әни?
Мин бит инде сабый бала түгел.

**ЭШТӘ ҺӘМ ӨЙДӘ**

Телескоп белән ул айкый киң
галәмне,
Ачышлар ясый да исбатлы сүз әйтә.
Ә өйдә... тик ачкыч сыешлы ярыктан
Күршеләр җәнҗалын җентекләп күзәтә.

**ИКЕНЕҢ БЕРСЕ**

Бар — иргә чыгу. Бар — вузга керү.
Һич аермыйча актан карасын,
Бер ана әйтә җиткән кызына:
«Кая алсалар, шунда барасың!»

**БОЛЬНИЧНЫЙГА ЧЫККАЧ**

— Биш кенә көн ятам әле өйдә мин,
Инде менә... нәкъ ун шешә бушады.

Димәк, эштә якын дуслар аз түгел,
Минем чирләү аларга бик ошады.

**ЭШТӘН КИТӘРГӘ СОРАУ**

— Врачка барып суыртыйм әле!—
Борчуы яман азау тешемнең...
— Кырык тапкыр инде шулай китәсең,
Тик утыз була теше кешенең.

**КҮҢЕЛСЕЗ ХӘБӘР**

— Җырләгән, ди, шагыйрь яшь-яшь
Пегасын,
Калмаган, ди, җанга якын бер кеме,—
Талчыктырган аны эшсез яшәве,
Тончыктырган аны «Казбек» төтене...

**АЛАЙ ДА БУЛСЫН, БОЛАЙ ДА**

— Бу толымны кисү җәл түгелме?—
Парикмахер сорый Гөлсемнән.
— Үзен кисмә! Ләкин шулай эшлә:
«Вот ичмасам парик!» дисеннәр.

**УРАМНАР ҺАМАН ПЫЧРАК**

— Кирза итек кирәк иде миңа!—
Дип ялвара бер кыз кибеттә.
— Ә нигә ул?
— Танцыларга чакыра,
Гашыйк булдым мин бер егеткә.

**АШХАНӘДӘ**

«Пилмәнегез нигә болай салкын?»
Сорый кемдер — читтән килгәне.
— Сез менюны күрмәдегезмени:
Чөнки бит ул Себер пилмәне.

*1978—1979*

## Укучының күңел дәфтәренә

**Осетин мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Кыюлыгың көчтән күбрәк булсын.*

*Әгәр азыңны кызгансаң, күбең дә кирәк түгел.*

*Арба артыннан чапкан эт чанага да иярә.*

*Биясенә карап таен сайла.*

*Карынның язы көз көне була.*

*Җирне кояш яктырта, кешене — аң-белем.*

*Кеп-кечкенә балтадан зур-зур агачлар ава.*

*Диңгезләр дә тамчыдан туа.*

*Тапталган сукмак — юлдан да киңрәк.*

*Курыккан күзгә тычкан да — тау.*

*Иске үзәндә су эзләп таш та табалмаганнар.*

*Агач ялгыз, таш ялгыз — икесе дә бәхетсез.*

*Агуы беткән елан үзен-үзе үтерә.*

*Кәкре пычакка кәкре кын кирәк.*

*Үз илеңдә яшәмәсәң — тормыш тәмен белмәссең.*

*Үзен яратмаган кеше бүтәнне сөя алмый.*

Гәрәй Рәхим

# ПЛАННАРНЫ ПЛАНЛАШТЫРДЫК

ЮМОРЕСКА

Юк, уңмады безнең комбинат директорлардан. Мин белгән дүрт-биш ел эчендә генә дә биш-алты директор алышынды, әмма бер генә елны да, бер генә күрсәткеч буенча да план үти алганыбыз юк. Отчет саен план үтәлеше 75—80 процент, һәм бет-те-китте. План үтәлмәгән саен директор алышына, директор алышынган саен план үтәлми.

Быелгы директорыбыз эшне бик крута башлады бит әле. Элеккеге директорлар сыман комбинатның эчке резервлары дип тә, тышкы резервлары дип тә чиләнмәде, механизация, реконструкция, фәлән-фәсмәтән дип тә теңкәгә тимәде, килә-килешкә үгезне мөгезеннән алды — даешь план!

— Да-а-а! Монда планнарны өр-яңадан планлаштырасы бар икән әле,— диде ул, комбинатның эш кәгазьләре, план-йөкләмәләре белән танышкач. Аннары бүлек мөдирләрен җыеп алды да, конкрет күрсәтмәләр бирде:

— Өч көн срокта һәр бүлекнең өр-яңа планын булдырырга кирәк. Планнарны яңадан карап чыгу безнең киләчәк планнарыбызны планлаштырырга ярдәм итәчәк. Шуңа күрә өч көн эчендә миңа түбәндәге эш планнарын төзеп китерерсез дип планнар исемлеген бирде.

Һ-и-и, план төземәгән кешеме соң без, кәгазь түзә ул, яздың-бирдең, дип киңәшмәдән тыныч кына таралыштык. Өйгә кайтып планнар төзергә утыргач аптырап калдым — шактый четерекле эш куш-кан бит безгә бу яңа директор. Чутлап карасам шаклар каттым — еллык, ярты еллык, квартал, айлык планнар үзләре генә дә унтугыз килеп чыкты. Шуның өстенә утыз алты декада һәм җитмеш ике бишкөнлек планы. Барысы буладыр 127 план! Инде дә килеп шуңа ел тәүлегендәге 305 эш көнен дә китереп кушсаң, ул була 432 данә! Әле бит бу календарь планнар гына. Безнең комбинат үзе кечкенә булса да, андагы производство 25 ләп операциядән тора һәм шуңа тагын көнкүреш-культура планнары килеп кушыла... Фу, шайтан алгырысы, барлыгы ничә план кирәк икәнен дә чутлап чыгарып булмый. Бу кадәр планны язып бетерергә кәгазең дә, сүзләрең дә, саннарың да җитмәле генә түгел икән...

Яңа директор алдында һич кенә дә сынатасы килми иде дә бит, нишлисең, өч көнгә 500 дән артык план төзеп бетерү һич мөмкин булмаган эш булып чыкты. Ничарадан бичара дигәндәй, өч көн буе төзегән 30 планымны тотып киңәшмәгә килдем. Ярый әле директор белән коллектив алдында бер үземә генә кызарырга, бер үземә генә

серәеп басып торырга туры килмәде — мөдирләрнең бөрсе дә планнарны тулысынча төзеп килә алмаган иде. Өч көн, өч төн буенча йокламыйча план төзи-төзи күзләре кызарып, кабаклары җилсенеп беткән, ләкин барыбер 20—30 дан уздыра алмаганнар.

— Да, комбинат планнарын планлаштыру планнарымны үти алмадыгыз, — диде директор ачынып. — Соң сез планнарны төзи дә алмагач, ул планнарны ничек тормышка ашырырга уйлыйсыз?

Шуннан соң директор тавышын күтәрмичә генә планнар төзүнең комбинат өчен никадәр әһәмиятле булуын, аларны тизрәк төзергә кирәклеген әйтеп үтте һәм бүлек мөдирләре арасында планнар төзү буенча удар бишкөнлек игълан итәргә тәкъдим кертте. Без тәкъдимне хуплап каршы алдык, бүлекләрнең бөтен көчен планнар төзүгә җиктек. Чыннан да, комбинаттагы барлык хезмәт резервларын файдалану аркасында без биш көн эчендә директорга бөтен планнарны төзеп бирдек.

Ә квартал азагында безнең комбинатта шатлыклы вакыйга булып алды. Ниһаять, соңгы алты ел эчендә безнең комбинат бер күрсәткеч буенча гына булса да планны арттырып үтәүгә ирешге — безнең еллык планнар төзү планыбыз 150 процентка җиткән иде. Бу уңай белән яңа директор бөтен коллективны клубка җыеп котлады. Шул җыелышта без производство планының бу кварталдагы үтәлеше 64 процент икәнен дә белдек.

# ИНТЕРВЬЮ

### КАЙБЕР ИНТЕРВЬЮЛАРГА ПАРОДИЯ

Күптән түгел безнең махсус хәбәрчебез республикабызның билгеле колхозында булып, аның председателеннән интервью алды. Хөрмәтле укучыларыбызга шуны тәкъдим итәбез.

Хәбәрче. Иптәш председатель! Сез җитәкләгән колхоз ирешкән уңышлар белән бөтен республикабыз горурлана. Сез игенчелектә мул икмәк, терлекчелектә мул продукция аласыз. Газета укучыларның күбесе инде сез үстергән икмәктән, сез җитештергән ит, сөт һәм майдан авыз да иткәннәрдер. Ләкин алар әле сезнең зур уңышларга ничек ирешүегез, сезнең уңышларның серен аңлап бетермиләр. Шул турыда берничә сүз әйтә алмассызмы?

Председатель. Безнең уңышлар ул...

Хәбәрче. Әйе, әйе, сезнең колхоз ирешкән уңышлар ул бер сезнең, ягъни колхоз председателенең генә уңышы түгел. Сезнең нәрсә әйтергә теләгәнегез аңлашыла, сез, тәҗрибәле җитәкче буларак, көчле техникага, химиягә, авыл хуҗалыгы фәне ирешкән өр-яңа ысулларга, барыннан да бигрәк тере кешеләргә таянуыгыз турында әйтергә телисез. Бу урында халыкның бик кызыклы бер мәкален искә төшереп үтәсе килә: «Бердәмлектә — көч!» — ди бит безнең халык. Әйткәнемчә, сез, тәҗрибәле җитәкче буларак, колхоз производствосын алга җибәрүдә әнә шул принципка таянып эш итәсез. Һәм минемчә, колхоз ирешкән уңышларның төп сере дә әнә шунда дип әйтергә телисез. Шулаймы?

Председатель. Ләкин...

**Хәбәрче.** Аңлашыла! Сез: «Ләкин әле тере кешеләргә, колхозчыларга коры таяну гына җитми»,— дип әйтергә телисез. Дөрес, кешеләр синең ышанычлы таянычың булсын өчен башта аларда хезмәткә, колхоз милкенә, җиргә мәхәббәт тәрбияләргә кирәк. Иптәш председатель, берничә сүз белән генә колхозчыларны тәрбияләүдәге бай тәҗрибәгез турында әйтеп китмәссезме икән?

**Председатель.** Безнең колхозчылар...

**Хәбәрче.** Дөрес, иптәш председатель, сезнең колхозчылар һәрвакыт үз белемнәрен күтәрү өстендә эшлиләр. Һәр колхозчы семьясы уртача өч ярым газета-журнал алдыра, һәр семьяда уртача 0,99 телевизор һәм, транзисторларын да кертеп исәпләгәндә, 1,2 радио ноктасы бар. Елына бер колхозчы башына ун ярым лекция һәм район киночелтәре аша 360 кинофильм төшә. Телевидение аша күрсәтелгән фильмнарны да кушып исәпләсәң, бу сан тагын да артыр иде. Гомумән, иптәш председатель, сезнең уегызча, колхоз производствосы ул колхозчыларны тәрбияләү буенча иң эффектив мәктәп булып тора. Югарыда әйтелгән тәрбия чараларын үткәрү нәтиҗәсендә колхозда ялкаулык, урлашу, хулиганлык, эчкечелек дигән яман чирләрнең проценты кимегәннән-кими бара. Сезнең колхоз тормышындагы бу уңай башлангычны республикабыздагы башка колхозларга да тәкъдим итәсе килә.

Инде, иптәш председатель, интервьюның соңында сезгә тагын бер сорау — газета укучыларга киләчәккә булган планнарыгыз турында сөйләсәгез иде.

**Председатель.** Ыһым...

**Хәбәрче.** Тамак кыруыгыздан ук күренеп тора, иптәш председатель, сезнең киләчәккә планнарыгыз гаять зур. Ул — автоматлаштырылган фермалар, мәңге яшел печән биреп торучы көтүлекләр, асфальт җәелгән авыл урамнары, берничә мең кешегә хезмәт күрсәтерлек универмаг, культура йорты һәм, иң әһәмиятлесе, тере кешеләр, колхозчылар. Планнарыгыз сокланырлык, иптәш председатель, бу планнарны тормышка ашыруда сезгә зур уңышлар телибез. Тирән фикерле, файдалы һәм кызыклы интервьюгыз өчен сезгә бөтен газета укучылар исеменнән зур рәхмәт.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## КАРАКАЛПАК АССРда ТАТАРСТАН АССРның ӘДӘБИЯТЫ ҺӘМ СӘНГАТЕ КӨННӘРЕ

Шушы елның 19—26 август көннәрендә Каракалпакстанда Татарстан әдәбияты һәм сәнгате көннәре булып узды. Сәнгать бәйрәмендә КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев (җитәкче), ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов, ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Г. А. Ахунов, КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин, ТАССР Художниклар союзы идарәсе председателе Ә. И. Тумашев, ТАССР Культура министры урынбасары Р. М. Харисов, СССР халык художнигы Х. А. Якупов, ТАССР Композиторлар союзы идарәсе председателе М. З. Яруллин, КПССның Казан шәһәр комитеты секретаре А. Г. Кадыйрова, КПСС өлкә комитеты инструкторы Ә. Ә. Хәсәнов иптәшләр катнашты.

Делегация составында язучылардан Сибгат Хәким, Туфан Миңнуллин, Нил Юзиев, Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Рафаэль Мостафин, Мөхәммәт Мәһдиев, Мөсәгыйть Хәбибуллин, Кояш Тимбикова, Рәдиф Гатауллин, Разил Вәлиев, Роберт Миңнуллин, композиторлардан Бату Мулюков, Ринат Еникеев, Рафаэль Билялов, Рәшит Абдуллин, художниклардан Василь Маликов, Абрек Абзгильдин, Виктор Аршинов, Татарстан китап нәшрияты директоры Гарәф Шәрәфетдинов, Казан кинохроника студиясенең баш редакторы Роберт Копосов, СССРның халык артисты Габдулла Шамуков, бер төркем журналистлар, кино һәм телевидение работниклары, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры солистлары, Г. Тукай исемендәге дәүләт филармония артистлары бар иде.

Ике халыкның рухи туганлыгына ишарә булып, Аму-Дарья буйларында бер атна буе Идел моңнары, татар җырлары яңгырады. Ул көннәрдә Каракалпакстанда «дуслык» сүзе бигрәк тә еш ишетелде. Үзбәкстан Компартиясенең Каракалпакстан өлкә комитеты һәм республика Министрлар Советы карары белән Нукус шәһәренең яңа бер мәктәбенә Габдулла Тукай исемен бирү, Кегейли районының «Куаныш Жарма» совхозын Муса Җәлил исемендәге совхоз итеп үзгәртү, Чимбай педагогия училищесына каракалпак совет әдәбиятына нигез салучыларның берсе, мәгърифәтче Сәйфелгабит Мәҗитов исемен бирү ике халык дуслыгы хөрмәтенә куелган һәйкәл кебек кабул ителде.

Татарстаннан килгән дуслык һәм туганлык җырлары республиканың мамык һәм дөге игүчеләре, бакчачылары һәм балыкчыларына да барып иреште. «Юность» халык бию ансамбле, Ринат Ибраһимов катнашлыгындагы «Орфей» вокаль-инструменталь ансамбле, Илһам Шакиров, Римма Ибраһимова, Зиннур Нурмөхәммәтов, Вафирә Гыйззәтуллина катнашлыгындагы эстрада бригадалары Каракалпакстанның төрле районнарында концертлар бирделәр.

Нукус шәһәренең Матбугат йорты каршында татар һәм каракалпак язучылары китаплары күргәзмәсе һәм аларны сату оештырылды. Анда нәкъ шушы көннәрдә каракалпак телендә басылып чыккан «Татар шагыйрьләре» исемле китап та бар иде.

Нукуста берьюлы тагын өч күргәзмә эшләде: Бердах исемендәге кино-концерт залында Татарстан рәссамнарының, республика Дәүләт музеенда Татарстанда булып киткән каракалпак художниклары иҗат иткән әсәрләр күргәзмәсе һәм крайны өйрәнү музеенда «Совет Татарстаны» дигән фотокүргәзмәләр тамашачыларда зур кызыксыну уятты.

Тамашачылар шулай ук кинотеатрларда «Моабит дәфтәре», «Хәзинә», «Хисләрнең яңаруы» исемле нәфис һәм Казан кинохроника студиясендә эшләгән документаль фильмнар карадылар. Татарстаннан килгән иҗат коллективлары, язучылар, артистлар телевидение һәм радиодан чыгыш ясадылар.

Әдәбият һәм сәнгать көннәре 25 август көнне тантаналы җыелыш белән тәгәлләнде. Җыелышта Үзбәкстан Компартиясе Үзәк комитеты бюросы члены, партиянең Каракалпакстан өлкә комитеты беренче секретаре, Социалистик Хезмәт Герое К. К. Камалов, Каракалпакстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе К. Р. Рзаев, Каракалпакстан АССР Министрлар Советы Председателе Е. А. Айтмуратов, партиянең Каракалпакстан өлкә комитеты секретаре К. Е. Юсупов, Татарстан делегациясе җитәкчеләре катнашты. Җыелышта катнашучылар бертавыштан Коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты Генеральный секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе иптәш Л. И. Брежнев исеменә тәбрикләү хаты кабул иттеләр.

## ХЕЗМӘТНЕ ҺӘМ ОСТАЛЫКНЫ ОЛЫЛАП

Каракалпакстанда Татарстанның социалистик культурасын пропагандалауда,

СССР халыкларының дуслыгын һәм туганлыгын тагын да ныгытуда зур роль уйнаган Татарстан АССР әдәбияты һәм сәнгате көннәрен уңышлы үткәргәннәре өчен Каракалпакстан АССР Верховный Советы Президиумы, үзенең 1980 ел, 25 август Указы белән, түбәндәге иҗат союзлары һәм сәнгать коллективлары Каракалпакстан АССР Верховный Советы Президиумының Почет грамоталары белән бүләкләнде: Татарстан АССР Культура министрлыгы, Татарстан АССРның Язучылар, Композиторлар, Художниклар, Журналистлар союзлары, Татарстан АССРның Телевидение һәм радиотапшырулар Дәүләт комитеты, Татарстан китап нәшрияты, Казан кинохроника студиясе, Г. Тукай исемендәге Татарстан Дәүләт филармониясенең симфоник оркестры, ТАССРның дәүләт җыр һәм бию ансамбле, ТАССРның Г. Тукай исемендәге дәүләт филармониясенең, «Орфей» вокаль-инструменталь ансамбле, «Яшьлек» халык бию ансамбле.

Совет сәнгатен пропагандалаудагы зур хезмәтләре, югары башкару осталыклары өчен һәм Каракалпакстанда Татарстан АССР әдәбияты һәм сәнгате көннәре үткәрү уңаеннан, Каракалпакстан АССР Верховный Советы Президиумының шундый ук Указлары белән М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры солистлары Юрий Борисенкога, Ринат Ибраһимовка, Зилә Сөнгатуллинага, Эльвира Хәбибуллинага, филармония солистлары Илһам Шакировка, Вафирә Гыйззәтуллинага Каракалпакстан АССРның халык артисты; композитор Мирсәет Яруллинга Каракалпакстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе; Татарстан АССР Культура министры урынбасары Ренат Харисовка Каракалпакстанның атказанган культура работнигы дигән мактаулы исемнәр бирелде.

## ИҢ ЯХШЫ ОЧЕРК, ПУБЛИЦИСТИК МӘКАЛӘГӘ РЕСПУБЛИКА КОНКУРСЫ

Социалистик ярышны, промышленность һәм авыл хуҗалыгы производствосы алдынгыларының, унынчы бишьеллык ударникларының казанышларының, коммунистларның производствода һәм культура төзелешендәге авангардлык ролен яктырту өлкәсендә журналистлар, язучылар, эшче-крестьян хәбәрчеләренең иҗат эшчәнлеген активлаштыру максаты белән Журналистлар һәм Язучылар союзлары, Татарстан АССРның Нәшриятлар, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт комитеты **«Бүгенге көн геройлары»** дигән девиз астында КПССның XXVI съезды хөрмәтенә иң яхшы очеркка, публицистик мәкаләгә иҗат конкурсы игълан иттеләр.

Конкурска җибәрелгән очерк һәм публицистик мәкаләләр совет кешесенең коммунистик идеалларын, партиянең XXV съезды һәм КПСС Үзәк Комитеты Пленумнары карарларын тормышка ашыру хакына алып барылган иҗади хезмәтен чагылдырырга, идея-художество дәрәҗәсе, профессиональ осталыгы белән аерылып торырга, зур иҗтимагый политик әһәмияткә ия булырга тиешләр.

Премияләр 1980 елның 1 августыннан 1981 елның 15 февраленә кадәр арада республика газеталары һәм журналларында, шәһәр һәм район матбугатында басылып чыккан хезмәтләргә бирелә. Республика матбугатына җибәрелә торган материал күләме машинкада 6—9 биттән артмаска тиеш. (200 әр сум күләмендә ике премия, район һәм шәһәр газеталары журналистлары, эшче-крестьян хәбәрчеләре өчен өч премия. Моннан тыш республика газеталары һәм журналлары редакцияләре дә премияләр билгелиләр).

## ЗУР ӘДИП ЮБИЛЕЕ КӨННӘРЕНДӘ

Татар һәм башкорт әдәбиятлары классигы Мәҗит Гафуриның тууына 100 ел тулуга багышланган тантаналы кичә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында уздырылды. Анда әдипнең тормыш һәм иҗат юлы турында доклад белән ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов чыкты. РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре Н. Доризо, Башкортстан Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары Р. Сафин, башкорт шагыйре һәм драматургы Ә. Атнабаев чыгыш ясады. Тантаналы кичәдә КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев һәм КПССның Казан шәһәр комитеты беренче секретаре М. К. Рәмиев иптәшләр катнашты. Соңыннан Татар дәүләт драма һәм комедия театры М. Гафуриның «Кара йөзләр» әсәре буенча куелган спектакль күрсәтте.

*
* *

Башкортстанның Гафури районы үзәге Красноусолда истәлекле вакыйга булды. Поселокның үзәк урамында, Матросов исемендәге кинотеатр алдында Башкортстанның халык шагыйре Мәҗит Гафурига куелган бюст ачылды. Аның авторы — күренекле скульптор, Ленин һәм СССР Дәүләт премияләре, БАССРның Салават Юлаев исемендәге премиясе лауреаты, академик Л. Е. Кербель.

*
* *

Казан шәһәренең Габдулла Тукай урамындагы 34 нче йортка Мәҗит Гафури истәлегенә мемориаль такта куелды. Анда: «Бу йортта 1905—1906 елларда язучы Мәҗит Гафури укыды» дип язылган.

Мемориаль такта кую тантанасына шәһәрнең партия, совет, иҗат һәм киң җәмәгатьчелек оешмалары вәкилләре, әдипнең иҗатын яратучылар килгәннәр иде.

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ АЧЫК ПАРТИЯ ҖЫЕЛЫШЫ

Тукай клубында Татарстан язучыларының чираттагы ачык партия җыелышы булып узды. Көн тәртибенә шагыйрь Роберт Миңнуллинның иҗат отчеты куелган иде. Р. Миңнуллинның иҗаты турындагы

докладларны шагыйрь Рәдиф Гатауллин һәм тәнкыйтьче Равил Кукушкин сөйләде. Фикер алышуларда шагыйрьләр Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, драматург Туфан Миңнуллин, тәнкыйтьчеләр Рафаэль Мостафин, Мансур Вәлиев, язучы Рәфкать Кәрами катнашты. Алар шагыйрьнең иҗат итүен, бигрәк тә балалар әдәбиятында житди эзләнүләрен, матбугатта еш чыгыш ясавын, һәм шагыйрь, һәм Казан шәһәренең Бауман район Советы депутаты буларак, җәмәгать эшләрендә актив катнашуын билгеләп үттеләр. Соңыннан Р. Миңнуллин каләмдәшләре алдында үзе чыгыш ясады, яңа әсәрләре белән таныштырды, иҗат планнары белән уртаклашты.

## «ЯШЬ ЛЕНИНЧЫ» ГАЗЕТАСЫ — ҖИҢҮЧЕ

Ленинниананы пропагандалауда илебезнең пионер матбугаты аерым бер урын тота. Моңа ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты һәм В. И. Ленин исемендәге Бөтенсоюз пионер оешмасының республика советы органы — «Яшь ленинчы» газетасы да зур өлеш кертте. Газетада «Алар Ильичка ант иттеләр» дигән рубрика белән бирелгән язмалар укучыларда аеруча кызыксыну уятты. Шулай ук «Ульяновлар Татарстан җирендә», «Ульяновлар гаиләсенең мораль кодексы», «Ильичның көрәштәшләре» исемле рубрикалар белән бирелгән материаллар да укучылар күңеленә хуш килде.

«Иптәш Ленин, мин Сезгә рапорт бирәм» дигән девиз белән комсомол һәм пионер газеталарына В. И. Ленинның тууына 110 ел тулуга багышланган Бөтенсоюз конкурсында катнашып, «Яшь ленинчы» газетасы җиңүче исемен алды, «Комсомол даны елъязмасы» китабына кертелде, ВЛКСМ Үзәк Комитетының I дәрәҗә Дипломы һәм акчалата премия, Ленин булган урыннарга бару өчен путевка белән бүләкләнде.

## ПОЭЗИЯБЕЗНЕҢ ИҢ ЯХШЫ ҮРНӘКЛӘРЕ

«Советская литература» журналының 6 нчы саны кушымтасы китап булып басылып чыкты. Ул күп телләргә тәрҗемә ителә һәм дөньядагы йөзләп илдә тарала. Әлеге чыгарылыш «Совет поэзиясе антологиясе. 1960—1980 еллар» дип исемләнгән. Китапка күпмилләтле поэзиябезнең иң яхшы үрнәкләре тупланган. Китапка татар шагыйре Зәки Нуриның да ике шигыре кертелгән.

*
* *

Ленинградтагы ике тапкыр Кызыл Байраклы хәрби физик культура институтының 60 еллыгына багышланган хәрби-тарихи конференция материалларын туплаган җыентык чыкты. Җыентыкта шушы институтта озак еллар укыткан якташыбыз запастагы полковник, педагогия фәннәре кандидаты Ә. С. Булатовның да «Данлы алтмыш ел», «Институтның башлангычы» һәм «В. И. Ленин исемендәге Кызыл Байраклы хәрби факультет Бөек Ватан сугышы елларында (1941—1945 еллар)» исемле мәкаләләре урнаштырылган. Алар институтның данлы тарихына багышланган.

*
* *

Шагыйрьләр Рәдиф Гатауллин белән Роберт Миңнуллин Башкортстанның Кушнаренко районында булып кайттылар. Алар Калинин һәм Горький исемендәге колхозларда уздырылган әдәби кичәләрдә яңа шигырьләрен укыдылар, «Казан утлары» журналының киләсе елда басылып чыгачак әсәрләре турында сөйләделәр. Горький исемендәге колхозда уздырылган шигырь кичәсендә яшь шагыйрьләр Нәҗибә Әминева һәм Рәшит Гатауллин да катнашты.

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ЧАЛЛЫ ОЕШМАСЫНДА

КамАЗ яшьләре өчен оештырылган «Ника» театраль студия залында яшь шагыйрьләр Николай Алешков, Георгий Сушко һәм Инна Лимонованың иҗат отчеты булды. Яшь шагыйрьләр үзләренең иң яхшы әсәрләрен укыдылар, сорауларга җаваплар бирделәр.

*
* *

«Орфей» берләшмәсе членнары, яшь шагыйрьләр Евгений Кувайцев белән Николай Алешков ВЛКСМ Үзәк Комитеты һәм СССР Язучылар союзы идарәсе тарафыннан оештырылган семинарда катнаштылар. Свердловскида уздырылган бу семинарга илебезнең төрле почмакларыннан эшчеләр темасын яктыртучы яшь авторлар чакырылган иде. Аңа СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре Юрий Верченко җитәкчелек итте. Кырыклап яшь язучыны бергә туплаган әлеге кызыклы форум Чаллы шагыйрьләре өчен бик файдалы булды.

*
* *

Оешманың чираттагы утырышында «Язучыларның һәм яшь авторларның вакытлы матбугатта катнашуларын активлаштыру» мәсьәләсе тикшерелде. Оешманың җаваплы секретаре Эдуард Касыймов иң башта шушы темага доклад сөйләде. Фикер алышуларда катнашкан Г. Кашапов, М. Газизов, Р. Якупов, Р. Хисмәтуллин һ. б. иптәшләр әлеге проблеманың чыннан да җитди булуын искәртеп, урындагы һәм республика газета-журналларында кызыклы һәм актуаль темаларга очерклар, зарисовкалар, репортажларны даими рәвештә язып торуның кирәклеген басым ясап әйттеләр, киләчәктә үзләренең бу эшкә җиң сызганып керешәчәкләрен белдерделәр.


*
* *

Оешманың чираттагы утырышында Чаллы язучыларының яңа төзелгән проза җыентыгы тикшерелде. Җыентыкны төзүчеләр — Равил Вәлиев белән Эдуард Касыймов.

# Ил йөрәге

ИЛДУС ЯКУБОВ музыкасы

ЗӘКИ НУРИ шигыре




Балкы, Мәскәү, нурың ялтырасын,
Сине күмсен җырлар ташкыны.
Дус сөенсен, дошман калтырасын,
Ил йөрәге типсен ашкынып.

Башкалам дип, Шатлыгым дип минем,

Кем тормышта үз язмышын синең
Язмыш белән уртак итмәде!

Син гүзәл дә, мәңге яшь тә, шат та,
Син батыр да, безнең башкала,
Җиңүләргә кайда атласак та,
Юлларыбыз синнән башлана.

## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАР!

Тиздән Сезнең кулга журналның быелгы соңгы 12 нче саны да килеп керер. Ул әдәбиятыбызның күренекле аксакалы — шагыйрь Хәсән Туфанның шигырьләр бәйләме белән ачыла. Шигырьләр авторның зур бәйрәме — аңа 80 яшь тулу уңае белән бирелгәннәр. Татар шигыре үсешендә аерым бер баскыч булып торган бу иҗатка багышланган мәкаләләр дә бар. Шагыйрьне юбилей тантанасы белән котлау йөзеннән язучыларыбыз Гомәр Бәширов, Сибгат Хәким, Туфан Миңнуллин Туфан иҗаты турындагы фикерләре белән уртаклашалар. Ф. Низамова белән А. Яхинның «Кайсыгызның кулы җылы» исемле мәкаләсе Х. Туфан иҗатының бер тармагына анализ төсендә тәкъдим ителә. Ә шагыйрь Рөстәм Кутуй исә аксакалның юбилей тантанасына багышлап «Аккош күлендә» исемле шигырь язган.

Журналның бу санында Татарстанның тагын бер талант иясенең 80 еллык юбилее билгеләнә. Декабрь — күренекле композитор Салих Сәйдәшевнең да туган ае. Бу уңайдан редакциягә килгән кайбер язмалар журналның 11 санында ук бирелә башлады. 12 нче санда исә музыка белгечләре, композиторлар истәлекләре белән уртаклашалар. Арада шагыйрь М. Хөсәеннең дә язмасы урнаштырылган.

Әдәбиятыбыз һәм сәнгатебез тарихына караган шундый зур даталарны билгеләү белән берррәттән журнал, үз гадәтенчә, бу санында да язучыларның яңа әсәрләренә шактый урын бирә. Поэзия бүлегендә Чаллы шагыйрьләреннән К. Сибгатуллин, Х. Хөснуллин, Н. Мадъяров әсәрләре тупланган. Зиннур Мансуровның яңа шигырьләре тәкъдим ителгән. «Дуслар иҗаты» рубрикасы исә укучыны Коми АССР шагыйрьләренең иҗат үрнәкләре белән таныштыра.

Проза бүлеге бу санга бер бәйләм яңа хикәяләр биргән. Алар арасында хикәя остасы Фатих Хөсни кебек өлкән буын вәкиленең әсәре дә, Рафаил Төхфәтуллин, Мөсәгыйть Хәбибуллин шикелле урта буын язучыларының хикәяләре дә, яшьләр иҗатыннан үрнәкләр дә бар.

Журнал шактыйдан бирле КПССның XXVI съездын каршылау уңаеннан язмалар биреп килә. 12 нче санда бу рубрика М. Зарипов һәм Г. Гомәров язмаларын эченә алган.

Әдәби тәнкыйть бүлегендә алда телгә алынган юбилей материалларыннан тыш И. Ахунҗановның «Тәрҗемәче ачкан тәрәзәләр» исемле мәкаләсе дә бар.

Бу санда шулай ук «Нәниләр дөньясы», «СССР Язучылар союзының яңа членнары», «Елмаеп та, көлеп тә...» рубрикаларына караган материаллар, 1980 елда журналда басылган әсәрләр исемлеге, әдәбият һәм сәнгать яңалыклары да урнаштырылган. Аларның һәркайсы, хөрмәтле укучы, сезне кызыксындырыр дип ышанабыз.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210